Т 122735

*Ибраһим Нуруллин*

ПРОВЕРЕНО
2008 г.

# ФАТИХ ӘМИРХАН

## (1886–1926)

НАУЧНАЯ БИБЛИОТЕКА КГУ
0000541028

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1988

ББК 84(2Р-Тат)-4
Н63

НАУЧНАЯ ... ОТЕКА
им. Н. И. Л... ского
КА... О ГО... УНИВЕРСИТЕТА

**Нуруллин И. З.**

**Н63** Фатих Әмирхан: Атаклы кешеләр тормышы.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1988.— 279 бит.

Китапта татар әдәбияты классигы прозаик, драматург һәм публицист Фатих Әмирханның тормыш һәм иҗат юлы тасвир ителә. Әдип образы күп төрле тарихи вакыйгалар эчендә һәм тарихи шәхесләр чолганышында күрсәтелә.

**Н** $\frac{4803010200-069}{М132(03)-88}$ **155—88** **ББК 84(2Р-Тат)-4**

© Татарстан китап нәшрияты, 1988.



*1 бүлек*

## «НӘНИ МУЛЛА»

### 1

Архивта Әмирхановларның баштүбән әйләндерелгән куакны хәтерләтә торган шәҗәрәләре саклана. Кәүсәнең очындагы «Гәрәй мирза» дигән исемне күреп, әдипнең ерак бабасы морза, русчалатып әйтсәк, дворян булган лабаса дип уйлап куябыз да кәүсә буйлап төшә башлыйбыз. Ботактан ботакка, тармактан тармакка күчә-күчә, бик күп бабалары, шул исәптән, Әмирхан һәм Хөсәен аша узып, безне кызыксындырган тармакка җитәбез: Мөхәммәтфатих.

Хәзер инде буыннар арасын егерме биш-утыз ел итеп билгелик тә (мулла балалары — мәхдүмнәр бик иртә өйләнмәгәннәр), ата-бабаларының тереклек итү вакытларын исәпли-исәпли, яңадан өскә күтәрелик. Гәрәй морза Казан ханлыгы Мәскәү дәүләте составына кергән һәм крайны колонизацияләү кызып киткән чорда яшәгән икән...

Бу төбәкне Россиянең аерылмас бер состав өлешенә әверелдерү өчен экономикага һәм политик-административ төзелешкә кагылышлы катгый һәм кырыс чаралар үткәрелә башлый. Дини-милли аерманы бетерүгә дә хөкүмәт зур игътибар биргән. Басурман булып йөрмәсеннәр, янәсе, кеше аңларлык телдә сөйләшсеннәр.

Халыкның бүтән катлаулары белән беррәттән, татар морзалары да авыр сынау алдында калалар: җирләрегез һәм колларыгыз кулыгыздан китмәсен дисәгез, чукыныгыз! Табыла андыйлар, рус дворяннары санын татар фамилияләре хисабына арттыручылар. Ара-тирә диненнән ваз кичмәгәне хәлдә җирен, колларын саклап калучылар да очрый. Мондыйлар — яңа хөкүмәт кочагына ташланып, хезмәткә кергән, һәм, җиңүчеләр файдасына зур эшләр башкарып, ышаныч казанган морзалар. Дворянлыгын саклап та, мал-мөлкәтсез калганнары һәм «чабаталы морза» дип йөртелә башлаганнары да бар. Диненнән язарга теләмәгән морзаларның күпчелеге исә гап-гади крестьянга әйләнгән яисә сәүдәгә керешкән, яки инде руханилар династиясен башлап җибәргән.

Гәрәй, күрәсең, Иван патшага буйсынырга теләмәүче, ул үткәргән чараларга, шул исәптән христианлаштыруга каршы торучы морзаларның берсе булган. Аның улы Җәлмәт, төп оя туздырылгач, «бәхет эзләп» булса кирәк, Сембер ягыннан Чистай төбәгенә килеп чыгып, Чирүле Шонталы авылына тукталган. Үзе турында да, улы Әхмәт һәм Әхмәтнең улы Кадермәт турында да күп мәгълүмат калмаган.

Ниһаять, шәҗәрәдә мулла пәйда була: «Морад хәзрәт». Бу зат, Чирүле Шонталы авылында яшәп, шунда вафат булган, шунда күмелгән. Тереклегендә ул шөһрәт казанган булса кирәк, Р. Фәхретдиновның «Асар»ендә әйтелгәнчә, бае-фәкыйре, олысы-кечесе каберенә баралар икән. Бу мәгълүмат безгә Әмирханнар династиясенең Морад хәзрәттән генә башланмаганлыгы, аның атасы Кадермәтнең дә Шонталыда яшәп, имам булганлыгы турында фараз кылырга мөмкинлек бирә. Мулланың улларыннан берсен үз урынына әзерләве, эстафета таягын тоттырып китүе киң таралган нәрсә.

«Исмәгыйль бине Морад,— диелә «Асар»дә,— Талкыш авылында зирагать * илә иштигаль идәр иде». Әмирханнар ыруының төп ватаны булып танылган Талкыш авылына (хәзер Чистай районына керә), димәк, беренче башлап Морад улы Исмәгыйль килеп төпләнгән. Әмма монда бер сорау туа. Әмирханнарның муллалык династиясе Исмәгыйльдә өзелеп торганмы, әллә инде бу зат игенчелек белән муллалыкны бергә кушып алып барганмы? Соңгысы дөреслеккә якынрак тоела. Чөнки гади крестьянның авылдан-авылга күчүе сирәк була торган хәл. Талкыш халкы-

---

* Зирагать — иген игү.

ның Исмәгыйльне приговор җыеп муллалыкка чакырган булуы ихтимал. Улының «Сәфәр хәзрәт» дигән исем белән шөһрәт казануы һәм тарихта теркәлеп калуы да шул ихтималны куәтли.

Сәфәр мулла — икенче бер җәһәттән дә кызыклы шәхес. Малмыж өязенең Югары Сасна авылында укып, шунда ун ел буе муллалык иткәч, ул, Сасна байлары белән тыныша алмыйча, туган җире Талкышка кайтып имам булган (атасы урынына түгелме?). Үз дәрәҗәсен белү, горурлык һәм бунтарьлык, күрәсең, Гәрәй морза токымына хас сыйфатлар. Моның белән әле без еш очрашырбыз.

Аннары — Исмәгыйль улы Габделмәннән. Әллә ни исем чыгара алмаган булса кирәк, чыганаклар аны читләтеп узалар.

Тагын бер баскыч төшкәч, без Әмирхан муллага җитәбез. Аның турында мәгълүмат күбрәк.

Башта агасы Сәфәр хәзрәттән, аннары Казан арты авылларының берсендә күпмедер белем алгач, ул Бохарага китеп укыган. Соңрак Югары Курса, Тимершәех һәм Төрек авылларында имам булган. 1809 елда Казанга күчеп килеп, Яңа бистәнең соңрак 9-мәчет дип йөртелә башлаган мәчетенә мулла булып урнашкан. Авылларны еш алыштыру сәбәбен без белмибез. Әлеге дә баягы килешә һәм тыныша алмау дип уйларга гына кала. Казанга килеп төпләнү сәбәбе исә беркадәр билгеле. Мәхәллә халкы элекке муллаларының шәкертләргә дәрес бирүдә булдыксызлыгын төшенеп алгач, аңа алмаш эзли башлаган һәм, ниһаять, Әмирхан хәзрәтне чакырып китергән. Укыту-тәрбия эшләрен, ул, күрәсең, тиешле югарылыкка күтәргән. Бу мәчет каршындагы мәктәпнең Хөсәен һәм Зариф муллалар вакытында да «Әмирхан мәдрәсәсе» дип йөртелүе әнә шул турыда сөйләсә кирәк.

Әмирхан остазы Мөхәммәдрәхим хәзрәт кызы Газизәгә өйләнгән һәм Хәсән, Ибраһим, Хөсәен, Фатима исемле балалары бер-бер артлы дөньяга килгән. Үлгән елы да тәгаен билгеле: 1827 ел.

Тарихчылар Әмирхан хәзрәтнең соңыннан танылып киткән шәкертләренең дә исемнәрен саныйлар. Берсен генә укучының зиһененә кертеп калдыруны кирәк табам: Фәхретдин Мостай улы эль-Норлатый.

Әдипнең бабасы Хөсәеннең үсмер чагы бик үк кояшлы, аяз булмаган. 1816 елда дөньяга килеп, унбер яшендә атасыз кала. Башта Чистай шәһәрендә, аннары Казанда һәм, ахыр килеп, Мәчкәрә авылында белем эсти. Бу елларда ул кардәш-ырулары тәрбиясендә булган дип уйларга

кирәк. Кайсыдыр елны Бохарага китеп, андагы мәдрәсә бирә алган кадәр гыйлем белән зиһенен баеткач, 1847 елда Казанга кайта һәм, указ алып, мәрхүм атасы мәчетенә Байморад мулла янына икенче, иптәш мулла булып урнаша.

Күп еллардан соң Ф. Әмирхан болай дип язды: «Казан имамнарының, бер-беренә дошман фиркаләргә аерылышып, Мәрҗани исеме вә мәсләге тирәсендә мөҗадәлә * кылышкан вакытларда минем атам вә соңгарак таба бабам да Мәрҗани тарафдары фиркага мәнсуб ** булганнар».

Ни өчен Хөсәен хәзрәт соңлый төшкән? Монда ике ихтимал булырга мөмкин. Беренчесе: Мәрҗани, гадәттән тыш талантлы, кыю һәм тәвәккәл кеше буларак, тизрәк аяк киенеп алып, алданрак көрәшкә ташланган. Хөсәенгә исә моның өчен күбрәк вакыт кирәк булган. Икенчесе: алар арасында көндәшлек дигән нәрсә яшәгән. Бохарада ул Мәрҗани белән бер үк вакытта гыйлем алды. Укуны тәмамлаулары арасы бер-ике генә ел. Казанда да бер үк мәҗлесләрдә еш булганнар. Кыскасы, уздырыштан гыйлем алалар, уздырыштан сүз сөйлиләр, уздырыштан яза башлыйлар. Ш. Мәрҗани кыю һәм төпле фикерләре, тирән эчтәлекле әсәрләре белән танылгач та, Хөсәен хәзрәт башта аңа ияргән, дөресрәге, ияргергә теләмәгән. Нәселдән килә торган сыйфатлары шул: һәр әйткәнгә ләббәйкә дип торырга, кеше эзенә басып барырга яратмыйлар. Әмма заман таләбе үзенекен иткән: ахыр чиктә Хөсәен сукмагын Мәрҗани сукмагына китереп кушкан, икесен дә татар мәгърифәтчелегенең олы юлына чыгарган.

Мәрҗани кадәр үк булмаса да, Хөсәен хәзрәткә дә искегә чытырдап ябышкан руханилар һәм фанатик сәүдәгәрләр һөҗүменә каршы торырга туры килгән. Яңа бистәнең 3-гильдия купецы Муса Понамарев, мәсәлән, 1857 елда урындагы власть ияләренә һәм Уфадагы диния назаратына түбәндәге эчтәлекле донос язып җибәрә.

Хөсәен мулла Әмирханов Коръән һәм шәригать кушканнарны төгәл үтәми. Ураза беткәнлеген һәм ифтар көнен үз белдегенчә билгели. 1855 елның 4 май көнендә, мәсәлән, ул, ягъни Муса Понамарев, намаздан соң мәхәллә кешеләре алдында Хөсәен мулладан яңа айны үзеннән гайре кем күрде, дип сораган. «Дүрт кеше», дигән Хөсәен кырыс кына. Аннары тагын да тупасрак итеп өстәгән: «Сиңа ни кирәк? Ник кысыласың?» Соңрак Мусага Хөсәеннең мондый сүзләрен җиткергәннәр: «Себер китсәм

---

* Мөҗадәлә — бәхәс, ызгыш, гауга.
** Мәнсуб — караган, бәйләнгән.

китәрмен, мин аны үтергәнче кыйнаячакмын». Дөрес, берничә көннән соң, янәсе, Хөсәен хәзрәт ике кеше белән берлектә Понамарев өенә килеп чыккан да эшне зурга җибәрмәскә үтенгән, шәригать таләпләрен төгәл үтәргә вәгъдә иткән. Әмма сүзендә тормаган, тагын башбаштаклыгына кайткан. Шәкертләрне дә юньләп укытмый икән.

Уразаның тәмамлану көнен билгеләү ул вакыт шактый четерекле мәсьәлә булган, күрәсең. Яңа туган айны берничә кешенең күрүе һәм шаһитлек итүе кирәк. Әгәр томан төшкән булса нишләргә? Бу мәсьәлә хәтта Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадель-әхбар» китабына да барып кергән.

1867 елгы ураза ахырында муллалар мәҗлесендә шушы хакта бәхәс чыга. Мөхәммәткәрим мулла гаеткә иртәрәк ди икән. Мәрҗани: «Вакыт», дигән. Күпчелек имамнар Мөхәммәткәрим ягында калып, Хөсәен хәзрәт кенә Мәрҗанине яклаган.

Билгеле мәгълүматлар Хөсәен мулланы таза бәдәнле, мәһабәт һәм гайрәтле адәм итеп җанландыралар. Үзенең төп вазифасын — намаз укыту, балага исем кушу, никах уку, үлгәнгә ясин чыгу кебек эшләрне ул чынлап та яратып һәм җиренә җиткереп башкармаган. Мондагы тәкәллефләр, гореф-гадәтләр туйдыру өстенә, шулкадәр искергәннәр ки, дөньяга яңача карый башлаган хәзрәткә бу эш рәхәтлек китермәгән.

Балаларны җүнләп укытмый дип гаепләүдә дә хакыйкать юк түгел. Указлы мулла булып алгач, баштарак ул, бүтән вазифаларыннан тыш, шәкертләрне дә укыткан, әлбәттә. Ләкин мәдрәсә зур да, мәшһүр дә түгел. Чынлыкта ул ибтидаи (башлангыч) мәдрәсә, ягъни мәктәп кенә. Бохара кадәр Бохарадан укып кайткан галим мулла өчен балаларга «әлеп-би-ти-си» дип хәреф таныту кебек эш бик үк мавыктыргыч булмаган. Тора-бара ул, күрәсең, бу эшне иптәш мулласы җилкәсенә күчереп, үзе читләшкән. Мәдрәсә зурая, программасы байый төшеп, рөшдигә (тулы булмаган урта мәктәпкә) әверелгәч кенә, Хөсәен олырак шәкертләргә дәрес әйтүдән тәм таба башлаган.

Хөсәен хәзрәтнең яратып башкарган һәм күп вакыт, зур көч сорый торган төп эше бар. Ул да булса — мөхәррирлек. Язу-сызу эшеннән күзәткән асыл максаты ислам идеологиясенең катып калган күп кенә догмаларын тәнкыйть астына алу, исламны яңа заманга, яңа таләпләргә яраштыру, яңа фикер, яңа идеяләргә юл әрчү. Ул сайлаган өлкә — тарих. Әмма без белгән тарих үк түгел, пәйгамбәрләр, изгеләр, ханнар, солтаннар тарихы. «Нөҗүм

эль таварих» («Йолдызлар тарихы», 1884 ел) исемле китабының керешеннән хәзерге телгә күчереп бер өзек китерик. «Мин бер фәкыйрь кол, халыкка файда китерер өчен һәм укучыларның догасын өмет итеп, бу китапны пәйгамбәрләрнең һәм изге әүлияларның күренеклеләрен могътәбәр китаплардан җыеп төзедем, каршылыклы сүзләрдән арындырдым, ных нигезләнгәннәрен генә керттем».

Бу китабында Хөсәен хәзрәт Мөхәммәткә кадәрге пәйгамбәрләрдән алып төрек солтаны Габделхәмиткә чаклы шәрыкнең бик күп билгеле шәхесләренең тормышына кагылышлы мәгълүматлар биргән. Моның өчен күпме китап укырга, чагыштырырга, уйланырга кирәк булгандыр!

Тарихчының моннан тыш тагын берничә басма китабы чыккан һәм шактый кулъязмасы сакланып калган. Аның шигырьдә дә каләм сынаганлыгы билгеле.

Шушы хезмәтләре белән Хөсәен хәзрәт үз заманының күренекле мөәррихы, ягъни тарихчысы булып танылган.

Бохарадан кайткач, Хөсәен, артык күп гомер үткәрмичә, Бәдриҗамал исемле кызга өйләнә, һәм менә шушы гаиләдә 1853 елның иске стиль белән 10 гыйнварында, беренчеме, икенчеме бала булып, Мөхәммәтзариф дөньяга килә. Аның бала чагы һәм үсмерлек еллары Яңа бистәдә, әнисе канат астында үткән.

Үз кул астында күпмедер укыткач, Хөсәен Зарифны Курса мәдрәсәсенә җибәрә. Аннары, Хвалын өязеннән килеп, үзендә укый башлаган Сәгъдетдин исемле шәкерт белән икесен бергә, Норлат мәдрәсәсенә илтеп, бер хөҗрәгә куя. Егет булып җиткән Зариф, 1872—1874 елларда шунда укып, «хәтме көтеп» итә.

Ник Курса һәм Норлат? Ник Бохара яисә Казан үзе түгел? Бохараи шәрифнең Казан имамнары һәм мөселманнары күзендә абруе төштемени инде? Алай дияр идең, Бохарага хәзрәт балалары китә торалар. Моннан соң да әле китәчәкләр. Күп еллардан соң Зарифка иптәш мулла булачак Садыйк Иманколый да әле Бохара гыйлемен дыңгычлап тутырып кайтачак. Атасы бар дисә, юллык һәм кеченерлек акчасын бирсә, Зариф китмәс идемени? Ләкин Бохара гыйлеменең кыйммәтен үзе татып белгән Хөсәен ул сүзне әйтмәгән.

Казан мәсьәләсенә килгәндә, мондый бер гыйбрәтле хәлгә игътибар итик. XIX гасырның ахырларына кадәр Бохарага китмәгән яшьләр, хәтта Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Уральскида туып үскән балалар да (күбесенчә мәхдүмнәр) төрле авылларга китеп укыганнар. Андый авылларның күпчелеге Казан тирәсенә урнашкан. Чөнки

оялары туздырылган морзалар һәм бүтән бай гаиләләр, авыл җирендә төпләнеп, яңа экономик үзәкләрнең калкып чыгуына һәм, шуңа бәйле рәвештә, яңа гыйлем учакларының барлыкка килүенә сәбәпче булганнар. Зур талант һәм белем ияләре тарафыннан нигезләнгән кайбер мәдрәсәләр, зураеп, камилләшеп, дан казаналар. Татарлар яши торган шәһәрләрдә исә мондыйлар белән ярышырлык уку йортлары XIX гасыр ахырына таба гына баш калкыта башлый. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 1882 елда, Оренбургтагы «Хөсәения»нең 1896 елда, Уфадагы «Галия»нең исә 1906 елда гына дөньяга килүләрен искә алыйк.

Норлат мәдрәсәсе дә, күрәсең, заманы өчен алдынгы уку йорты булган. Зарифның белем эстәү юлын шунда төгәлләве, моннан кала, мәдрәсә башлыгы Фәхретдин мулланың Әмирхан хәзрәт шәкерте булганлыгы белән дә аңлатылса кирәк.

Ничек укыган соң Мөхәммәтзариф? Тумыштан ук зирәк, зиһенле һәм үз дигәнен булдыручан егет алдынгы шәкертләрнең берсе булган дип уйларга туры килә. Сәгъдетдин мулланың күп еллардан соң биргән белешмәсенә караганда, Зариф мәдрәсәдә чакта ук «коръән хафиз» булган, ягъни коръәнне яттан белгән. Кыйраәәт остасы да икән. Гавышы калын һәм матур. Норлат мәчетендә дә, атасы мәчетенә кайтып та коръән укып күрсәткәнлеге билгеле.

Әмма Зариф дин гыйлеменә мөкиббән киткән фанатик шәкерт булган икән дип уйларга ярамый. Таза һәм дәртле бу егет дөньяны да сөйгән, тормыш ләззәтләреннән дә баш тартмаган, дөнья хәлләре һәм иҗтимагый мәсьәләләр белән дә кызыксынган.

Зариф мулланың Норлат чорыннан калган бер калын дәфтәре бар. Ул анда, дәфтәр битенең ике ягын буш калдырып, кыска юллар белән «Исагуҗи»ны күчергән. Аннары шул чиста урыннарга үзеннән шәрех язарга керешкән, ләкин никтер тәмамламаган. Әнә шушы дәфтәренә ул, көнен, аен күрсәтеп, кайбер вакыйга һәм фактларны теркәп барган. Бу язмалардан аның юмор һәм сарказмнан да мәхрүм булмаганлыгы күренә. Изге «Исагуҗи»га багышланган дәфтәргә Зариф шәкерт хәтта җенси куәтне арттыра торган чаралар турындагы язманы күчереп алудан да тартынмаган.

1847 ел. Зарифның укуы тәмам. Шуннан нәрсә? Казан губерна идарәсенең 1875 елның 1 февралендә Диния назаратына җибәргән кәгазеннән без түбәндәгеләрне беләбез.

Яңа бистәнең Зур соборный мәчете мәхәлләсе кешеләре Мөхәммәтзариф Әмирхановны мәрхүм Мөхәммәтсафа мулла урынына әтисе Хөсәенгә иптәш мулла итеп сайлаганнар. Идарә булачак муллага әйбәт кенә характеристика бирә дә имтихан алырга үтенә. Зариф Уфага киткән һәм, 1875 елның маенда имтихан тапшырып, имам хатыйп һәм мөдәррис дигән исем алган. 22 яшьлек егет өчен начар түгел!

Шул ук елның җәендә, Шаһиәхмәт мулла өендә ут чыгып, йорт каралтылары-ниләре белән янып бетә. Мулланың җиһазларын, авыр-авыр сандыкларын чыгаручылар арасында беләкләрендә көч, күңелендә дәрт уйнап торган яшь мулла Зариф та булган. Иманколыйларның гаиләсе вакытлыча Хөсәен хәзрәт йортына күчә. Әнисе җитәкләгән хәлдә өйләренә килеп кергән биш яшьлек Садыйкның күп еллардан соң үзенә иптәш мулла булачагы Зарифның ул вакытта, билгеле, башына да килмәгән.

Муллалык вазифасын ничек башлаган ул, ничек үтәгән, без боларны юньләп белмибез. Шулай да, дөньясын онытып, баш-аягы белән чумган, шәригать кушканны җиренә җиткерү өчен тиресеннән чыгып тырышкан дип уйларга туры килми. Ни өчендер өйләнергә дә ашыкмаган. Яшь чак, хозур чак, камыт кияргә өлгерербез дидеме, әйтеп булмый.

Ел артыннан ел узган. Зариф мулланың да тормышы майлагандай гына бармаган. Күңелсезлекләр дә чыккалаган, бәлагә дә юлыккан. Моңа гаҗәпләнергә туры килми. Яңачарак уйлый, яңачарак гамәл кыла. Руханилык вазифасын башкаруга мөкиббән китмәгәне хәлдә, дөнья сәүмәк «чир»еннән дә азат түгел. Дус бар, дошман бар дигәндәй, иске фикерле муллаларның Зариф Әмирханыйны өнәмәүләре табигый. 1896 елда, мәсәлән, хәрби мулла Гариф Габделвәли улы аның өстенә ике гаеп ташлап, Диния назаратына кәгазь язып җибәргән. Беренчесе — яше җитми торган үсмер егеткә никах укыган икән. Икенчесе — Федор Никифоров исемле керәшен белән Бибн-Саҗидә исемле мөселман кызын никахландырган. Тикшерү нәтиҗәсендә соңгысы чеп-чи ялган булып чыга, баштагысы раслана. Зариф хәзрәт ник моңа барган? Җистереп җавап бирү кыен. Әмма никах укырга үтенүчеләр арасында Әхмәтҗан Апаковның, шаһитлар арасында Зарифның кияве (сеңлесе Мәрьямнең ире) Шәкүр Апаковның булуы төрле фаразларга юл калдыра. Бәхеткә каршы, судка эләгүдән Зарифны ниндидер манифест коткарып калган.

Алма агачыннан ерак төшми дигәндәй, Зариф мулланың калыплашуы, дөньяга карашының билгеле бер рәвеш алуы, барыннан да бигрәк, Хөсәен хәзрәт йогынтысы белән бәйле. Соңрак китаплар язарга керешүе дә очраклы хәл булмаса кирәк. Фикри үсеше, күрәсең, тукталып калмаган, Ф. Әмирхан әйткәнчә, атасыннан элегрәк ул Ш. Мәрҗани тарафдарына әверелгән.

Дөрес, Зариф хәзрәтнең иҗтимагый-сәяси иманы моннан күп алга китми. 1905 елгы революциядән соң без аны либераль карашлы мулла итеп күрәбез. Полиция агентурасының күзәтүләренә караганда, ул кадетлар партиясенә күңел баглаган. Яңа гасырга кергәч, уртарак юл тота торган Зариф белән суллашып киткән улы Фатих арасында әле каршылыклар чыга башлаячак, үзара мөнәсәбәтләре соңрак гаять кискен төс алачак. Хәер, без бик күп алга сикердек бугай, хикәяләвебезне үз урыныннан ялгап китик.

...Яшь мулла Мөхәммәтзариф, ниһаять, Зиннәтулла кызы Бибирабигага никахлана. 1882 елда аларның кызлары дөньяга килә. Исемен Бибисәгадәтбану дип куялар. Тагын дүрт елдан соң, ягъни 1886 елда, бу китапның герое, булачак бөек язучы, публицист һәм тәнкыйтьче Фатих Әмирхан дөньяга килә. Язмыш шуклыгыдырмы, ул апасы белән бер үк көндә — иске стиль белән 1 январьда туган.

## 2

Казан, бигрәк тә аның бистәләре, еш кына зур-зур янгыннарга дучар булып торган. Саный китсәң, сәбәпләре күп: тоташ агач өйләр, җәйнең коры килүе, ата-аналары эштә булып, караучысыз калган балаларның шуклыклары, үч алу өчен төртеп яндыру...

1749 елда Иске бистәне ялмап алган зур янгын Яңа бистәнең барлыкка килүенә сәбәп була. Татарларны христиан диненә көчләп кертү кампаниясенең гаять куәтләнгән, ямьсез һәм шәфкатьсез рәвеш алган дәвере иде бу. Татарлар арасында Аксак Каратун дигән кушамат белән мәшһүр булган епископ Лука Конашевич, бу фаҗигадан файдаланып, ярлы татарларның тире белән сугарылган, көлгә әйләнгән хезмәтләре белән ашланган җирне чиркәү файдасына тартып алуга ирешә. Йортсыз-җирсез калган халыкка моннан күчеп китәргә боерык бирелә, урын да күрсәтелә. Әнә, Иске бистәнең аръягында, Иделгә таба, саеккан күлләр һәм сазлыклар белән әйләндереп алынган ярым утрау бармы, менә сезгә урын! Янгыннан соң ук өч

йөзләп фәкыйрь гаилә шунда күчеп китә. Шул ук елларда Казан татарлары әлеге ярымутраудан зират өчен дә җир бүлеп алалар. «Яңа бистәгә үлгәннәр һәм бөлгәннәр генә бара» дигән әйтем әнә шуннан килеп чыккан.

Яңа бистәнең шәһәргә таба ягы да үзәнлек булганга күрә, яз-көз айларында кешеләр шәһәргә бата-чума чыкканнар. Ташу вакытында исә ярым утрак утрауга әверелгән, көймә һәм паром белән йөргәннәр.

Шунысын да әйтик, Яңа бистәнең хәзерге вокзалга караган ягы, мичкәләр белән шәһәрдән китереп аударыла торган нәҗес урыны булып, бик үк татлы тоелмаган ис таратып яткан. Моңа тагын сазлыклардан килеп ябырылган озынборыннарны өстик. Күнегелгән гадәттерме, әллә инде кәҗә күп асрагангамы, бистә халкы яшелчә үстермәгән, ашаганнары өйрә, токмач, бәрәңге кыстыбыеннан узмаган. Әнә шуларның нәтиҗәсе буларак бизгәк, чахотка, балаларда рахит хөкем сөргән. «Кыйгач кашлы, кәкре аяклы Яңа бистә кызлары» дип юкка гына җырламаганнар. Үлем-җитем күп булган, бигрәк тә балалар кырылган.

Беренче килеп утырган кешеләр хисабына Яңа бистә халкы бик үк ишәймәсә дә, шәһәрдән күчә торучылар, бигрәк тә тирә-як авыллардан килеп төпләнүчеләр хисабына ул киңәйгән, зурайган, XIX гасырда инде өч мәхәлләгә бүленгән, өч таш мәчете булган.

Яңа бистә кешеләренең баштагы төп кәсебе — кустарьчылык. Ирләр кием-салым, бүрек, читек-кәвеш теккән, хатын-кызлары кәләпүш, калфак каеган, такыя чиккән. Товарларын Иске бистә байларына сатканнар. Хәллерәкләре ат тоткан, ямщик булып йөргән, һөнәрсезләре Усиялдә крушник булып йөк ташыган, Бакалтайда утырып калган салларны утынга тураган. Ач та булмаганнар, тамаклары да туймаган.

Узган гасырның урталарына таба Яңа бистәдә борынгыдан килгән кәсеп-һөнәрләрдән сабын кайнату, тире иләү, мех эшкәртү предприятиеләре калкып чыга башлый. Дөрес, аларны фабрика дип атау да кыен. Эшчеләр саны 2—3 тән башлап, 30—40 ка кадәр генә. Хуҗаларыннан Глинкин, Үтәмишев, Кәҗә Якуб кебекләрне атап китәргә мөмкин. Аның саен арта торган эшче кулларны бу предприятиеләр генә йотып бетерә алмаган. Күпләр Крестовниковларның сабын, Петцольдның сыра заводында һәм бүтән җирләрдә ялланып эшләгәннәр. Билгеле инде, квалификация сорамый торган кара эштә.

Әнә шул килеш Яңа бистә Казанның зур булмаган бер административ төбәгенә әверелә. Халык ишәйгәч кирәк

бит: кибетләр, сәүдәгәрләр саны арта, кустарьларның товарларын җыеп алып ары таба җибәрә торганнары килеп чыга. XX гасыр башында без Яңа бистәдә яшәгән беренче, икенче, хәтта беренче гильдия купецлары белән дә очрашабыз. Шулай инде, байлар байый, ярлылар очны-очка гына ялгап баралар.

Тагын ние белән мактана ала Яңа бистә? Пекарнясы, суның көянтәсен бер тиенгә сата торган «фанталы», бер татар «духтыры», «божий фирка» башлыгы Гайнан Вәисеве, камчылы ишаны, Насыйр бутишнигы, «акушерка» Әчәтте Гаффәсе, сукыр карые һ. б. белән.

Кыскасы, бистә дисәң бистә. Ни авыл, ни шәһәр түгел. Авыл дияр идең, иген икмиләр, шәһәр дияр идең, бер-беренә сырышкан кечкенә агач өйләрдә гомер итүчеләр тавык-каз, сыер-кәҗә асрый. Иске гореф-гадәтләр, шәригать кушканнар белән миләре агуланган. Байлар да алардан күп ерак китмәгән. Искечә тора, искечә сәүдә итә, иске яшәеш кагыйдәләренә буйсына.

Моннан соң инде Әмирхан, Хөсәен һәм Зариф хәзрәтләрнең дөньяга яңача карый башлап та, күкрәкләрендә көч-гайрәт асрап та, урта юл тотулары, алга таба бик үк ыргылмыйча яшәүләре аңлашыла. Һәр эшең, һәр фигылең, һәр адымың күз алдында. Итәк-җиңне җыеп йөрергә, сүзеңне үлчәп сөйләргә кирәк. Артыграк яңарып киттеңме, кара халыкны биздерүең, байлар алдында ышанычны югалтуың мөмкин. Бөтен тормышың — торак-җирең, өс-башың, ашау-эчүең (Гәрәй морза варислары дәрвиш булып яшәргә күнекмәгән), мәдрәсәң шулардан килгән доходка бәйләнгән бит. Карт хәзрәтне әйтеп тә тормастан, Хөсәен бер генә тапкыр да фоторәсемгә төшмәгән. Хәтта Зариф та, Тукайны күмгәндә үзе дә сизмичә объективка эләккәннән тыш, рәсемен алдырмаган. («Ул вакытта әле рәсем алдыру вә аны өйдә саклау зур бер җинаять санала торган шәйләрдән берсе иде», ди Ф. Әмирхан.)

...Шәһәр ягыннан килеп, Яңа бистәнең трамвай йөри торган урамына күтәрелик. Бу урам элек Мало-Симбирский дип аталган, хәзер — Мәҗит Гафури. Урамның сул як тротуары буйлап атлыйк. Әһә, менә килеп җиттек: 35 нче капка. Буп-буш ишегалдының аргы башында яны белән салынган алты почмаклы өй күренә. Кайчандыр зур һәм матур булган бу йорт хәзер инде, чүгә төшеп, төсен җуйган. Җентекләбрәк карасаң, сырлап эшләнгән наличниклы тәрәзә араларында канатларын җәйгән күгәрчен сурәтләрен күрергә мөмкин. Өйнең ике ягында бакча, эреле-

ваклы куаклар. Кайчандыр анда карга оялары белән чуарланган мәһабәт тупыллар шаулап утырган.

Фатих Әмирхан туган йорт шушы була инде... Ул дөньяга килгәнче күп еллар элек әмирханныкылар Мало-Симбирскига чыгарып салынган һәм хыялны бик көчләсәң, ике катлы дип исәпләрлек өйдә яшәгәннәр. Хәзер инде ул йорт юк. Кайсыдыр елларда Рабига остазбикә аның бер бүлмәсендә кыз балалар укыткан, бүтән бүлмәләрендә хезмәтчеләре яшәгән, фатирчылар торган. Ишегалдының капкадан кергәндәге уң ягында келәт, ат, сыер абзарлары һәм бүтән төр каралтылар тезелеп киткән. Әмирхан һәм Хөсәен ничек булгандыр, әмма Зариф хәзрәтнең атлар тотканы, сыер асраганы билгеле. Фатих имчәк баласы чакта сыерны Рабига үзе сауган.

Артык мәшһүр кеше кызы булмагандырмы, Рабига остазбикә хакында мәгълүмат күп түгел. Менә алтмыш яшенә җитеп килгән чагының оның кызы Разия язып калдырган портреты. «Чандыр гына, кечерәк буйлы, бик хәрәкәтчән, озын кара чәчле бу карчык гаҗәеп зирәк һәм кабилиятле кеше иде... Аның бик купшы һәм пөхтә киенергә яратуы, кунакка барырга җыенганда, көзге алдына басып, кара күзләренә сөрмә тартып торулары күз алдымда калган». Моннан аның кыз чагын һәм яшь хатын вакытын да беркадәр күз алдына китерергә мөмкин.

Ул заманның гадәтенчә, мулла хатыннары мәхәлләдәге кыз балаларны укытырга тиеш булганнар. Яшь остазбикәне бу эшкә мулла үзе әзерләгән булса кирәк. Эшкә башлагач та әле Рабига һәр дәресен, хәзерге тел белән әйтсәк, ире консультациясеннән соң үткәргән. Разия Әмирханованың язмасына караганда, илленең теге ягына авышкан чагында да ул һәр көн кич иреннән гарәп грамматикасы буенча дәрес ала икән.

Билгеле инде, Рабига остазбикәнең белеме акрынлап арта, караш даирәсе киңәя, укыту ысуллары камилләшә барган. Яңа гасыр башында, мәктәбе шактый киңәеп һәм ныгып, абруй казангач, ул инде үзендә укып бетергән сәләтлерәк кызларны мөгаллимә итеп калдыра башлаган. Шәхси кулларда саклана торган түбәндәге документ та бу сүзләрнең дөреслеген раслый.

«Шәһадәтнамә.

Бу шәһадәтнамәне күрсәтүче Нәфисә иптәш Габделхаликъ кызы Миниева 1916—18 елларда Яңа бистәнең Әмирхания кызлар мәктәбендә беренче, икенче һәм өченче сыйныфларда мөгаллимлек итте. Мәзкүр мәктәпнең

мөдирәсенең вафаты сәбәпле шул вакыйганы игълам вә тәсдыйк итү мөдирәнең варисларыннан берсенә йөкләнәдер.

Бу хосуста шәһадәт бирәм.

Фатих Әмирхан, 27/X — 20».

Үзенең башына килгәнме, яки инде ире киңәш биргәнме, бер вакыт Рабига остазбикә диннең элементар мәсьәләләрен яктырткан китапчык-кулланма язарга карар итә. Менә ул кечкенә китап безнең алдыбызда: «Нәҗат эль-мөкәлләфин» (якынча: «Үсеп җиткәннәрнең котылуы»). Титул битендә мондый сүзләр укыла: «Ибтидаи мәктәпнең соңгы сыйныфлары өчен игътикадка даир мәсьәләләр. Бу рисалә берничә еллар кызлар мәктәбендә хифзан укытылып, файдасы тәҗрибә ителгәндән соң нәшер ителде. 2 нче, 3 нче, 4 нче сыйныфлар өчен.

Мөрәттибәсе: Р. Әмирхания.
Нәшире: «Юл» китапханәсе.
Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1910».

«...Мин 188+ ел гыйнварының таңында тудым. Туган вакытымның ел башы һәм ел башының да таң вакыты булуын хәтергә төшерсәләр, укучы әфәнделәр үзләре дә минем буш кеше түгел икәнемә ышанырлар дип уйлыйм».

Әмирханның «Минем тәрҗемәи хәлем» исемле юмористик автобиографиясе әнә шулай башланып китә. Билгеле инде, ник мин бу фани дөньяга килдем дип уйлап тормаган, ата-баба эшләгәнне эшләргә кирәк дип, кычкырып елый башлаган. Аны бу дөньяга кабул итүчеләрнең моңа бер дә исләре китмәгән. «Ир бала, ир бала!» дип шатланышканнар да, ашыкмый-кабаланмый гына чүпрәккә төреп, авызына ими каптырганнар. Шуннан малай шып була: тамак тук, өс бөтен, тагын ни кирәк?

Тудыңмы, үсәргә тиешсең. Безнең кечкенә Фатих та үсә башлый, теш чыгарумы кирәк, тәпи йөреп китүме, сөйләшә башлаумы кирәк, һәркайсы җирле җиренчә.

Әнисенең әйтүенә караганда, ул бик тә тынгысыз, тиктормас, шаян бала булган. Сыер саварга чыкканда да, Рабига абыстай аны чыгырга утыртып, бәйләп куя икән.

Бераз үсә төшкәч безнең Фатих казлар белән дә конфликтка керә башлаган: «...без тора торган җирнең зыярәте буендагы үләнлектә бәбкәләрен саклап йөри торган казлар ни өчендер мине әүвәл танышуымда ук дошман күрә башладылар. Алар миңа кайда гына туры килсәләр дә, «пх-х-х-х...» дигән бер төрле ямьсез вә минем өчен тарихи

куркыныч тавыш чыгарып, куып йөри торган яман гадәткә өйрәнделәр. Кайда гына бәбкәле бер каз очрамасын, ул мотлак, муенын сузып, минем артымнан кууны үзенең вазифаи казыясыннан * хисаплый иде». Монда бер шик туа: бу конфликт күбрәк малайның үзеннән чыкмадымы икән? Әнә бит ул апасы Сәгадәт белән энесе Ибраһимны елатканчы үчекләргә һәм иптәш малайларының ачуын китерергә дә бик оста булган. Хыял җимеше булмаса, ата казга каршы да ул хәйлә тапкан. Теге муенын сузып килә башладымы, кечкенә генә матур ак этен өстерә икән дә, алар сугыша торганда, үзе тая икән. Балигъ булып кулына каләм алгач, Фатихның чалмалы һәм чалмасыз «казлар»ны котыртырга бик маһир булганын искә төшерсәк, әлеге ихтималның чынлыктан ерак тормаганына ышанырбыз.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә килүенең очраклы хәл булмаганлыгын күрсәтеп һәм юмор катыштырып, әдип тагын болай дип яза: «... мин 5—6 яшьләргә җиткәндә инде таш тәти (чынаяк ватыклары) мөхибләреннән идем. Хәтта бик озак заман һәм тырышлык сарыф итеп, мөкәммәл бер таш тәтиләр коллекциясен дә җыярга муаффәкъ булган идем...» Юморын юмор, әмма безнең буын да әле чынаяк ватыклары белән әвәрә була иде; кемнәрнеңдер өй җылысын сиздереп торган әнә шул зәңгәр, яшел, сары, кызыл, шәмәхә, ал бизәкләрдә ниндидер серле дөнья күреп, татлы хисләргә бирелә иде.

Язучы булачагын хәбәр итә торган эш-фигыльләренә килсәк, өч яшьлек Фатих бабасының китап битләрен диңгез дулкынына охшаш сызыклар язып тутыра башлый. Өйдә китап күп, кара-каләм дә, үрнәк тә бар, ник ул гына язмасын? Ләкин бу эше ата-анага бик үк ошап бетмәгәнгә, китапларны аның буе җитмәс төшкә куя башлыйлар. Кечкенә мөхәррир моңа да аптырап калмый, җае чыккан саен һәрбер яссы нәрсәгә язгалый тора. Бармагын карага манып әлеге дулкыннарын Ибраһимның битенә дә төшереп караган. Бусы инде олы улының «иҗатын» кече улының битеннән тиргәнә-тиргәнә юып төшерергә мәҗбүр булган анага ошамаган.

Ләкин ул вакытларда әле бабасы һәм этисе, мөхәррирлектән бигрәк, Фатихны мулла, хәзрәт булулары белән кызыктырганнар. Чалма-чапан киеп, озын таяк тотып, намазга барулары, намаздан кайтулары, юлда очраган агайларның кулларын күкрәккә куеп, «әссәламегаләйкем, хәзрәт» дип олылап калулары малайның хыялына аеруча нык

---

* Вазифаи казыя — казлык вазифасы, бурычы.

тәэсир иткән. Әдип үзе дә моны раслый. «Мин мулла баласы булганга, бик кечкенәдән үк муллалык дәрәҗәсенең, пәйгамбәр вә сәхабәлектән кала, иң зур дәрәҗә икәнен бик яхшы төшенә идем».

Биш яшеннән безнең Фатих намазга йөри башлый. Тәравих вакытларында, тәрәзә төбендә йоклап китеп, сәҗдәгә киткән абзыйларының өсләренә дә егылып төшкәләгән. Соңыннан өстәлгән булмаса, биш яшьлек «мәчет карты» тапкыр җавапка осталыгын да күрсәткән. Бервакыт шулай мәчеткә килгән малайлар белән сөйләшә башлагач, Вәли карт: «Намаз эчендә сөйләшергә ярамый, мәхдүм» дип кисәтә. Фатих аптырап калмаган, аңа да үз янындагы Сәгыйть карт белән сөйләшә-сөйләшә намаз укырга киңәш биргән.

Көннәрдән бер көнне кечкенә Фатихның башына шәп фикер килә: нигә үз яшьтәшләре арасында аңа мулла булып йөрмәскә? Ул бит сиңа Яңа бистә малайларыннан бер малай гына түгел, карт хәзрәтнең оныгы, Зариф мулланың улы. Менә безнең Фатих үз гәүдәсенә таман булган чалма-чапан таләп итә. Малайның теләге кызык тоелганмы, әллә инде үзенекен итмичә туктамаячагын белгәнгәме, олылар каршы килмиләр. Әтисенең иске бикасап казакиен сүтеп, чапан тегәләр, шундый ук иске чалмадан кисеп, кечкенә чалма булдыралар. Инде таяк кирәк. Урамда каз куа яисә атланып чаба торган таяк ярамый монда. Әнә бит бабасының таягы нинди. Мәсьәләне әнисенең эшкә ярамый торган зонтигы хәл итә. Фатих шуның сабын суырып чыгара да мәчет таягы итеп тота башлый.

Тиктормас, шук һәм тәтелдек малайның, алмаштырып куйгандай, кинәт җитдиләнеп китеп, таягын тукылдата-тукылдата намазга баруын, намаздан кайтуын күз алдына китерү кыен түгел. Ишегалдында яисә лапасларында яшьтәш малайларын сафка бастырып намаз укытканлыгына, апасын яки аның берәр иптәш кызын остазбикә ясап уйнаганлыгына да шикләнмәскә мөмкин.

Күп еллардан соң ул болай дип язды: «Мин шулай итеп намазга йөрим дә йөрим, ә мәхәлләнең сакаллы сабыйлары мине кечкенә клоун дип йөрисе урынга, «нәни мулла» дип йөриләр...» Бу сүзләрендә инде юмор һәм ирония генә түгел, бәлки оялу һәм үкенү тойгысы да ишетелә. Үкен-үкенмә, тик ул вакытта бүтәнчә була алмаган. Ата-ана шат, авыру карт хәзрәт тә канәгать: булыр моннан, җилле мулла чыгар. Тирә-күрше, дус-иш һәм мәхәлләнең карт-корылары «әссәламегаләйкем, кечкенә хәзрәт» дип, күңелен үстереп торалар.



Т 122735
НАУЧНАЯ БИБЛИОТЕКА им. Н. И. Лобачевского Казанского гос. университета

Өй дә мәчет, мәчет тә өй... Бистә малайлары белән бер дә уйнамаганмыни соң ул? Уйнаган, билгеле. Сазлыкларны да ерып йөргән, балык та сөзгән. Бакалтайга да чыккан. Так-каравыл, шар сугу, лапта кебек уеннардан да читтә калмаган, сугышкан да, үкереп кайткан чаклары да булган. Кем белә, бәлки әле бистә урамында яисә болында итекче Мөхәммәтвәлинең асрарга алган малае Габдулланы да күргәндер. Ләкин күргән тәкъдирдә дә аралашып китмәгән: ул кем дә, Фатих кем! Фикердәш, көрәштәш һәм якын дуслар булып, бер аяктан атлап барасылары, билгеле инде, ул вакытта ике йоклап бер төшләренә дә кермәгән.

Бу урында ассызыклап шуны әйтергә кирәк: архивта саклана торган автобиографиясеннән күренгәнчә, Ф. Әмирхан бала чагында, бигрәк тә мәктәп яшенә кергәч, туйганчы уйный алмаган. Өйдәгеләр урамга чыгармаска, күздән бик үк ычкындырмаска тырышалар. Озаграк югалып торса, өйдә шау-шу куба, эзләргә чыгалар, әрли-әрли алып кайталар. Хикмәт бәла-казага юлыкмагае дип куркуда гына түгел. Хикмәт тагын Фатихның бистә малайларыннан бер малай булып үсүен теләмәүләрендә. Әлеге автобиографиясеннән күренгәнчә, ата-анасы аңа һәрвакыт тукып торган: мулла буласы кешегә үзенең булачак мәхәллә кешеләре белән уйнарга ярамый, килешми. Тыңламаса, куркытудан да кире тормаганнар:

— Чыбык ашыйсың килмәсә, яхшылык белән тыел!

Алты яшь ярымда Фатих мәктәп бусагасын атлап керә. «Безнең хәлфә юан гына, ялкау гына бер мишәр иде,— дип яза Әмирхан «тәрҗемәи хәл»ендә.— Ул миңа кәгазь өстенә ясалган таш тәтиләр шикелле нәрсәләрне күрсәтте дә, болар баш «ба», урта «ба» булалар, диде. Мин аның белән бәхәсләшеп тормадым, боларның таш тәти сурәтләре икәнен бик яхшы белсәм дә, урта «ба», әллә нәрсәләр дип ышанып йөргән кыяфәт күрсәтә торган булдым. Акрын-акрын хәлфә миңа, табагач сурәтләре күрсәтеп, кечкенәсен «һәмзә», зуррагын «гаен» дип йөрергә кушты. Башыңа төшкәч, бернәрсә эшләр хәлең юк: табагачларны «һәмзә» һәм «гаен» исемнәре белән йөртә башладым. Хәлфәмнең иң ахыргы ялганы — шикәр ваткычы сурәтен «ләмәлиф» дип ялганлавы булды. Шул ялганга ышанган көннән башлап, мине язу таный торган бала дип йөртә башладылар».

Нәрсә бу, авылдан күчеп утырган фәкыйрь көнлекче баласы кебек, шыр надан хәлдә мәктәпкә килдеме Фатих? Юк, һич юк! Хәлфәгә барганда инде малайның, хәрефләрне

ятлап бетереп, сүзгә әверелдерә башлаганы турында кистереп әйтергә була.

Акыл керә төшкәч, аңардан китапларны, билгеле, яшерми башлаганнар. Әлек китап тышындагы, аннары эчендәге кайсы таякка, кайсы табагачка, кайсы кайчыга охшаган серле билгеләргә, әлбәттә, ул игътибар иткән, нәрсә икәнлекләрен белергә теләгән. Апасының укый башлавы да аның күз алдында. Әнисе кыз балаларга дәрес биргәндә Фатихның кереп, еш кына тыңлап утырганлыгына да шикләнмәскә мөмкин. Кыскасы, кечкенә Фатихка хәреф танытырлык кешеләргә кытлык юк.

Соң ник шулай язган Фатих Әмирхан? Беренчедән, әйткәнебезчә, бу юмористик автобиография. Икенчедән, әдип анда гомумиләштерә, иске мәктәпләрдә язу таныту, укытуның гомуми хәлен, типик күренешен җанландырырга тырыша. Бәлки әле хәрефләрне белгән килеш укый башлаган булуы үзе үк Ф. Әмирханны мәктәптәге беренче адымнарын әнә шулай мәзәкләштереп язуга этәргәндер. Хәлфә, бүтән шәкертләр белән беррәттән Фатихка да: «Бусы, урак төслесе «йа», ди-ди, өйрәтергә керешкәндер. Малай «мин аларны беләм» дип әйтер иде, ярамый. Хәлфә кеше бит. Үзе зур, үзе юан. Иямәшә төшкәч, шуклыкка бирелүе, «Бу нәрсә?» дигән сорауга, белмәмешкә салышып, «табагач», «шикәр ваткыч» дип әйтеп ташлавы да мөмкин.

Хәер, нигә юрап маташырга? Архивтагы автобиографиясендә әдип үзе үк, мәктәптә үткәргән ике елын күздә тотып, болай дип яза: «Монда мин шактый зур уңышларга ирештем».

Фатих мәхдүмнең хәзерлеген күреп алгач, хәлфәсе аны «сикертебрәк» укыта башлаган дип уйларга туры килә. Хикмәт шунда: кадим мәктәпләрдә сыйныф, ягъни класслар, булмаган. Балаларның белем дәрәҗәләре нинди китап укулары белән билгеләнгән. Башта «Иман шарты» укытылган, аның артыннан «Һәфтияк», төрки китаплар һ. б. тезелеп киткән. Бер укучы «Иман шарты»н җиңә алмый азапланганда, икенчесе «Һәфтияк»кә керергә, аны узып, төркине дә башларга мөмкин.

«Иман шарты»нда озак тукталмыйча, укуының беренче елында ук Фатих, «Һәфтияк»не ерып чыгып, төркигә кергән дип уйларга кирәк. Икенче елында да, әнә шулай «сикеребрәк» укып, бу мәктәп бирә алырлык гыйлемне зиһененә сеңдереп бетергән булыр. Үз мәктәбендә ике ел укыткач, Зариф хәзрәтнең Фатихны, чагыштырмача яшь булса да, абруй казанырга өлгергән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчерүе әнә шул турыда сөйли. Икесен бергә алып бару,

алып кайту җайлырак булыр дипме, кече улы Ибраһимны да ул «Мөхәммәдия»гә бирергә карар иткән.

1893 елның январь аенда Хөсәен хәзрәт вафат була. Гаиләдә бу беренче үлем, бигрәк тә шундый олы шәхеснең вафаты Фатихка ничек тәэсир иткәндер, без моны белмибез. Баба белән оныкк арасында нинди мөнәсәбәт яшәгәнлеге хакында да мәгълүмат юк. Тарих һәм дин фәлсәфәсенә чумган кырысрак табигатьле Хөсәен хәзрәт төчеләнмәсә дә, үт-үт итеп кенә тормаса да, оныгына битараф булмаган дип уйларга кирәк. Беренче улының беренче ир баласы бит. Аның эшен дәвам иттерергә тиешле бала. Бабасыннан бераз өрексә дә, Фатих та аны яраткан булыр.

Үлеп киткәч, бабаның кадере тагын да арта, сыны зурая, эреләнә бара, исеме Шиһап Мәрҗани белән берлектә телгә алына башлый. Булачак «герое» Фәтхулла хәзрәт кыяфәтендәге фанатик руханилар йогынтысыннан арынуда күпмедер дәрәҗәдә Фатихка бабасы сурәте дә ярдәм итәчәк әле.

*2 бүлек*

## МАЯКЛАР АЛЫШЫНГАНДА

### 1

Казан сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Галиев улы Галимҗан, Бохарада укып кайтканнан соң, 1881 елда Тихвинский урамындагы * 4-мәчет мәхәлләсенең приговоры нигезендә икенче мулла итеп куелган. Берникадәр заманча уйлый, яңача фикер йөртә торган кеше буларак, ул, күрәсең, Бохарадан ук үзенчә зур планнар корып кайткан. Туган җиренә аяк басу белән үк яшь мулла атасы акчасына мәдрәсә салдыру чарасына керешә һәм 1882 елда үз мәктәбендә балалар укыта башлый. «Мөхәммәдия» дигән исем астында дан казанган мәдрәсә әнә шулай калкып чыккан. Билгеле инде, Казанның «Фәтхулла хәзрәт»ләренә болар ошамый. Шулай бервакыт, Мәрҗани өендә булган кечкенә мәҗлестә кемнәрдер «ул солдат малае» фәлән-төгән дип. Галимҗан мулланы яратмый сөйли башлагач, Шиһаб хәзрәт кырт кисеп туктаткан: «Ул солдат малае булса да, Казанның һәммә имамнарыннан өстен. Аңарга тел озайтмагыз».

---

* Хәзер Тукай урамы.

Ел артыннан ел уза, шәкертләр арта, мәдрәсә киңәя, укыту-тәрбия эшләре камилләшә бара. Хәзрәтнең үзенә зур укымышлы, олуг остаз дигән мәгънәне аңлата торган «дамелля» сүзе аерылмаслык булып ябыша. Шулай дип әйттеңме, исемен-ниен кушып торасы юк. Баруди дигән яңгыравыклы псевдоним-фамилиясенә килгәндә, бусы — нәсел-нәсәбенең Пороховой бистәдә тереклек иткәненә ишарә. «Баруд» — гарәпчә дары дигән сүз.

Казан мөдәррисләреннән беренче буларак, Галимҗан Баруди 1891 елда укырга-язарга өйрәтүдә «ысул җәдит» дип йөртелгән яңа метод кертә һәм «Савадхан» исемле дәреслек-кулланма язып бастыра. Уй-фикер һәм эш-гамәлендә яңарак юл тоту өстенә, кадим-җәдит көрәшенең кызган вакытында бу адымны ясавы Барудиның хәлен җиңеләйтмәгән, әлбәттә. Вәхшиләр арасына килеп чыгып, шулардан очкан уклар астында йорт коручы хәлендә калган дип әйтсәк, шаять хата булмас.

Шактый еллардан соң булган бер вакыйга да әнә шулай уйларга мөмкинлек бирә.

1897 елда агач мәдрәсәсе янып көлгә әйләнгәч, Галимҗан хәзрәт, байлардан акча җыеп, яңа зур мәдрәсә салу чарасына керешә. 1901 елның көзендә, ниһаять, өч катлы мәһабәт таш бина калкып чыга һәм мәдрәсәне ачу вакыйгасы тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Ф. Әмирханның шәкертлек дәфтәренә теркәлгән язмадан күренгәнчә, ул түбәндәгечә узган. Мәҗлескә Казанның зур байлары, хәзрәтләре, хәлфә-укытучылары чакырылган. Мәдрәсә каршындагы рус классларының берсендә учитель булып торучы Һади Максуди котлау өчен сүз ала һәм, кадимчеләргә төрттереп, мондый сүзләр әйтә:

— Алла мөбарәк итсен, тәкъсир. Сез милләткә олуг хезмәт кылдыгыз, күп мәшәкать чиктегез. Без Сезгә булышлык күрсәтүдән бигрәк төрле сүзләр ишеттердек, сүктек, хөседлек * иттек, хурладык. Әмма безнең бу эшләребез Сезне туктатмады, Сезгә тырышлык һәм ныклык кына өстәде.

Ташның кем бакчасына төшкәнен шундук абайлап алган Шакир, Сабир, Йосыф һәм Хисам муллалар тавыш куптаралар:

— Туктат нотыгыңны, зиндикъ **, сөйләмә. Без хөсед тә итмәдек, сүкмәдек тә!

Тантана чәй мәҗлесе белән тәмам була. Әлеге дүрт

---

* Хөседлек — көнчелек.
** Зиндикъ — динсез.

хәзрәт, аштан олы булып булмый дигән мәкальне дә оныtyp, ташлап чыгып киткәннәр.

Шунысы кызык, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең архитектур ансамбле үзе үк ул заманның иске белән яңа тартышын гәүдәләндерә.

Хәзерге Тукай урамындагы 34 нче йорт капкасыннан атлап кергәч тә, уң якка карасагыз, бер генә катлы, кечкенә таш өй күрерсез. Заманында ул югарыда телгә алынган Йосыф ахун Сәгыйтев мәктәбе булган. Шушы өйгә терәтеп салынган (соңыннан кушылып ук киткән) өч катлы зур, мәһабәт һәм зиннәтле бинага игътибар итегез. Бусы «Мөхәммәдия»нең 1901 елда тантаналы төстә ачылган корпусы. Ансамбльнең үзәге булса да, капкадан керми торып, аны юньләп күрә дә алмыйсың.

Эш болай булган икән. Баруди, яңа корпусны планлаштырганда, фасадын урамга чыгарып салу нияте белән, Йосыф хәзрәткә мондый тәкъдим ясаган: мәктәбеңне, тәкъсир, әйдә сүтеп ташлыйк. Яңа бинадан үзең теләгән кадәр мәйдан алып, үзең теләгәнчә дәрес әйтерсең. Ахун хәзрәт башта риза була. Ләкин яраннары киңәшен тыңлаптырмы, соңра кирели. Менә ни өчен «Мөхәммәдия», урамны бизәп тору урынына, эчтә посып калган.

Без киләчәктә күрербез, Йосыф ахун Баруди тормышында гына түгел, бәлки Ф. Әмирхан тормышында да үзенчәлекле урын тотачак. Монда исә Фәтхулла хәзрәт прототибының нәкъ менә шушы Йосыф ахун булганлыгын әйтү белән генә чикләник.

Кара яссылык өстендә соры тап та якты булып күренгән шикелле, Галимҗан Баруди — төрле кыяфәттәге «Фәтхулла хәзрәт»ләр фонында, һичшиксез, прогрессив шәхес. Әмма XIX гасыр ахырының иң алдынгы иҗтимагый фикереннән ул беркадәр ундарак торган. Сәбәпләре, билгеле, күп: Бохарада калыпланган белеме, караш һәм гореф-гадәтләре, уртагасырчылыкка кендекләре белән береккән дин әһелләре йогынтысында яшәүче мәхәллә кешеләренең йөз дүндерү ихтималы, хөкүмәт чиновниклары һәм охранканың мәдрәсәне, мәдрәсә башлыгының һәр адымын күзәтеп торуы. Байлар хакын хаклау мәҗбүрияте үзе генә дә ни тора. Мәдрәсәнең бар чыгымы шулар өстендә. Чыгым исә аз түгел. Яңа гасыр башында инде аның азмыкүпме вазифа ала торган унбишләп хәлфәсе, ярыйсы гына җиһазландырылган тулай торагы, кухнясы, шифаханәсе, врачы, төрле мастерскойлары, сад-бакчасы, ишегалдында хәтта катогы булган. Моңа тагын читтән килгән фәкыйрь

шәкертләрнең тулай торак һәм укыган өчен бөтенләй диярлек түләмәгәнлекләрен өстик.

Әнә шулар барысы бергә Барудины, хәттин ашмыйча, уртарак юл сайларга, үлчәү тәлинкәләрен чәүмәлтмичә, тигезрәк тотар өчен дипломат булырга мәҗбүр иткән.

Ысулы җәдитне кертүе заман өчен, әлбәттә, кыю адым. Әмма бу башлангыч сыйныфларга гына карый. Рөшдия, игъдадия һәм галия бүлекләрендә исә, аз-маз яңарту һәм сипләүләрне искә алмаганда, дәресләрнең эчтәлеге дә, укыту ысуллары да борынгыча кала килгән.

Дамелляның Троицк ишаны Зәйнулла Рәсүлигә кул биргәнлеге, ә соңрак үзенең дә, ишанлыкка дәгъва итеп, шәкертләреннән мөрит җыя башлаганлыгы билгеле. Кем белә, бәлки бусы да дипломатик максаттан эшләнгәндер. Ләкин моның белән ул Казанның иске фикерле байлары күзендә отса да, яңара башлаган яшьләр күзендә нык оттырган.

...1895 елның көзендә Зариф мулланың ике улы — Фатих һәм Ибраһим — әнә шушы мәдрәсәдә укый башлыйлар.

Үзе дә «Мөхәммәдия» шәкерте булган шагыйрь Миргазиз Укмасый ике мәхдүмнең мәдрәсәгә килү-китүләрен истәлегендә болайрак сурәтли.

Кышкы иртә. Нечкә тимер табанлы нәфис чанага җигелгән кара ат мәдрәсә ишек төбенә кар туздырып килеп туктый. Көмеш тәңкә тезелгән эшлия, җиңел күн камыт, тасма дилбегә, нечкә тубылгы дуга...

Толып кигән кучер чана башыннан карга сикерә дә, малайларның тезен каплаган йомшак тирене ычкындырып, төшәргә булыша. Шәһәрчә ыспай киенгән һәм кулларына яхшы сумка тоткан ике мәхдүм ашыкмыйча гына мәдрәсә ишегеннән кереп китәләр.

Көндезге сәгать ике. Әлеге кара ат тагын мәдрәсәнең баскыч төбенә килеп туктый. Кучерны беркадәр көттереп, мәхдүмнәр ишектән килеп чыгалар, бик артык кабаланмый гына матур чанага менеп утыралар. Кучер тирене иплэп кенә тезләренә яба, эләктерә дә чана башына менеп кунаклый. Тасма дилбегәне бер чиертүе була, кара ат, ыргылып, капкадан чыгып китә.

Мәхдүмнәрнең китап-дәфтәр, карандаш-каләм һәм бүтән әсбаплары да җитү икән. Ашаганнары да ләвәш тә сумса.

Авылдан килгән фәкыйрь шәкерткә бәлки Зариф хәзрәт мәхдүмнәренең казы күркә булып күренгәндер, ярты гасырга якын вакытның зәңгәр томаны аша карагач исә,

дөя кошы булып үскәндер. Хатирәнең 1940 елда, Фатих Әмирхан буржуа язучысы саналганда язылган булуын да истән чыгармыйк.

Фатих укый башлаган чакта ук «Мөхәммәдия» дүрт баскычтан торган: дүрт сыйныфлы ибтидаия (башлангыч), дүрт сыйныфлы рөшдия (тулы булмаган урта), өч сыйныфлы игъдадия (урта) һәм галия (югары). Соңгысы башта вакыт ягыннан чикләнмәгән булса да, соңрак өч еллык курс рәвешен алган.

Укыган фәннәреннән чыгып хөкем итсәк, Фатихны ибтидаиянең соңгы сыйныфына утыртканнар дигән фикергә килербез. Беренче хәлфәсе — Таһир Габделхәким улы Мәчкәрәви дигән казый булган. Озын буйлы, киң җилкәле, кара сакаллы, кара сипкел төшкән битле бу кеше, гыйлеме белән аерылып тормаса да, тәрбия эшендә үрнәк булырлык икән. Вәкарь белән, ягъни борын аша тынкышланып сөйли белә, юк кына гаеп өчен дә шәкертләрне, бөтен шартын китереп, чаж-чож суктырырга оста.

Зур мәдрәсәнең зур хәлфәсе шундый булырга тиеш дип белеп, безнең Фатих бик дәртләнеп укый. Таһир казыйның камчысы һәм ата каз кебек ысылдавы аңа бик үк кагылмый. Чөнки сабагын белә, тәртибе яхшы. Өстәвенә, яшькә кечкенә булып, билгеле хәзрәтнең улы да бит әле.

Зирәклек һәм тырышлык бушка китми: еллык шәһадәтнамәсендә, китабәттән (язудан) кала, барлык «фән»нәрдән дә әгъла, ягъни «отлично». Бу фәннәр арасында гарәп сарыфы (морфология) да бар.

Икенче елында, бүтән «фән»нәрдән тыш, нәхү (синтаксис) һәм мантыйк укый башлавыннан чыгып, Фатихның рөшдигә күчкәнлеген чамаларга мөмкин. Еллык шәһадәтнамәсендә ике «тәхсин»нән (яхшы) бүтән билгеләре — тагын «әгъла». Төп хәлфәсе шул ук Таһир казый. Әмма аңа Җәгъфәр Сираҗетдин улы дигән хәлфә өстәлгән.

Өченче уку елында Фатих аеруча дәртләнеп укыган булса кирәк. Барлык «фән»нәрдән дә — «әгъла». Беренче бүләккә лаек булып, «Могаллакате сәбга» исемле китап алган. Бу ел, Таһир казыйдан котылып, риясыз, нифаксыз *, дәрвиш табигатьле һәм йомшак холыклы Җәгъфәр хәлфәнең шәкерте булып киткән.

Дүртенче елында шул ук хәл: тоташ — «әгъла», бүләк. «Фән»нәре, укыган китаплары да инде ни җитте генә түгел: хәдис, викая, кодури. Фатих «Исагуҗи»ны башлавы белән аеруча горурланган булса кирәк. Соңыннан ирония

* Нифак — икейөзлелек.

белән ул болай дип язды: «Фәтхулла хәзрәтнең бу китапны бик тырышып укыганлыгын ишетә идем, мин дә тырыштым һәм, шул тырышлыгым аркасында бер ай укыгач та үземнең «хайване натыйк» * икәнлегемне белдем». Төп чыганагы Платон һәм Аристотель әсәрләренә кайтып кала торган бик борынгы бу мантыйк китабын Фәтхулла хәзрәт кенә түгел, Фатихның бабасы һәм әтисе дә тырышып «кимергәннәр» иде. «Исагуҗи»ны «ашап» чыккач, безнең Фатих та моназыйр, ягъни оста бәхәсче булып китә.

Укучы бәлки игътибар иткәндер, Фатихның «Мөхәммәдия»дә моңарчы укыганнары — дин дә мантыйк. Физика, химия, геометрия кебек фәннәрне әйтеп тә тормастан, тарих, әдәбият, география кебекләрнең исеме дә юк. Игъдадиядә дә, галиядә дә шулай булачак. Хәзергә әле безнең Фатих шулай булырга тиеш, шулай гына була ала, дигән ышаныч белән укый бирә. Бер дә файда алмаган, вакытын бөтенләй бушка уздырган дисәк, хакыйкатьтән шактый читләшкән булыр идек. Гарәп телен тирәнтен үзләштерүгенә дә ни тора! Фатих бу телне чынлап та яратып һәм теләп укыган. Зариф хәзрәт һәм Рабига остазбикә дә тел белүне зур дәрәҗә санаганнар һәм, балаларын тизрәк өйрәтү максаты белән, өйдә гарәпчә сөйләшүне кертергә тырышканнар. Бервакыт шулай Сәгадәт, юынган чагында, 9 яшьлек энесенә «вәһәпте ләкә» дип, калфагын тоттырган. Аннары кире алмакчы була, Фатих бирми:

— Бүләкне кире алмыйлар,— ди.

— Мин сиңа тотып торырга гына бирдем ич.

Шунда малай «вәһәпте ләкә» — «бүләк иттем» дигән сүз дип ярып салган һәм апасы «тотып кына торырга бирәм» дигән җөмләне гарәпчә әйтергә өйрәнгәнгә кадәр калфакны кайтармаган.

«Мөхәммәдия»дә укуының икенче елында ук Таһир хәлфәнең ниндидер гарәпчә китапны укытып чыгаруы да Фатихның гарәбияттә шактый иркен йөзә башлаганлыгы турында сөйли.

Ел артыннан ел уза, «фән» артыннан «фән» артта кала, китап артыннан китап зиһенгә кереп урнаша. Рөшдине сикертебрәк узган кебек, игъдадиядә дә Фатих озак утырмый. 1901 елда инде 15 яшьлек егет кисәген без галиянең әүвәлге сыйныф шәкерте, хәзергечә әйтсәк, беренче курс студенты итеп күрәбез. Фатихның төрле язмалар өчен тота торган шәкертлек чоры дәфтәреннән күренгәнчә, сый-

---

* Хәйване натыйк — сөйләшүче хайван.

ныфташларының һәркайсы аңардан дүрт яисә биш яшькә олы булган.

Фәтхулла хәзрәт дәрәҗәсенә ирешүгә, хәтта аңардан да уздырып җибәрүгә дәртсенгән малайга уйнар өчен вакыт, билгеле, күп калмаган. Җитмәсә, югарыда әйтелгәнчә, ата-анасы Фатихны бистә малайларыннан читтәрәк тотарга тырышкан. «Мөхәммәдия»дә үткәргән вакытның баштагы ике елында, килеп-китеп укыганлыгы сәбәпле, мәдрәсә шәкертләре белән дә аралашмаган дип әйтерлек.

Ләкин ул да бала бит. Яшьтәшләренә азмы-күпме катнашкан, уйнаган да, әмма башлыча баерак гаилә балалары, әти-әнисе йөрешкән мулла мәхдүмнәре белән.

Әмирхановлардагы күңел ачуның бер төре — язларын, үз атларына утырып, боз киткәнне карау өчен Усиягә чыгу. Өелешеп аккан бозларны тамаша иткәч, алар хәрчәүнәгә кереп, пәрәмәчләп, әфлисунлап чәй эчәләр. Җәйләрен самоварлар белән кая булса да урман-яланга пикникка чыгалар.

Һәр җәй саен дип әйтерлек Зариф хәзрәт гаиләсен, пароходка утыртып Чистайга, энесе Нәҗип муллага кунакка алып бара. Мөхәммәтнәҗип Әмирханов — ул вакытларда мәхәллә имамы, шактый зур мәдрәсәнең башлыгы, мөдәррис. Хөкүмәт чиновникларына байтак борчу, мәшәкать тудырган кеше. Аны шәкертләренең рус классына йөрүен тоткарлауда гаепләиләр. Бервакыт хәтта мәдрәсәсен ябу мәсьәләсе күтәрелгән.

Нәҗип хәзрәт шәкертләргә рус теле өйрәтүгә гомумән каршы булган дип уйларга ярамый. Аңа, күрәсең, бу эшне көчләп тагу, казенныйлаштыру ошап җитмәгән. Чистай мөселманнарының фанатиклыгын да исәпкә алган булыр.

Халык училищелары инспекторы Гайев белән Нәҗип мулла тартышы бер ел буе барган. Инспектор чакырта, хәзрәт килми. Чиновник үзе мәдрәсәгә барырга мәҗбүр. Русча бер дә белмәгәнгә салышып, Нәҗип мулла тылмач ярдәмендә сөйләшә. Килешкән булып, тегене җайлап кына озатып җибәрә. Эштә исә үзгәреш юк. Тагын шикаять, тагын Казаннан — усал кәгазь. Аны муллага тапшырырга, аңлатма таләп итәргә кирәк. Бер бара инспектор, ике бара, тота гына алмый бит. Аптырагач, остазына бирергә кушып һәм кулыннан подписка алып, кәгазьне бер шәкерткә тапшыра. Әмма җавап тагын юк. Кат-кат исенә төшерү дә файда бирми... Ниһаять, көннәрдән бер көнне Нәҗип мулланың шәкерте төнге сәгать унбердә, Гайевны уятып, җавап кәгазен китереп бирә. Шул ингче, Гәрәй морзага барып

тоташа торган нәселнең холкы монда да чагылмый калмаган.

Шунысы да мәгълүм булсын: Нәҗип мулла — заманында исеме шактый киң таралган Закир ишан Камаловның кияве һәм варисы. Ишан инде үзе вафат. Кече хатынынн туган бер ир бала һәм тугыз кыз яшәп яталар. Берничәсе инде кияүдә. Фатих белән яшьтәшләре һәм кечерәкләре дә бар.

Зариф хәзрәт гаиләсенең Чистайда вакыт үткәрүе дә бер рәвешлерәк булган. Кунакка бару, кунак чакыру яки ашамлык, савыт-саба, самовар төяп табигатькә чыгу. Нәҗип хәзрәтнең балалары әле кечкенә булганга күрә, Фатихның вакыты күбрәк өлкәннәр арасында үткән. Торабара ул, үзеннән күп олы булса да, Закир ишан улы Ибраһим белән аралаша башлый. Кызлары белән аралашуы хәзергә әле үчекләшүдән ары китми. Хәер, Шәмсениса исемлесенә Фатихның ул чакта ук аерыбрак каравы ихтимал. Әмма шушы кызга гашыйк булачагы, татлы да, газаплы да хисләр кичерәчәге, язмыш аларны аергач, бу кызны гомере буе оныта алмаячагы ул вакытта әле аның башына да кереп чыкмаган...

Ике елдан соң мәдрәсәдә торып укый башлавына да карамастан, Фатих, күпләгән җан дуслары табып, шунда кереп эрегән дип әйтеп булмый. Атнакич җиттеме, әлеге дә баягы, атларына утырып өенә кайтып китә. Ана кеше улларын һәрвакыт юксынгандырмы, атна арасында да, теге яки бу сылтау табып, мәхдүмнәрне килеп алалар. Үсә төшкәч тә, Фатихның сердәш дуслары бик артмаган. Фикер ягыннан күпкә узып киткәнгә, яшьтәшләре, бигрәк тә авылдан килгән шәкертләр белән ул кызык тапмый. Үзеннән олыракларга тартылса да, баш иеп бармый, бәйсезлеген сакларга тырыша. Аннары узышу, җиңешү дигән нәрсә дә бар бит.

Ләкин бу әле Фатих кырга чыгып үскән ялгыз агач булып яшәгән дигән сүз түгел. Аңа якынаерга, сердәш булырга теләүчеләргә кытлык юк. Күп белә, кыюлыгы бар, сүзгә оста, мәзәкчел. Үзе күреп, әтисе даирәсендә ишетеп яисә китаптан укып белгән нәрсәләрен хыял катыштырып сөйләп җибәрсә, шәкертләр авызларын ачып тыңлыйлар. Тик ул әшнәлеккә дәгъва итүчеләрне ераграк тотарга, арада күпмедер бушлык калдырырга тырыша. Авторитетын танып, сүзсез буйсына, чәнечкеле сүзләргә җәберсенми торган бер-ике шәкерткә генә Фатихның дусты дигән исем казанырга насыйп булган. Шуларның берсе — Ризван

Ибраһимов-Алуши. Буе озынлыгын искә алмаганда, бу шәкерт бер ягы белән дә аерылып тормаган. Соңыннан да гадәти укытучы булудан ерак китми. Шушы егет күп еллар буе Әмирханның ахирәт дусты булып калачак, араларында туктаусыз хат йөреп торачак, ара ераклыгына карамастан, күрешүләр дә булачак. (Хәер, үзенә тиңнәргә салкын караганы хәлдә, даһиның гадәти кешеләрне дус итүе тарихта сирый торган нәрсә).

...Безнең Фатих әнә шул гыйлеме, шул фикер-карашлары һәм гадәт-холкы белән, XIX гасырны тәгәлләп, яңа гасырга аяк баса. Коръәнгә, аның тәфсирләренә, хәдискә тирән үтеп керүе, ислам диненең тарихын һәм фәлсәфәсен үзләштерүе шулай ук зарарга гына булды дип әйтә алмыйбыз. Бит ул татар дөньясындагы искелеккә, туңлыкка, схоластика һәм догмаларга каршы баш күтәрәчәк, тора-бара яңалык өчен көрәшүче яшь көчләрнең җитәкчесенә әвереләчәк. Моның өчен дошман кулындагы коралның хасиятен, көчле һәм зәгыйфь ягын яхшы белү бик тә мөһим.

Әмма иң әүвәл Фатихның үзе изге санап йөргән нәрсәләргә бүтән күзлектән каравы, акны карадан, караны актан аера башлавы, фәнчә әйтсәк, дөньяга карашының үзгәрүе кирәк иде. Бусы да үзен озак көттермәде.

## 2

Бер гасырның тәгәлләнеп килүе, яңа гасырның ишек шакуы гына түгел иде бу еллар. Гасыр ахырында Россиядә азатлык хәрәкәтенең яңа, пролетар этабы башланды. Сан һәм сыйфат ягыннан гаять үскән эшчеләр сыйныфы самодержавие һәм капитализмга каршы көрәшне әйдәп баручыга әверелде. Җирсезлек, салымнарның күплеге һәм капитализмның авылга да үтеп керүе нәтиҗәсендә бөлгенлеккә төшә барган крестьяннар да тавышларын ишеттерә башладылар. Бүтән демократик катлаулар, шул исәптән, укучы яшьләр дә хәрәкәткә килде.

Революциянең якынлашып килүен сиздерә торган галәмәтләр иде болар. Казан да читтә калмады. 1898 елда Казан эшчеләре әүвәл мәртәбә 1 Майны бәйрәм итәләр. 1901 елда революцион эшчеләрнең һәм студентларның беренче политик демонстрациясе булып уза.

Давыл күтәреләсен хәбәр иткән җилләр чагыштырмача тын култык булып ятучы татар тормышын да хәрәкәткә китерә. Татар эшчеләре, рус иптәшләренә ияреп, кайберләре исә оештыручылар сыйфатында, көрәшкә кушылып

китәләр. Учительская школа укучылары арасында марксизм идеяләре белән кызыксынучылар килеп чыга.

Казан мәдрәсәләренең урта гасыр ташыннан салынган калын диварлары да инде көрәш авазларының, азатлык фикерләренең үтеп керүенә тоткарлык итә алмый.

Яңалыкка аеруча сизгер мәдрәсә, әлбәттә, «Мөхәммәдия» иде. Яшь Әмирханны Фәтхулла хәзрәт белән арасын өзүгә китергән сәбәпләрне, барыннан да элек, әнә шуннан, мәдрәсәнең үз эченнән эзләргә кирәк. Фатихка кадәр дә анда фикер, тын хәлендә калмыйча, азмы-күпме хәрәкәт иткән. Аек карашлы хәлфәләр һәм укыган сабагыннан канәгатьләнмичә, татар дөньясының кимчелекләрен күрә башлаган шәкертләр килеп чыккан. Түгәрәк сыман нәрсә оештырып, чыш-пыш итеп сөйләшү, фикер алышулар башланган, кулъязма матбугат кебек нәрсә барлыкка килгән. «Мөхәммәдия»дә укыган чагында, мәсәлән, Хөсәен Ямашев «Тәрәккый» исемендә газета чыгаручыларның берсе була. Галиәсгар Камал да бу газета эшенә якыннан катнашкан. Алар белән Фатих аралашканмы, юкмы, без белмибез. Үзеннән өч-дүрт яшькә олы Борһан Шәрәф белән якын мөнәсәбәткә кергәнлеге, аның йогынтысында күп нәрсәгә күзе ачылганлыгы билгеле. «Шушы елларда мин Сәгъди әфәнде (хәзер «Вакыт» мөхәррирләреннән) белән дусландым. Ул әдәбият гарәбия мөхибләреннән * һәм мәдрәсәдәге схоластикага иң әүвәл каршы тора башлаган шәкертләрдән берсе иде».

Күп еллардан соң, төгәл әйтсәк, 1908 елда Ф. Әмирхан болай дип язды: «...моннан ун ел элек мин, яңа язу танып җиткән бала, «Тәрҗеман» газетасының почтадан алынганын дүрт күз белән көтеп, баштагы игъланнарыннан башлап, ахырдагы имзаларына кадәр укып чыгып, үзем йөри торган мәктәпнең тышындагы дөньядан бәгъзе эшләр белән белешләнә вә татар мәгыйшәтенең нoксаннары тугрысында бик гайре мөгайян һәйәттә ** булса да, фикеремдә бер нәрсә калдыра алдым». («Яңа язу танып җиткән бала» дип язса да, Фатих ул вакытта инде рөшдидә укыган).

Әмирхановларның газетага мөнәсәбәтенә кагылышлы мондый риваять яши. Зариф хәзрәт газетаны улыннан укытырга ярата икән. Менә ул аштан соң, авыз тирәсен сөртеп алып, җиңелчә бер кикереп куйгач, диванга килеп мендәргә таяна да Фатихка эндәшә:

---

* Әдәбият гарәбия мөхибе — гарәп әдәбиятын сөюче.
** Гайре мөгайян һәйәт — бик анык булмаган рәвештә.

— Яле, улым, җәридәне укып җибәр әле.
— Кай төшеннән укыйм?
— Башыннан укы.
— Нумира 144, мөхәррәм әл хәрам 27 сәнәи һиҗрия 1324...
— Алары кирәкми...
— Кайсысы кирәк соң, тәкъсир?
— Астанрак укы,— ди әтисе.
— Баш өсте, тәкъсир,— ди дә Фатих җитди кыяфәт белән берәр сәүдә фирмасының игъланын укырга керешә.
— Анысы да кирәкми!
— Ярый алайса.

Фатих, коръән укыгандагы кебек итеп, көйләп, сузып баш мәкаләне укырга тотына. Зариф хәзрәт көләргә дә, ачуланырга да белмичә, газетаны алып, үзе укырга керешә. Фатих газетаның бу санын, билгеле инде, башыннан ахырына кадәр укып чыккан, шуңа күрә шуклыкка бирелә.

Югарыда телгә алынган дәфтәренә Фатих шәкерт түбәндәге сүзләрне теркәп куйган: «1901 елның 2 үктәбер яуме * чәһаршәмбедә остазымыз дамеллядан шәргы гакаид башладык».

Бу фәнне өйрәнүдә ул вакыт төп кулланма булып «Гакаидел-Нәсифи» исемле китап хезмәт иткән. Төп өлеше — XII гасырда яшәгән Нәсифинеке. Әмма бу китап Тәфтазани (XIV) тарафыннан язылган шәрехе белән атаклы. «Галләмә», ягъни галимнәр галиме булып танылган Тәфтазани мөселман дөньясында шулкадәр зур дан казанган ки, аның һәр сүзе энҗе-мәрҗән урынына йөртелгән, һәр әйткәне иң соңгы хакыйкать саналган.

Ф. Әмирханның «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе» исемле мәкаләсеннән без түбәндәге юлларны укыйбыз. «Еллар үтте, мин, мәдрәсәдә укып, гакаидханлык дәрәҗәсенә ирештем. Кирәк «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дәге барыш вә кирәк хәлфәләремнең бәгъзеләренең дәлаләте белән, мин Мәрҗанинең «Әлхикмәтел-балига»сын да моталага кыла ** башладым».

Гакаид һәм шуннан соң ук «Әлхикмәтел-балига»... Җир йөзе, коймак сыман яссы булып, бик зур үгезнең мөгезенә эленеп тора дип ышанган баланың учительдән «җир ул карбыз кебек түгәрәк һәм кояш тирәсендә әйләнеп йөри» дигән сүзләрне ишеткәч гаҗәпләнүен йөз мәртәбә

---

* Яум — көн.
** Моталәга кылу — уку.

арттырсак, Фатихның шул вакыттагы кичерешләрен беркадәр күз алдына китерә алырбыз.

Мәсьәлә аңлашылсын өчен, укучыдан гафу үтенеп, үткәнгә таба бер чигенеш ясап китәргә мәҗбүрмен.

Ислам диненең төп өйрәтмәләре, мәгълүм булганча, Коръәнгә һәм хәдисләргә тупланган. Алланың барлыгы, берлеге, дөнья, аның яратылышы, ахыр заман, җәннәт, тәмуг һ. б. турындагы догмалар да шунда (бусы — игътикад), кешеләр арасындагы хокук мөнәсәбәтләре (бусы — фикъһы) һәм әхлак кагыйдәләре дә шунда. Барысы бергә буталган, бер-беренә керешкән, очы-очка ялганмый. Коръән һәм хәдисләр дөньяга килгәч, аларны системага салу, бер рәвешле итеп аңлау һәм аңлату ихтыяҗы туа. Озын-озын шәрехләр языла, бөтен бер «фән» тармагы барлыкка килә. Коръән һәм хәдисләргә дөрес аңлатма бирү өстендә эшләүчеләрне мөҗтәһидләр (иҗтиһад итүчеләр, ягъни көч куючы, тырышучылар) дип йөрткәннәр.

Менә бер заман эш тәмам була, барысы да үз урынына утыртыла, какшамас канун һәм догмалар барлыкка килә. Мөселман кешегә баш ватасы калмый. Шул канун һәм догмаларга сүзсез ышанырга һәм шулар кушканны җиренә җиткерергә генә кирәк. Мөҗтәһидләр заманы узды, иҗтиһад монкарыйз (бетте, юкка чыкты), диләр.

Гасыр артыннан гасыр уза тора, мөдәррис һәм хәлфәләр әлеге мөҗтәһидләр, борынгы дин галимнәре китапларында әйтелгәннәрне бердәнбер хакыйкать санап, шәкертләренә өйрәтәләр, соңгылары ятлый, йота бирәләр.

Менә XVIII гасыр килеп җитә, аны XIX йөз алыштыра. Зирәк акыллы аерым шәхесләр абайлап алалар: изге канун һәм догмалар заман рухына, тормыш таләпләренә туры килми икән ич. Бүтәнчә була да алмый: борынгы китапларда Коръән һәм хәдисләргә феодализм тәртипләрен ныгыту максатыннан чыгып аңлатма бирелгән. Хәзер исә ашын ашаган, яшен яшәгән бу җәмгыять җимерелеп бара, алмашка капитализм килә. Аерым акыл ияләре диннең төп чыганакларын кайтадан җентекләп өйрәнергә, борынгы изге китаплар белән чагыштырырга, догма һәм кануннарны тәнкыйть иләге аркылы үткәрергә керешәләр һәм ныклы нәтиҗәдә киләләр:

— Юк, иҗтиһад монкарыйз түгел!

Татарлардан бу фикерне беренче башлап мәйданга ыргыткан кеше Габделнасыйр Курсави булса, һәрьяктан нигезләп, ныклы дәлилләр белән ныгытып, дөньяга тараткан зат — Шиһабетдин Мәрҗани.

Әмирханнар гаиләсендә Мәрҗани, абруйлы шәхес бу-

ларак, һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән телгә алынган. Сабый чагыннан ук Фатих түбәндәге сүзләрне ишетеп үсә:

— Мәрҗани яхшы атлар җигә, мәһабәт туннар кия, кибаранә * кыяфәт тотарга ярата иде...

— Мәрҗани вакытының бик мәшһүр Кышкар дамеллаларына, Күл буе мәдрәсәсе мөдәррисләренә бер дә әһәмият бирми, аларны наданга саный иде...

— Мәрҗани гавамнан берәүгә дә тәлинкә тотмый гына түгел, бәлки алардан, хәтта зур байларыннан үзенә ихтирам таләп итә иде...

— Мәрҗани булган мәҗлесләрдә дошманнары ачыктан-ачык аңа һөҗүм итәргә җөрьәт итә алмыйлар иде...

Көннәрдән бер көнне әнисе Фатихка, беркемгә дә әйтмәү шарты белән, Мәрҗанинең рәсемен дә күрсәткән.

Фатихның хыялында акрынлап буй җитмәс зур, олы хәзрәт сурәте җанлана, аның өчен маяк, идеал барлыкка килә.

— Их, шул Шиһап хәзрәт шикелле имам булырга!

Инде менә уналты яше белән бара торган безнең Фатих Мәрҗанинең «Әлхикмәтел-балига»сын укып чыкты. Тәфтазаниның шәрехенә язылган хашия, ягъни аңлатмага аңлатма икән ул. Шиһап хәзрәт анда «галләмә»не элеп алып селкеп сала, һәр сүзен көчле дәлилләр ярдәмендә юкка чыгара һәм нәтиҗәдә Тәфтазанины гади бер компилятор итеп калдыра. Яшь Әмирхан күзендә Мәрҗани хәзер бар имамнардан өстен имам гына түгел, бәлки олы язучы, мөхәррир булып калка. Тәфтазани һәм башка борынгы авторитетлар бөтенләй кичерәеп калалар, моңарчы укыган һәм укып ята торган дин сабакларының кыйммәте бермә-бер кими.

Юмористик тәрҗемәи хәлендә Ф. Әмирхан болай ди: «Бу елларда мин гарәп вә төрек әдәбияты белән шөгыльләнә һәм һәрбер яңа чыккан татар китапларын укып чыга башладым. Горфи ** дәресләрем булган «Гакаид» вә «Тәһзиб»ләрне Фәтхулла хәзрәт белән очрашканда сүгешә алырга җитәр кадәр генә укый идем».

Гарәп әдәбиятыннан кемнәрне укыгандыр, без белмибез. Борынгы поэзиясе белән куәтле булганга, шагыйрьләрен, аерым алганда, Мәгаррины укыган дип уйларга мөмкин. Шәкертлек дәфтәренә берничә гарәпчә шигырьне теркәп куюы да шул фикерне куәтли.

---

* Кибаранә — олы, горур булып.
** Горфи — гадәти.

Төрек әдәбиятына килгәндә, гасыр ахырына таба татар яшьләре игътибарының шул якка юнәлүе гомуми күренеш иде. Мәгърифәтчелек хәрәкәтеннән үсеп чыккан татар әдәбиятының алга барышы, ныгуы өчен читтән ярдәм һәм үрнәк кирәк булды. Мәгърифәтчелек реализмы юнәлешендә беркадәр алданрак формалашкан һәм тел җәһәтеннән татарларга якын булган төрек әдәбияты нәкъ менә шул вазифаны үтәде. Н. Кәмалның «Зәваллы чуҗык» пьесасының Г. Камал тәрҗемәсендә «Кызганыч бала» исемендә дөньяга чыгуы яисә Тукайның төрек әдәбияты белән кызыксынып китеп, башлангыч шигырьләрен күбесенчә шул телдә язуын гына искә төшерик. Төрек әдәбиятыннан кемнәргә күңел баглаганын Фатих атап әйтми. Әмма 1902—1903 елларда язган хатларының һәм әлеге дәфтәрендәге язмаларының төрекчәгә якын телдә язылганлыгын төрек әдәбияты тәэсире итеп карарга кирәк.

Татар әдәбиятыннан кемнәрне һәм нинди әсәрләрне укыганлыгын чамаларга мөмкин.

Барыннан да элек, билгеле инде, Каюм Насыйри. Еш кына «Урыс Каюм» дигән кушамат белән йөртелгән бу галим турында да Фатих яшьтән үк ишетеп үсә. «Мөхәммәдия»дән ике генә адымда яшәгән Насыйриның үзен күргәләвенә, хәтта таныш булуына шикләнмәскә мөмкин.

Шушы елларда булса кирәк, Фатих базарда К. Насыйриның «Ләһҗәи татари» исемле аңлатмалы сүзлеген сатып алган. Хөҗрәсендә бик бирелеп укып утырганда, шәрикләреннән берсе — таза гәүдәле, гаять тәкъвә мишәр егете килеп керә. Нәрсә укыганы белән кызыксынып, китапны алып карый, һәм күзе «йомрык» дигән сүзгә төшә. Аңлатмасын укыгач, ул, авызын чалшайтып һәм зәһәрләндереп, зур йодрыгын Фатихның борынына тери дә болай дип куя:

— Аны китаптан укып беләсе юк. Вата, күр.

Каюм Насыйриның вафаты уңае белән Фатих әлеге дәфтәренә болай дип язып куйган: «Халык милләткә хезмәт итүчеләрнең кадерен белмәгән бер заманда хезмәт иткән бу зат бик күп китап иясе булса да, язганнарының кадере соңгы заманнарда гына беленә башлады».

Олы буын мәгърифәтчеләре эшчәнлекләрен тәгалләргә өлгермәделәр, яңа буын җитеште. Күбесе әдиплек каләме тотып мәйданга атылды. Менә Риза Фәхретдинов һәм аның «Сәлимә» белән «Әсма»сы. Менә Ф. Кәриминең «Җиһангир мәхдүм», «Салих бабай», «Шәкерт һәм студент» хикәяләре. Менә «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» һәм «Яфрак асты, яки Мәкәрҗә ярминкәсе» повестьлары авторы

Ш. Мөхәммәдев. Менә Г. Камал һәм аның «Бәхетсез егет»е белән «Өч бәдбәхет» пьесалары. Менә «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясен һәм «Себер тимер юлы» поэмасын биргән М. Гафури.

XIX гасырның икенче яртысында башланып, яңа гасыр кергәндә куәтләнгән уяну дәвере, барыннан да элек, милли уянуга кайтып кала иде. Мәгърифәтчеләр татарларны алдынгы милләтләр янына куеп күрсәтәләр дә әйтәләр: әнә карагыз, алар кая киткән дә, без кайда торып калганбыз! Моның сәбәбе, диләр, борынгы гореф-гадәтләргә ябышып ятуыбыз, схоластикага чумып, яңа фикергә юл куймавыбыз, дөнья өчен кирәкле белем һәм гыйлемнәрдән йөз чөерүебез. Арада кыюрак һәм зирәгрәкләре милли яктан изелүне дә бер сәбәп итеп күрсәтәләр.

Мәрҗанинең көр тавышыннан уянып киткән безнең Фатих та колагына кергән яңа тавыш, яңа сүз, яңа фикерләрнең мәгънәсен төшенеп алгач, үзен татар милләтенең бер улы хис итеп, аның артталыгына ачына, алга җибәрү, мәртәбәлерәк урынга күтәрү теләге белән яна башлый.

Менә 1902 елга караган тагын бер язмасы. Яшь Әмирханның уй-фикер һәм хис-тойгыларын чагылдыру белән бергә, ул киләчәктә аңардан куәтле публицист һәм әдип чыгачагыннан хәбәр бирә.

8 июнь көнне Тихвинский урамында туксаннан артык йорт янган. Ике чиркәү һәм бер мәчеткә дә ут кабып, соңгысы күмергә әйләнгән хәлдә, чиркәүләрне коткарып калганнар. Чөнки, дип яза Фатих, руслар һәм мөселманнардан җыелган акчага асрала торган пожарный команданың насослары, чиркәү сүндерү белән мәшгуль булып, мәчет янына килеп тә карамадылар.

Манарасы гөрселдәп авар алдыннан мәчетнең зарланып әйткән сүзләре гүя ки аермачык ишетелгәндәй була:

— И, әсир татарлар! Миңа әсирлектән капкан ут безнең эчегезгә ялкын кабызыр дисәм дә, күрәм, башымның иелүенә, аемның җиргә кадалуына гына ярдәм итәрсез ахры.

Бу сүзләр, ди Фатих, эчемдә ялкын кабызды, һәм күзләрем су сипмәсәләр (ягъни яшь коймаса), ул мине һәлак итәчәк иде.

Янгын «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә дә килеп җитә, игъдадия бинасына ут каба. Булачак әдипнең сүзләрен бу урында тәрҗемә итмичә китерергә тиеш табам. Түбәсенә кызыл әтәч кунган мәдрәсәгә эндәшеп, Фатих, янәсе, болай дигән: «И бостаны гыйльмемез и җәннәте әмәлемез, и дәлиле һидаятемез, и галәме тәрәккыемез, әсирлек уты синең

башыңа һәм тукынды, сәмаватә чыкмыш башыңи каплаярак (бер сүз танылмый.— *И. Н.*) йибәрде». Мәдрәсә аңа түбәндәгечә җавап биргән: «И монтазар һәдия, и талибе тәрәккый *, имин ул ки, ошбу әсирлек уты капламыш башы, бер вакыт улачак ки, хөррият байраклары каплаячактыр».

Милләт кайгысы, милләтне тәрәккый иттерү фикере бу елларда инде гомум хезмәтендә ат уйнаткан шәхесләрне генә түгел, бәлки азмы-күпме күзе ачылган шәкертләрне дә биләп ала. Ничек, нинди юл белән? Бу мәсьәләне милли азатлык өчен көрәш белән бәйләп караучылар берәмсәрән очраса да, социаль азатлык өчен көрәшкә китереп терәүчеләр әле күренми. Иң зур күпчелек, XIX гасырдан ук килә торган идеяне анык бер рәвешкә китереп, әлеге сорауга болай дип җавап бирә:

— Мәдрәсәләрне ислах итү юлы белән! Дөнья көтәр өчен кирәкле гыйлемнәр белән коралланган кешеләр җитештерми торып, милләт тәрәккый итмәячәк.

Милли азатлык мәсьәләләре турында уйлый башлаган яшь Әмирхан өчен дә бу фикер, бу идея якындагы маяк, әгәр шулай әйтергә яраса, программа-минимум булып китә, һәм ул ислах өчен көрәшкә баш-аягы белән чума.

Шушы ук вакытларда Фатихның тормышында аның сукмагын зур юлга алып чыгуда мөһим роль уйнаячак үзгәреш була. Архивтагы автобиографиясеннән без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Бер заман рус теле белән дә танышырга вакыт җитте. Әтинең тизрәк минем муллалыкка имтихан тапшыруымны теләве сәбәпле, гражданлык законнары муллаларның русча грамоталы булуларын таләп иткәнгә күрә, мин өч ай буе татар учителеннән рус теле өйрәндем».

«Татар учителе» дигәне шактый еллар элек Казан учительская школасын тәмамлап Яңа бистәдәге рус классында укытып яткан Миңлегаффар Шәфиев булса кирәк. Кул астында гына учитель барында нигә әллә кайдан эзләп йөрергә?

Тел өйрәнүгә булган табигый сәләтенә дә карамастан, Фатихка рус теле авыр бирелгән («...рус теле миңа читен һәм кызыксыз тел булып тоелды»). Чөнки ул бу эшне

---

* Бостаны гыйлем — гыйлем бакчасы; җәннәте әмәл — өмет җәннәте; дәлиле һидаять — дөрес юлга керергә юл күрсәтүче; галәме тәрәккый — прогресс дөньясы; сәмавәтә — күкләргә; монтазар һәдия — көтелгән бүләк; талибе тәрәккый — алдынгы шәкерт.

соң һәм бөтенләй диярлек тел белмәгән килеш башлады. Яңа бистә — тоташ татар төбәге, «Мөхәммәдия»дә рус теле фән итеп кертелми, үзара сөйләшү гел татарча, я гарәпчә. Аннары рус теленә ул, кирәге чамалы булган өстәмә эш итеп карап, этисе кушканга гына, теләми һәм яратмыйча кереште.

1901 елда Әстерханга барып кайтуы уңае белән дәфтәренә теркәлгән юлъязмасындагы түбәндәге сүзләргә алданырга ярамый: «Сембергә кадәр Симбирский корпуста укучы рус шәкертләре илә мөсахәбә итеп килдем». Белмим, өч айлык гыйлем саф рус телендә әңгәмәләшү өчен җитте микән... Сөйләшү ярым русча, ярым татарча, ярым төрекчә (әлеге укучылар төрек офицерлары белән дә аралашалар икән), ә күбрәк халыкара телдә — кул ишарәсе ярдәмендә булган дип уйларга кирәк.

3

«1901 елда Казандагы «Мөхәммәдия» шәкертләре арасында «Иттихад» исемле яшерен бер җәмгыять төзелде. «Иттихад»ның төп максаты Казандагы барлык шәкертләрне берләштереп, мәдрәсәләрен ислах итүгә чакыру иде. Җәмгыятьнең әгъзалары Фатих Әмирхан, Ризван Алушев, Гали Могыйнов, Хаҗи Түләки, Бари Сәедгалиев һәм Сибгат Шәриф улы иделәр. Бу җәмгыять «Әль-мәгариф» исемле яшерен гәзитә чыгарып, аның мөхәррире Фатих, язучысы (секретаре) Ризван иде. Фатих ул вакытта буйга кечкенәлеге белән баладан аермасыз булса, яше дә 14—15 ләрдә генә иде».

Ризван Ибраһимов-Алуши истәлегеннән китерелгән бу өзек шунда ук Ф. Әмирханның «Егерменче гасырның әүвәлге еллары» дигән аңлатма белән басылган «Милләт тәрәккый иттерү» (1908) исемле хикәясен хәтергә китерә.

Хикәянең төп каһарманы Хөсәен — җәдит мәдрәсәсендә гакаидхан. Икенче ел инде «Тәрҗеман»ны яздырып алып укый. Яңа чыккан китапларның һәркайсын күздән кичереп бара.

Бу персонажда яшь Әмирхан үзе төсмерләнә түгелме? Ары таба китик.

Хөсәен фикеренчә, милләтне тәрәккый иттерү өчен, мөселманнарны берләштерергә, бер фикергә китерергә кирәк. Моны исә түгәрәкләр, җәмгыятьләр ярдәмендә генә тормышка ашырырга мөмкин. Хөсәен, фикере ачыла төшкән шәкертләргә сүз сала башлап, алты әгъзасы булган бер җәмгыять оештыруга ирешә (Р. Алуши истәлегендә

«Иттихад» җәмгыятенең әгъзалары да — нәкъ алты шәкерт).

Җәмгыятьнең беренче мәҗлесе билгеләнә һәм «Сарай» кунакханәсеннән номер алына. Менә мәдрәсә «шагыйре» Йосыф һәм «дин галиме» Мөхәммәтҗан гаять җитди кыяфәт белән килеп керәләр, Хөсәенгә сыңар кул биреп (бу инде яңалык) күрешәләр дә, ят кеше юклыгына ышангач, kәләпүшләрен салып куялар (бусы да тәрәккыйпәрвәрлек галәмәте). Калган өч әгъза да килеп җитә. Арада берсе — мишәр шәкерте — гадәттән тыш озын буе белән аерылып тора.

Алты прибор һәм 18 пәрәмәч китертелә. Коридордан куркыныч нәрсә кętелмәгәнлек билгеле булгач, эш башлана. Хөсәеннең кереш сүзеннән соң җәмгыятькә исем бирү мәсьәләсе карала. Кызу-кызу бәхәстән соң Хөсәен тәкъдиме уза: «Әл-иттихад» (Р. Алушида да — «Иттихад»).

Мәҗлеснең төп өлешендә алдан әзерләп килгән доклад, мәкалә һәм шигырьләр укыла. Барысында да бер үк мауэуг: милләтне тәрәккый иттерү, ислах һәм иттихад. Һәркайсы, ахырданрак сүз алып, иптәшләрен шаккатырырга тели. Бигрәк тә үзсүзле мишәр гыйлем ягыннан бик үк аерылып тормаса да, үзенә игътибар таләп итә. Бүтәннәр басып укыганда, ул миссионерлар белән дәһриләрне хур итеп ташлаган докладын утырып укый һәм моны, мәзәк кулланып, нигезләнгәндәй итә:

— Мин дә басып укер идем дә, башларегезне сузып карәргә кирәк булыр дип куркәм.

Мәҗлес тәмам булу белән хикәя дә бетә. Җәмгыять әгъзалары, канәгать булып, һәм моннан соң инде милләт тәрәккый итәр, итми хәле юк дигән ныклы ышаныч белән тараладар.

Хикәя сатира дәрәҗәсенә җитә язган юмор белән сугарылган. Бүтәнчә була да алмый: әсәрен язган вакытта Ф. Әмирхан инде, дөньяга карашында зур сикереш ясап, мәсьәләләргә бөтенләй бүтәнчә карый иде. Ә менә 1905 елгы революция шаулап узуга һәм иҗтимагый фикернең яңа баскычка күтәрелүенә дә карамастан, кыска ыштаннан калып, милләтне тәрәккый иттерү турындагы әллә кайчангы фикерләрне әйләндерә-әйләндерә сөйләп йөрүчеләр байтак. Шундыйларның кабыргаларына төртми ярамый.

Шулай да Казандагы шәкертләр хәрәкәтенең юлбашы нигездә хикәядәгечә булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. «Иттихад» җәмгыятенең инициаторы, билгеле инде, Фатих. Түгәрәкнең беренче утырышы хикәядәгечә, әмма җитдирәк һәм эшлеклерәк узган. Арада калкыбрак күренергә теләгән,

эчтән генә үзен Фатихка көндәш итеп тойган бер-ике шәкерт булырга мөмкин. Ләкин, малай кыяфәтле булуына карамастан, Фатихның өстенлеге һәм авторитеты инде бәхәссез. Шуңа күрә дебатсыз-нисез генә җәмгыятьнең секретаре итеп ул сайлана. Исем биргәндә дә аның тәкъдиме уза. Курку-сагаю белән доклад, мәкалә һәм шигырьләр укыла (хур булмагаем). Шул ук утырышта кулъязма газета чыгарырга карар ителәә. Редакторлыкка Фатихны сайлыйлар.

Без, дип яза М. Укмасый, «түбәнрәк шәкертләр үзебезгә аерым кружок төзегән идек. Безнең кружок башында... Фатих Әмирхан тора иде». «Иттихад» һәм бу түгәрәк икесе бер үк түгелме? Түгел. М. Укмасый раславынча, мәдрәсәдә түгәрәкләр сыйныф-бүлек принцибыннан чыгып оештырылганнар. «Иттихад» исә гомуммәдрәсә түгәрәге булып мәйданга килгән. Аның әгъзалар саны бик тиз үсә башлый һәм, 1904 ел кергәч, 75 кә җитә. «Җәмгыятькә башлык булу белән бергә, энергиясе ташып торган Фатих, күрәсең, игъдадия түгәрәген дә алып барган.

«Иттихад» җәмгыятенең төп максаты, төп бурычы — мәдрәсәдәге уку-укыту тәртипләренең яраксызлыгын шәкертләрнең аңына сеңдерү һәм аларны ислах өчен актив көрәшкә әзерләү. Күп төрле рәвештә, күп төрле чаралар ярдәмендә алып барыла бу эш.

Фатих шәкертләрне эчтән генә түгел, тыштан яңартуга да зур игътибар биргән. Башта үзе үрнәк күрсәтә. Бүтән шәкертләр чабуы тубыкка җиткән, изүе каплаулы казаки белән йөргәндә, Фатих тезенә җитәр-җитмәс тора торган тужурка киеп ала. 1903 елга таба ул, мәдрәсәдән тыштагы мәдәни мәҗлесләрдә катышу өчен, костюм, ак яка, манжетлар, галстук, бант, штиблет булдыра, бераз соңрак борынына пенсне эләктереп куя. (Замандашы: «Фатих саукүзенә пенсне киде», дисә дә, моңа шикләнеп карарга туры килә; аның чаклы укысаң, синең дә эшең күзлеккә калыр иде.)

Читек-кәвеш, казаки-җиләнгә каршы көрәштә Фатих, үгет-нәсихәт һәм юмор-сарказм белән генә чикләнмичә, казакины алыштыра торган кием уйлап чыгарган. Изү төймәләрен каптырып бетерсәң, казакидан аерылмый диярлек. Өске төймәләрен ычкындырып, күкрәк тирәсен як-якка ачып җибәрдеңме, җәйге пальто була да куя. Фәкыйрь шәкертләр өчен нәкъ үзе! Фатихтан һәм энесе Ибраһимнан күрмәкче, күп шәкертләр әнә шундый кием киеп йөри башлыйлар һәм, җөббә — пәлтә дигәнне кыскартып, исем дә кушалар: җөкпә.

Шәкертләрне Европа мәдәниятенә якынайту һәм халык

җырлары, халык көйләре ярдәмендә милли тойгы тәрбияләү максаты белән Фатих һәм фикердәшләре әдәби-музыкаль кичәләр үткәргәннәр. Шундый кичәләрнең 1904 ел гыйнварында булып узган берсен М. Укмасый болайрак тасвир итә.

Мәдрәсәнең урамга таба сузылган очында кеше тормый, дәрес үткәрелми торган бер бүлмә бар. Парҗылыткыч кертелмәгәнгә күрә салкын һәм иң ерак булганга, аратирә карцер хезмәтен дә үтәгәнгә, аны «Сахалин» дип йөрткәннәр. Ниндидер гаепләре өчен Фатих та анда утыргалап чыккан икән.

Кичә әнә шул бүлмәдә уздырыла. Фатих, кайдандыр табып, граммофон алып килгән. Шәкертләрнең кесә ягы такыр булу сәбәпле бик үк сату итә алмаса да, буфет та оештырылган.,

Кичәнең җаны, рух бирүчесе — Фатих. Чыгыш ясаучыларны, мәзәк катыштыра-катыштыра мәҗлескә тәкъдим итүче — конферансье дә ул. Граммофонны борып, тәлинкәләрен алыштырып торучы һәм шәкертләргә танцы кагыйдәләрен өйрәтүче дә ул. Ут борчасы кебек тыз-быз чапканда, сикергәндә, биегәндә нечкә чылбыр белән пиджак якасына тоташтырылган пенснесы борыныннан төшеп-төшеп киткәнен күз алдына китерү кыен түгел.

«Иттихад» җәмгыятенең тагын бер эш формасы — шул заманның күренекле милләт хәдимнәрен утырышка чакырып тыңлау.

Соңрак «тарихи кыңгырау» дип йөртелә башлаган Рәшит казый Ибраһимов — XIX гасырның ахырына таба тарлык хакына, татар милләтен алга җибәрү, мәртәбәлерәк урынга күтәрү хакына көрәш мәйданына атылган шәхесләрнең гаять кызыклысы. Бу тынгысыз җан Россиянең татарлар яши торган төбәкләрен йөреп чыга, чит илләрне гизә, кая барса, анда тәрәккый фикерләрен ялкынланып сөйли, эшкә чакыра, китап яза. 1900 елда ул татарча журналларның یاралгысы итеп санарлык «Мирьат» (көзге) исеме астында брошюралар чыгара башлый: менә карагыз үзүзегезгә, күрегез, нинди хәлдә яшисез.

Әнә шул зат үзенең кыңгыравын шәкертләр колагына чыңлатмый каламы соң! «Ул үзенең речьләрендә,— дип яза М. Укмасый,— мәдрәсәләрнең яраксызлыгын, анда укыла торган мантыйклар урынына физика, математика, җәгърәфия, төрек һәм татар теле, фәлсәфә, коръән тәфсире кертергә тиешлекне, Европа милләтләренең алга китеп, безнең йокы хәлендә икәнебезне, ислам гыйлеме саф вакытта гарәпләрнең шәрыктан гарепкә кадәр үсүләрен, татарларның

да шанлы вакытлары булганлыгын сөйләп безне таң калдыра иде».

Рәшит казыйны чакырып китерүнең Фатих эше булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. «Милләт тәрәккый иттерү» хикәясендә мондый сүзләр бар: Хөсәен «...зыялылар мәҗлесеннән дә калмый, Сәгыйть (ягъни Рәшит.— *И. Н.*) казыйның Казанга һәр килүендә номерасына барып күрешә вә яңа фикерләр тыңлап кайта».

«Зыялылар мәҗлесеннән дә калмый» дигән сүзләргә игътибар итик. Унбиш-уналты яшьлек Фатих, димәк, милләт хадимнәренең һәм каләм ияләренең ара-тирә булып торган киңәш-табыш мәҗлесләренә үтеп керә башлаган, кайберләре белән танышырга һәм якын мөнәсәбәт урнаштырырга тырышкан.

Журналистика өлкәсендәге беренче адымнарына карата Әмирхан үзе болай дип яза: «Ундүрт яшьләремдә инде мәдрәсәдә кулъязма, нәшер ителә торган яшерен журналларга бик фәлсәфи, чикылдаган фәлсәфи мәкаләләр яза торган идем». Кулъязма журнал да чыгарылганмы, чыгарылса, кем тарафыннан, нинди исемдә, әллә инде юмористик автобиографиясендә әдип газета һәм листовкаларны ирония белән журнал дип атыймы — без моны белмибез. Мөхәррире Фатих булган «Әл-мәгариф» газетасының да нөсхәләре табылганы юк. Төрекчәләтеп язылган һәм шушы газетада чыккан мәкаләсеннән бер өзек кенә Алуши истәлегенә теркәлеп калган. Аны, хәзерге телгә күчереп, бу китапка да кертеп җибәрик. «Тәрбия итү күркәм әхлакны баланың гадәткә кергән сыйфатларына әверелдерү дигән сүз. Бу исә ике яшеннән җиде яшенә кадәр була. Чөнки ул вакытта әле балага бозык әхлак йокмаганга күрә, яхшы әхлакка өйрәтү, аны күңеленә сеңдерү бик тә мәшәкатьсез эш. Ә инде бу вакытны уздырсаң, бала начар гадәтләргә биреләчәк, һәм аны шулардан биздерү, шуларның киресе булган яхшы әхлак сыйфатларын кертү гаять кыен булачак. Димәк, балага тәрбия бирү, ана кулында чактагы яшь вакытларында була. Әнә шуңа күрә кызларыбызның дәртле һәм тырыш милли галимә итүгә кадәр укыту тиеш» (1902, 19 май).

1903—1904 уку елында Фатих һәм фикердәшләре чәчкән орлыклар тишелеп чыга: Казан мәдрәсәләре тарихында беренче буларак «Мөхәммәдия»дә кузгалышлар башлана. «Көннәрдән бер көндә,— дип яза Ф. Әмирхан,— без мөдәррис хәзрәтләреннән мәдрәсәгә фөнүне җәдидә * һәм фәл-

---

* Фөнүне җәдидә — яңа фәннәр.

сәфәи диния кертүне таләп кылдык». Дамелля петиция белән таныша, уйлана һәм, кырт кисеп кире кагарга базмыйча, яңа низамнамә төзи дә «озын бер хөтбә» сөйләгәч, шуны шәкертләргә игълан итә.

Мондый ярты-йорты чаралар шәкертләрнең алдынгы өлешен, бигрәк тә әгъзалары җитмештән узып киткән «Иттихад» җәмгыятен канәгатьләндерми, билгеле. Яңа ел кергәч, ислах өчен көрәш тагын да көчәеп китә. Менә Баруди кулына яңа петиция килеп керә. Уен-муен гына түгел икән бу, эшләр җитдиләшеп бара. Нишләргә?

Бохара җимеше булуына карамастан, дамелляны шәкертләренең теләкләрен аңламаслык дәрәҗәдә кара кисселгән хәзрәт дип булмый. Тарих, җәгърәфия, математика кебек дөньявый фәннәр кертүгә дә, дин фәлсәфәсе һәм хәдисләр укытуга да каршы түгел ул. Тик бер кыенлыгы бар: тиз арада гына шул фәннәрне укытырдай кешеләрне кайдан табасың? Тапкан тәкъдирдә, мәдрәсәне асраучы байлар моңа ничек карар?

Алай да уйлап карый хәзрәт, болай да, киңәш-табыш итә һәм мондый бер маневр кулланырга була. Ярар, ди, киләсе көздән сез теләгән фәннәр кертелер, үзем дин фәлсәфәсен укыта башлармын.

## 4

Фатихның дөньяга карашы ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Рәсми яктан да инде ул галия шәкерте генә түгел. Югары сыйныфның иң сәләтле шәкертләрен укытучылык эшенә тарту традициясе буенча Фатихны хәлфә итәләр. Бер хатында, юмор катыштырып, үзе дә бу турыда әйтә: «Камилән хәлфә булып җиттем. Борыннан сөйләшергә генә өйрәнәсе калды» (1904, 25 декабрь). Икенче бер чыганактан аның рөшдидә география укытканлыгы аңлашыла.

Менә сыйныф ишеге кинәт һәм киң генә ачыла да җитез адымнар белән Фатих килеп керә. Калын алсу иреннәре чак кына елмая, үткен карасу күзләре көлемсери. Мәзәк катыш кереш сүздән соң нәүбәттәге темасын башлый. Очлы таягын харита буйлап йөртә-йөртә сөйли, укыганнарыннан чыгып, үзе белгәнчә, үз системасы буенча сөйли. «Күз алдында,— ди шәкертләреннән берсе,— Сена елгасы, Эйфель манарасы, Латин кварталы, Елисей кыры белән мәһабәт Париж каласы баса, томанга өретелгән Темза буендагы соры Лондон калка». Истәлекче күп арттырмаган дип уйлыйсы килә. 1902 елда ук инде Фатих мәгълүм дәфтәрендә сыйныфташларының берсенә — гадәттән тыш озын буйлы

һәм күсәкнең күсәге булган шәкерткә биргән характеристикасында «Эйфель» сүзен кулланган иде. («Буе — Эйфель манарасы кадәр, акылы чыпчык авызындагы су чаклы».)

1902—1904 елларда инде Фатих мәдрәсәдән тыштагы дөньяда да шактый гына күренекле фигура булып китә.

Казанның тәрәккый пәрвәр купецы Сөләйман Аитов йортында ул күптән инде үз кеше. Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри белән якын мөнәсәбәттә булган һәвәскәр тарихчы Мөхәммәтҗан Аитов гаиләсендә туып буй үстергән Сөләйман без ишетеп белгән гадәти кибетче-сәүдәгәр түгел. Аның эше — зур сәүдә фирмаларына арадашлык хезмәте күрсәтү. Көнчыгыштан партия-партия чималны Көнбатышка, Көнбатыш товарларын Көнчыгышка озата. Казанда, Оренбургта һәм Кокандта конторалары бар.

Сөләйман әфәндenең уй-нияте, күрәсең, табыш арттыру белән генә чикләнмәгән. XIX гасырның ахырыннан башлап мәгариф эшенә аның шактый акча сарыф иткәнлеге мәгълүм. С. Аитовның мондый эшчәнлеге, табигый, охранканы сагайткан. Күзәткәннәр, тикшергәннәр һәм карашлары ягыннан ул кадетларга якын тора дип, беркадәр тынычланганнар.

С. Аитов киңәшләре һәм акчасы беләнрәк кенә катышса, аның җәмагате Фатиха ханым Аитова татар кыз балаларын укыту, агарту һәм һөнәргә өйрәтү эшенә бөтен гомерен багышлый. Бу вакытларда ул — үрнәк итеп йөртелгән кыз балалар мәктәбе мөдирәсе. Гаять тырыш, энергияле, уйлаганын таш яуса да ахырына җиткерә торган хатын. Ире Сөләйман юкка гына аны «Батый» дип йөртмәгән. Атка утырып чыкса, дилбегәне үзе тота, кызу чаптырып йөрергә ярата икән. Кызлар укыту арбасының дилбегәсен дә ул нык тоткан булыр.

Әнә шул Фатиха ханым Петербургта халык мәгарифе министры иптәшенә (урынбасарына) кадәр җитеп, 1915 елда беренче татар кызлары гимназиясе ачуга ирешә.

Фатих бу гаиләдә ничек үз кеше булып киткән? Беренчедән, Иске бистәдә яшәгән Сөләйман купецның Яңа бистәдәге рус классының почетлы караучысы булуы һәм акчалата ярдәм итеп торуы Зариф хәзрәт белән дә якын мөнәсәбәттә булганлыгы хакында уйларга мөмкинлек бирә. Икенчедән, С. Аитовның уллары Исмәгыйль һәм Ибраһим шул ук «Мөхәммәдия»дә укыганнар. Беренчесе Фатихның сердәш дусты булып китә, икенчесе, шәкерте сыйфатында, география дәресләренә йөри.

Аитовлар аркылымы, эллә инде бүтән юл беләнме, яшь Фатих Казанның күренекле гаиләләреннән берсе — Терегуловлар семьясына да үтеп кергән.

Ибраһим Терегулов, Уфа ягы морзалары нәселеннән булып, башта Казанның ветеринария институтын, аннары университетын тәмамлап чыга. Яңа гасырга кергәндә, без аны Татарская учительская школада (моннан соң аны, татарчалаштырып, КТУМ дип атарбыз) табигать укытучысы итеп күрәбез. Татарларны агарту, культура-мәгариф эшләрендә дә ул җиң сызганып катнашкан.

Ф. Әмирхан катышкан гаиләләрдән тагын 1900 елга, ягъни үлгәнчегә кадәр КТУМ инспекторы, икенче төрле әйткәндә, директоры булып торган Шаһбазгәрәй Әхмеров, Син-Цзянда Россия илчелегендә эшләгән Шәрәфетдин Габитов (бу вакытта инде дөньяда юк) һәм надворный советник Гали Саинов гаиләләрен күрсәтергә мөмкин.

Без бу гаиләләрнең аерым вәкилләренә әле әйләнеп кайтырбыз. Хәзер исә Ф. Әмирханның тормышында шактый зур роль уйнаган тагын бер даирәгә тукталып китик. Ул да булса, әлеге КТУМ, ягъни Казан татар укытучылары мәктәбе. Хөкүмәтнең азчылык милләт балаларын русча укыту турындагы карарын тормышка ашыру йөзеннән рус теле укытучылары әзерләү өчен 1876 елда ачылган бу мәктәптән 25—30 ел эчендә йөзләгән татар егетләре укып чыгып, мәгариф, фән, әдәбият, сәнгать өлкәләренә һәм шулай ук революцион хәрәкәткә зур өлеш керттеләр. Мәктәпнең укучылары, кагыйдә буларак, кичәге шәкертләр иде. Школаны абитуриентлар белән тәэмин итүдә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе дә күренекле урынны тотты дисәк, шаять, хата булмас. Х. Ямашевның, мәсәлән, «Мөхәммәдия» җиләнен салып ташлап, КТУМ формасын киеп җибәргәне турында әйтелгән иде. Яңа гасыр башлангач, андыйларны инде дистәләп санарга мөмкин. Кичәге шәкертләр мәдрәсә белән араны өзеп бетермиләр, килеп-китеп йөриләр, яшьтәшләрен теге яки бу уңай белән школага китерә башлыйлар.

КТУМның татар яшьләре укыган иң алдынгы уку йорты булганлыгы, идеяләрнең, аерым алганда, марксизм тәгълиматының аңа тизрәк һәм җиңелрәк үтеп кергәнлеге, гасыр башында инде социал-демократик түгәрәкләр барлыкка килгәнлеге мәгълүм. Без әле күрербез: 1905 елгы революция башлангач, аеруча кызып киткән шәкертләр хәрәкәтенең авангардында барган «Мөхәммәдия» укучылары социал-демократлар йогынтысында булганнар. Моның төп сәбәбен Учительская школа белән «Мөхәммәдия» арасындагы тыгыз бәйләнештән эзләргә кирәк.

Фатихның «школьниклар» белән дуслашып, КТУМ бусагасын атлап кергән шәкертләрнең беренчеләреннән булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. Ул бервакыт хәтта школага күчә язып калган. Хәер, бу турыда соңрак.

КТУМның тагын бер тарихи хезмәтенә — татар яшьләрен театр сәнгатенә якынайту юнәлешендәге эшләренә тукталып китәргә кирәк.

Школада рус теле һәм рус әдәбиятын укыту чагыштырмача яхшы куелган була. Драматик әсәрләрне өйрәнгәндә рольләргә бүлеп укыту инде күптән гамәлдә. Бу алым, бу ысул, күрәсең, укучыларны спектакль кую фикеренә китергән. Фатих белән бер вакытта «Мөхәммәдия»дә гыйлем алып яткан, соңрак «Әльислах» газетасының рәсми редакторы булып киткән Вафа Бәхтияров яза: «Һәр кыш Татарский учительский школада пасха, рождество бәйрәмнәрендә берничә тапкыр рус телендә театр уйнала торган иде. Ел саен мәшһүр «Ревизор»ны уйнамый калмыйлар иде... «Мөхәммәдия» шәкертләре тамашачы булып бара иделәр».

Үрнәкчедән күрмәкче дигәндәй, шәкертләр дә кабынып китеп, татарча театр уены уйнау фикеренә киләләр. Иң элек кем башына килгән бу фикер, кем аны тормышка ашырырга керешкән? «Без,— дип яза В. Бәхтияров,— театр уйнау фикерен Гыймад хәлфә Нугайбиковка һәм Фатих Әмирханга белдердек. Гыймад Нугайбиков башта каршы торды. «Дамелля белсә, яхшы булмас, барыбызга да бер-бер хәл булмасын дип куркам»,— диде. Фатихка белдерү белән үк хуплап каршы алды, үзенең катышачагын белдерде». Кем ул «без»? В. Бәхтияров үзе һәм аның белән бер сыйныфта укыган һәм школадагы спектакльләргә йөргән берничә шәкерт дип уйларга кирәк. Болар башлаган була, Фатих кушылып киткән була...

Татар театры идеясе, руслар әйтмешли, күптән инде һавага сеңгән, баш өстендә әйләнә. XIX гасырның беренче яртысында рус театры бусагасын атлап кергән татарлар ук инде (билгеле, өстен катлау вәкилләре): «Эх, безнең татарда да шундый уеннар булсын иде»,— дип хыялланганнар. Гасырның икенче яртысында, мәгърифәтчелек хәрәкәте куәт алгач, театрның кирәклеге үзен бигрәк тә нык сиздерә башлаган. «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», «Комедия Чистайда» пьесаларының мәйданга килүе әнә шуны күрсәтә. Бу вакытларда инде «аристократлар» гына түгел, бәлки урта катлау вәкилләре дә рус театрына теләп йөри башлыйлар.

Мәгърифәтчеләр әзерләгән рухи азык белән тукланып буй үстергән Фатих аларның театр турындагы уй-хыял-

ларын колак яныннан гына үткәреп җибәрә ала идеме? Әлбәттә, юк. Шуңа күрә аны кемнәрдер башлаган эшкә кушылып китүче итеп кенә күрү дөрес булмас иде. Ул, һичшиксез, бу эшнең дә үзәгендә булган, бу эштә дә тон биргән. Моны В. Бәхтияровның үз язмасыннан да чамаларга мөмкин.

Менә Гыймад хәлфә, Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров һәм тагын берничә шәкерт, әлеге «Сарай» номерына җыелып, спектакль кую турында киңәш коралар. Нәрсәне, кайда һәм кайчан уйнарга? «Бичара кыз»ны ди берсе, «Бәхетсез егет»не ди икенчесе. Соңгысына тукталалар. Ләкин пьеса сәхнә таләпләренә җавап биреп җиткерми. Нишләргә? «Нугайбиков һәм Фатих,— ди Бәхтияров,— «Бәхетсез егет»нең кайбер җирләрен төшереп калдырырга, кайбер җирләренә арттырулар ясарга өсләренә алдылар» (күренә ки, тагын Фатих!). Әнә шул килеш «ремонт ясалган» пьеса буенча «Сарай»да берничә репетиция үткәрелгәч, театр уенынын көне һәм урыны тәгаен ителә. Декорация һәм костюмнар әзерләнә.

Ниһаять, көткән көн килеп җитә. 1903 елның декабре. Иртәгә җомга дигән көнне кич, дамелля һәм хәлфәләрнең зур мәҗлескә китүләреннән һәм шәкертләр кайсы кая таралганга, мәдрәсәнең бөтенләй диярлек бушап калуыннан файдаланып, өченче кат коридорында сәхнә сыман нәрсә әмәллиләр, чаршау коралар һәм тамашачы сыйфатында катнашкан 15—20 шәкерткә «Бәхетсез егет»не уйнап күрсәтәләр. Башкаручыларның менә кайберләре: Ибраһим Әмирханов (Закир), Хәлил Әбелханов (Кәрим бай), Касыйм Габдуллин (Җәмилә). Вафа Бәхтияров (Сәгыйть Сабитов), Солтан Рахманкулов (Әхмәт), Габдрахман Мостафин (Гайшә).

Укучы игътибар иткәндер, уйнаучылар арасында Фатих юк. Аның эше — суфлерлек һәм грим салу. Режиссер кем? Белмибез. «Артистларның» әлеге махсус режиссер кирәк булганлыгын аңлау дәрәҗәсенә ирешмәгән булуы да ихтимал. Бу эшне азмы-күпме Фатих башкарган дип уйларга туры килә. Бит ул пьесаны сипләп чыкты. Репетиция вакытында да киңәш бирми калмас. Суфлерлек итүе дә кәгазьдә язылганны «артистларга» җиткерү белән генә чикләнмәгәндер. Өстәвенә, бу вакытта инде Фатих үзе — чын «артист», мәдрәсәдән тыштагы «труппа» куйган спектакльдә роль башкарган кеше.

1904 елның апрелендә, Барудиның авырып ятуыннан файдаланып, тагын бер спектакль күрсәткәннәр. Мәдрәсә эчендә уйнау мөмкин булмый башлагач, бу вакытта

«Мөхәммәдия»дә укып йөргән, ә киләчәктә күренекле партия-совет работнигы булып үсәчәк Мәхмүтләрдә, Яңа бистәнең Вахит мәэзин өендә берничә тапкыр уйнаганнар. «Репертуар» да байый, «Бәхетсез егет»кә, «Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» өстәлә.

Хәер, беренче спектакльнең инициаторы Фатих булмаска мөмкин. Соңгы еннарда да тирләп-пешеп чапмавы ихтимал. Чөнки ул мәдрәсә һәвәскәрләренә зур өмет багламый. Беренчедән, мәдрәсәдә тиешле шартлар юк, икенчедән, хатын-кыз рольләрен дә егетләр башкарырга тиеш. Шулай да күңелләрен суытмый, катнаша, булыша: дәртләре кузгалган икән, әйдә маташтырсыннар.

1903 елда университет, ветеринария институты, югары курслар, гимназия һәм реальное училищеда укый торган бер төркем татар-башкорт егетләре һәм кызлары оешып алалар да, Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары белән берлектә татар әдәбиятын өйрәнү максаты белән эшкә керешәләр. Аннары татар телендә өй спектакльләре куя башлыйлар. Тора-бара түгәрәкнең эшчәнлеге политик төс ала.

Беренче рәсми утырышлары Шаһбазгәрәй Әхмеров йортында булып, Мулланур һәм Нәби Вахитовлар, Әминә Тегрегулова, Суфия, Сара һәм Ильяс Әхмеровлар, Зәйнәп Габитова, Гайшә Богданова, Фатыйма-Зөһрә, Зәйнәп һәм Солтан Саиновлар, Әхнәф Мамлеев һәм Сөләйман Чанышевлар катнашкан. Һәр атнаның шимбә көнендә әлеге дүрт гаилә өендә чиратлашып җыела башлыйлар. Әгъзалар өстәлә тора. Мәдрәсәдән Фатих, Гыймад Нугайбиков һәм Гарифҗан Мостафин килеп кушыла.

Унҗиде-унсигез яшьлек Фатих — мәдрәсә шәкерте — бу даирәдә үзен ничек тоткан? Ишек катындарак, урындыкның кырыена гына утырып, яртылаш русча сөйли торган ул морза кызларына, ялтыр төймәле студентларга исе китеп, сокланып карап тормаганмы?

«Урталыкта» романының 8 һәм 9 бүлекләрендә «Шимбә» түгәрәгенең Сөләймановлар өендә узган бер мәҗлесе тасвир ителә. Яңа спектакль куярга әзерләнәләр. Иң элек мәҗлестә катнашучыларның икесе белән танышыйк: беренчесе — Шәриф. Әсәрдән күренгәнчә, ул элеккеге мәдрәсә шәкерте. Хәзер — газетчы һәм «модага кереп бара торган» язучы. Урта буйлы, чандыр. Куе кара чәчле, кылыч борынлы. Муенында зур кара бант. Хәтфә паласлар, йомшак урындык һәм кәнәфиләр арасына кереп югала торган йомшак, акрын тавыш белән сөйли. Һәр сүзендә дип әйтерлек юмор, ирония.

Икенчесе — гамәлдән бигрәк хыялда үзен куркыныч революционер итеп күреп, шапырынып йөрүче Саматов. Күп сөйли, сөйләп бетергәч, тыңлаучысына җиңгән сыман карап, борыныннан «кеңкых» дигән тавыш чыгарып куя.

Спектакль өчен сайланган пьесаны укырга керешәләр. Бөтен шартын китереп, Шәриф укый. Саматов борын җыерып, кыбырсып утыра: р-р-революционный эш урынына сафсата белән шөгыльләнәләр, янәсе. Аннары түзми: журнал ала да чыштырдатып актара-актара, укыган булып утыра башлый. Шәриф укуыннан бүленеп, йомшак, ягымлы тавыш белән өй хуҗасының улы Мөхәммәткә эндәшә:

— Синең иске журналларың күп иде, матурым. Шулардан берәр экземплярын кунакларга өләшеп чыксаң, алар да күркәмлек өчен укып утырырлар иде.

Шәриф белән Саматов арасында тагын бер инцидент булып ала. Куелачак спектакльдән килгән акчаны нәрсәгә тоту турында сүз башлангач, Мөхәммәт университеттан чыгарылу алдында торган ике фәкыйрь студентка бирергә тәкъдим итә. Саматов исә политик гаеп өчен төрмәдә утыручылар файдасына тотарга кирәк ди дә, төкерек чәчәчәчә, бу кешеләрнең халык файдасы өчен җәфа чигүләрен исбат итәргә керешә. Аны тыңлап бетергәч, Шәриф, кулларын чалбар кесәсеннән чыгарып, өч мәртәбә шапылдата да болай дип куя:

— Яшә, Саматов туган! Син сөйләмәгән булсаң, бу халык төрмәдәге политическийларны медаль алыр өчен кереп утырганнар дип уйлап йөргән булыр иде.

Шәриф образында Ф. Әмирхан чалымнарын абайлау кыен булмаса кирәк.

Дөрес, романдагы вакыйгалар 1906 елга карый. «Шимбә»челәр инде өй спектакльләре куйганнар, хәзер исә ачык, публичный спектакль әзерлиләр.

1903 ел башында Фатих, «Шимбә» түгәрәге бусагасын атлап кергәч, азмы-күпме җайсызлык хис итми булмас. Әмма ул сиздермәскә, үзен иркен һәм хөр тотарга, түгәрәкнең тулы хокуклы әгъзасы итеп күрсәтергә тырышкан. Бу вакытларда Фатих беренче рольләрне башкармаса да, өченче, дүртенче рольләрдә дә торып калмаган.

Роль дигәннән, 1904 елның 20 февраль тарихлы хатында Фатих мондый сүзләр яза: «Студентлар вә гимназисткалар илә үткән ел башында татар лисанында ике уен уйнадык. Берсе — «Кызганыч бала», берсе — «Гыйшык бәласе». Мин «Кызганыч бала»да Хәлил булып уйнадым, «Гый-

шык бәласе»ндә Габдесамат әфәнде булып уйнадым. Халык тарафыннан шаян * тәхсин улынды».

Ничек башкарган бу рольләрне Фатих, нинди буяулар кулланган, тамашачыда нинди тәэсир калдырган, без моны белмибез. Игътибарны җәлеп иткәне шул: унҗиде яшьлек егет ике очракта да шактый өлкән яшьтәге кеше булып уйный. Беренче пьесада ул — төрек бәге, гаилә башлыгы. Икенчесендә — егет булып җиткән яшь бәкнең хәлфәсе. Әтисен, Сөләйман байны һәм бүтән гаилә башлыкларын күзәтүдән кала, баритон тавышы да ярдәмгә килгән дип уйларга кирәк.

«Шимбә»челәр даирәсендә Фатих, характерына хас рәвештә үзен тигез һәм хөр итеп тоткан дисәк тә, эчтән кимсенергә һәм язмышын каргарга җитди бер сәбәп булган. Ул да — русчасының зәгыйфьлеге. Әнә бит студент һәм гимназисткалар рус телендә татарчага караганда да остарак сөйләшәләр. Чиста итеп үз ана телендә сөйләргә теләгән гимназистканың, башлаган җөмләсен бүлеп: «Ходаем, татарча ничек була соң?» — дип өзгәләнеп куюы Фатихны елмайта да, сокландыра да, ачындыра да. Аларның бит әле руслардан дус-ишләре, әшнәләре дә бар. Болар белән очрашырга туры килгәндә Фатихның хәле тагын да мөшкелләнә.

Хөкүмәт мәктәпләрендә укучы «шимбә»челәрнең табигать фәннәреннән генә түгел, бәлки социаль фәннәрдән, шулай ук Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары тарихыннан әллә ничаклы нәрсә белүләре да Фатихны уйландырмый калмаган. Дөрес, бу яшьләр шәрыктан килгән гыйлемдә Фатих белгәннең меңнән бер өлешен дә белмиләр. Әмма Россия мәмләкәтендә яшәгән татарлар Көнбатышка таба йөз белән борылган бер чорда бу зур юаныч түгел.

Нишләргә? Билгеле инде, рус телен ныклап торып өйрәнергә кирәк. Белем хәзинәсенә ачкыч — шул. 1903 елда Фатих әнә шундый фикергә килә («Бу көннәрдә русча укымак сададында ** торам, алла ни язмыштыр», 19 май) һәм, архивтагы автобиографиясеннән күренгәнчә, ниятен тормышка ашыра башлый. «Зур кыенлык белән булса да, мин аңардан (әтисеннән — *И. Н.*) тагын бер өч ай русча укырга рөхсәт алдым».

Зариф хәзрәт уенча, имтихан тотып указ алыр өчен Фатихның русчасы бик җиткән. Шуннан артыгы, аны бүтән юлга кертеп җибәреп, атаның күңелдәге хыялларын җиме-

---

* Ш а я н — лаек.

** С а д а д — аек караш, уй-исәп.

реп ташлавы мөмкин. Бу бер. Икенчедән, учитель яллап, бу кирәкмәс эшкә акча тотарга туры килә.

Картның курыкканы чынлап та тормышка аша башлый. 1904 елның җәендә Фатих, энесе белән берлектә, ике ай буе Самарада (хәзер Куйбышев) ниндидер курста укып кайткан. Шул ук елның көзендә — этисе рөхсәте беләнме, рөхсәтсез генәме, моны без белмибез — аның, китап-дәфтәрләрен күтәреп, тагын учительгә йөргәнлеге мәгълүм. Бу укытучысы китапта әле урын алачак студент Сергей Николаевич Гассар булган дип уйларга нигез бар.

Фатих Әмирханның тагын бер сыйфаты шул: читтә йөреп кайтырга, сәяхәт итәргә ярата. Ел саен, җәй килдеме, Чистайга китеп бара. 1903 елгы сәяхәтендә инде Закир ишан улы Ибраһимга ул үз тиңе итеп карый башлаган. Хәер, соңгы бер-ике елда аны Чистайга Нәҗип хәзрәт гаиләсе һәм Ибраһим Камалов гына тартмаган. Анда бит уналты яшен тутырган Шәмсениса туташ та бар...

Ярар, Фатихның «Мөхәммәдия»дәге хәл-әхвәлен яздык, мәдрәсәдән тыштагы даирәләрдә дә күрсәттек. Бит әле аның Яңа бистәсе, туган йорты, ата-анасы бар. Мәдрәсәдә торып укыса да өенә еш кайтып йөри, кунып та кала. Әмма соңгы вакытта бу хәл үзенә элеккегедәй рәхәтлек бирмәгән кебек, ата-анасына да бик үк шатлык китерми башлый. Чөнки ата белән угыл арасы бозылып бара, Фатих бик тиз һәм бик нык суллашты, ата исә бер урында торып калды, димәк, аралары ерагайды.

Зариф хәзрәт бәлки, Фатихның кайбер эшләренә күз йомып, булган хәл белән килешер дә иде. Ләкин ул Казанның могтәбәр байларыннан, дус-иш муллаларыннан, бигрәк тә Галимҗан Барудидан сүз ишетеп тора: тый улыңны, хәзрәт, урыс булып бетте. Фетнәче, шәкертләрне аздыра. Патшага каршы бара торган студентлар шайкасына кергән.

Үгетләп тә карый хәзрәт, куркытырга да азаплана. Кая ул! Әллә кайдан китереп, әллә ничек кенә әйләндереп әйтә дә, көлке хәлгә төшкәнеңне сизми дә каласың.

Өч ай буе учительгә йөреп сабак алгач, 1903 елның җәй ахырында булса кирәк, Фатих болай дип белдерә:

— Мәдрәсәне ташлыйм, Учительская школага күчәм!

Зариф хәзрәтнең өстенә бозлы су сиптеләрмени! Олы улын бабаларының эшен дәвам иттерүче итеп күрү хыяллары чәлпәрәмә килә түгелме? Тиз кабынып китә торган үзсүзле хәзрәт кырт кисә:

— Моннан соң син миңа ул түгел, дүрт ягың кыйбла!

Энисе, Рабига абыстай елый башлый, ярсып китеп, һуштан яза.

Характер ныклыгы ягыннан бер дә калышмый торган Фатих бәлки әтисе сүзенә карап та тормас иде. Әмма сөекле әнисе дә, ире ягыннан торып, улының бу карарына каршы төшкәч һәм моны шулай авыр кичергәч, Фатихка язмышка буйсынудан бүтән чара калмый.

Күңеле белән яңалыкка тартыла торган ананы Фатихның чәч җиткереп, костюм киеп, галстук бәйләп йөрүе дә, шәкертләргә утаман булып китүе дә, каланың мәшһүр зыялы гаиләләренә катышуы да аз борчыган булыр. Аны иң изгәне — ата белән угыл арасының бозылып китүе. Ир хакы да бар, бала да газиз. Бер кулы белән картына, икенчесе белән улына ябышкан, якынайтмакчы, килештермәкче. Тегеләр исә, бичара ананы урталай өзәрдәй булып, ике якка тартылалар.

Конфликт гаилә эчендә генә калмый. Фатихның төс-кыяфәте, өс-башы, үзен тотышы, эш-гамәле Фәтхулла хәзрәт яраннарының күптән инде саруын кайната башлаган. Фатихның гайбәтен сату, атасына әләкләү белән генә чикләнмичә, алар турыдан-туры һөҗүмгә күчәләр. Фатих зарарына кылган гамәлләренең барысын да без белмибез. Әмма берсен — иң әшәкесен Әдип үзе теркәп калдырган.

1904 елның көзендә була бу. Фатих атнасына берме-икеме тапкыр шәһәрнең «рус ягына», учителенә дәрес тыңлатырга йөри. Димәк, Болак күпере аркылы чыгарга кирәк. Көннәрдән бер көнне шул тирәдә клиентлар көтеп йөри торган урам кызы Фатихка тагылып ала да, дөньяда нинди әшәке сүз бар, берсен дә калдырмыйча, хурлый башлый. Әллә ни чаклы җир ияреп барып, сүгә дә сүгә. Икенче тапкырында да әлеге кыз каршы ала, өченчесендә дә... Бу хәлдән гаҗиз булып, Фатих бүтән күпердән йөри башлый. Әмма фахишә аны тагын эзләп таба. Күпмедер вакыттан соң бу сәер, ямьсез вакыйганың хикмәте ачыклана. Әдипнең үзе әйтүенчә, «Казанның иң фахиш, иң хулиган байларыннан берсе «Печән базары»нда болай дип мактанган:

— Чукындырдым бит Зариф мулланың теге чукынчыгын: ул кяфергә хәзер Болак күпереннән үтеп йөрергә дә калмады инде».

...1904 ел тәмам. Маяктан-маякка күчә-күчә, дәртләнеп, ялкынланып яшәгән безнең Фатих, киләчәккә зур өметләр баглап яңа, 1905 елның ишеген шакый. Аны тагын да зуррак вакыйгалар, кайгы-шатлыклар, яңа маяклар көтә.

*3 булек*

# ҖӘМӘГАТЬ ХАДИМЕ БУЛЫРГА ТЕЛӘП

## 1

Фатихның 1905 ел 4 мартта язган хатында түбәндәге сүзләр бар: «Монда, иптәш, Казан кайный да тора. Һәртөрле яңа вакыйгалар тулып ята». «Канлы якшәмбе»дән соң үзәктә күтәрелгән революция дулкыны Казанга тәгәрәп килеп җиткән көннәр бу.

Барыннан да элек революцион социал-демократлар җитәкчелегендә эшчеләр хәрәкәткә килә, забастовка көрәше башлана.

20 январь көнне, мәсәлән, Алафузов фабрикасының җеп эрләү цехыннан 70 ләп хатын, эшләрен ташлап, фабрика ишегалдына чыгалар да эш вакытын киметү, хезмәт хакын арттыру, штрафларны бетерү турында таләп куялар. Ул да булмый, йөздән артык ир килеп кушыла. Төшке аштан соң яшерен оешма әгъзалары (арада Казан университеты студенты Скворцов та бар) эшчеләрне забастовкага өндиләр, агитациягә бирелмәүчеләрнең фабрикага үтеп керүенә тоткарлык ясыйлар. Скворцов җитәкчелегендә бер төркем, цехтан цехка кереп йөреп, үгетли, оялта. Нәтиҗәдә фабрика туктап кала.

21 январьда да станоклар хәрәкәткә килми. Ике йөзләп эшче бүтән заводларда эшне туктату нияте белән Бишбалтага юнәләләр. Ләкин аларны атлы стражниклар каршылый. Яңадан Ягодный бистәсенә кайталар. Фабрика тирәсе халык белән тулы. Забастовкачыларны таратырга, «котыртучыларны» кулга алырга теләгән стражникларга таш һәм таяклар белән коралланып каршы торалар.

Татар эшчеләре ничек? Алар үзләрен ничек күрсәткәннәр? «Пролетарская революция» дигән җыентыкта бер автор болай ди: «Алафузов эшчеләре арасында татар эшчеләре иң алдынгы элемент булып чыктылар. Рус эшчеләренә караганда нык эксплуатацияләнгән, җәберләнгән татар эшчеләре эш ташлауларда, хәрәкәтләрдә һәрвакыт авангард булып бардылар». Татарларның активлыгы һәм кыюлыгы күбрәк яшерен җыелыш барган чакта сакта тору, ораторларны полиция кулыннан йолып алу, стражник яисә казакларга таш ату кебек эшләрдә күренгән, әлбәттә. Әмма, сан ягыннан азрак булса да, татар эшчеләре арасында стачка комитеты әгъзлары да, РСДРП(б) членнары да

байтак. Алафузов заводы вакыйгалары уңае белән кулга алынган унҗиде эшченең өчесе, мәсәлән, татар.

Казанның завод-фабрикаларында булып торган мондый вакыйгалар һәм татар эшчеләренең катнашы турында Фатих белгәнме? Әлбәттә, белгән. Беренчедән, бу хакта бөтен Казан шаулый. Икенчедән, социал-демократлар арасында Фатихның танышлары бар. Ниһаять, Сәгадәт апасы янына барып йөрүе дә эшче бистәләренең хәл-әхвәленнән хәбәрдар булып торуга ярдәм итми калмаган.

Каршы як та тик ятмый.

Сарай мәйданындагы залплар яңгыравы тынарга да өлгерми, әлеге дә баягы Рәшит казый Ибраһимов Эчке эшләр министрына үтеп керә дә, аңардан кайбер вәгъдәләр алгач, татар төбәкләренә сәяхәткә чыгып китә. Уфада, Оренбургта, Троицкида була, Кызылъяр, Чистай, Буби якларын әйләнеп килә. Бай йортларда уздырылган аш-су мәҗлесләрендә милләт һәм дин, тәрәккый һәм мәгърифәт турында күп сүзләр сөйләнелә, оешу, берләшү турында киңәш-табыш корыла. Баш министр Витте исеменә мөселманнарның ихтыяҗын түбәнчелек белән белдергән петицияләр җибәрү эше башлана.

Февраль ахырларында Рәшит баба Казанга килеп чыга һәм шәһәрнең атаклы байлары, либераль карашлы зыялылары, яңа фикерле руханилары белән очраша башлый.

Март башында татар сәүдә корольләренең берсе Әхмәт бай Хөсәенов өендә 60—70 кеше катнашында зур мәҗлес үткәрелә. Күп сүзләр була, күп фикерләр-тәкъдимнәр әйтелә. Мәҗлеснең беренче карары — пайтәхеткә петиция җибәрү. Аны язу либераль адвокат Сәетгәрәй мирза Алкинга тапшырыла. Икенчесе — карар дисәң дә ярый, теләк дисәң дә — Россия мөселманнарының съездын чакырып, бер оешма яисә партия барлыкка китерү. Кырым, Кавказ, Урта Азиянең күренекле шәхесләре белән бу турыда язышу, мәслихәтләшү эше булачак партиянең булачак идеологы Йосыф Акчурага тапшырыла.

Бу вакыйганы Фатих белгәнме? Белгән генә түгел, мәҗлескә үтеп кергәнлеген ышанып әйтергә мөмкин. Җитезлеге бар, Рәшит казыйның танышы, Казанның могтәбәр затлары игътибарын да җәлеп итеп өлгерде. Аннан да бигрәк ул — шәкертләр хәрәкәте лидерларының күренеклесе. Милләт хадимнәренә исә бу хәрәкәтне үз артларыннан ияртү кирәк.

Ике котып булып яшәгән ике социаль көч әнә шулай революция чорына килеп керде. Алар арасында тора торган социаль катлаулар да хәрәкәткә килә. Шәһәрне күздә тотканда, власть ияләрен аеруча борчый торганнары —

приказчиклар һәм шәкертләр. Приказчиклар, әйдә, оеша башласыннар, союз ясасыннар, без исә шәкертләр хәл-әхвәленә күз ташлыйк.

Авангарды «Мөхәммәдия» булган Казан шәкертләре хәрәкәтендә 9 январь фаҗигасеннән соң яңа этап башланды. Күзе ачылган шәкертләр дөньяви фәннәр кертү, коръән тәфсире, ислам тарихы укытуны таләп итүдән инде ары киттеләр. Алар мәдрәсәләрне тамырыннан үзгәртеп кору мәсьәләсен куя, ул гына да түгел, укыту-тәрбия эшләрен илдә барган политик вакыйгалар белән бәйләп карый башладылар. Ислах хәрәкәте сәяси төс алды.

Шул вакытның ярыйсы гына ышанычлы шаһитләреннән берсе М. Укмасыйны тыңлыйк: «...халык арасында без төрле партияләр — кадетлар, социалист-революционерлар, социал-демократлар, максималистлар бар икәнен аңладык. Аңладык, дигәч тә программалары, тоткан юллары белән җентекле танышып түгел, исемнәрен ятладык та, кайсы партиянең кемнәргә, нинди сыйныфларга таянганын белеп алдык».

Фатих 1905 ел башында мәдрәсә шәкерте саналса да, бар вакытын, бар көчен биреп башкарган эше — шәкертләр хәрәкәтенә юлбашчылык итү. Бу хәрәкәтнең элекке хәле, элекке рәвеше инде канәгатьләндерми. Барыннан да бигрәк таркаулык күзгә ташлана. Һәр мәдрәсәнең үз түгәрәге, үз оешмасы. Һәрберсе үзенчә хәрәкәт итә, үзенчә мөгез чыгара. Идея берлеге, оешма берлеге кирәк! Фатих һәм аның фикердәшләре Казан шәһәрендәге шәкертләрнең барысын бер оешмага туплау инициативасын үз өсләренә алалар.

Тора-бара мәмләкәтнең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендәге шәкертләр хәрәкәте белән җитәкчелек итү өчен үзәк орган барлыкка китерү фикере туа. Җитди сорау килеп баса: нинди юлдан барырга, нинди тактика тотарга, нинди программа буенча хәрәкәт итәргә?

Революция башлангач, Фатих бер нәрсәне аңлап алды: самодержавие деспотизмы яшәп килгәндә, мәдрәсәләрне үзгәртеп коруның бик үк зурдан булмаган программасын гына тормышка ашыру да ай-һай мөмкин микән? Әнә бит таләпләр куя башладыңмы, мөдәррисләр һәм мәхәллә байлары куркыта башлыйлар: малайлар, азмагыз, хөкүмәт әһелләренә барып җитәр, полиция килеп басар, мәдрәсәне ябарлар.

Самодержавие белән инде сугыш башланды. Халыкны үз артыннан ияртергә тырышкан партияләр кыюланып киттеләр. Арада эсер дигәннәре аеруча гайрәт ора. Алар да

халыкны, бигрәк тә крестьяннарны, хөкүмәткә каршы күтәрү ягында. Гомуми восстаниене көтеп тормыйча, жандарм, губернатор, министрларны, хәтта патшаның үзен үтерү юлы белән максатка ирешү фикерен алга сөрүчеләре дә бар. Татарлардан да байтак кеше эсер булып китте. Агитаторлары мәдрәсәләргә дә килеп керделәр һәм үз иманнарын тукый башладылар.

Кем хаклы? Эсерлар әйтә: патшаны төшерәбез, республика урнаштырабыз, җирләрне крестьяннарга бирәбез һәм шуннан социализм туа. Юк,— диләр социал-демократлар,— моның белән генә эш бетми әле. Властьны пролетариат кулына алып, завод-фабрикаларны халык милкенә әверелдерергә, авылда да, шәһәрдә дә кеше көченнән файдалануның чыганагын ук бетерергә кирәк, шул булыр социализм, диләр.

Мәсьәләнең нечкәлекләренә төшенеп җитмәсә дә, Фатихның зирәк акылы соңгыларының хаклылыгын сизеп ала: социал-демократларга йөз тоту, эшне алар өйрәткәнчә алып бару дөрес булыр.

Сәер түгелме? Ф. Әмирханны без «кызылга» буямыйбызмы? Бит ул либераль карашлы рухани гаиләсендә мохтаҗлык күрми үсте, ун ел гомере мәдрәсә диварлары эчендә узды. Пролетариат белән танышлыгы, Яңа бистә һөнәрчесен танып белүе яисә Крестовников заводының «төшереп» алган эшчесен тамаша итүдән, сәяси иманы,- Ш. Мәрҗани, И. Гаспринский, Р. Ибраһимов кебек милләт хадимнәре карашыннан күп ерак китмәгән иде.

Ниһаять, Фатихның укытучысы студент Гассарны сәхнәгә кертергә вакыт җитте.

Сергей Николаевич Гассар, Казанда чиновник гаиләсендә туып, гимназия тәмам иткән һәм, шактый олыгайгач, 27 яшендә университетның физика-математика факультетына укырга кергән. РСДРП(б) сафына Казандагы марксистик түгәрәкләрдә «пешеп чыгып» килгән булса кирәк. 1904—1905 елларда инде ул губерна партия оешмасының күренекле работнигы булып җитешә. КГЖУ начальнигы рапортыннан без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Нык-лап тикшерелгән агентура белешмәләренә караганда, Гассар социал-демократик партиянең җирле комитеты карамагындагы Крестовников районында (Крестовников заводы) оештыручы вазифасын үти һәм комитетның эшлекле работнигы булып тора».

Фатих дәрес ала башлаганда С. Н. Гассарның берсе җиде, икенчесе биш яшьлек ике улы һәм бер яшьлек кызы булган. Хатыны акушерлыкка укып йөри икән. Репети-

торлыктан бүтән кәсебе һәм килере юк. Әтисе вафат, әнисе кече кызы белән пенсиягә яши.

«Урталыкта» романыннан да без Гассар турында беркадәр мәгълүмат алабыз. Ни хикмәттер, Ф. Әмирхан әсәрнең «каһарманы» Хәсән Арслановны аттестатка әзерләүче студентның исемен үзгәртүне дә кирәк тапмаган.

«Сергей Николаевич,— диелә романда,— озын буйлы, озын борынлы, сап-сары озын чәчле 29—30 яшьлек бер студент иде. Аның зәп-зәңгәр күзләре һәммә кешегә генә түгел, бәлки һәммә нәрсәгә дә әллә ничек йомшак итеп, сөеп карыйлар да бик изге булып күренәләр иде». Сергей Николаевичны төрле хәлләрдә күргән булса да, Хәсән аның ачуланганын, каты сүз әйткәнен ишеткәне юк. Әнә бит күңелле утырышларны яратуы һәм иренчәклеге сәбәпле ул рәтле-башлы җавап бирә алмагач, учителе беравык дәшми тора да йомшак кына тавыш белән:

— Сез, Хәсән, боларны ныграк укыр идегез... Имтихан өчен дә, гомумән, үзегез өчен дә кирәк алар,— дип куя. Тавышны күтәреп әйтелгән шелтәгә караганда да Хәсәнгә бу катырак тәэсир итә: комачтай кызара ул, тирләп чыга, белгәннәрендә дә бутала башлый. Сизгер һәм нәзакатле Сергей Николаевич шәкертен кыен хәлдән чыгарырга ашыга:

— Алгебра белән ничек? Чыгара алмый калган мәсьәләгез булмадымы?

Әнә нинди кеше Фатихның хәлфәсе Гассар. Мәмләкәтне астын өскә китереп үзгәртергә җыенучы революционерлар һич тә канга сусаган таш йөрәкле кешеләр түгел икән ләбаса. Аларның батырлыгы үз кул көче белән көн күрүче гади кешеләрне кызганудан, кимсетелгән, кыерсытылганнарның хәленә ачынудан, тартып алынган хокукларын кире кайтару теләгеннән килеп чыга икән.

С. Н. Гассарның хәлфәлеге гимназия программасы кысасында гына калмаган, билгеле. Ул шәкертен сынаган, күзәткән һәм акрынлап үз карашларын сеңдерә башлаган. Диктант яздырганда, текстны төрлечә сайларга мөмкин. Сочинение темасын да максатка яраштырырга була. Рус әдәбиятын да тиешле юнәлештә аңлата аласың. Тарих турында инде әйтәсе дә юк.

Шәкертенә ышанычы ныгып җиткәч, Гассар Фатихны агымдагы хәлләр белән таныштыра, марксизм буенча сабак бирә башлаган. Ә көннәрдән бер көнне шәкертен яшерен эшләргә тартырга мөмкин дигән карарга килгән. Ибраһим Аитов истәлегеннән Фатихның, Гассар белән бергә,

гектографта листовкалар басып таратуда катнашканлыгы билгеле.

Кем белә, бәлки әле Фатихка поляк теленнән русчага тәрҗемә ителгән «71 нче ел коммунасы» исемле брошюраны укырга нәкъ менә Гассар тәкъдим иткәндер. Үз китапханәсеннән биреп торган булуы да мөмкин. Яшь Әмирханның Париж коммунасы тарихын марксизм яктылыгында аңлаткан әсәрне укуын, татарчага тәрҗемә итү фикеренә килүен һәм якынча өчтән бер өлешен 1906 елның җәендә «Әлгасрелҗәдит» журналында бастырып чыгарганын бүтәнчә аңлату шактый кыен. Бу факт икенче яктан да кызыклы. Булачак дусларның каләмнәре беренче башлап ерак Уральскида, шушы «Әльгасрел-җәдит» журналында очрашкан икән.

Хәер, С. Н. Гассар чәчкән орлыклар әзерлексез туфракка төшкән дисәк, бу бик үк дөрес булмас. Без Фатихның беренчеләрдән булып КТУМга сукмак салганлыгын беләбез. Х. Ямашев белән очрашулары да яшерен җыелышларда гына булмаган. Г. Сәйфетдинов белән якыннан танышлыгына да шикләнмәскә мөмкин.

Шәкертләр лидеры Фатих та, шул заман тәгъбиренчә әйтсәк, «демократлар» ягын куәтләгәч, үзләрен «революционер», ягъни эсер санаучы шәкертләрнең хәле бөтенләй мөшкелләнә. Яшь Әмирханның нечкә көлү, ачы ирония белән сугарылган дәлилле сүзләре «революционер»ларның кызыл күлмәк өстеннән киң каеш буып җибәргән агитаторларын тәмам хур итеп ташлый. Эсерлыкка «язылучы»ларның саны кими һәм, гомумән, «Мөхәммәдия»дә бу политик агымга җирлек тараеп кала. «Таң»чыларның, ягъни татар эсерлар группасының, бераз соңрак, «Ислах комитеты»на көндәш итеп, «Берек» исеме астында бер оешма барлыкка китерүләре очраклы хәл түгел.

РСДРП(б)ның Казан комитеты укучы яшьләр арасында эшләүгә зур игътибар биргән, моның өчен махсус кешеләр билгеләгән. Х. Ямашев һәм Г. Сәйфетдинов та шәкертләрнең политик аңын үстерүгә күп көч куйганнар, күп вакыт биргәннәр.

Беренчесе турында сүз озайтырга хаҗәт юк. «Мөхәммәдия»дә ул «үз кеше»: шундый ук шәкерт булган, кайчандыр шушы ук йортта укып йөргән. Шуңа күрә сүзе аеруча үтемле.

Г. Сәйфетдинов хакында өстәп берничә сүз әйтми булмый.

Курку белмәс бу тынгысыз революционер 1904 ел башларында ук охранкага борчу тудыра башлый. КГЖУ күрсәтмәсе буенча КТУМ педсоветы шул елның 12 октябрендә

школадан сөргәч, репетиторлык белән тамак туйдырганы хәлдә Г. Сәйфетдинов, бөтен көч-куәтен җигеп, революцион эшкә чума. КТУМ инспекторы Пинегинның губернаторга җибәргән язуында мондый сүзләр бар: «...Татар укытучылар мәктәбе укучыларына һәм, ишетүемә караганда, хәтта мәдрәсә шәкертләренә юлдан яздыргыч йогынты ясавы сәбәпле, Сәйфетдиновның Казанда яшәве гаять зарарлы». Сорау алу беркетмәсендә дә шуңа охшаш сүзләр укыла: «Үз-үзен тотышы һәм телдән пропаганда ясавы белән мөселман укучы яшьләренә гадәттән тыш куәтле аздыргыч йогынты ясый». Төрмәдән язган хатыннан күренгәнчә, Галимҗанны нәкъ менә шәкертләр җыелышыннан тотып киткәннәр. Г. Сәйфетдиновның күбрәк «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә булуына, «Мөхәммәдия» шәкертләре белән аралашуына шикләнмәскә мөмкин.

Инде килеп югарыда әйтелгәннәрне, ул вакытта Уфада булса да, шәкертләр хәрәкәтенә якыннан катнашып, Казандагы хәлләрдән хәбәрдар булып торган Галимҗан Ибраһимов кебек абруй иясе сүзләре белән ныгытып куйыйк. 1905 елның көзенә таба оешып җиткән «Әльислах комитеты»н күздә тотып, ул болай ди: «Бу татар социал-демократлары тәэсирендәрәк барырга тырыша иде».

Ләкин ассызыклап шуны әйтергә кирәк: йогынтыга бирелү әле «Ислах комитеты» социал-демократик оешма булып мәйданга килде, ә аның җитәкчесе яшь Әмирхан большевистик позициягә басты дигән сүз түгел. Социал-демократлар белән аралашу, марксизм белән танышу, Фатихның соңгы маягы сүнеп, алдында яңа маяк кабынуга гына китерде. Ачыграк әйтсәк, социал-демократлар йогынтысында ул, либераль-буржуаз лагерьга арка белән борылып, революцион демократизмга таба адым ясады.

## 2

Фатих һәм фикердәшләре либераль буржуазия һәм аның идеологлары белән дә араны өзеп бетермиләр. Бүтәнчә була да алмый. Бу сиңа эшчеләр хәрәкәте түгел. Хәл кайчан тамырыннан үзгәрер әле, мәдрәсәләр хәзергә татар байлары, татар купецлары субсидиясенә яши. Капитал хуҗалары һәм милләт хәдимнәре чабуына ябышып бармый хәлең юк. Аларга таләпләр кую, мәдрәсә ислахы файдасына эш башкарту иң дөрес тактика булыр. Менә ни өчен Фатих либералларның хәрәкәтен җентекләп күзәтеп тора, алар үткәргән чараларның берсеннән дә калмаска тырыша.

«Чистай туе» дип тарихка кергән вакыйгага катнашмый калуын, мәсәлән, күз алдына китерү кыен.

1905 елның 20 маенда Мөхәммәтзакир кызы Әсмаигалия белән Ростов-Дон мулласы Муса Җарулла улы Бигиевнең никахлары метрика дәфтәренә теркәлә һәм зурдан кубып туй үткәрелә. Кем генә юк бу туйда! Мөселман дөньясында танылган милләт хадимнәре дисеңме, Казан, Уфа, Чистай һәм башка шәһәрләрнең зур байлары дисеңме, могтәбәр имам һәм мөдәррисләр дисеңме... Атаклы Рәшит бабаның түр башында утыруы үзе генә ни тора!

Билгеле инде, бу кадәр олы затлар мәрхүм ишан һәм М. Бигиевкә ихтирам йөзеннән генә килмәгәннәр. Пылау һәм бәлеш ашау, лимон салып варенье белән чәй эчү, ике яшькә ходайдан бәхет сорау, тигез мәхәббәт һәм озын гомер теләүләр арасында милләт кайгысын кайгырталар, якындагы бурычлар турында киңәш-табыш коралар. Казанда туган фикер — съезд җыеп, Россия мөселманнарының уртак оешмасын, төгәлрәк әйтсәк, партиясен булдыру фикере нәкъ менә шушы туйда анык бер рәвеш ала.

Фатихның урыны түрдә үк булмаса да, ишек төбендә дә түгел. Чөнки монда ул үз кеше. Бикәч Нәҗип абзасының балдызы, димәк, Фатихка кодача тия. Әтисе Зариф хәзрәт туйдагы могтәбәрләр арасында йөри, җизнәсе Габдулла мулла — егет ягыннан шаһитларның берсе.

Фатихны Чистайга барудан таш яуса да туктатып кала алмаслык тагын бер сәбәп бар: ул да булса, зифа буе, сөрмәле күзе белән егетне иләс-миләс иткән кодачасы Шәмсениса...

Май ахырларыннан башлап, съездны әзерләү кампаниясе аерата җанланып китә. Казан, Кырым, Кавказ, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Төркестан арасында язышу бара, «эмиссарлар» йөреп тора. Шул төбәкләрдән Петербургка бер төркем вәкилләр килә. Тиешле учреждениеләргә кереп, гозерләрен сөйлиләр, петиция тапшыралар. Сановникларның икеле-микеле җавапларын ризалык билгесенә юрап, мәслихәтләшәләр дә, тәвәккәлләп, ныклы карарга киләләр: җыярга съездны. Моның өчен иң кулай урын, билгеле инде, Нижний Новгород, Мәкәрҗә ярминкәсе. Ник дигәндә, империянең кесәсе дип йөртелгән бу ярминкәгә һәр елның августында миллионерлардан башлап шәкертләргә чаклы әллә никадәр мөселман килеп тула.

Карар шәкертләргә дә ирешә, съездда катнашу фикеренә киләләр, вәкилләр сайларга керешәләр. «Мөхәммәдия»дән сайланучыларның берсе, әлбәттә инде, Фатих. Дөрес, аларга беркем дә тәкъдим ясамады, беркем дә ча-

кырып тормый. Мондый эштә чакырганны көтәргә ярыймыни? Әнә эсерлар да тик ятмый ди. Башлыклары Г. Исхакый белән Ф. Туктаров та съездга барырга булганнар икән.

Менә август урталарында Казаннан сайланган рәсми делегатлар үзләре, «чакырылмаган кунаклар» үзләре пароход белән Мәкәрҗәгә килеп төшәләр. Бүтән төбәкләрдән дә вәкилләр килеп җитә. И. Гаспринский, кавказлы бай адвокат Г. Тупчибашев, Р. Ибраһимов та бар. Й. Акчура һәм С. Алкин да хуҗалар сыйфатында тыз-быз йөриләр. Зур байлар, исеме танылган муллалар да байтак. Фатихка якын булганнарыннан С. Аитов белән Г. Барудины телгә алып китәргә кирәк.

Оештыру эшләре башлана . Иң могтәбәрләрдән берничә затны рөхсәт сорар өчен губернаторга җибәрәләр. Әмма вәкилләрнең борыны салынып кайта: шәһәр хәрби хәлдә булганлыктан, губернатор рөхсәт бирә алмавын әйткән икән. Алай уйлап, болай уйлап карыйлар да, буржуага бик үк хас булмаганча, кыю фикергә киләләр: рөхсәтсез үткәрергә. «Густав Струве» исемле пароходны, 300 сум түләп, бер көнгә сатып алалар да пикникка чыгу сылтавы белән съездны шунда ясарга карар итәләр.

Тик тагын бер кыенлык бар. Үзләрен социалист дип йөргән яшьләр дә килгән икән. Съездда катнашмакчылар. Җанҗаллы халык, мәҗлеснең ямен җибәрмәгәйләре. Ничек котылырга? Балачакта булгалап тора торган мондый бер манзара күз алдына килә. Берничә малай иртән иртүк торып, балыкка барырга киңәшәләр. Берсенең энесе «мин дә барам», ди. Син әле кечкенә дип, үгетләп карыйлар. Юк! Хәйләгә керешүдән бүтән чара калмый: ярар, барырсың, уятырбыз. Иртән исә шыпырт кына чыгып сызалар. Авыл очында артларына борылып карасалар, әлеге бала, үкереп елый-елый, болар артыннан чаба. Нишләсеннәр, иярәтергә мәҗбүр булалар.

Әнә шуның шикелле, олы абзыйлар иртәнге унда китәргә тиешле пароходны унынчы яртыда кузгатып, «малайларны» йоклатып калдыралар. Инде котылдык, ходага тапшырып, эш башларга вакыт дип уйларга өлгермиләр, теге «малайлар», тиз йөрешле катерга утырып, куып җитмәсеннәрме! Бүтән чара юк, пароходка алалар, әмма бик каты кисәтеп куялар: бу сезгә социалистлар митингысы түгел, бу иттифак мәҗлесе, тыныгызны чыгарасы булмагыз. Югыйсә, ярга төшереп калдырачакбыз.

Котлаулар, котлашулар була, докладлар укыла, сүз алып сөйләүләр яңгырый. Нәтиҗәдә Россиядә яңа бер пар-

тия туганлыгы игълан ителә. Исем дә кушыла: «Иттифакы мөслимин». Партиянең үзәк комитеты сайлана. Россиядә яшәүче мөселманнар уналты районга бүленә, һәркайсының үзәк шәһәре билгеләнә, һәркайсына үз комитетын булдырырга кушыла. Съезд резолюция сыман нәрсә дә кабул итә. Анда без җир яисә мөселман эшчеләре турында бер сүз дә тапмабыз. Булган кадәресе шул: б а р л ы к мөселманнарны үзара якынайту, мөселманнар хокукын чикләүгә каршы з а к о н р ө х с ә т и т к ә н чаралар кулланып көрәшү һәм мәктәп, китапханә, газета-журналлар булдыру эшләрен җайга салу. Ат уйнатучылары зур байлар һәм аларга ләббәйкә дип торган милләт хадимнәре булгач, бу «партиядән» шуннан артыгын көтәргә туры килми.

Татар социал-демократлары Мәкәрҗә ягына әйләнеп тә карамаганнары хәлдә, эсерлар, шәкерт һәм приказчик вәкилләре олы абзыйлар мәҗлесенә әрсезләнеп барып керделәр. Ниятләре изге иде югыйсә. Трибунага менеп,. мондый сүзләрне ярып салу иде:

— Мөселманнар бер бөтен түгел, бае бар, ярлысы бар, крестьяны бар, морзасы бар. Бүре белән куйны иттифакка китереп булмаган кебек, мөселманнарны бер партия җитәкчелегендә берләштерү мөмкин түгел!

Фатих өчен, киләчәге өчен съездга килүенең файдасын да инкарь итеп булмый. Беренчедән, Фатих кайчандыр үзе табынган Исмәгыйль бәк Гаспринскийны, ишетеп кенә белгән күп кенә бүтән мәшһүр шәхесләрне күрде, фикерләрен тыңлады. Милләт хадиме булырга җыена торган унтугыз яшьлек егет өчен бусы да аз түгел. Икенчедән, ул яңа партия пешеп чыккан кухняның эчендә булды. Оешу принципларын, структурасын үз күзе белән күрде. Фатих та бит Россиядәге татар шәкертләрен берләштерә торган оешма ясау уе белән яна. Программасы ярамаса да, «Иттифак»ның кайбер тәҗрибәсе ярап куяр. Ниһаять, өченчедән, су өстендәге мәҗлес либералларның чын йөзен танып алып, моңарчы нур эчендә йөзә кебек тоелган кайбер милләт хадимнәренең йогынтысыннан котылуга да булышмый калмады. Алар да затлы камырдан ясалмаган икән бит. Гыйззәте нәфесләре, ягъни самолюбиеләре бар. Һәркайсы үз фикерен өскә чыгарырга тырыша. Үпкәләшәләр дә, интрига да коралар.

Бу яктан мәҗлеснең ахыры аерата гыйбрәтле.

Менә «Густав Струве» пароходы кайту ягына борыла. Һәркем көләч, һәркемнең күңеле куаныч белән тулы булырга тиеш иде кебек... Чөнки күптән хыялда йөргән оеш-

ма дөньяга килде. Ләкин, кояш болыт астына кереп, салкынча җил исеп куйган шикелле, бер заман халыкның йөзенә пошаманга төшү галәмәте чыга. Пристаньда полиция көтеп торса? Беркетмә, карарлар, резолюция полиция кулына эләксә? Гаскәр чолганышында төрмәгә илтеп япсалар? Элек пышылдап, аннары ачыктан-ачык вәсвәсәләрен тышка чыгара башлыйлар. Нишләтик бу кәгазьләрне, кая куйыйк? «Мин алмыйм,— ди И. Гаспринский,— әнә суга ташлагыз». «Яндырырга кирәк»,— ди кайсыдыр. Бер йөрәкле адәм табыла. Ул да булса Рәшит казый Ибраһимов: «Бирегез миңа».

Төнге сәгать унберләрдә пароход, яны белән шыгырдап, пристаньга килеп терәлә. Курка-курка чыгалар. Ләкин... тып-тыныч, полициянең исәбендә дә булмаган. Берәүләрнең, шактый җайсыз хәлдә калып, битләре яна башлаганын, берәүләрнең акланырга керешкәнен күз алдына китерү кыен түгел.

3

Менә көз житә, шәкертләр җыела башлый. Ләкин укуның рәте-чираты юк. Искечә укыйсылары килми, яңача укуны көрәшеп аласы бар. Революция аның саен куәтләнә, үзенең югары ноктасына якынлашып килә. Шәкертләр мәдрәсәдән мәдрәсәгә яшерен җыелышларга йөриләр, митингларга чабалар.

1905 елның көзен Фатихның матур, парлак һәм бәхетле чоры дип атасак, хата булмас. Эшләр уңышлы бара, Казан мәдрәсәләрендәге түгәрәкләр берәм-берәм уртак оешма эченә керергә ризалыкларын белдерәләр. Бүтән шәһәрләрдән дә уңай хәбәрләр килеп тора.

Ноябрь аенда, ниһаять, «Мәркәз ислах комитеты» исеме астында житәкче оешманың дөньяга килүе рәсми рәвештә игълан ителә. Социал-демократлар лозунгысына охшатып уйланган: «Уяныгыз, бөтен татар шәкертләре!» — дигән чакыру белән башлана торган мөрәҗәгать Оренбург, Уфа, Чистай, Буби, Кырым һәм Себер мәдрәсәләренә җибәрелә. 29 ноябрьдә җилем басмада яшерен рәвештә чыгарыла башлаган атналык «Әльислах» газетасының беренче саны дөнья күрә. Аның да исеме астында шул ук сүзләр укыла: «Уяныгыз, бөтен татар шәкертләре!»

Кыскасы, барысы да җирле җирендә. Барысы да зурдан кубып эшләнә. Комитетның хәтта түгәрәк печате дә бар. Печать кенәме әле! Партия урынын тота торган житди оешма гимнсыз була аламыни? Гарифҗан Мостафин «Беренче сада» дип телгә кергән җыр яза, «Икенче сада» ди-

гәнен Муллахмәт Бәдигый исемле егет чыгара. Шәкертләр ятлап алалар да гимн итеп җырлый башлыйлар:

Кояш чыкты, нур балыкты,
Тәрәзәдән өйгә аркылды.
Ятма йоклап, уян, шәкерт,
Кузгалырга вакыт җитте!

«Әльислах»та «Марсельеза»ның да тәрҗемәсе басылып чыга. Көен отып алып, шәкертләр аны да җырларга кирешәләр.

Революция дулкыннары анын саен куәтләнә бара. Забастовка, митинг, демонстрацияләр ешая. 17 октябрь манифесты да бу дулкынны туктата алмый. Большевиклар эшчеләрне коралллы восстаниегә әзерлиләр. Халык милициясе оештырыла башлый. Милициягә, эшчеләрдән кала, студентлар, гимназия укучылары һәм шәкертләр языла. Соңгыларының күпчелеге «Мөхәммәдия»дән булганлыкка шикләнмәскә мөмкин. 21 октябрьдә Дума бинасына бикләнеп, хөкүмәт гаскәренә каршы торган каһарманнар арасында берничә шәкертнең дә булганы билгеле.

Фатих митингларга да йөргән, демонстрацияләрне дә тамаша иткән. Әмма аның, корал тотып, турыдан-туры б... релешләрдә катнашканлыгы турында мәгълүмат ю... рәсең, ул берничә иң якын көрәштәше белән күбр... «штаб»та булган, шәкертләр хәрәкәтенең дилбегәсен кулында тоткан.

Әле бит шәкертләрнең үзләренә генә караган максатлары да бар. Фатих кулы белән әнә булачак оешманың программа проекты язылды. Аны мәдрәсәләрдә укыйлар, тикшерәләр. Россия шәкертләренең беренче съездын чакыру буенча хәзерлек эшләре дә башланды. Әлеге проект шунда каралачак һәм гамәлгә кертеләчәк.

Әмма съездны һәм шәкертләр «партия»сенең рәсми рәвештә туганын көтеп торып булмый. Мәдрәсә башлыкларына һәм мәхәллә байларына бүген үк таләпләр куярга, шуны тормышка ашыру өчен тарткалашырга кирәк. «Казане мөхбире» газетасының 1906 елгы 19 март са... түбәндәге юлларны укыйбыз: «17 үктәбердә Ка... ләре иттифакан * хәзрәтләренә мәдрәсәләрнең һ... тенә дә ислах кыйлуларны сорап гариза биргәннәр. Шул матлабларына җавап бирелмәенчә, дәрес укымаска б... дәрес ташлаганнар. Күбрәк мәдрәсәләрдә бу көндә ...бастовка (дәрес ташлау) дәвам итмәктәдер».

* Иттифакан — бергәләп, сүз берләштереп.

Иттифакчылар да тик ятмыйлар. 17 октябрь манифестыннан соң кыюланып китеп, Сәетгәрәй Алкин агымдагы хәлләр турында сөйләшер өчен мәҗлесләр ясарга губернатордан рөхсәт ала. Төп бурыч — «Мөселман иттифакы»ның программасын эшләп, чираттагы съездда тәсдыйк иттерү һәм булачак Дума вәкилләрен сайлауга әзерләнү. «Сарай» номерында, Әхмәт бай һәм Сөләйман Аитов өйләрендә шундый мәҗлесләр булып уза. Үрнәк өчен ике программа игътибар үзәгенә куела: кадетлар һәм октябристлар программасы. Эсерларның һәм бүтән төр демократ яшьләрнең кирегә сукалаулары, тавыш куптарулары сәбәпле мәҗлесләр бик үк шома үтмәгәннәр. Шулай да берсе әйбәт кенә узган, һәм Габдулла мулла Апанаев ахырда болай дип сөйләгән:

— Ошбу мәҗлесемез әлхәмделилла бик гүзәл булды. Сәбәбе исә — бу кичәдә социал демократ (эсерлар белән бутый — *И. Н.*) мәзһәбендәге яшьләр юктыр. Җилгәннәре дә җиңелү сәбәплеме, әдәпкә килделәрме, сөйләмәделәр.

Әнә шул мәҗлестә кадетлар программасына туктала-лар. Чәчен китәреп, сакалын кыскартып, мыегын нечкәртеп аңа кәләпүш кидерергә карар кылына. Бер үк вакытта икенче съездны үткәрүгә әзерлек эшләре дә бара. Ниһа-...ть, урыны һәм вакыты тәгаен ителә: 1906 елның 15 ян-... Петербург.

Бу юлы инде таңчылар һәм ислахчылар да рәсми төс-... катнашачак. Күрәсең, «Иттифак»ның башлыклары эсерлар ничаклы куркыныч сүзләр сөйләсәләр дә, ул кадәр үк хәвеф-хәтәр китерә алмаганлыкларын, ислахчыларны исә үз артларыннан ияртергә кирәклеген абайлап алганнар.

Фатихның Петербургка китү тарихына карата М. Укмасый мондыйрак мәгълүмат бирә.

Казан шәкертләренең уртак бер җыелышында теңкәгә тигән шул ук нәрсәне — ислах мәсьәләсен көн тәртибенә куеп тикшергәннәр. Чыгып сөйләүчеләр күп булган, һәркайсы үз карашын белдергән, үз планын тәкъдим иткән.

Менә Фатих Әмирхан сүз ала һәм мондый фикер әйтә: ...рәсә ислахы матди нигезсез мөмкин түгел. Мәд-...асраучы байлар без таләп иткән ислахка бер-...риза булмаячаклар. Без нык торсак, алар мәдрәсә файдасына бер тиен дә бирмәячәкләр. Шуңа күрә ...бургка вәкилләр җибәрергә, хөкүмәткә керергә, та-... халкыннан җыела торган земский сборның мәгариф-... торган процентын мәктәп-мәдрәсәләр файдасына ...уны таләп итәргә кирәк.

Бу «шәп фикергә таң калган» шәкертләр, ди Укмасый, рухланып китеп, вәкилләр сайлый башладылар. Ахыр чиктә бертавыштан Фатих сайланган. Барып кайту, ашау-эчү чыгымнары өчен һәр шәкерттән 50 шәр тиен акча җыярга карар ителгән. Фатих, янәсе, махсус «җөббә» тектереп алган да Петербургка китеп барган.

Монда чыны-уйдырмасы бергә катыш.

Әлбәттә, Казан шәкертләренең уртак җыелышы булган. Фатихны вәкил итеп сайлаганнар. Ләкин министр янына керү өчен түгел, бәлки «Мөселман иттифакы»ның 2 нче съездында катнашыр өчен. Юл чыгымына акча да җыйнаганнардыр, Фатих өс-башын да рәтләгән булыр. Әмма барыннан да әһәмиятлесе шул: Фатих ул вакытта ук татар мәктәп-мәдрәсәләрен хөкүмәт уку йортлары белән хокукта тигезләү тарафдары булган. Яшь Әмирхан фикеренчә, идарәсе үз кулыбызда калган хәлдә, уку йортлары дәүләт хисабына яшәргә тиешләр. Бу хокукны исә министрга баш ору белән түгел, бәлки «Мөселман иттифакы»ның программасына һәм съездның карарына керттереп, чакырылачак Дәүләт Думасы көче белән генә хөкүмәттән яулап алырга мөмкин.

...1906 елның 12 январе. Казан вокзалы Петербург съездына китүче делегатларны озатырга килгән мөселманнар белән тулы. Руслар да байтак: чиновниклар, гаскәриләр, купец һәм промышленниклар. Хәрби оркестр уйнап тора. Бу ни тамаша? Хөкүмәт әһелләренең дә игътибарын җәлеп итеп, оркестр белән озатырлык кадерле кешеләрмени соң безнең иттифакчылар? Түгел икән, оркестр да, русның зур кешеләре дә икенче урынга күчерелү сәбәпле Казаннан китеп баручы губернатор Рейнботны озатырга килгәннәр икән. Әнә шул очраклылык безнең вәкилләрне озатуга тантана өстәгән икән.

Шунысы кызык: бу ике төркем бер-берсенә битараф калмыйлар. Әхмәтҗан бабай Сәйдәшев, рус сүзләрен ватасындыра, барлык мөселманнар исеменнән Рейнботка саулык, яңа урында яңа уңышлар тели. Губернатор җавап сүзендә рәхмәт әйтә һәм Казанны беркайчан да онытмаячагын белдерә.

Вокзалның бер тарафында милләт хадимнәре белән патша чиновникларының, төчеләнеп, бер-берсенә мәхәббәт игълан итүләренә аз гына да игътибар итмәстән, 150 ләп шәкерт, үз вәкилләрен уратып алып, уңыш телиләр, меңләгән шәкертләрнең ярдәмгә әзер торуын һәм вәкилләренә ышанганлыкларын белдерәләр. «Вәкилләрдән Фатих әфәнде Әмирханов,— диелә «Казан мөхбире»ндә чыккан репор-

тажда,— өсләренә алган эшнең бик әһәмиятле икәнен сөйләде вә бар куәте илән шуңар тырышачагын вәгъдә итте».

Кыңгырау өч мәртәбә суккач, поезд акрын гына кузгала, тизлеген бик үк арттырмыйча, алга таба шуыша башлый. Озатучылар вагоннарга ияреп баралар, хушлашалар, кул болгыйлар, баш киемнәрен салып селкиләр. Шәкертләр исә, куакка сырган корт иле кебек, вәкилләре утырган вагонга ияреп барган килеш яшь күкрәкләрдән ургылып чыккан гайрәтле тавышлары белән оркестрны күмәләр:

— Яшәсен шәкертләр!

— Яшәсен ислах!

— Яшәсен хөррият!

...15 енә билгеләнгән мәҗлес, хөкүмәт органнарыннан рөхсәт ала алмау сәбәпле, 17 январьда гына ярым яшерен сурәттә ачыла. Дөрес, делегатлар моңарчы да кул кушырып утырмадылар. Рөхсәт артыннан йөргән арада мөселман байлары үткәргән аш-су мәҗлесләрендә булдылар, «Әлфәт» газетасы әйтмешли, бер-берсенә «дустанә мәхәббәтлек» күрсәттеләр, мактадылар, макташтылар.

Егерме бишенә кадәр төрле урыннарда уздырылган рәсми утырышларында өч мәсьәлә тикшерелә: программа проекты, устав һәм булачак Думада кайсы партия белән бару. «Картлар» фикере, билгеле инде, бер эздән аккан, «яшьләр» исә кирегә сукалаганнар. «Яшь зыялыларымыз,— диелә «Казан мөхбире»ндә,— бөтен мөселманнарның бер генә гомуми хизыб * берлә оешып йөрүләре мөмкин булмаганны исбат итәргә тырыштылар». Кемнәр? Билгеле инде, таңчылар һәм ислахчылар. Соңыннан язылган бер истәлегендә Ф. Әмирхан үзе дә моны раслый: «...без, съездда оппозициядә торган берничә яшь җилбәзәкләр (шулар арасында мин дә) бюро мәҗлесләренең бер икесендә үзебезнең нoктаи назарларны ** әйтеп калырга теләдек».

23 январь көнне Петербургның тәрәккыйпәрвәр бае Галим Максудов өендә уздырылган мәҗлестә соңгы мәсьәлә буенча да карар кабул ителә: сайлауларга кадетлар белән бергә барырга. Шуннан соң Фатих кабат сүз ала, мәдрәсәләрне ислах итү турында төпле һәм кайнар сүз сөйләгәннән соң, мәктәп-мәдрәсәләр мәсьәләсен көн тәртибенә кертергә, фикер алышып, карар чыгарырга тәкъдим итә.

---

* Хизыб — партия.
** Ноктаи назар — караш, фикер.

Съезд шәкертләр башлыгының тәкъдимен кире кага һәм бу мәсьәләне өченче съездга калдырырга карар итә.

Бер-бер артлы ике телеграмма сугыла һәм «Казан мөхбире» газетасында басылып чыга.

«Петербург җыелышы.

Сәр мөхәррир * Сәетгәрәй Алкиннан алынган телеграмма.

Съездга рәсман рөхсәт итмәсәләр дә, алай да булды. Мөселманнар партиясенең программасын ясады. Думага беренче сайлауда конституционно-демократический партия берлә бергә хәрәкәт итәргә карар бирелде».

«Шәкертләр вәкиленнән (Ф. Әмирханнан.— *И. Н.*) алынган телеграмма:

Җыелулар дәвам итә: мәдрәсә мәсьәләсе 15 нче августка кичектерелде».

Съезд тәмам, делегатлар таралып китәләр. Фатих белемен арттыру максаты белән күпмедер вакытка Петербургта торып кала, ниндидер курсларга йөри.

Нәкъ шушы вакытларда Фатихның биографиясенә яңа сәхифә өстәячәк бер вакыйга була: ул прогрессив карашлы дәүләт хезмәткәре Заһид Шамил белән таныша. Бу кеше балалар өчен Мәскәүдә бер журнал чыгару артыннан йөри икән. Ул, күрәсең, съезд мәҗлесләрендә чын интеллигент кыяфәтле яшь егетнең төпле һәм үткен чыгышларын тыңлаган. Ә соңрак, сәләтле һәм хәзерлекле икәненә ышанып җиткәч, булачак журналның секретаре вазифасын тәкъдим иткән.

### 4

Фатих, әйдә, Петербургта юансын, без Казанга кайтыйк.

Февраль башларында шәкертләр хәрәкәте тагын да киңрәк колач ала. Укучы хәтерлидер, без шәкертләрне мөдәррисләргә һәм мәхәллә байларына таләпләр язып керткән һәм, җавап булмый торып, дәрескә кермәскә карар иткәннәре хәлдә калдырып киткән идек. «Мөхәммәдия» идарәсе һәм мәдрәсәне караучы байлар бу таләпне кабул итмәгәннәр һәм башлап йөрүче дүрт шәкертне куарга карар кылганнар. Инде сүзне «Казан мөхбире» газетасына бирик. Дамелля һәм берничә мәхәллә бае мәдрәсә идарәсенең әнә шул карарын белдергәч,— диелә анда,— «игъдади 1 вә 2 нче сыйныфлар вә рөшдия 4 нче сыйныфтан 20 гә

---

* Сәр мөхәррир — баш редактор.

кадәр шәкерт боларның мәдрәсәдән чыгарылуына разый булмаячакларын вә аларны чыгартмаячакларын вә, алар чыгарылса, үзләре дә чыгачакларын ихтилал вакытындагы тавышлар илән игълан иттеләр.

Мәхәллә кешеләре үзләре коты очкан җиз төймәлеләрдән шәкертләр дә куркыр өмиде илә палисә чакыртамыз дип иглам иттеләр. Шәкертләр чакыртамыз дигәннән генә курыкмаганнан, байларның гайрәте интикам * тамырлары кузгалып, мескен шәкертләр өстенә пристав, 10 кадәр городовойлар китерделәр.

Алар, килгәч тә, шәкертләрне чыгарырга төрле тавышлар илән сөйләп карасалар да, сәгать 4 ләргәчә (Ислах комитетыннан катгый хәбәр алынганга кадәрле имеш) тәваккыф ** иттеләр.

Сонра ул 4 шәкерт вә башка сыйныфташлары өйләренең лампа вә тәрәзәләрен ватып, мәдрәсәне хәрәбә хәлендә калдырып, «Беренче сада», «Икенче сада» дигән мөнәҗәтләрне җырлап, 82 шәкерт чыгып киттеләр».

Сиксән ике эчендә Фатих булмаган кебек (ул әле Петербургта), куылган дүрт шәкерт арасында да ул юк. Укучыда сорау туарга мөмкин: шактый еллар буе шәкертләрне station аздырып килүче бу «кызыл авыз»га ничек бер дә кисәтү ясалмады, җәза бирелмәде, ничек шушы көнгә кадәр мәдрәсәдән куылмады икән? Кисәтү, әлбәттә, булган, җәза да бирелгән («Сахалин»да, ягъни карцерда утырып чыкканын хәтерлик). Куылу мәсьәләсенә килгәндә, Габдулла мулла Әмирхановның энесе, кода Ф. Әмирхан II (язганнарына шулай дип имза куйган) болай дип яза: «Галимҗан Баруди Фатихның атасы Зариф мулла белән бик якын дус кеше, Зариф мулла үзе дә Казанның иң атаклы муллаларыннан берсе. Шулай булгач, Зариф мулла улы Фатихны ничек итеп бу шартларда мәдрәсәдән куарга? Калдырырга тагын ярамый! Менә шуңа күрә дә Галимҗан Баруди, тиешле шәкертләрнең исемлеге төзелгәнгә кадәр үк, Зариф муллага «үз ихтыяры белән» Фатихны мәдрәсәдән алырга киңәш бирә. Башка дус-ишләре дә бу киңәшне яклыйлар. Нәтиҗәдә русча укырга керешү сылтавы белән Фатих мәдрәсәдән чыга». Күптән инде шәкертлектән узган Фатих, 1905—1906 уку елы башлангач, димәк, рәсми рәвештә дә мәдрәсә белән арасын өзгән.

Петербургтан кайткач, безнең Фатих кырык төрле эшмәшәкать эченә чума. Кичектермәс беренче эш — «Мөхәм-

---

* Гайрәте интикам — үч алу гайрәте.
** Тәваккыф — тукталып тору.

мәдия»не ташлап чыккан шәкертләрне торакка урнаштыру, тамак якларын кайгырту, русча укуларына булышлык итү. Моның өчен, билгеле, акча кирәк. Фатих кайтканчы ук шәкертләр файдасына иганә җыю кампаниясе башланган була. «Казан мөхбире» газетасы акча бирүчеләрнең исемнәрен һәм керткән сумаларын игълан итеп тора. Шунысы игътибарга лаек: бу кампания азмы-күпме укымышлы татарлар катышы белән генә чикләнмәгән. Иганә кертүчеләр арасында, мәсәлән, С. Н. Гассар да бар. Казан университеты студентлары да, үзара акча җыеп, Ф. Әмирхан кулына тапшырганнар икән.

Икенче мөһим эш — бөтен татар шәкертләренең I съездын әзерләү. Программа һәм устав төзелеп ята, «Әльислах» оешмасының урыннардагы шәгъбәләрен, ягъни бүлекләрен булдыру буенча эш алып барыла. Мәркәз комитетның «Казан мөхбире»ндә чыккан белдерүендә мондый сүзләр бар: «Шәкертләр съезды хакында комитетның күптәнге карары булса да, ошбу көндә мәдрәсәләре илә шөһрәт тотмыш йирләрнең һәр каюсында тәэсис * иделмәктә улан шәгъбәләр карар тапканчы игълан итми торырга мәҗбүрдер. Май числосына кадәр ничек вә кайда булачагыны гомум шәкертләргә игълан идәчәктер».

«Ислах» оешмасы белән Ф. Әмирхан бу вакытта атасы йортында яшәп җитәкчелек итә. Комитет утырышлары, «Әльислах» газетасын язу, гектографта басу, листовка һәм өндәмәләр җитештерү эшләре төрле урыннарда — «Сарай» номерында, мәдрәсә хөҗрәләрендә, аерым өйләрдә, әйтик, С. Аитов яисә Мәхмүт Дулат-Алиларда башкарылган.

Зариф хәзрәт белән Фатихның бер-берсенә мөнәсәбәтләре күптән киеренке төс алган иде инде. Хәзер исә, Фатих мәдрәсә белән арасын өзгәч һәм Петербург якларыннан урап кайткач, ата белән угыл арасындагы каршылык үзенең югары ноктасына якынлаша. Икесендә дә характер бер чама, икесе дә әйткән сүзеннән бер карыш та чигенми. Хәзрәтнең дус-ишләре, яраннары, мәдрәсәсен тәэмин итүче байлар мәхдүмнең, тәмам бозылып, кып-кызыл «социалист» булып җитүе турында бәреп әйтә торалар. Өстәвенә Фатих энесе Ибраһимовны аздыра, үз артыннан ияртә.

Бу сәбәпләр элек тә бар иде. Хәзер инде каршылык сәяси төс алды, капма-каршы ике сәяси агымның бер гаилә эчендәге чарпышына әверелде. Әнә бит Зариф хәзрәт иттифакчылар арасында үз кеше булып йөри, кадетларга күңел баглап өлгерде. Әхмәт бай өендәге мәҗлестә Зариф

---

* Тәэсис — нигезләү.

мулла да булган иде, хәтта кадетлар программасын яклап сүз дә әйткән иде. Улы исә, социалистлар мәсләген алга сөреп, «Иттифак»ны да, кадетларны да эштән чыгарып хурлый. Петербург мәҗлесендә дә, кирегә сукалап, бөтен съездны үзенә каршы куйган.

Фатихка бердәнбер юл калып бара: өйдән китеп, мөстәкыйль яшәү. Ләкин ана кызганыч. Әнә бит ул, ике яктан очкан укларның күкрәген җәрәхәтләвенә карамастан, араларына керә, килештерергә тырыша.

Көннәрдән бер көнне шундый бәрелеш вакытында Зариф хәзрәт, күрәсең, кызып китеп, Фатихка ишек күрсәткән, соңгысы аны шап иттереп ябып чыгып киткән. Ф. Әмирхан II мәгълүматына караганда, Фатих, Собачий переулокта яшәүче бер рус гаиләсеннән бүлмә алып, шунда күченә. Истәлекче сүзләре «Урталыкта» романы белән дә раслана. Әсәр Хәсән Арслановның нәкъ шул урамга, гимназиядә укый торган кызы булган бер рус хатынының буш бүлмәсенә күчеп килүе белән башланып китә. Дөрес, Хәсән белән Фатих арасына тигезлек билгесе куярга ярамый. Шулай да, Г. Флоберның «Мадам Бовари — ул мин» дигәне кебек, әдип күпкырлы характерының аерым сыйфатларын героена күчерә икән, бу бер дә гаҗәп түгел.

Мөстәкыйль яши башлагач, Фатих бәйдән ычкынгандай була. Ни әйтсәң дә, егермесен тутырып, егерме бергә чыккан егет бит ул. Тамырларында Морад хәзрәт, Әмирхан, Хөсәен һәм Зарифлар каны йөгерә. Буйга озын булмаса да, гәүдә килешле, өс-баш заманча, биткә дә ярыйсы чибәр, калын алсу иреннәре үбешер өчен генә яратылган диярсең.

Моңарчы да Фатихның зыялы егетләр һәм кызлардан танышлары байтак иде. Әмма рус кызларыннан танышлары юк иде.

Фатих күчеп килгән өй хозяйкасының да бәлки гимназистка кызы булгандыр. Гимназистка икән, аның сабакташлары була, килеп йөриләр. Фатих тә бәлки, Хәсән кебек, хуҗа кызының кавалеры сыйфатында театр яисә концертка баргалагандыр. Фатихның русчасы хәзер ару гына. Ара-тирә хаталар җибәрә җибәрүен, әмма сакланыбрак сөйләшсә рус гимназисткасының игътибарын җәлеп итәрлек хәле бар.

М. Укмасый «Музуров кунакханәсеннән» номер алып тора башлаган Фатихның бер рус кызы белән сөйләшеп утырганлыгы турында яза. Бер таныш кызының Мария исемле булганлыгы хакында да риваять бар. Архивта саклана торган хат шулай ук кызыклы. 1908 елның 28 сентябрендә аны Ярославльдән С. П. Смирнова дигән укытучы

кыз язган. Эчтәлегеннән күренгәнчә, ул Казанда укыган, татар яшьләре, аерым алганда «Соня Кулахметьева» (Гафур Коләхметовның сеңлесе Сафия) белән аралашкан. Хаттан бу туташның Фатихны хөрмәт иткәнлеге, дус күргәнлеге, хәтта ярата башлаганлыгы сизелә.

«Җәйдән соң сезнең тормыш гадәти эзенә төшкәндер дип беләм: язасыздыр, укыйсыздыр, сезнең инициатива белән милли кичәләр, спектакльләр үткәреләдер. Бер генә кичне булса да иске дуслар арасында уздырыр өчен әллә ниләр бирер идем... Үзегезне күрсәң иде, яздан соң шактый үзгәргәнсез дип беләм. Карточкагызны еш карыйм, әмма ул бит акылга да, йөрәккә дә күп нәрсә әйтми торган җансыз кәгазь».

Шактый еш һәм тиз гашыйк була торган Фатих 1906 елның яз, җәй һәм көз айларында татарыннан һәм русыннан, кызлардан һәм кияүдәгеләрдән байтак хатын-кыз белән мавыгып алган дип уйларга туры килә. Бәлки ул да «Кадерле минутлар»дагы Рәшат кебек, Кабан күле ярында берәр Аля белән, орынырга да базмыйча, әмма үзен чиксез бәхетле хис итеп, таң аттыргандыр, кызны озатып куйгандыр. Кереп китәр алдыннан кыз үзе тәҗрибәсез иреннәре белән Фатихның ирен кырыеннан үбеп алгандыр. Бәлки яңа гына кияүгә чыккан берәр Хөршитнең мәхәббәте Фатихка баглы калгандыр. Кем белә, бәлки шул Хөршит кебек бер яшь ханым, сөйгәнен соңгы мәртәбә күреп калыр өчен, кузгалып өлгергән паромга сикергәндер...

Укучының, аптырый төшеп, болай уйлавы мөмкин: Шәмсениса туташны оныттымыни инде Фатих? Хыянәт иттеме? Юк, онытмады да, хыянәт тә итмәде. Шәмсениса бик еракта: күрешү, сөйләшү, бергәләп таң арттыру ихтыяҗы туган саен Чистайга чыгып чаба алмыйсың. Аннары Чистай кызына карата туган хисе Фатихка гадәти бер мавыгу булып тоелган, бу хиснең чын мәхәббәт булганлыгы әле аңына барып җитмәгән.

1906 елның язын һәм җәен Фатих театр һәм концертларда, танцы һәм аш-су мәҗлесләрендә, дача һәм пикникларда гына үткәргән, еш мавыккан, еш суынган икән дип уйларга ярамый. Болары да булган. Әмма эшне тиз һәм җиңел башкара алу сәләтенә ия булуы сәбәпле, Фатихның шәкертләр хәрәкәтендә лидерлык итүенә кимчелек китермәгән.

Съездга кызу әзерлек бара. «Әльислах» газетасы ай саен ике тапкыр чыгып тора. «Басылган» материалларның яртысы — Фатих иҗаты.

1906 елның 10 маенда, ниһаять, Россия татар шәкерт-

ләренең I съезды ачыла. Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Буби, Троицк, Самара һәм Себер мәдрәсәләреннән килгән утызлап вәкил катнаша. Съезд уздыруга рәсми рөхсәт-фәлән юк. Шуңа күрәдерме, әллә инде беркадәр «Иттифак» съездына охшатыпмы, күңел ачарга чыгу сылтавы белән съездны Кабан күле өстендә көймәләрдә ачып җибәрәләр.

Өч мәсьәлә карала: 1) Мәдрәсәләр ислахы; 2) Шәкертләр хәле; 3) Хәрәкәтнең методлары.

Ислах хәрәкәтендә активлык күрсәткән һәм соңрак Фатихның якын дусларыннан булып киткән Ибраһим Бикқулов болай дип язды: оешманың «...программасы, докладлары, шул җөмләдән мәдрәсәләрне ислах турындагы доклад — һәммәсе Фатихның үзе тарафыннан, яки аның юл күрсәтүе буенча эшләнәләр. Съездның рәисе, рухы Фатих була».

Менә «съезд» тәмам. Оешманың, әйтик, стратегия һәм тактикасын билгели торган зур гына карар кабул ителә. Вәкилләрнең һәркайсы аңа имзасын куя. «Әльислах комитеты» рәсми рәвештә бөтенроссия татар шәкертләренең үзәк җитәкче органы итеп таныла. Карарда тагын бер пункт бар: оешманың матбугат органын легаль төстә чыгарырга, моның өчен мая тупларга, әзерлек эшләренә керешергә.

1906 елның май һәм июнь айлары да Фатих тормышында чагыштырмача хозур, парлак һәм бәхетле дәвер булды дисәк, шаять ялгышмабыз. Чөнки шәкертләр хәрәкәте күрелмәгән колач алды, оешу ягыннан да анык рәвешкә керде. Дилбегәне үз кулында тотып, хәрәкәткә керткән өлешенең сизелерлек булганын тоеп тору егерме яшьлек егет өчен азмыни? Татар милләте, дөресрәге, аның үз кул көче белән яши торган күпчелеге бәхете хакына көрәшә торган милләт хадиме булырга теләүче Фатихның хыяллары тормышка ашып килә түгелме?

Тик бер нәрсә җитми хәзергә. Ул да булса — о б р а з о в а н и е. Мәдрәсә г ы й л е м е белән — никадәр ул тирән булмасын — бүген ерак китә алмыйсың. Фатихның якын елларга исәп тоткан программасы шул: өлгергәнлек аттестаты алу, юридик факультетка керү.

Ләкин быелгы укуы белән Фатих мактана алмый. Әллә ничаклы эш-шөгыльне берьюлы башкару аның көч-куәтенә ия булган кеше өчен дә җиңел түгел. Быелгы сабаклары беркадәр «Урталыкта» романындагы Хәсәннекен хәтерләтә. Дәрес артыннан дәресе кала. Аннан-моннан гына караштырган хәлдә барыр иде, Сергей Николаевич зәңгәр күзләрен текәп, сүзсез генә шелтәләп караячак.

Фатихның 1906 елгы язы һәм җәе берьюлы ике кояш чыккандай, балкып узган дисәк, шулай ук дөрес булмас иде. Борчулар да туып торган. Хәтта җитди, хәвефле борчулар. 6 март хатыннан түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Бу көннәрдә Казан башыма тар булып тора: Йосыф Акчураны арестовать иттеләр, хәлфәм Гассарны арестовать иттеләр, бәлки үземне дә ошбу көндә итәрләр». Дөрес, С. Н. Гассар бу юлы төрмәдә утырып калмаган. Жандарм идарәсе начальнигының губернаторга җибәргән кәгазендә болай диелә: «1035 статья буенча сорау алу өчен формаль нигезләр булмаганга, кулга алыну аны тетрәткәнгә һәм, күзе яшьләнгән хәлдә азат итүне үтенеп, революцион даирә белән арасын өзәргә вәгъдә бирүен һәм, ниһаять, сырхаулыгын исәпкә алып, ул азат ителде, әмма өстеннән җентекле яшерен күзәтү билгеләнде».

Фатих тынычланырга өлгерми, 17 март көнне «Әльислах комитеты» әгъзасы Нургали Маминны кулга алалар. Ә бит комитетның язу-сызу эшләре, газета чыгару әсбаплары һәм төрле материаллар аңарда саклана иде!

Шуннан соң безнең Фатих ярым легаль хәлгә күчә: бүлмәсен алыштыра, дусларында кунгалап йөри, туган йортына кайтканда бакчалар аша арт яктан керә башлый.

Н. Мамин, күрәсең, беркемне дә сатмаган. Фатих һәм аның фикердәшләре полиция кулына эләкми калалар. Тормыш элекке эзенә төшкәндәй була. Әмма озакка түгел...

21 июньгә каршы төндә, тентү белән килеп, Гассарны алып китәләр. Бу юлы инде хөкемгә тартырга нигез җитәрлек булган. «Төрмәдән чыгарылу белән үк,— диелә әлеге кәгазьдә,— Гассар яңадан революцион мохитка керде һәм эшче районнарының тырыш организатор-пропагандисты булып китте. Ул шулай ук Россия социал-демократик эшчеләр партиясенең Казан комитеты хәрби дружиналарын коралландыру мәсьәләсен хәл итүдә якыннан катнашты».

Тикшерү, сорау алу һәм язышулар белән ике айга якын вакыт үтә һәм менә губерна төрмәсендә яткан Гассарны сентябрьдә Себергә ике еллык сөргенгә җибәрәләр.

Фатих төрмәгә аны күрергә бардымы, киткән чагында озатып калдымы, соңгырак елларда алар күрештеләрме — бу хакта безнең кулда мәгълүмат юк. Тик шунысы бәхәссез: иманына турылыклы булып калган, Октябрь революциясен көрәшчеләр сафында каршылаган, 1918 елда ак чехлар тарафыннан үтерелгән бу гүзәл кеше, бүтән хезмәтләреннән тыш, Фатихның зур әдип булып үсүенә булышлык күрсәтте. Моның өчен без аның алдында рәхмәт әйтеп баш ияргә бурычлыбыз...

15 август көнне Мәкәрҗәдә «Мөселман иттифакы»ның 3 нче съезды ачыла. Нинди дә булса гадәттән тыш хәл комачауламаса, Фатихның бу съездга бармый калуы мөмкин түгел. Чөнки көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең берсе — мәктәп һәм мәдрәсәләр хәле.

Съезд шаулап узып китә: докладлар укыла, чыгып сөйләүләр, фикер алышулар, бәхәс, үпкәләшү, кычкырышулар була. Кырмыска оясына таяк тыгып бутаучылар, әлеге дә баягы, яшьләр — таңчылар һәм ислахчылар. Съездның мәктәп-мәдрәсәләргә багышланган утырышы чагыштырмача җәнҗалсызрак узып, яшьләр тырышлыгы белән шактый киң һәм радикаль программа кабул ителгән.

Менә көз җитә. Фатих «Музуров номерлары»ндамы, түләүле бүлмәсендәме, торып ята. Шөгыле — «Ислах комитеты», газета, үзлегеннән уку, дус-ишләре, кыз-кыркыннар белән аралашу, театр, концерт, әдәби һәм гадәти кичәләрдә булу.

Әтисе белән конфликт югары ноктасына җитә. Фатих Мәкәрҗә съездында җәнҗалчыларның берсе сыйфатында катнашкан булса, моңа гаҗәпләнергә туры килми. М. Укмасыйга ышансак, Фатих туган йортын ташлап чыкканнан бирле Зариф хәзрәт аңа аттестка әзерләнер өчен сукыр бер тиен дә бирми башлаган. Фатих биш-алты баланы русча укытып алган акчасын репетиторына түли икән. Хәер, Рабига абыстайның картыннан яшереп күрсәткән ярдәме арага кергән булыр.

Көз үз хокукын яулап алгач, кояшның яктысы һәм җылысы кимегән шикелле, Фатихның Казандагы тормышы шактый шыксызланып кала. Ара-тирә теләсә кая баш алып качасы килгән минутлары да була. Бәлки болай ук сабырсызланмас, көч-куәте бар, түзәр иде. Әмма Казаннан китәчәге инде хәл кылынган. Мәскәүдә Заһид Шамил «Тәрбиятел-этфаль» журналын чыгаруга кызу әзерлек алып бара. Вакыты җитүгә, Фатихны чакырып хәбәр бирәчәк. Булса, тизрәк булсын иде инде!

Ниһаять, көтелгән хәбәр килә һәм Фатих сәер, каршылыклы хис-тойгылар кичерә башлый: «Иптәшләремнән аерылам. дөньяда мине иң якын күрә торган йөрәккә (әнисенә — *И. Н.*) яра салам — авыр. Казаннан вә аның татарларыннан котылам — шатлык. Эш башлыйм, үземнең истигдадымны * күрәм — изтыйраб ** вә мәҗһүлият ***».

---

* И с т и г ъ д а д — сәләт, булдыклылык.
** И з т ы й р а б — икеләнү, аптырау.
*** М ә ж һ ү л и я т — билгесезлек.

19 октябрь көнне җомга вакытында Фатих, энесе Ибраһим белән берлектә, вокзалга юнәлә. Бер төркем иптәшләре анда көтеп торалар икән.

Поезд акрын гына кузгала. «Хуш, Фатих!» «Онытма, хат яз!» дигән тавышлар...

Вагонда Фатих бер сәгать чамасы уйга чумып, эчке кичерешләрен барлап, тикшереп, үз-үзен аңларга тырышып утырган. Казандагы соңгы көннәре, китәргә әзерләнүләре, туган шәһәреннән аерылу күренешләре яңадан хыялыннан кичкән.

Менә күзләре яшьләнгән әнисе:

— Улым, зинһар безгә ачуланма. Хат яз,— ди.

Менә шактый җиңел табигатьле, ваемсыз энесе Ибраһимның, җитдиләнеп китеп, хафага төшүе:

— Абый, мине онытма! Беләсең әтинең холкын. Син киткәч, миңа тагы да уңайсызрак булыр.

## 5

Шунысы да мәгълүм булсын, милләт балаларын тәрбияләү кебек изге эшне башлап җибәрү өчен Фатих Әмирханны көтеп утыручы Заһид Шамил — легендар Шамилнең оныгы.

Дагыстанның Россия составына керүе, тарихи перспективада караганда, әлбәттә, прогрессив акт. Ләкин бу эле тау иле мәрхәмәтле ана кочагына керде дигән сүз түгел. Патша самодержавиесе, миллионлаган үз «балалары» — крепостной крестьяннарның җелекләрен суырган бер вакытта, «үги балалары»на якты йөз һәм мәрхәмәт күрсәтә алмаган, билгеле. Дәүләт чиновниклары һәм гаскәр башлыклары, җирле феодаллар белән бер булып, халыкны буйсындырырга, кол итәргә, аның кул көченнән рәхимсез файдаланырга керешәләр. Ирек сөюче тау халыклары моңа риза була алмыйлар, билгеле. Көчәеп киткән милли азатлык хәрәкәтенә әлеге Шамил җитәкчелек итә башлый.

Карашлары, тоткан юлы һәм гамәлләре белән каршылыклы шәхес бу. Дагыстанда феодаль таркаулыкны бетерүгә көч куюын, халык массаларының хәлен азмы-күпме җиңеләйтү хакына рус һәм бүтән милләт крестьяннарының дошманы булган самодержавиегә сизелерлек ударлар ясавын файдага түгел дип әйтә алмыйбыз. Шул ук вакытта дин байрагы астында баруы сәбәпле азатлык сугышының, ара-тирә газават рәвешен алып, рус һәм тау халыкларының үзара якынаюына күпмедер тоткарлык ясавын да әйтеп китәргә кирәк.

Тик ни генә булмасын, шәхси мәнфәгатен бер якка атып, егерме биш ел буе патша сатрапларына каршы кыю һәм оста көрәш алып барган, соңгы чиккә кадәр үз иманына турылыклы булып калган бу талантлы шәхес ихтирамга лаек. Кулга төшкәч, ботарлап ташлыйсы урында, Шамилнең исән калдырылуы һәм Калуга шәһәренә сөргенгә генә җибәрелүе очраклы хәл булмаса кирәк.

Сөргендә дә, күрәсең, Шамилнең яшәү шартлары бик үк начар булмаган. Олы улы Гази-Мөхәммәт Төркиягә китеп укыган. Икенче улы Мөхәммәт-Шәфи, Россиядә укып, гаскәри хезмәткә кергән, полковник дәрәҗәсенә ирешкән. Кайсыдыр елда аны, генерал-майор чины өстәп, отставкага чыгаралар. Шуннан соң Шәфи Шамил Казанга күчеп килә.

Шәфи Шамилнең улы Заһид 1870—1871 еллар тирәсендә Калугада дөньяга килгән. Ни өчендер Төркиядә агасы Гази-Мөхәммәт гаиләсендә үскән, шунда лицей тәмам иткән. 1898 елда ул Казанга, әтисе йортына кайта һәм озакламый касимлы купец Байбеков кызына өйләнә. 1902 елда инде без аны Мәскәүдә, кайнатасының Цветной бульвардагы ике катлы өендә яшәп ятканы хәлдә күрәбез.

Ф. Әмирханның хөрмәт белән телгә алуына караганда, Заһид Шамил прогрессив карашлы кеше булган. Татарлар белән якыннан аралашкан, ул гына да түгел, тәрәккыйпәрвәр милләт хадимнәренең берсе санала башлаган.

...22 октябрь. Фатих — Мәскәүдә. 24 октябрь тарихлы хатында мондый сүзләр бар: «Заһид әфәнде саясендә * вакыт бик рәхәт уздырыла. Заһид әфәнденең истикъбаль ** вә мөгамәләләреннән типичный редактор бюрократ түгел, бәлки башка иптәшләр кеби бер күңелле иптәш идеке күренмәктәдер. Хәзер Москваның иң әгъла бер урамында (Петровка) Мәрьям Шамил квартирында гостинаяда икамәт итәм».

Тагын бер «Шамил»! Бусы кем тагы? Сораштыру, архивка керү, актарыну Әмирхановларның электән үк Шамилларга кечкенә генә кагылышлы булуын күрсәтә.

Казанда Апаков фамилиясен йөртә торган берничә могтәбәр гаилә яшәгән. Арада беренче гильдия купецы да бар. Зариф хәзрәтнең сеңелесе Мәрьям Апаковларның берсенә — уртакул сәүдәгәр Шәкүргә кияүгә чыккан. Хатта телгә алынган Мәрьям, дөресрәге Мәрьямбану исә —

---

* Сая — күләгә, ышык.

** Истикъбаль — киләчәк, булачак. Монда: каршы алу, хөрмәтләп каршылау.

потомственный почетный гражданин Ибраһим Апаков кызы. Калугада чагындагы беренче хатыны (Заһидның анасы) үлеп киткәч, Мөхәммәт-Шәфи Шамил Казанда әнә шул Мәрьямбану Апаковага өйләнгән. Тукай урамындагы «Шамил йорты» дип йөртелә торган өй, Ибраһим Апаков акчасына салынып, Мәрьямнең мәһәре рәвешендә килгән булса кирәк.

Фатих килгәндә генерал Шамил инде үлгән була. Мәрьямнән туган ике кызы, кияүгә чыгып, бу оядан күчеп киткәннәр, олыгайган Мәрьям ханым япа-ялгыз торып калган.

Казаннан гаип булып тору ихтыяҗыннан тыш, безнең Фатих Мәскәүгә зур өмет, хыял һәм планнар белән килде. Барыннан да элек, хезмәт хакы ала башлап, һичкемнән бәйсез һәм хөр яшәү. Икенчедән, типографиядә басыла торган чын журналда гади хезмәткәр генә түгел, бәлки җаваплы секретарь булып эшләү, үзе дә язу, радикаль фикерләрен балалар һәм балаларның ата-аналары аңына сеңдерү. Ниһаять, өченчедән, Казанда аксабрак барган һәм ахырда өзелеп калган укуын дәвам иттерү, яңача һәм тәртипле алып бару.

Баштагы икесе тормышка ашты. Ә менә өченчесе...

Егерме берен тутырып килә торган безнең Фатих Мәскәү чаклы Мәскәүгә килеп урнашты, яңа даирә эченә керде. Җитмәсә, кесәдә акча чылтырый башлап, кием-салымны яңа шартларга яраклы рәвештә алыштыру мөмкинлеге туды, төшкә дә кермәгән җиһазлы «аппартамент»-та яши. Кыскасы, аның Мәскәүдәге беренче айлары кәеф-сафа беләнрәк үтә башлый. («Москвадагы татар вә хәтта рус аристократларыннан, хәтта бюрократларыннан әллә никадәр гаиләләр белән таныштым. Һәр кич дип әйтерлек вечерларда, балларда йөрергә туры килә» — 9 январь, 1907 ел).

Фатихның килү хөрмәтенә Заһид Шамил, күрәсең, үз өендә мәҗлес уздырган. Игътибар үзәгенә эләккән Казан егете сынауны уңышлы үткән булырга кирәк. Кунак ашы кара-каршы диләр бит: Мәскәүнең могтәбәр гаиләләре дә шундый ук кичәләр ясый башлыйлар. Боларында да Фатих кадерсез кунак булмаган.

Шамиллардагы кичәдә Фатих бер генерал кызы белән таныша. Танцевать итәләр, сөйләшеп утыралар һәм, үзе әйтмешли, «и так далее». Аннары генералның өендә очрашалар. Сөйләшә-сөйләшә тагын танцевать итәләр. Бервакыт генерал кызы, кыюланып китеп, егетне аулак бүлмәгә алып керә. Араларында мондый сөйләшү була:

— Мин сездән бер нәрсә сорасам, гаеп итмәссезме? Һәм дөрес җавап бирерсезме?

Фатих, югары тәрбия алган кешеләрчә, нәзакәтле итеп:

— Пожалуйста,— дип куя.

— Миңа әйттеләр, сез будто-бы социалист? Шул сүз дөресме? Өмет итәм, дөрес түгелдер...

Фатихның ул вакыттагы яшьлек максимализмына аристократка кызның игътибарын җәлеп итү теләге кушылган булса кирәк, ул кырт кисеп җавап бирә:

— Совершенно верно, социалист.

Кыз башта куркып китә, аннары тынычлана төшеп, егеткә томырылып карый да болай ди:

— Соң бит сез бик милый, бер дә куркыныч түгел.

— Разве вы думаете, что социалисты все страшны?

— Это несомненно.

Социалистларның очраган бер кешене үтерә торган явызлар булмаганлыгын кызга төшендерү өчен Фатихка ярым сәгатьләп вакыт кирәк булган.

Укуы мәсьәләсенә килгәндә, нинди дә булса курс тапканмы, әллә репетитор яллаганмы, нәрсә укыган, ничек укыган, без боларны белмибез. Тик шунысы билгеле: беренче айларда аның укуга бик үк вакыты калмаган. («Хәзер инде ул вечер-балларны ташлап, чынлап укырга тотынам» — 7 декабрь). Гыйлем эстәү артыннан йөрүе соңрак күпме җимеш биргәндер, бусы да безгә караңгы. Тик шунысын әйтергә мөмкин: танышларының рус яшьләре хисабына да артуы укып йөрүе белән бәйле булырга тиеш. Шуларның берсе, соңрак кайдадыр провинциядә стоматолог булып эшли башлаган Кузнецова фамилияле туташ яисә ханым Фатихка язган хатында болай ди: «Безнең Мәскәүдәге хәл-әхвәлебезне бик рәхәтләнеп искә төшерәм». Хатта тагын гомуми танышларыннан Люда һәм ниндидер Гали телгә алына.

«К. М.» инициалын имза итеп Германиядән хат язган бер рус егете дә Ф. Әмирханның Мәскәү танышы булса кирәк.

Укуына комачаулык итсә дә, әлеге кичә һәм баллар, театр һәм концертлар, төрле кешеләр белән танышу, утырдаш булу, уйнау-көлү Фатих өчен һич тә зарарга гына булмаган. Тарих һәм хәзерге хәл, сәясәт һәм фәлсәфә, мәхәббәт һәм гаилә, милләт язмышы һәм балалар тәрбиясе буенча ничаклы фикер ишеткән ул! Кайсын хуплаган, кайсы белән телдән һәм эчтән бәхәсләшкән.

Мәскәүнең үзенә күрә бер аристократик даирәсенә килеп кергән Фатих беренче мәртәбә калага аяк баскан авыл

малае яисә пишкадәмнәр мәҗлесенә эләккән рөшдия шәкерте хәлендә калмаган. Беренче көннәреннән үк ул үзен бер дә ким кеше түгел итеп куя. Тора-бара Мәскәү могътәбәрләренең дә әллә кая ерак китмәгәнлекләрен, күбрәк тыштан ялтыраганнарын күрә, аларга үзе өстән карый башлый. («Шундый вакытлар була ки, шул аристократка вә аристократларның кыланышларыннан (извини за выраж.) косасылар килә»).

Фатихның төп эшенә — «Тәрбиятел-этфаль»дә секретарьлык вазифасын башкаруына кайтыйк. Тик бу урында Р. Ибраһимов-Алушига язган хатындагы сүзләре сәерсендерә. Журналның эчтәлегеннән зарланасың, ди ул. Ләкин аның эчтәлеген билгеләүдә минем катышым юк. Икенчедән, мин бу журналга Москвада торырга мөмкинлек бирә торган чара итеп кенә карыйм.

Юк, «Тәрбиятел-этфаль» — Ф. Әмирханның беренче «законлы» баласы, яраткан баласы («законсызы» — яшерен «Әльислах» иде). Төрекчә, французча, русча яхшы белеп тә, татарча ярым-йорты гына сөйләшеп, бөтенләй яза белми торган З. Шамил редакторлыгындагы журнал гарәп-фарсы гыйбарәләре белән чак кына авырайтылган саф татар телендә чыгып килә. Кем редакцияләгән аны? Билгеле инде, Фатих.

Кемнәр язган журналга? Материалларның күпчелеге имзасыз чыкканга күрә, бу сорауга җавап бирү кыен. Шулай да күбесенең Фатих тарафыннан язылганын яисә тәрҗемә ителгәнен чамаларга мөмкин. Бер хатында үзе үк бу турыда әйтеп уза. Биш номерның да «Идарәдән» дигән исем астындагы баш мәкаләсе аныкы икән. Истамбул, Мәскәү һәм Петербург шәһәрләре турындагы мәкаләләр, «Куктә күренә торган нәрсәләр», «Зилзилә», «Гөл агачы», «Дума ачылды», «Менделеев», «Гаяз», «Галимәтел-Бәнат» исемле материаллар да аның каләменнән чыккан. Моңа тагын Андерсен экиятен «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» дигән исемдә тәрҗемә итеп бастыруын өстик.

Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә: шәкерт чагында ук шигырьдә каләм сынаган Фатихның ни тезмәдә, ни чәчмәдә оригиналь әдәби әсәре очрамый. Балалар тәрбиясенә караган тәрҗемә дә публицистика. Безнең Фатихта әле, күрәсең, әдип булу теләге тумаган. Һаман да әле ул милләт хадиме «карьерасы» турында уйлап яши.

Югарыда телгә алынган хатында гаять кыйммәтле искәрмә бар. Журналда басылган мәкаләләрен санаганда, Фатих, «ләкин кирәкле җирләре төшереп калдырылган», «кирәкле җирләре төшерелгән», «иң кирәкле җирләре кал-

дырылып» дигән сүзләрне, җәя эченә алып, кыстырып бара. Кулъязмалары сакланмаганга күрә, ул мәкаләләрдән нәрсәләр сызылганын без, әлбәттә, белмибез. Соң нәрсә калган?

Менә 4-санының Дәүләт думасы мәсьәләсенә багышланган баш мәкаләсе. 17 октябрь манифестында Дума чакырырга вәгъдә ителгән булса да, ди автор, хөкүмәт моны башта ук иске тәртипләргә кире кайтуга исәп тотып эшләгән иде. Думага ул «патша хөкүмәтенең теләгенә юл куярга тиешле бер җәмгыять дип кенә карый иде». Шуңа күрә Беренче Дума белән хөкүмәт арасында низаг чыкты һәм Дума таратылды. «Һәм икенче Дума да әүвәлгесе шикелле тыңлаусыз булмасын өчен, аннан башка да үзенең максудына ирешүдә һич нәрсәдән чиркәнми торган хөкүмәт золым вә истибдат * сәясәтене тагын да куәтләндерде». Күренә ки, хөкүмәт ачыктан-ачык тәнкыйть ителә һәм халыкка каршы көч итеп бәяләнә. Мәкаләдә патшаның үзенә карата да итагать күрсәтү сизелми. Самодержавие исәнимин калган тәкъдирдә, Думаның халыкка көткәннәрен бирә алмаячагы аның өчен инде көн кебек ачык. Димәк, яшь Әмирхан инде конституцион иллюзияләрдән азат. Бу исә революцион-демократик позициягә басу дигән сүз. II Дәүләт Думасының ачылуына багышланган язмасы да бу фикерне куәтли.

Дума утырышы булачак көнне меңләгән халык Таврида сарае каршына җыелган икән. Бина полиция һәм казаклар тезмәсе белән уратып алынган.

Менә депутатлар килә башлый. Уң депутатларны халык салкын каршылый. Уртарак юл тотучыларны: «Сәяси гаеплеләр өчен гафу!», «Җир һәм Ирек!» — дигән тавышлар белән каршы алып, беркадәр якты чырай күрсәтә. «Кызыл бантлар таккан социал-демократлар вә башка сул әгъзаларны,— дип дәвам итә автор,— бигрәк тә шатлык вә мәхәббәт белән каршы алып, куллар өстендә йөрткәннәр вә һәр яктан «Иптәшләр, сәясиләргә гафу, җир, ирек алыгыз!» дигән тавышлар белән бөтен Петербургны яңгыратканнар».

Фатихның үзен социалист хисаплавы белән әлеге мәкаләләрдәге мәгънәнең үзара ярашканын күрү кыен түгел. Нинди социалист һәм нинди социализм тарафдары булганлыгын киләчәктә күрербез. Хәзер исә аны Мәскәүдән озатырга вакыт җитте.

---

* Истибдат — реакция.

## 6

Казаннан, аның бер ише кешеләреннән, гаиләдәге җәнҗалдан туеп киткән булса да, озакламый туган шәһәрен, туган-тумачасын, дус-ишләрен, бигрәк тә анасын сагына башлый. «Һәр хат, һәр кечкенә генә хәбәр, шул тарафтан искән һәр җил бик кадерле була икән». Февраль кергәч үк ул Заһид Шамилга язын Казанга кайтып ял итеп килү теләген белдергән. Нашир исә, секретаренең яңадан килмәү ихтималыннан куркып, җәйне үзе белән бергә сәяхәттә үткәрергә тәкъдим иткән, әмма теләгенә ирешә алмаган.

Җир яшәрә башлап, Идел дәрьядай җәелеп киткән һәм кош-кортлар дәртле чыркылдашкан көннәрнең берсендә Фатих, ниһаять, Казанга кайтып төшә. Ананың, билгеле инде, куанычы эченә сыймый, улын кая утыртырга, ни белән сыйларга белми. Ата да караңгы чырай күрсәтми. Туган-тумачалары, дус-ишләре килеп торалар. Йөремсәк Фатих үзе дә визитлар ясый, иптәшләрен барлый: кем бар, кем юк, ни уйлый, ни белән яши.

Үзе әйткәнчә, бу елның җәен ул фәкать истирәхәт кылып, ягъни ял итеп үткәргән. Фатихның күп вакыты, былтыргы кебек, Югары Осланда, Ибраһим Кулиевларда һәм Аитовлар дачасында узган дип уйларга кирәк.

Элек тә игътибар үзәгендә булган Фатих бу җәйдә билгеле бер даирәнең төше, җаны булып китә. Аның Казаннан югалып торуы үзен, күрәсең, нык кына сиздергән. Юксынганнар, сагынганнар. («Күптән түгел генә Ибраһимнан хат алдым. Казанда мине бик көтәләр имеш. Һич көтмәгәндә Фатыйма Юнусовадан да бер хат алдым, «гаҗәеп сагындык, Казанга кайтыгыз», дип яза»). Өстәвенә ул Мәскәү күргән, Мәскәү һавасын сулаган.

Иптәшләренең, дус һәм таныш кызларының өметен җимермәс өчен, Фатихка югартын торып, акыллы сүзләр генә сөйләргә, фәлсәфәгә чумарга кирәк иде дә, характеры андый түгел. Ул күбрәк «җүләр сата», Мәскәүдә булган хәлләрне, үзеннән дә кушып, мәзәкләштереп сөйли, могтәбәр затларны, үзләренә охшатып, көлке кыяфәткә кертеп күрсәтә. Берәрсе, белдекләләнеп, сүзне җитди мәсьәләгә борырга теләсә, Фатих мондыйрак реплика белән чабуыннан тартып җиргә төшерә:

— Мелла кем, син юкта йоклап ятмагансың. Карале, кемнән тектерәсең? Костюмың ифрат килешеп тора.

...Үзендә әллә ничаклы көч-куәт сизгәне хәлдә, якты дөньяга, тормышның матур якларына гашыйк булып, ки-

ләчәккә зур өметләр баглап яши башлаган Фатихны Казанда коточкыч фаҗига көтеп торган икән: 15 август көнне паралич сугып, аның аяк-куллары хәрәкәтсез кала, бер күзе күрмәс була.

Казанның татар төбәге шау килә, бигрәк тә печән базарчылар тантана итәләр:

— Зариф мулланың урыска сатылган чукынчыгын каһәр сукты!

— Кызыл авызга остаз бәддогасы төште!

Нидән шулай булды? «Авыру тарихы» сакланмаганга күрә, без бу сорауга кистереп җавап бирә алмабыз. Телдән-телгә күчеп килгән имеш-мимешләр, истәлекләргә кереп калган фараз һәм раслаулар белән генә чикләнергә туры килә. Мещаннар уйлап чыгарган һәм әдипнең шәхесен кимсетә торган уйдырмаларны, ике дә уйламый, читкә атыйк. М. Укмасый версиясе дә тәнкыйтьне күтәрми. Хәл белергә килгән Укмасыйга Фатих, янәсе, бу хәлгә төшүенең сәбәбен болай аңлаткан:

— Трамвай юлын (*Мәскәүдә — И. Н.*) аркылы чыкканда гына шулай булдым. Ток сукты бугай.

Ф. Әмирхан II версиясен кабул итәргә мөмкин. Эссе бер көнне кемнеңдер дачасында вакыт үткәргәндә, Фатих, энесе Ибраһим һәм Вафа Бәхтияров белән берлектә, тирләгән килеш су коенган. Аннары, беркадәр юангач, шәһәргә кайтырга чыкканнар. Кольцога җитәрәк Фатих кинәт туктаган да «миңа нидер булды, үземне начар хис итәм» дигән. Ул да булмый, аяклары хәлсезләнеп, җиргә чүгә. Извозчик яллап үз бүлмәсенә кайтарып салалар.

Булачак әдипнең көннәре больница һәм клиникаларда уза башлый. Дәвалану нәтиҗәседерме, әллә инде организмы җиңгәнгәме, беркадәр вакыттан соң, куллары хәрәкәткә килә, күзе элекке хәленә кайта. Ә аяклар... Организм үзе дә, дәва һәм вакыт та көчсез булып кала. Алар инде беркайчан да йөрмәячәкләр...

Әнә шул килеш Ф. Әмирханның тормышында яңа чор, батырлык үрнәге итеп саналырлык яңа дәвер башлана. Кем белә, бәлки әле Фатихның бәхетсезлеге күтәрелеп килә торган татар демократик әдәбияты бәхетенә булгандыр. Фаҗигага юлыкмаса, киләчәктә аның нинди юл сайлаячагын төгәл генә әйтү кыен. Бу хәлендә исә аның өчен иң кулае — нәфис әдәбиятка, сурәт дөньясына, хыял дөньясына йөз тоту. Хәерле юл сиңа, бәхетсез дә, бәхетле дә Фатих...

*4 бүлек*

## ЯНАР ТАУ ИТӘГЕНДӘ

### 1

Алты ай буе аерылып торганнан соң урын өстендә калган Фатих гаиләнең игътибар үзәгенә әйләнә. Ананы әйткән дә юк: Фатихы терелү ягына киткәч тә, бик сирәк ялгыз калдыра. Сылтау табып та, сылтаусыз-нисез дә бүлмәгә кереп чыга.

— Менә моны ашап кара әле.

— Эчеп җибәр шушыны, файдасы тимәсме.

— Берәр нәрсә кирәкмиме?

Авыру йокыда чакта аяк очларына гына басып керә, улының тын алуын тыңлап тора, юрганын рәтли. Бу чаклы кайгырту беркадәр ялыктырса да, ана мәхәббәте хакына Фатих ризасызлык белдерми, күп дигәндә, «болай иркәләсәң, мин юри терелмәм» кебек сүзләр белән чикләнә.

Атаның да йөрәге таштан түгел икән. Врачларга һәм даруга акча кызганмый. Улының әле аякка тиз басмаячагы ачыклангач, резина тәгәрмәчле коляска-кресло сатып ала. Хезмәтенә «малай», ягъни үсмер егет тота башлый. Тарантасы белән атын аңа тәгаенли.

Фатих янына көн саен дип әйтерлек дуслары һәм иптәшләре өерләре белән киләләр. Хәтта «урыс» һәм «марҗа»лардан да хәл белергә килүчеләр булгалый. Көлешәләр, чыркылдашалар...

Фатихның көннәре тагын ничек үткән соң?

1907 елның 25 ноябрь хатында мондый сүзләр бар: «Хәзер, 5 нче ноябрьдән бирле, клиникада ятам. Авыруның берникадәр файдасы булды: өч ай эчендә күп нәрсә укып чыктым». Соң нәрсәләр укыган? Җавап бирү кыен. Чөнки ул көндәлек алып бармаган, бу вакыттагы блокнот-фәләне сакланмаган. Хатларында вак-төяк хәбәрләр, уен-көлке, мәзәк җитәрлек булса да, җитди мәсьәләләр сирәк кузгатыла, әдәби симпатия һәм антипатияләре, нәрсәне ошатуы, нәрсәне ошатмавы турында бер сүз дә юк. Күрәсең, ул үзен «галим» итеп танытырга, эрудициясе белән шаккатырырга ихтыяҗ сизмәгән.

Хәле авыр чакта фикерләү сорамый торган җиңелрәк нәрсәләр укыган булыр. Терелү ягына киткәч исә, билгеле бер максат куеп, системалы төстә укырга керешкән. Максат дигәнебез, билгеле инде, еракта җемелдәп, һаман үзенә чакырып торган маяк — өлгергәнлек аттестаты. Вакыт

җитәрлек: көннәр, атналар, айлар буе ул урын өстендә. Көндезләрен милләтне тәрәккый иттерү һәм икмәк хакына эшләп, кичләрен мәҗлесләрдә, концерт яисә танцыларда үткәрәсе, кызлар озатып таң аттырасы юк.

Мәкаләләрендә, хикәя, повесть һәм пьесаларында иң күп телгә алынган исемнәр түбәндәгеләр: Фонвизин, Крылов, Жуковский, Гоголь, Лермонтов, Тургенев, Толстой. Соңгысына Фатих аеруча күп вакыт биргән кебек тоела. Чөнки имтихан өчен кирәк булудан тыш, даһи язучының 80 яше тулу бәйрәме якынлашып килә. 1908 елның 9 мартында, ягъни юбилейга ярты ел вакыт калганда «Толстойның 80 еллык юбилее» дигән мәкалә белән чыгуы күп нәрсә турында сөйли. Б. Шәрәфнең Фатихка язган бер хатындагы сүзләр дә кызыклы: «Анна Каренина»ны бетердем. Толстойның иске нәрсәләрен һәммәсен укып чыгарга илтизам * иттем. Нөсхәсен тапкач та «Война и мир»ны укыячакмын» (1908, 11/IX). Толстой дөньясына чумган Фатих, бу турыда сүз чыккач, күрәсең, бөек әдипнең әсәрләрен укырга киңәш биргән. Борһан абзасы ул киңәшне колак яныннан гына үткәреп җибәрмәгәнлегеннән хисап бирә.

Гоголь уңае белән дә якынча шуларны әйтергә мөмкин. Ул да программада зур урын тота. Аның да тууына 100 ел тулу көне якынлашып килә. Аның турында да Фатих мәкалә язып чыга. Кыска мәкалә генә түгел, бәлки биографиясен бирә, иҗатына кыскача күзәтү ясый.

Пушкинга да ул, һичшиксез, яңадан кайтып, кайбер әсәрләрен кабат укыган, зиһенен тулыландырган. Тургенев әсәрләрендә чагылыш тапкан рус тормышының 60—70 еллары белән XX йөз башы татар тормышы арасындагы охшашлык турында Ф. Әмирхан үзе үк мәкаләләрендә каткат әйтеп уза. «Аталар һәм балалар» авторының романнары Фатихка «өстәл өсте» китаплары булып хезмәт иткән дисәк, шаять хата булмас.

Ф. Әмирханның язганнарында Чехов телгә алынмый. Әмма, араларында гаҗәеп охшашлык. Икесе дә прозаик һәм драматург. Икесе дә менә дигән юморист һәм сатирик. Икесе дә нәфис психологик хикәя һәм повесть авторлары. Икесендә дә мещанлыкны фаш итү һәм урталыкта калган интеллигенция темасы зур урын тота. Инде килеп «Акчарлак» белән «Тигезсезләр»не янәшә куеп карагыз. Гаҗәеп аваздашлык!

* Илтизам — үз-үзенә йөкләү.

Юк, Фатихның Чехов иҗаты белән кызыксынмавы мөмкин түгел. Чеховны яратып укыганлыгы турында М. Укмасый да әйтеп уза. Моңа соңгы вакытта табылган фактны өстик. «Сюжеты читтән алынды» дигән аңлатма белән чыккан «Хәзрәт үгетләргә килде» исемле хикәясе А. П. Чеховның «Винт» новелласыннан файдаланып язылган икән *.

Шул ук истәлектә Фатихның А. М. Горький белән дә кызыксынганлыгы әйтелә. Әмма, утызынчы елларның ахырына хас булганча, М. Укмасый, Горький әсәрләренең эчтәлегеннән бигрәк, телен, язу рәвешен, сәнгатьчәлеген ярата иде дип өстәргә ашыга.

Исәннәрдән тагын Леонид Андреев әсәрләрен Фатих кызыксынып укыган булырга тиеш. Әдәби тәрҗемә белән артык мавыкмаган Ф. Әмирханның 1908 елда «Рассказ о семи повешенных» повестен татарчалаштыруы шул турыда сөйләсә кирәк.

Сүз арасында шуны да әйтик: әсәрнең татарча исеме — «Асылган җиде кешеләр хикәясе» озак вакытка сөйләргә сүз булган. Фатихны өнәмәүчеләр хихылдап көлгәннәр: ислахчылар әдибе безне язарга өйрәтә, ә үзе телдә элементарный хата җибәрә. Дус-ишләрен бу хәл гаҗәпләндерү катыш көендергән.

Безнең заманның бөек футболчысы Пеле бер вакыт бөтенләй буш капкага биш метрдан тупны тибеп кертә алмаган икән. Әнә шуның шикелле, бөекләрнең бик сирәк очракларда гади кешеләр дә эшли алмый торган хаталар җибәрүен тарих белә.

Фатихның укыганнары, билгеле, болар белән генә чикләнми. Тарих белән дә шөгыльләнгән ул. Аттестатка әзерләнүдән тыш, публицист буларак эшчәнлеге дә шуны таләп иткән. Гомуми культура дәрәҗәсен күтәрү өчен укыган китаплары да байтак булырга тиеш.

Фатихның бу чордагы төп эше — «Әльислах». Югарыда китерелгән хатта тагын мондый сүзләр укыла: «Әльислах» газетасында сәркәтиплек иттем һәм хәзер дә итәм. «Әльислах» сезгә барып ирешкән булса, баш мәкаләләр вә «Дамелля» имзалы мәкаләләрне аяксыз дустың Фатих кулы белән язылган дип уйларсың! Вә шулардан карап, авыруның миңа рухани тәэсире булганмы, юкмы икәнне белерсең».

Чынлап та тәэсире булганмы, мәкаләләрендә үзгәреш

* Карагыз: Р. Гайсин. Бер сюжетның сере. («Казан утлары», 1985, № 12).

сизеләме? Газетаның баштагы 3—4 санын күздән кичерәбез дә гаҗәпләнү катыш куану белән нәтиҗә ясыйбыз: юк, бернинди дә үзгәреш сизелми. Хәер, үзгәреш бар, әмма уңай якка: фикер аныклыгы һәм тирәнлек, юмор һәм тапкырлык, телдә сурәтлелек һәм йөгереклек бермә-бер арткан.

Фатих гомерлеккә аяксыз каласын әле, күрәсең, башына да китерми, булган хәлгә, әйтик, җигүле ат астында калып аягы сынгандай, вакытлы бәхетсезлек итеп кенә карый, сау-таза хәленә кайтачагына ышанып яши.

25 ноябрь. «Хәзер инде хәлем бер дәрәҗәдә яхшыланып, терелү тарафка китте: кулларымнан вә күземнән паралич китеп, аякларымда аз-маз хәрәкәт күренә башлады. Алай да бөтенләй сәламәтләнүне тиз көтмим!»

12 май 1908 ел. «Хәзер үзем бер гипнотизерда лечиться итәм. Бәлки берәр файдасы булыр».

15 сентябрь. «Хәзер тәпиләрем, әлхәмделиллаһи раббелгаләми, чибәрләнәләр. Тизлектә таякка өстерәлә башлармын дип ышанам».

26 октябрь. «Сәламәтлек акрын алга бара. Впрочем, акча юклыктан бик күп вакыты җиткән дәваларны кылмый торырга туры килә».

2 декабрь. «Агаң хәзер зур үсеп килә инде. Ихтимал, тиздән тәпи дә йөри башлар».

23 апрель, 1909. «Хәзер сәламәтлек өметле сурәттә алга барган шикелле күренә, җәй уртасына кадәр йөри башлармын дип өмет итәм».

19 май. «Бер дүрт-биш көннән фактически йөри башлавымны көтәм. Әүвәлге адымнан соң, инша алла, сезгә язып җибәрермен».

Ике елга якын Ф. Әмирхан, йөри башлаячагына ышанып, димәк, киләчәккә өмет баглап яшәгән. Хәер, акыл иясе һәм зиһенле кеше буларак, күңеленә шик тә кергәләгәндер. Әмма терелү теләге гаять көчле булганга, азмыкүпме алга китеш аңарда бөтенләй савыгу өмете тудырган. Дәвалаучы врачлар да, күрәсең, хакыйкатьне яшерә төшеп, өметләндереп торганнар. Врачлар да андый-мондый гына түгел, Казанның танылган белгечләре. Шунысы кызык, әнә шундый табиплар белән генә канәгатьләнмичә, үзе теләпме, ата-анасының, туган-тумачасының кыставы беләнме, төрлечә дәваланып караган. Замандашының язуына карaганда, электр һәм гипноздан кала, ул үлән белән дәвалаучы карчыклар, им-том итүчеләр, хәтта камчылы ишан «осталыгына» да мөрәҗәгать иткән. Боларына ышану

кыен. Булган тәкъдирдә дә, гадәтенчә шуклыкка бирелеп, әлеге «табип»ларның кыланышларын сәер итү һәм түләүсез спектакль оештыру өчен булыр.

## 2

«Әльислах»ка әйләнеп кайтыйк. Ел ярымга сузылган хәзерлектән соң, ул, ниһаять, идән астыннан чыгып, якты дөньяга йөзен күрсәтте. Бу вакыт эчендә нәрсә эшләнгән соң? Төп эш, билгеле, сәрмая, ягъни тиешле сумада акча туплау. Ф. Әмирханның әйтүенчә, мондый эшне башлап җибәрер өчен кимендә дүрт-биш мең сум акча кирәк. Ярый ла, берәр меценат яисә байлар ширкәте янчыгын чишсә. Әнә «Әхбар». Артында калын кесәле байлар торгач, матур гына яшәп ята. Алтын приискасы хуҗалары Рәмиевләр акчасына чыга башлаган «Вакыт»ның хәле дә зарланырлык түгел.

«Әльислах»ка исә андыйга өмет багларга туры килми. Чөнки ул, социал-демократлар җырын җырлап, иттифакчы милләт хадимнәренең һәр эшен, һәр сүзен тәнкыйть астына ала торган «җәнҗалчы Ислах» оешмасының органы булачак.

Соң акча кайдан алганнар? Беренче чыганак — шәкерт тиеннәре. Шулар газетасы икән, шулар күтәрешергә тиеш. «Ислах комитеты» Казан мәдрәсәләрендә эш алып бара, татарлар яшәгән бүтән шәһәр, авыл мәдрәсәләре белән язышa, мөштәриләр туплый, иганә җыя. Әмма моннан килгән белән генә ерак бара алмыйсың. Тагын шул ук байларга, дөресрәге, аларның алдынгырак карашлы улларына барып егылырга кала. Исмәгыйль Аитов, Газиз Гобәйдуллин һәм Хәкимев фамилияле бер бай малаеның, мәсәлән, «Әльислах» фондына шактый акча керткәнлекләре мәгълүм.

Икенче эш, гариза язып һәм бүтән рәсми якларын җиренә җиткереп, хөкүмәттән рөхсәт алу. Комитет редактор һәм нашир итеп Вафа Бәхтияровны тәгаенләгән. Дөрес, мәгълүматы, фикер-карашлары белән аерылып тормый, язу-сызу эшенә сәләте дә чамалы. Аның каравы күндәм һәм тырыш. Рөхсәт алу өчен яшең 25тән ким булмаска тиеш. Бу яктан да ул туры килә.

Көннәрдән бер көнне Вафа Бәхтияров Учительская школада укый башлаган Гыймад Нугайбековтан гариза яздырып ала да губернатор канцеляриясенә илтеп тапшыра. Билгеле инде, полициягә һәм жандарм управлениесенә кәгазь китә: кем ул, нинди кеше, ышанычлымы? Җа-

ваплар уңай: Саратов губернасы, Хвалыйн өязе, Зимничә авылыннан; атасы хөкүмәткә тугрылыклы мулла; «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмам иткән, хәзер мөселман балалары приютында дин һәм татар теле укыта; сәяси ышанычлылыгын шик астына куя торган мәгълүматлар юк.

Менә бер заман рөхсәт кәгазе кулга керә. Эшне башлап җибәрерлек акча инде тупланып җиткән. Беренче саннар өчен материал бар. Редакциягә дип «Болгар»дан бүлмә алына, басмаханә белән договор төзелә. Һәм, ниһаять, 3 октябрь көнне «Әльислах»ның 1 санын кулга тотып уку бәхетенә ирешәләр. Эре хәрефләр белән исеме басылган, елы, көне, чыга торган урыны, бәясе күрсәтелгән. Баш мәкалә дә, бүтән төр мәкаләләр дә бар. «Дахили (эчке) хәбәрләр», «Казан хәбәрләре», «Мәдрәсә хәбәрләре» дигән рубрикалар ачылган. Шигырьгә дә урын бирелгән. Газета редакторның исем-фамилиясе белән төгәлләнә: нәшире һәм мөхәррире Вафа Бәхтияров дигән.

Фаҗигагә юлыгып, урын өстендә калгач, Фатихның күп елларга сузылачак көн тәртибе, хезмәт режимы калыплаша.

Ибраһимны чыгарып, бүлмәдә үзен генә калдыралар. Ике тәрәзәсе ишегалдына, бер тәрәзәсе бакчага карый. Җиһазы хәзергә гадәти генә. Тимер карават, карават янында өстәл. Этажерка һәм урындыклар. Кием шкафы да булмый калмас. Чөнки зәвык белән киенергә, вакытына карап, өс-башын еш алыштырырга ярата торган Фатихның гардеробы шактый бай. Мәскәүдә ярыйсы гына эшләп, кием-салымнан байтак нәрсә алып кайткан иде. Монда да тулыландыра тора. Бервакыт Рабига абыстай улына әйтә икән:

— Нигә бу кадәр күп төрле галыстык аласың? Дөнья кадәр акча бетерәсең...

Фатих, көлеп, болай дип җавап биргән:

— Мин бит синең улың, әни. Ул яктан, аллага шөкер, син дә ямьсез йөрергә яратмыйсың.

Дус-ишләре китеп беткәч һәм өйдә аяк тавышы тынгач, Фатих язарга утыра. Тиз яза, күп яза. Ярты төн авышканчы эшли, кайвакыт таң аттыра. Иртән соң гына уянса да, торырга ашыкмый, йоклаган булып ята. Бу аның уйлану сәгате. Тиз һәм күп язуының, төзәтми-нитми типографиягә озатуының сере әнә шунда.

Ана, билгеле, улының хәйләсен һәм мутлануын бик тиз сизеп ала да, ярату катыш ризасызлык белән «хорасан ялкавы» дигән кушамат тагып куя.

— Хорасан ялкавы торганмы әле?

— Хорасан ялкавын юындырыгыз.

— Бар, хорасан ялкавына чәй керт!

Фатихның иртәнге чәе еш кына өйдәгеләрнең төшке ашы белән бер вакытка туры килә.

Фатих, сырхаулап китеп, бигрәк тә көзге һәм язгы пычракларда, атына утырып та «Болгар»га бара алмаганда, бу бүлмә редакция вазифасын да үти. Менә мөхәррир әфәнде килеп чыга, «үз аягы» белән килеп кергән материалларны «секретаренын» өстәленә китереп сала. Киләсе санга нәрсәләр кертү, кемгә мөрәҗәгать итү, кемнән нәрсә яздыру турында киңәшә. Еш кабатлана торган тема — акча мәсьәләсе. Матбагага бурычлы калганнар икән. Кәгазь өчен дә түлисе бар. Нишләргә? Фатихның бердәнбер чыганагы — әлеге дә баягы яшь байлар кесәсе. Аталары сау-сәламәт булып эшне үз кулларында тотканга күрә, аларның да кесәсендә еш кына җил исә. Шулай да Фатих, әле берсенә, әле икенчесенә үтенеч кәгазе язып, мөхәррирргә тоттыра. Әнә шул килеш «секретарьның» җитди дә, мәзәкчел дә, туры да, кинаяле дә сүзләрен тыңлап шактый утыргач, Вафа абзагыз Фатихның төнлә язганнарын әләктереп китеп бара.

Мөхәррир белән секретарьның үзара мөнәсәбәте, эш вазифаларының бүленеше «Әльислах» тукталганчыга кадәр якынча әнә шул рәвешле була. Усал телләр сөйлиләр икән, бервакыт янәсе Вафа Бәхтияров болай дип зарланган: «Ай-һай бу мөхәррирлек эше авыр икән. Бер батман кәгазь тюгын җилкәңә күтәреп матбагага китереп ташлыйсың. Адәм күтәрмәслек гәзит кипларын почтага илтеп тапшырасың».

«Әльислах»ның баштагы биш санын өстән генә күздән кичерик. Барысының да баш мәкаләләре Фатихныкы. Болардан тыш 1 санда — өч мәкалә, 2 санда да шул чаклы. 4 санда ике мәкалә һәм газета өчен шактый озын булган хикәя — «Гарәфә кич төшемдә». 5 санда өч мәкалә һәм «Әдәбият кичәсе» дип исемләнгән репортаж. Астагы имзалары — «Фатих Әмирхан», «Ф. Әмирхан» яисә «Дамелля». Имзасыз чыккан материаллардан кайберләренең шулай ук Фатих каләме белән язылганлыгы турында сүз йөртергә нигез бар. 4 сандагы «Хисап сорыйлар» исемле мәкаләнең, мәсәлән, «Шәкертләр» дигән имза куелуына карамастан, Фатихныкы булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. Чөнки анда Яңа бистәдә дарелмөгаллимин ачып маташулары турында сүз бара. «Казан хәбәрләре» дигән рубрика астында чыккан информацияләрнең кайберләре һәм «Идарәдән җаваплар» шулай ук Фатих тарафыннан язылган.

Газетаның хәзергә атнага бер генә тапкыр чыкканын искә алганда да, моны аз дип булмый.

Җитәкчелек итүдән тыш, шул чаклы язган Әмирханның хезмәт хакы күпме булган соң?

1908 елның 17 апрельдә язган хатында түбәндәге сүзләр укыла: «Әльислах» октябрь башыннан апрель башына кадәр, ягъни ярты ел микъдары вакытта 1400 сум расход тоткан. Бу җөмләдән — мөхәррирләр вә редакция тотуга барысы 400 сум тотылган... Хәзер «Әльислах» фатир өчен 20 сум түли; секретариатка — 20 сум; мөхәрриренә — 15 сум; вак расходлар — 12—13 сум микъдарында». Димәк, редакциядә бердәнбер кеше эш хакы ала. Ул да булса редактор, ягъни Вафа Бәхтияров. Секретариатка билгеләнгән 20 сумны Фатихның эш хакы дип булмый. Чөнки сирәк очракларда булса да, авторларга әнә шул суммадан гонорар түләнгән. Димәк, Фатих аллаһы әкбәргә секретарьлык иткән кебек, басылган мәкалә, фельетон, рецензия һәм хикәяләре өчен дә гонорар алмаган.

...Октябрь башларында «Әхбар» газетасында секретарьлык итә торган Борһан Шәрәф кичкырын Фатих янына бер кунак алып килә. Уртадан кыскарак буйлы, чандыр, чәче җитү. Өстендә казаки дисәң казаки түгел, пальто дисәң пальто түгел бер нәрсә. Яше унбиш, уналтыдан артык булмас. Ислахчы шәкерттер бу, бүтән түгел... Б. Шәрәф, хуҗаның уен сизгәндәй, ашыга төшеп:

— Габдулла әфәнде Тукаев бу,— дип куя.

«Фикер» газетасында һәм «Әльгасрелҗәдит» журналында басылган шигырьләре буенча бу исем Фатихка күптән таныш. Тукайның ерак Уральскидан шушы араларда Казанга килеп төшкәнлеген ул, әлбәттә, ишеткән. Чөнки Тукай инде Сәгыйть Рәмиевне, «Йолдыз» редакциясенә кереп Галиәсгар Камалны күргән. Вафа Бәхтияров белән дә танышып өлгергән. Араларында мондый сөйләшү дә булган икән:

— «Әльислах»та кемнәр эшли?

— Хәзергә Фатих белән мин.

— Алайса, өченчегез мин булам.

Тукайның, Казандагы күренекле кешеләр янына барып, «менә бу мин» дигәндәй, әрсезләнеп танышу гадәте юк. Танышырга теләсә, үзенчә хәйлә куллана, әйләнгеч юл белән барып максатка ирешә. Үзе башлап Ф. Әмирханның өенә килеп чыгу ихтималы бик аз. Фатих, күрәсең, Тукайның Казанга килгәнен ишеткәч, иптәшләре аркылы шагыйрьне өенә чакырган яисә алып килүләрен үтенгән. Кунакны көтсә дә, Б. Шәрәф алып килгән «малайның» Тукай

булуы әүвәл мизгелдә аның башына да килмәгән. Чөнки шигырьләре Фатих хыялында бүтәнрәк сурәт тудырган.

Инде хуҗаның үзенә сүз бирик.

«Яңа кунак, мин күрсәткән урынга утыргач, бераз вакыт миңа карап торды-торды да минем сөальләремә каршы берәр генә җөмләле өзек-өзек җаваплар бирде. Аның берсе бераз зәгыйфьрәк күзләренең карашындагы үткенлек һәм караган нәрсәләреннән рәнҗегән сымаклык аз гына дикъкать иткән кешегә дә сизелерлек дәрәҗәдә куәтле иде.

Минем: «Казан яшьләрен ничек таптыгыз?» — дигән сөалемә каршы, ул кыска гына итеп:

— Казанга Уральски булырга ярамый инде,— мәфһүмендә * җавап бирде».

Ике сәгать чамасы сузылган утырышта тагын ни турында сүз барган, бу хакта Ф. Әмирхан тәфсилләп язмаганга күрә, без аз-маз чамалый гына алабыз. Билгеле инде, асрау кыз яисә Рабига абыстай чәй керткән булыр. Хуҗа кеше, ашап-эчәргә кыстый-кыстый, кунакны сүзгә тартыр өчен әле бер яктан, әле икенче яктан китереп сорау биргәндер. Борһан да тема ташлап карагандыр. Әмма мәҗлеснең ахырына кадәр дип әйтерлек, кунак язылып китә алмаганга, әңгәмә, юлсыз төшкә кереп адашкан арба кебек, һаман бер тирәдә әйләнгән.

Ф. Әмирхан истәлегендә мондый сүзләр игътибарны җәлеп итә: «...бу әүвәлге күрешү миндә Тукаев хакында билгеле бер тойгы калдыра алмады. Тукаевны мин үзем белгән татар яшьләре типларыннан берсенә дә нисбәт бирә алмадым. Аның әллә нәрсәсе минем күзләрдән, минем аңлаштан өртүле калган шикелле булды».

Без киләчәктә әдип буларак танылып җиткән Ф. Әмирханга хас бер сыйфат белән танышырбыз. Ул да булса гадәттән тыш күзәтүчәнлек, яңа күргән кешесенә тишеп карау, үзе белгән кешеләрне типларга аерып, яңа танышын шул типларның берсенә кертергә тырышу. Берәр матдәнең структурасын билгеләү һәм, теге яки бу төргә кертер өчен лупа яки микроскоп аша карый, утта көйдерә, яисә кислотага сала торган галим кебек, Әмирхан танып белергә теләгән кешесенә үзенчәлекле сорау бирә, кинаяле сүз әйтә (Аңлармы?), парадокслар яудыра (Ничек җавап бирер?).

Тукай булып киткәннән соң берничә көн үткәч, шагыйрьнең «Тәнкыйть кирәкле шәйдер» исемле мәкаләсен

---

* Мәфһүм — мәгънә.

китерәләр. Фатих, билгеле, кызыксынып укып чыга. Ошата. Ләкин бер-ике җөмләне төшереп калдыруны шарт итеп куя. «Әльислах»та эшләшә торган иптәшләр,— дип яза Ф. Әмирхан,— Тукаев моңа риза булмас диештеләр». Икенче тапкыр очрашулары «Әльислах» идарәсендә булган. Тукай мәкаләсенең язмышын белергә килгән икән. Күрәсең, уртак тел тапканнар, мәкалә газетаның 17 октябрь санында басылып чыга.

Туган якларында солдатка каралып һәм котылып кайткач, Тукай, жалованье-фәлән алмыйча гына, «Әльислах»ның даими сотрудникгы кебек редакциягә көн саен диярлек килеп йөри башлый. Шигырьләрен, мәкаләләрен бирееп бастыра, үзен редколлегия әгъзасы санап, газетаның бүтән эшләрендә дә катнаша, хәтта әдәбият бүлеген алып бара. «Менә шул газета тирәсендә без,— ди Ф. Әмирхан,— Тукай белән тәмам танышып җиттек вә бик тиз арада бер-беребезгә шәхси ихтирам саклаша башладык».

3

«Әльислах»ның мәсләгенә, ягъни тоткан юлына, һәм шуңа бәйле рәвештә Ф. Әмирханның бу дәвердәге иҗтимагый карашларына тукталып китик.

Газетаның «Казан, 3 нче октябрь» дип исемләнгән программный мәкаләсен укырга керешәбез.

Укыйбыз, укыйбыз һәм мондый җөмләгә тап булабыз: «Мәгыйшәтнең * һәр тарафы, матди вә мәгънәви җәһәтләре — һәммәсе мәктәп-мәдрәсәләр өстенә бина кылынгандыр». Автор белән бәхәскә керергә ашыкмыйк. Башта аның дәлилләрен тыңлыйк.

Бүген без файдалана, безнең яшәешне җиңеләйтә торган барлык нәрсәләрне уйлап чыгаручылар кемнәр? Кайчандыр мәктәп укучылары булган кешеләр түгелме? Географик карталарны, сынлы сәнгать әсәрләрен, мәһабәт биналарны, телефон, телеграф, трамвай, пароход һәм тимер юлларны иҗат итүчеләр, сәламәтлек сагында торучы врачлар чәчәк шикелле вакытларын мәктәптә үткәрмәгәннәрмени? Тормышның яхшы һәм начар якларын дөрес һәм тәэсирле итеп күрсәтә торган әдәбиятны тудыручылар яисә яшәешнең катлаулы мәсьәләләрен аңлатып бирүче философлар шулай ук мәктәп җимешләре түгелме?

Мәктәп-мәдрәсәләр төзек һәм заман таләпләренә җавап бирерлек булсалар, тормыш үзе нигезле, төзек, заманга

* Мәгыйшәт — тормыш.

ярашлы була. Алар иске һәм черек икән, тормышның да шуңа баглы рәвештә тәртипсез булмый хәле юк. Без татарларны карагыз. Мәдрәсәләребез 12—13 гасырлар дәрәҗәсендә торып калганга, тормышыбыз да түбәнәйгәннән түбәнәйгән, заман барышыннан әллә кая артта калган, тарайган, кысылган.

Әнә шуңа күрә, барыннан да элек, безгә мәктәп-мәдрәсәләребезне нигезеннән үзгәртеп корырга кирәк. «Менә,— ди Ф. Әмирхан,— газетамызның мәсләге».

Шушы урында тукталыйк та уйланып алыйк. Бу кадәресендә Ф. Әмирхан безгә зур яңалык әйтмәде. Моңа Қ. Насыйри һәм Х. Фәезханов, М. Акъегет-задә һәм Р. Фәхретдинов, З. Бигиев һәм З. Һади да рәхәтләнеп кул куярлар иде.

Чынлап та бит нәрсә килеп чыга? Яхшы инженер һәм врачлар, агроном һәм архитекторлар, галим һәм философлар, язучы һәм художниклар җитешер дә, шулар эшчәнлеге нәтиҗәсендә җәннәт үк булмаса да, матур тормыш туар. Халык тук булыр, дуслык, туганлык урнашыр. Пычакка-пычак килеп сугышуларның, бернинди революциянең дә кирәге калмас.

1905 елгы революция давылы шаулап узганнан соң алга сөрелгән бу фикер инде үткәнне кабатлау, ирешелгәннән чигенү генә түгел, бәлки, буржуа идеологлары тегермәненә су кою булыр иде. «Тәрбиятел-этфаль» чорында ук революцион демократик позициягә баскан Ф. Әмирханның мондый караштa торуы, әлбәттә, мөмкин түгел. Соң эш нәрсәдә? Җавап — мәкаләнең ахырында: «Моның белән бергә газетамызның сәяси мәсләге дә тәгаен ителәдер: гыйлем юлларын һәрбер сыйныфка бертигез ачык итә торган сәяси вә икътисади * сәбәпләрне үзләренә максут иткән сәяси хизепләр ** безнең дусларымыздыр».

Цензура күзеннән үтәчәген исәпләп язылган сүзләрне җәебрәк һәм аңлаешлырак итеп әйтсәк, болай була: газетаның сәяси яктан тоткан юлы илдәге политик һәм социаль-экономик стройны эшче һәм крестьян балалары мәктәпләрдә тиешенчә белем алырлык итеп үзгәртү өчен көрәшә торган партияләр программасына якын. Нинди партияләр соң алар? Билгеле инде, сул партияләр, башлыча социал-демократлар. Моңарчы әйтелгәннәр, димәк, газетаның сәяси мәсләге түгел, бәлки эш программасы.

---

* Икътисади — экономик.
** Хизеп — партия, төркем, бүлек.

Яисә менә Дәүләт Думасына багышланган мәкаләләр циклы. «Думалар» исемле мәкаләдә Ф. Әмирхан 3 июнь законы нигезендә сайлау тәртибе үзгәртелүдән соңгы 3 Думаның нинди буласы турында фикер йөртә.

«Суллар,— ди Ф. Әмирхан,— фәкыйрь халыкның тормышы хакында сөйләп, моннан соң төзеләчәк яңа тәртип эшче халык вә крестьянның үз тарафыннан вә алар файдасына урнаштырылсын дип чыктылар. Урталар (кадет һәм аларга якыннар) иске тәртипләрне аз-маз тәнкыйтьләп, «фәкыйрьләргә дә бер кисәк бирергә, ләкин эснафе мөмтазәне * какмаска кирәк» диделәр. Уңнар (октябристлар һәм уңраклар) барысы да искечә калсын, «безгә болай да рәхәт» дип, «зур байлар вә зур җир хуҗалары фикерен» алга сөрделәр. Әмма соңгылары сан ягыннан аз булганга, беренче һәм икенче Думалар күндәм булып чыкмадылар, хөкүмәт аларны таратты.

3 июнь законы исә сулларның да, урталарның да вәкилләрен киметеп, уңнарга бер урынына биш вәкил сайларга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә, суллар фикеренчә, ди Ф. Әмирхан, «Өченче Дума дворяннар думасы, «уң» дума булачак».

Яисә менә «3 нче июнь кануны вә партияләр» исемле мәкалә (17 октябрь). Әлеге закон күп кенә партияләрнең тактикасына үзгәреш алып килгән икән. Октябристларның уң канаты карагруһчыл «Чын руслар союзы»на каш сикертә башлый. Кадетларның лидерлары, октябристларга «яман атлы күренмәскә» тырышып, бер яктан сулларга таба тәнкыйть угы җибәрәләр, икенче яктан октябристларга комплимент әйтәләр. Кыскасы, уңнар да, урталар да һаман уңлаша баралар. «Сул партияләргә килгәндә,— ди Ф. Әмирхан,— 3 нче июньнең аларга иткән зарары башка һәрбер партияләргә иткәннән артыктыр. Шулай да хөкүмәтнең бу зарбәсе ** аларны уңлаштыра алмады.

Социалистический партияләргә 3 июньнең бераз тәэсире булса, ул да — с. д. ларның меньшевик вә большевиклары арасындагы хатты хәрәкәттәге (тактика) аерманың дәхи дә ачыграк күренә башлавы була белер: күптән түгел меньшевиклар рәисе Плеханов «Товарищ» газетасына язган бер мәкаләсендә большевикларның хатты хәрәкәтләрен ачы сурәттә тәнкыйть итте. Ләкин большевиклар андый тәнкыйтьләрдән генә бер дә тәэсирләнмичә, әүвәлге-

---

* Эснафе мөмтазә — өстен сыйныфлар.
** Зарбә — бәрү, сугу.

чә, Дума мөнбәренә* халыкка сүз ишеттерер өчен булган бер җир дип карауларында дәвам итмәктәләрдер».

Социал-демократларның стратегия һәм тактикаларын яхшы белү өстенә, Ф. Әмирханның, меньшевикларны өнәп бетермичә, большевикларга ачыктан-ачык симпатия белдерүен сизми мөмкин түгел. Әмма моннан чыгып, «Әльислах» социал-демократик юнәлешле газета, ә аның фактик редакторы большевик булган икән дигән нәтиҗә ясарга ярамый.

Газетаның программный мәкаләсенә кайтыйк. Соңгы өстәмәсе белән берлектә бербөтен итеп караганда да «бәйләнерлек» урыннар бар анда. Уку йортларының һәм, гомумән, мәгърифәтнең җәмгыятьне үзгәртеп корудагы мөмкинлекләрен, мәсәлән, Ф. Әмирхан арттырыбрак бәяли. Бу бер. Икенчедән, ни дигән сүз ул «гыйлем юлларын һәр бер сыйныфка (ассызык минеке.— *И. Н.*) бертигез ачык итә торган сәяси вә икътисади сәбәпләр»? Бу сүзләргә большевиклар кул куя алмаслар иде. Ниһаять, өченчедән, Дума турындагы мәкаләләрендә Ф. Әмирханның уңнарга һәм урталарга каршы тора торган сул партияләрнең барысын да социалистик партияләр итеп каравына игътибар итик. В. И. Ленин исә болай ди: «Без, элеккечә үк, социалист-революционерларның карашларын социалистик карашлар дип түгел, ә революцион-демократик карашлар дип саныйбыз» **.

Кыскасы, Ф. Әмирханның «Тәрбиятел-әтфаль» чорында ук калыпланып килә торган иманы ныгыды, анык рәвеш алды: самодержавиене аударып, демократик строй урнаштырырга, помещик һәм казна җирләрен тартып алып, түләүсез-нисез крестьяннарга бирергә, эшчеләр өчен сигез сәгатьлек эш көнен гамәлгә кертергә кирәк. Болар буржуаз-демократик революция башкарырга тиешле революцион-демократик бурычлар булганга күрә, шикләнмичә әйтә алабыз: «Әльислах» газетасы революцион-демократик хәрәкәтнең ныклы органы булган кебек, аның җитәкчесе Ф. Әмирхан иҗтимагый-политик карашлары ягыннан эзлекле революцион демократ булып җитеште.

Дөрес, мәгълүм сәбәпләр аркасында «Әльислах» битләрендә без «Долой самодержавие!», «Яшәсен җөмһүрият!», «Барлык җирләр крестьяннарга!» кебек лозунгларны очрата алмыйбыз. Әмма Ф. Әмирхан, җаен һәм әмәлен та-

---

* Мөнбәр — трибуна.

** В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. Татарстан китап нәшрияты, 1957, 10 т., 7 бит.

был, еш кына «эзоп теле» белән үзенең карашларын эзлекле рәвештә үткәрә килә.

Бер генә мисал китерим. Г. Тукайның шигырьләр җыентыгына язган рецензиясендә «Мужик йокысы» исемле ирекле тәрҗемәне тәнкыйть итеп, болай ди: «Мал юк дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә Россия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәкләр». Тәнкыйтьченең әйтергә теләгәне шул: крестьянның фәкыйрьлеге аның ялкаулыгыннан түгел, бәлки җирнең азлыгыннан һәм налогларның күплегеннән килә.

Ф. Әмирханның да иң зур, иң мөкатдәс идеалы — социализм. Ләкин изелгән милләт улы булуы һәм пролетариаттан ераграк торуы аңа революцион социал-демократларның кыю һәм бөек стратегиясен йөрәге аша уздырып, аңына сеңдерергә комачаулый иде. Аның социализмы вак буржуаз социализмнан күп ерак китмәгән иде.

Шул ук вакытта социал-демократларга симпатия белән карый торган Әмирханның зирәк акылы бер нәрсәне ачык сизә: югарыда саналган демократик үзгәрешләр белән генә эксплуатация дигән нәрсә бетми әле. Соң тагын нәрсә эшләргә кирәк? Фатихның бу сорауга әле анык җавабы юк. Томан эченнән генә тик бер фикер, бер идея җемелди... Озак еллар дәвамында кешеләрне, бигрәк тә яшь буынны әхлак ягыннан тәрбияләп максатка ирешеп булмасмы? Сукырның күзен ачсаң, наданга гыйлем бирсәң, ялкауны эшләргә өйрәтсәң, һөнәрсезне һөнәрле итсәң, саранны юмартландырсаң, шәфкатьсезне мәрхәмәтле ясасаң, бәлки, эшләр җайга салыныр.

Туктале, мәгърифәтчелек түгелме соң бу? Әйе, мәгърифәтчелек. Ф. Әмирхан, каләмдәшләре һәм фикердәшләре Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури кебек үк, мәгърифәтче. Ләкин Қ. Насыйри, М. Акъегет-задә, З. Бигиев, Х. Фәезханов тибындагы мәгърифәтче түгел, бәлки бер баскыч өстәрәк тора торган, революцион демократизм югарылыгына күтәрелгән мәгърифәтче.

Әнә шундый караш һәм идеяләр белән сугарылган хәлдә безнең Фатих көрәш мәйданына атылды. Барыннан да элек аңа «ничек бар, шулай калсын» дигән принцип белән яшәүче искеләр, кадимчеләр белән сугышырга туры килде: яңа тормыш өчен көрәштә, аяк астында чуалып, комачауламасыннар.

Кемнәр соң болар? Күпчелеге Бохара җимешләре булып, дини схоластика белән миләре түнгән мулла-ишаннар. Яшәеш рәвешләре, гореф-гадәтләре, эш йөртү ысул-

лары XVII—XVIII гасырдагы хәлендә катып калган һәм әлеге Бохара козгыннарын тәгъзим итә торган тиречe, итчe, мануфактурачы, ончы сәүдәгәрләр. Ниһаять, «Бәянелхак» һәм «Дин вә мәгыйшәт» кебек, шушы ике төркемнең җырын җырлый торган газета-журналлар, аларның нашир-редактор һәм язышучылары.

Лидерлары кемнәр?

Берсе укучыга инде таныш: үзенең тавык кетәге чаклы мәктәбе белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә юл бирмәскә, якты дөньяга чыгармаска азапланган Йосыф хәзрәт. Күп еллардан бирле ул ахун, ягъни Казан муллаларының башлыгы.

Бервакыт шулай ураза вакытында Йосыф ахун (Зариф хәзрәткә йомыш белән килгәнме, башкачамы) чыгып барганда ачык тәрәзәдән Фатихның бик һәйбәтләп икмәк белән сыр ашап утырганын күрә. Шуннан соң күп тә узмый, ул голәма мәҗлесендә, җаен туры китереп, Фатих мәхдүмне генә түгел, аның элекке остазы Галимҗан Барудины да хур итү максаты белән, дамелляга мәсьәлә куя:

— Мелла Галимҗан, әйт әле, рамазан шәриф аенда сабын ашарга ярыймы?

Мәҗлес халкы, берни аңламыйча, бер-берсенә карашып ала.

— Аңлатыбрак әйтсәгез лә, тәкъсир,— ди Баруди.

— Зариф хәзрәт улы Фатих мәхдүмнең пычак белән кисеп, икмәк өстенә куеп, сабын ашаганын үз күзем белән күрдем.

Мәҗлестә утыручылар, эшнең асылын төшенеп алып, көлеп җибәрүдән көчкә тыелып калалар. Ахун кеше бит — ярамый. Баруди, зиһене тиз җитешеп, болай дигән:

— Сабын бит ул, тәкъсир, тәгам* әйберсе түгел. Кәлам шәрифтә дә ул тугрыда сүз юк.

1906—1907 елларда мәдрәсәләрне берләштерү идеясе калкып чыга. Ник дигәндә, мәхәллә саен, урам саен бер мәдрәсә. Һәркайсы ибтидаи, рөшди сыйныфлары белән генә чикләнмичә, игъдади, хәтта галия сыйныфлары булдырырга тырыша. Иң зурларында 200—300 шәкерт укыса, күпчелегендә исә йөзгә дә җитми. Бер-ике дистә ибтидаи, берәр дистә рөшди, биш-алты игъдади һәм 2—3 галиягә калдырып, мәдрәсәләрне ник берләштермәскә? «Әльислах», бу мәсьәләгә кат-кат әйләнеп кайту белән бергә, «Зурлар белән мәдрәсәләр берләштерү хакында мөзакәрә»

* Тәгам — ашамлык.

исемле фельетон да бастырып чыгара. «Ташмөхәммәт» әфәнде, имештер, Казанның мәшһүр кешеләреннән мәдрәсәләрне берләштерү хакында фикерләрен сорап, интервью алган.

Менә аның Йосыф хәзрәт белән әңгәмәсе.

«Мин:

— Тәкъсир, хәзер мәдрәсәләрне берләштерү мәсьәләсен кузгаталар. Шул турыда сезнең фикерегезне белергә телим.

Ахун:

— Әнәтерәк, инде һәммәсен бер ясыйбыз диләрмени? Әнәтерәк, мулла Галимҗанмы инде? Шулай димени инде?

Мин:

— Тәкъсир, шулай диләр.

Ахун:

— Әнәтерәк, байлар ни диләр соң?

— Белмим.

— Әнәтерәк, без байлардан узмабыз инде. Шулай инде. Мулла Галимҗан минем мәдрәсәне бетермәкче мени инде?

— Хуш, хәзрәт.

Чыгып киттем».

Интервью алучы тагын дүрт мулланы йөреп чыккач, имештер, кадимчеләр лагеренең икенче лидеры — «Бәянелхак» газетасы нашире Әхмәтҗан бабай Сәйдәшев катына барып, шул ук сорауны биргән.

«Ул:

— Син кем углы буласың әле?

Мин:

— ...углы.

Ул:

— Ә, алаймы, алаймы? Бик яхшы. Минемчә, бу ислахчы малайлар белән катышып йөрүче шәкертләрне... берәм-берәм мәдрәсәдән тиешле җирләренә озатырга кирәк. Менә әүвәл, без укыган чакта, бу эшләр юк иде. Алай да әле, аллага шөкер, 70 кә кадәр милләткә, дин-исламга хезмәт итәбез.

Мин:

— Милләткә, дин-исламга? Әһә, хушыгыз!»

Әнә шул килеш Ф. Әмирхан күп кенә фельетоннарында печән базарчы һәм «йосыфчы»лардан эштән чыгарып көлә, урта гасырлар иске-москысыннан типчеп тегелгән киемнәрен салдырып төшереп, шыр ялангач калдыра.

Болар да кул кушырып утырмыйлар. «Әльислах»ка һәм

Әмирханга каршы хәлләреннән килгән барлык әшәкелекне эшлиләр.

1908 елның апрель ахырында Казан губернаторы канцеляриясенә түбәндәгечә башланган прошение барып керә.

«Его Превосходительству Господину Казанскому Губернатору
от Ахуна г. Казани и указных мулл

Прошение

В г. Казани издается с не давних времен татарская газета «Эль-Ислах», сотрудниками каковой являются из разных наших училищ, в г. Казани, не прилежные к учению ученики, не удовлетворяющими поведениями...» Шыр надан каләм белән язылган бу гаризаны күчереп маташмастан, мәгънәсен генә белеп китик. Ул малайларның максаты, диләр муллалар, «прогрессивность» түгел, бәлки «возмущающая». Газетаның һәр санында имамнарга каршы язып, беркатлы мәхәллә халкын безгә икенче күз белән карарга мәҗбүр итәләр. Шуңа күрә без Сездән, Галиҗәнаблары, бу газетаны туктатырга фәрман бирүегезне түбәнчелек белән үтенәбез.

Прошениегә унбер мулла кул куйган. Шулардан алтысы — Йосыф ахун, Хисам, Ибраһим, Сабир, Шакир һәм Сафый муллалар Ф. Әмирханның мәдрәсәләрне берләштерү турындагы фельетонына эләккәннәр иде. Фельетонга кермәгән муллалардан Садыйк Иманкулов имзасы игътибарны җәлеп итә.

Бохара мәдрәсәсен тәмамлап кайткач, күпмедер вакыттан соң Садыйк 9 мәчеткә, Зариф хәзрәт янына иптәш мулла булып урнашкан. Озын чандыр гәүдәле, кечкенә башлы. Күзе зурлык кына түгәрәк кысалы күзлек киеп йөри. Бохара бирә ала торган мәгълүматны җитәрлек туплаган. Динне химая итеп мәкаләләр яза, шигырьләр тәртип итә. Зариф хәзрәтнең ваемсызлыгыннан һәм җәнҗал сөймәвеннән файдаланып, мәдрәсәне үз кулына алып бетерә язган. Әмма күңеле канәгать түгел. Ким дигәндә Зариф хәзрәтне кысрыклап чыгарып баш мулла буласы, җил арттан иссә, ахунлык дәрәҗәсенә ирешәсе килә. Әнә Йосыф хәзрәт картайды, урыны бушарга тора. Садыйкка ул чыбык очы кардәш тә тия икән.

Кадимчеләр лагеренда лидерлыкка дәгъва итә башлаган Садыйк Иманкуловка карата Фатих, билгеле инде, битараф кала алмый иде. Бу очракта атасы хәзрәткә бәйле гаиләви, шәхси мотив та күпмедер роль уйнаган булыр.

Менә аның «Егерменче гасыр әфиунчысы» исемле фельетоны. Автор монда рецензия формасын сайлаган. «Ташмөхәммәт» әфәнде, янәсе, Өрәк хәзрәтнең әнә шул исемдәге әсәренә рецензия яза. Җәя эчендә мондый сүзләр укыла: «Өрәк хәзрәт таснифы *. Карәнчә догасы наширенең варәсәләре ** нәшере. Ике данәсе бер тиен, зәкяттән *** өләшенгәндә бер сумнан хисапланачак». Аз гына сүздә ничаклы мәгънә, тапкырлык, үтергеч ирония! Бер данәсе, димәк, ярты тиен. Ярты тиенлек акчаны руслар «грош» дип атасалар, татарлар «сукыр бер тиен» дип йөрткәннәр. Әнә шул сукыр бер тиен генә торырлык әсәрен мөсанниф, ягъни автор, зәкят итеп биргән очракта бер сумга хисаплаячак. Биредә инде үтмәс малларын югары бәяләп, зәкят сәдакасына бирә торган татар байларының афераларына ишарә.

Өрәк хәзрәтнең С. Иманкулый булганлыгын сиздерү өчен фельетончы пародия рәвешендәге берничә шигъри өзек китерә дә болай дип язып китә: «Менә бу шигырьләрне укыганнан соң, Өрәк хәзрәтнең шагыйрьлегендә берәү дә шөбһә итә алмыйдыр. Касим Уралец шикелле, татар шагыйрьләрен «әсаслы» белүче тәнкыйтьчеләр, иншаа алла, бу тугрыда рус матбугатын да үз тәнкыйтьләре белән баетсалар кирәк.

Бик матур парочка була:

Шагыйрь Өрәк Иманкулец — тәнкыйтьче Касим Уралец!».

## 4

«Әльислах» һәм кадимчеләр арасында чыккан конфликт котылгысыз булса да, яңа конфликт түгел, бәлки күптәннән килә торган коллизиянең комедиячел төскә кергән дәвамы иде.

Югарыда әйтелгәнчә, мәгърифәтчеләр, социаль чыгышларына, субъектив яктан кайсы иҗтимагый төркемне күңелләренә якын итүләренә карамастан, 1905 елга кадәр дип әйтерлек бер эздәнрәк бардылар. Революция, йомылып яткан эчке каршылыкларны тышка чыгарып, гомум мәгърифәтчелек хәрәкәтен икегә аерып ташлады. Бер яктан революцион-демократик лагерь, икенче яктан штабы

---

* Тасниф — китап язу, китап чыгару.

** Варәсә — варислар.

*** Зәкят — керемнең садака итеп бирелергә тиешле кырыктан бер өлеше.

«Мөселман иттифакы» партиясе булган либераль-буржуаз лагерь барлыкка килде. Араларында «атыш» башланды.

Татарларда бөек бүленешү чоры иде бу.

«Азат халык», «Фикер», «Таң йолдызы» кебек газеталар чыгудан туктап, революцион демократиянең бердәнбер органы булып калган «Әльислах» ике фронтка — кадимчеләргә һәм либералларга каршы көрәш алып барырга тиеш булды. 1908 елның җәендә аңа Тукайның «Яшен»е килеп кушылды. Шуннан соң алар, иңне иңгә куеп, чолганышта калганда исә бер-беренең аркасын саклап, ике яктан очкан укларга икеләтә-өчләтә җавап бирә башладылар.

«Вакыт» газетасы, 1905 елгы революциянең либераллар теләгән чикне узганын, марксистик идеяләрнең татарлар арасында да бик тиз таралганын күреп, социализм турында мәкаләләр бирә башлый. Әйтергә теләгәне якынча шул: мөселманнарга социализм дип баш катырасы юк, русларга ияреп һәм партияләр ясап пычакка-пычак килеп сугышу, кан түгү һич ярамый. Ислам дине үзе үк аларны социализм тәгълиматы максат иткән тормышка алып бара. Шуның өчен, коръәнне дөрес аңлап, ул кушканнарны җиренә җиткерергә генә кирәк.

«Әльислах»ның 15 январь санында «Газеталар галәменнән» исемле фельетон бастырып, Ф. Әмирхан Оренбургка таба бер ук җибәрә: «Вакыт» газетасы бик тырышып-тырышып социализм белән сугыша... Фәкать шуны гына беләсе иде: мондый һөҗүмнәрдән социализм фикеренең ничә шөребе какшады икән?»

«Әльислах»ның 1908 елгы 9 февраль санында Думага кертү өчен татар мәктәпләре турында закон проекты әзерләү мәсьәләсенә багышланган баш мәкалә басылган. Ф. Әмирхан, проектның үзеннән көлү белән бергә, бу юл белән халык мәгарифе мәсьәләсен хәл итеп булмый дигән зур гомумиләштерү ясый.

«Мәгариф эше,— дип яза ул,— халыкның әхвәле икътисадиясе (социальное положение) белән бик нык багълангандыр. Шуңа күрә дә бер мәмләкәттә яхут бер милләт арасында тәгаммем * мәгариф итәр өчен иң әүвәлге шарт та аларның әхвәле икътисадиясен яхшы халәткә китерүдер». Аннары фикерен ачыклый төшеп, болай дәвам итә: «Көненә 11 сәгать кибеттә басып торган приказчиклар, көненә 11—12 сәгать эшләп хәлдән тайган фабрика эшчеләре, ачлыктан йөдәгән крестьяннар вә балалары шул

---

* Тәгаммем — бердәй, бертигез итү.

хәлләрендә калдырылган вакытта, алар өчен бер авылга, бер мәхәлләгә берәр түгел, унар мәктәп ачсаң да, әллә нинди мәгариф тарата торган җәмгыятьләр вөҗүткә китерсәң дә алардан файдалана алачак вә зыялана * алачак түгелдер». Бу бөтен Россия күләмендә шулай, ди Әмирхан. Татарларда исә моңа кадимчеләрнең мәктәп-мәдрәсәләрне яңартуга аяк чалулары, алар коткысына бирелгән халыкның мондый мәктәпләргә дошман күз белән каравы өстәлә.

«Фәкыйрьлек, тәгассып ** — безгә менә шул ике нәрсә белән сугышырга кирәк була!».

«Вакыт» газетасы, билгеле инде, мәсьәләнең болай куелышы белән килешә алмый. Ул Фатих Кәрими каләме белән «Әльислах»ка җавап итеп язылган мәкаләсендә, үзенчә ирония кушып һәм беркадәр демагогия кулланып, болай ди: «Бу фикер гүзәл! Ләкин фәкыйрьлеккә вә тәгассыпка каршы гыйлемнән башка нинди корал бар икән?.. Байлыктан гыйлем тууны көтү — кыздан ана тууын көтү кабиленнәндер зан итәмез».

Өлкән Фатих сиңа мәсьәлә куйды, әйдә ерып чык, кече Фатих! Кайсы алданрак яралган: йомыркамы, тавыкмы?

Әйе, XIX гасырның олы буын мәгърифәтчеләре мәгърифәт — бәхет ачкычы, мәгърифәт — экономик һәм әхлакый мәсьәләләрне хәл итүдә төп корал дип чыкканнар иде. Ул дәвердә бу мөһим яңалык иде, ислам догмаларын корал иткән урта гасырчылык калдыкларына каршы көрәштә ул файдалы эш башкарды. Бишенче ел вакыйгаларыннан соң инде бу фикер, бу идеяне алга сөрү либераль буржуазия тегермәненә су коюдан, демократиягә каршы көрәштә иттифакчыларга көч-куәт бирүдән бүтән нәрсә түгел иде.

Ф. Әмирхан «Әльислах»ның 9 март санындагы баш мәкаләсендә ирония һәм сарказм чараларына бик үк мөрәҗәгать итмичә, салкын кан белән генә җавап бирә. Чөнки мәсьәлә җитди.

Әйе, ди ул, бөтен бер халыкны күздә тотсак, мәгариф аңа байлык китерә дип өлешчә әйтергә була. Әмма «бер адәмнең мәгарифле булуы аны баета дип әйтергә мөмкин түгел». Шулай ук теге яки бу милләтнең «буржуазия сыйныфы шул милләтнең иң мәгарифле кыйсме» дип тә раслап булмый.

* Зыялану — яңару, агару, культуралану.
** Тәгассып — тискәрелек, фанатизм.

Бөтен хикмәт җәмгыятьнең социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси төзелешендә. «Хәзер бөтен галәмдә хөкем сөрә торган капиталистический строй кеше хезмәте вә кеше мәшәкате белән башка хәйләкәррәк кешеләрне (капиталистларны) файдаландырырга ятрактанга күрә, бәни адәм файдасына, бәни адәм кулы белән эшләнгән эшләрнең иң симез кисәкләрен бәни адәм сәгадәте өчен кулын да, фикерен дә хәрәкәтләндермәгән кешеләргә бирәдер». Бу, ди Ф. Әмирхан, мәсьәләнең бер ягы. Икенче ягы да шул ук фикерне куәтли: «Горфи бер крестьянга, бер рабочийга баласын, ике-өч йөз сум расход тотып, фән мәктәпләрендә укыту мөмкин түгеллеген кем инкяр итә аладыр». Мәкаләсен ул, Эзоп бабай ярдәменә дә мөрәҗәгать итмичә, түбәндәгечә тәмамлый: «Менә нәрсә өчен без, гавам халык мәгарифе аның әхвале икъдисадиясе белән баглы, дибез. Менә нәрсә өчен башка кавемнең гавами кыйсме * мәгарифе тәгаммем өчен хәзерге г а д ә л ә т с е з (ассызык минеке.— *И. Н.*) төзелгән әхвале икътисадияне үзгәртергә тиеш, диләр». «Әльислах»ның Х. Ямашев яисә Г. Сәйфетдинов та кул куярлык баш мәкалә белән чыккан бу санын конфискацияләмәүләренә яки газетаны бөтенләй туктатмауларына гаҗәпләнергә генә кала.

Ике Фатих арасында башланып киткән һәм күп еллар буе дәвам итәчәк «дуэль»нең бүтән эпизодларына, «кече» Фатихның И. Гаспринский, Р. Ибраһимов, Һади һәм Садрый Максуди кебек милләт хадимнәренә һөҗүм итү очракларына тукталып тормастан, мөһим бер искәрмә генә биреп китмәкче булам.

Әйе, революцион демократлар һәм либераллар капма-каршы ике лагерьга аерылдылар һәм баррикаданың ике ягыннан торып сугыша башладылар. Әмма В. И. Ленинда безгә юл күрсәткеч йолдыз булып хезмәт итәргә тиешле мондый сүзләр бар: «Изелгән милләтнең һәрбер буржуаз милләтчелегендә изүгә каршы гомуми демократик эчтәлек бар. Һәм менә шул эчтәлекне без һичсүзсез яклыйбыз, ә милли аеручанлык омтылышын һич уртаклашмыйбыз, поляк буржуазиясенең еврейләрне кысу омтылышына һ. б. һ. б. каршы көрәшәбез» **.

Татар буржуазиясе мәнфәгатен күзәтүче безнең хадимнәр дә хөкүмәтнең һәр эшенә ләббәйкә дип торырга телә-

---

* Г а в а м и к ы й с е м — халыкчыл өлеш, төркем. Сул партияләр күздә тотыла.

** В. И. Л е н и н. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 1960, 20 т., 417 бит.

миләр, самодержавие терәкләрен какшатуга азмы-күпме өлеш кертәләр. Шуның өстенә һәркайсы үз өлкәсендә — фән һәм әдәбиятта, педагогикада һәм журналистикада — татарларның мәдәни үсеше өчен файдалы эш башкардылар. Менә ни өчен «тар милләтчеләрне», карагруһчылар белән бер тактага куеп, тоташ реакцион масса итеп карау дөрес түгел.

Татар социал-демократлары шул заманда ук моны яхшы аңлаганнар. Г. Сәйфетдинов бер мәкаләсендә «Вакыт» газетасын кадимче «Бәянелхак» һөҗүменнән яклап болай язган иде: «Минем тар милләтче газета булганга күрә, «Вакыт» белән дуслыгым юк. Шулай да мин аны мәсләксез газета яхут реакционный мәкаләләр дәреҗ итә дип гаепли алмыйм». Кадимчеләр белән либералларны бер тактага куймастан, Әмирхан да, соңгыларының политик карашларын тәнкыйть итү белән бергә, файдалы эшчәнлекләрен таный.

...Көрәш кыза. Искеләр ягыннан «Әльислах» белән «Яшен» өстенә очкан пычракка либераль-буржуаз матбугат җибәргән уклар өстәлә. Дөрес, «Тәрҗеман», «Вакыт», «Йолдыз» кебекләр урам сүзләре кулланмыйлар, шактый әдәпле бәхәсләшәләр.

Менә бервакыт Әмирхан «Көчек» дип атаган «Чүкеч» журналы да, Оренбургтан өрә башлап, ара-тирә хәтта «Бәянелхак»ны да уздырып җибәрә. Редакторы — Тимерша Соловьев. 1908 елның урталарыннан башлап җаваплы секретаре — Зариф Бәшири.

Соңгысы, кайчандыр «Мөхәммәдия» шәкерте буларак, редакциягә еш килеп йөргәнгә һәм Ф. Әмирханны олылаганга, баштарак битарафлык саклаган. Тора-бара язганнарын «Әльислах»ның басмавына, хәтер калдыргыч җаваплар бирүенә үпкәләве, бигрәк тә зәвыксыз шигырьләрен Тукайның авырттырып тешли башлавы һәм, ахыр килеп, Оренбургтагы хуҗаларына ярарга тырышуы аны, күрәсең, каршы як лагерьга китереп кушкан. Либераллар уйлап чыгарган сүзне эләктереп алып, ислахчыларны «коричневый паразитлар» («кызыл паразитлар» — таңчылар) дип хурлап яза, «Яшен» журналына, Тукайга пычрак яудыра башлый. З. Бәширинең «тәнкыйте» ни рәвешле булганын чамалау өчен бер өзек китерү дә җитсә кирәк. «Кемгә нинди һөнәр җитә?» дигән баш астында без мондый сүзләрне укыйбыз: «Дамелля әфәндегә — мәдрәсәи Мөхәммәдиядәге шәкертләр китапханәсенең 70 сум акчасын ашый белсә, шул җитә» (1908, ноябрь).

Шунысы кызык: Әмирханның идея дошманнары, биг-

рәк тә либераллар ислахчылар башлыгын фикердә дошман күрсәләр дә, үзләре дә хисап бирмәстән, ихтирам итми булдыра алмаганнар. Төркиядә укып кайтып, Томскида акча хакына ниндидер ярамас эш эшләгәне өчен «Әльислах» тәнкыйтенә эләккән, киләчәктә «Тормыш» исемле газета чыгарачак Вагыйз Наурузов 1908 елның май ахырында Казанга килеп чыга. Шәһәр тормышы белән танышмакчы. Кайдан башлап, ничек танышырга? «Бәянелхак»тагы мәкаләсеннән күренгәнчә, бу турыда ул, газета мөхәррирләре белән киңәшү фикеренә килеп, күп кенә редакцияләрдә булган, әмма «Әльислах»ка барып чыгарга кыюлыгы җитмәгән. Чөнки, ди, беренчедән, мәсләкләребездә аерма бар, икенчедән, редакторлары безнең ише шәкертлектән чыкмаган кешене кабул итмәслек дәрәҗәдә мәгърурдер. Ниһаять, өченчедән, «Әльислах», бәнем хосуси фикеремчә, утлары сачрап тора торган бер янар тауга охшыйдыр. Ул янар тауга, аның янына бармак өчен, «Әльислах» комитетына мәнсуб улмак вә яхут башка бер тылсымга малик улмак шарттыр».

Үз фикерен, шулай ук «Әльислах»ның дус һәм дошманнары фикерен арттырмый-киметми, дөрес итеп әйтеп биргәне өчен Мөхәммәтвагыйз әфәндегә рәхмәттән бүтән сүзебез юк.

## 5

1908 елның җәен Фатих Самарадан 70—80 чакрым ераклыктагы Серноводск санаториенда дәваланып үткәрергә карар итә. Мәшһүррәк санаторийга, әйтик, Кырым яисә Кавказ якларына китмичә, даны белән бик үк мактана алмый торган бу урынны сайлавы аңлашыла: үзе акча тапмаганга шуннан артыкка өмет итәргә хакы юк. Самарадагы таныш-белешләренең киңәше дә билгеле бер роль уйнарга мөмкин. Хәер, тагын бер ихтимал бар. Закир ишан остазбикәсе, өч кызы (Шәмсениса, Хәтимә һәм Өммегөлсем) белән берлектә, былтыр җәйне Серноводскида истирахәттә * үткәргән. Быел да барырга ниятләп торалар икән. Фатихның карарына әнә шул хәбәрнең дә йогынты ясавы бик мөмкин.

17 июнь көнне Фатихны һәм хезмәтче «малае» Мәгъсүмне, билгеле инде коляскалары белән берлектә, пристаньга илтәләр.

---

* Истирахәт — ял итү.

Самарада каршы алучы булганмы, шәһәрдә тукталганнармы, әллә инде тоткарланмыйча юлларын дәвам иткәннәрме — без боларны белмибез. Поезд, аннары — извозчик, һәм менә алар Серноводскида.

Сургут елгасына таба сөзәкләнеп төшә торган иңкүлеккә урнашкан фәкыйрь генә рус авылы икән бу. Алдан сөйләшеп куйганнармы, әллә Фатих үзе тапканмы — бусы да мәгълүм түгел — «малае» белән алар авылның үзәк урамындагы (чиркәүгә чапырыш кына) Трифонов фамилияле крестьян өеннән фатир алалар. Икесенә бер бүлмә, өч тәрәзәсе бакчага, ике тәрәзәсе санаторийга таба төшә торган урамга карый. Шул урам буйлап аска таба 150—200 сажин чамасы атласаң, санаторий капкасына барып төртеләсең. Капканы үткәч, паркка барып керәсең. Кайсы зур, кайсы кечерәк берничә агач һәм таш корпус, киоск һәм беседкалар, бию мәйданы һәм оркестр өчен сәхнә. Биек-биек агачлар күләгәсендә кызыл ком сибелгән аллеялар, артлы эскәмияләр. Шул аллеяларның берсе буйлап паркның арткы ягына чыгасың. Түгәрәк таш түшәлгән юлдан шактый текә тауның итәгенә төшәсең. Урман булып үсеп утыра торган агачлар чолганышындагы түмтүгәрәк күл пәйда була, борыныңа күкерт исе ярып керә. Күл ярында таш баганаларга утыртылган берничә чатырбеседка. Эчләрендә тау астыннан бәреп чыга торган күкертле су күлгә агып төшә.

Күлнең сул ягыннан урап узсаң урманга барып керәсең. Аны да үткәч, яшел болын ачылып китә. Болын юлыннан чирек чакрым атласаң, ике яклап тезелгән таллар күләгәсендә агып ята торган Сургут елгасына барып чыгасың.

Ф. Әмирханның ике айга якын гомере әнә шул төбәктә уза башлый. Көннәрен ул укып, язып һәм процедурага йөреп уздыра. Кичләрен, санаторий паркына барып, музыка тыңлый, таяклы һәм таяксыз яки үзе кебек коляскага утырган авыруларны күзәтә, ял итәргә генә дип килгән сау-таза егет һәм кызларның, дама һәм господиннарның кыланышларын тамаша итә.

Бу вакыт аралыгында Фатих «Әльислах»ның үзе юкта чыккан һәр санына баш мәкаләләр, берничә рецензия һәм фельетон өстенә «Авырулар галәмендә» исемле зур күләмле очерк язган. Бу вакыттагы рухи халәтен һәм дөньяга карашын аеруча тулы чагылдырганга, соңгысына киңрәк тукталыйк.

Ф. Әмирхан бер көнен, дөресрәге, кичке аштан соңгы вакытын, хис-тойгыларын, уйлануларын тасвир итә.

Менә ул Сургут буенда. Елга, төньяктан искән җилдән зарлангандай, дулкынланып, шаулап ага. Дулкыннарга карап тору автор күңелендә кешеләргә кагылышлы уй-хисләр тудыра. Мондагы адәмнәрне дә бит ниндидер шомлы җилләр урыннарыннан куптарган да бу якларга китереп ташлаган... Кинәт, хикәяләүгә катышы булмагандай күренгән ике риторик сорау.

«Әй син, адәм углы, бәхетеңнән шикаять * итәмсең? Ул ярамый бит, ул алладан шикаять була бит!

Әй син, фәкыйрь, дөньядагы гаделәтсезлекләрдән шикаять итәмсең? Сак бул, телеңне кисәрләр».

Фатих якындагы урманга текәлә. Әнә агачлар да тигез түгел. Бар биекләре, уртачалары, бар үтә бәләкәйләре. Төньяк җиленнән бөгеләләр, сыгылалар. Тагын риторик сорау: берегезнең биек һәм мәһабәт, икенчегезнең кыска һәм кечкенә булып калуы кемгә кирәк булды? Ник сез, җилгә буйсынып, горур башыгызны иясез?

Кояш баюга таба бара. Әнә яртысы инде тау артына күмелде. Ак яктылык кими барып, су өстен һәм болынны кызгылт шәүлә каплый башлады. Ник ашыгасың, кояш? Тагын бер генә сәгать яктыртсаң, ни булыр иде? Юк, әнә күмелде...

Парктан музыка тавышы ишетелә, кичке шәфәкъ тудырган сагышка моңсулык өсти.

Менә тәгәрмәчле кресло белән берәүне акрын гына этеп киләләр. Уналты-унҗиде яшьлек, фәрештә кебек бер кыз икән. Тирән кара күзләрендә моң, сагыш.

«— Туташчык, гафу итегез, авыру авыруга кардәш дип игътикат иткәнгә күрә: «Күптәнме бу хәлдә сез?» дип сорарга җөрьәт итәм.

— У... рәхим итегез, мин үзем дә шул игътикатта; авыруыма тиздән унбер ай була.

— Борчыла торгансыз?

— Хәер, мин, шатлык нәрсә икәнен белмәгән шикелле, кайгы нәрсә икәнен дә белмим.

— Туташчык, сезгә монда җил...

— Рәхмәт хәер хаһлыгызга. Акулина, мине алып кит. Хушыгыз!»

Бу эпизод та автор күңелендә социаль каршылыкларга ымлый торган уй-хисләр кузгата. «Әй син, табигать, башкаларга иткән җәберләрең генә җитмәгән шикелле, лэтафәте мөҗәссәмәләргә * тотындыңмыни?». «Әнә теге, зә-

---

* Шикаять — зарлану.

** Лэтафәте мөҗәссәм — нәфислекнең гәүдәләнеше.

һәрлеге йөзенә чыккан аристократка, 60—70 яшьлек карчык, үз аяклары белән йөри бит. Ник бу кыз урынында ул карчык утырмый? Ник ул карчык урынына бу кыз йөрми?».

Тагын бер очрашу. Параличтан ишетми һәм сөйләшә алмый башлаган студент һәм аның карчык анасы.

«Башыма әллә ниләр килә: бу, бу яшь егет моннан алты гына ай әүвәл әллә нинди планнар коргандыр. Алты гына ай әүвәл дөньяда бәхет бар дип ышангандыр, кем белә, бәлки, алты гына ай әүвәл оптимист булгандыр!

Бер дәкыйка *, табигатьнең бер һөҗүме ул планнарның астын-өскә китергән. Бер дәкыйка ун-унике ел тәхсыйль иткән мәгълүмат, унике ел ышанган нәрсәләрне җилгә очырткан.

...Кайда китте бу озын, аристократически бөгелә-сыгыла белә торган фигураң (камәтең), зәкявәтең ** белән шәһадәт бирә торган ачык маңлаең, бик матур таралган кара сачларың, ачык, аркылы үтәрлек итеп карый торган күзләрең белән, әллә нинди фәрештә шикелле кызларның күңелләрен аулап, йөрәкләрен каты селкенергә мәҗбүр иткән чакларың?»

«Алты ай» дигән сүзләрне «ун ай» дип үзгәртик тә бу өзекне кабат укып чыгыйк. Фатихның үзе турында ич бу! Студентның үткәнен, үзе күргәндәй, күз алдына китереп бастыру өчен рус карчыгының бер-ике җөмлә сүзе генә җитмәс иде югыйсә.

«Бәлки алты гына ай әүвәл оптимист булгандыр...» Моннан ун гына ай элек Фатих та оптимист иде. Ә хәзер?

Замандашлары хәйран: бервакытта да авыруыннан, аяксызлыгыннан зарланмас. Бу хакта сүз чыкса, шаяртыр, мәзәкләштерер. Бервакыт туганнан туган сеңлесе Зәйнәпкә болай ди икән:

— Үз аякларымны синекенә алыштырмас идем.

— Ник, Фатыйх абый? Синекеләр йөрми бит.

— Аның хикмәте дә шунда шул, җүләр. Алар шиблит туздырмый.

Ә бер көнне яшь адашы (ягъни Ф. Әмирхан II) «Әльислах» идарәсендә утырган да китәргә җыена башлаган. Фатих җитди кыяфәт белән сорап куйган:

— Карале, тышта пычракмы?

— Пычрак шул...

---

* Дәкыйка — минут.
** Зәкявәт — зирәклек.

— Алайса булмады инде.

— Нәрсә булмады, Фатих абый?

— Сине озата чыгып, һава алыштырып керимме дигән идем дә, калошлар өйдә калган.

Кайгы белмәс шат күңелле булып күренүе тышкы як кына икән ләбаса. Ул да борчылган, кайгырган, авыр минут һәм сәгатьләр кичергән. Гомере буе карават һәм коляскага баглы калачагын аңлый башлагач, фаҗига бөтен дәһшәтлеге белән аның каршына килеп баскан. Бар да бетте, корган планнар чәлпәрәмә килде... Инде нишләргә, ничек, ни белән яшәргә?

— Әйдә, иптәш, паркка, минем эчем поша!

Тезелеп киткән фонарьлар аллеяны саран гына яктырталар. Эстрададан музыка тавышы ишетелә. «Кешеләр, кешеләр, кешеләр, әллә никадәр кешеләр арлы-бирле йөренәләр. Әллә нәрсәләрен җуялткан шикелле эзләнәләр: франт, аякларын шаркать итеп, үз-үзенә гаҗәпләнеп, кәеф-сафа эзли; карт, бөкрәйгән буйлары, зәгыйфьләнгән хәвасы * белән җуялткан яшьлеген эзли».

Мөселман агай-эне дә күренә. Аллеяның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып атлыйлар, узган-барганнарга чекрәеп карыйлар, бармак төртеп күрсәтәләр. Татар хатын-кызлары да, ниндидер гаеп эшләгәндәй, качып-посып кына йөренгән булалар. Кизләү ишанының сеңеле дә бар икән монда. Үзе авыруларны агасына өшкертергә барырга кыстый, ә үзе ваннага утырып дәваланырга дип килгән.

— Әйдә, иптәш, өйгә кайтыйк, мин арыдым.

Фатирында аны кичке почта китергән хат һәм газеталар көтеп тора икән. Хатлар — яшьләрдән, Фатихның дусларыннан. «Һәммәсе... үзләреннән бер фәрднең ** (Ф. Әмирханның — *И. Н.*) отставкага чыгарылырга тиеш түгел икәнлегенә ышанганлыкларын күрсәтәләр». Аннары «татар мәгыйшәте»нә күчеп, «картлар» һәм «яшьләр» көрәшенең кульминациягә җиткәне турында сүз ачалар, ахыр чиктә яңаның җиңәчәгенә ышаныч белдерәләр.

«Өченче хатны укый башлыйм. Иптәшләремнән бер шагыйрь хаты. Анда әсаслы *** бер эшкә тотынып китә алмавыннан зарлана:

Уянды (хандра) күңелемдә инде,
Караңгылык күңелдә нурны җиңде».

«Ләкин мин,— ди автор,— иптәшемнең (ягъни Тукай-

---

* Хәвас — тойгы-хисләр.
** Фәрд — аерым шәхес.
*** Әсаслы — нигезле.

ның — *И. Н.*) бу пессимизмына мөшарәкәт * итмим. Бу халәтләрнең безнең башта вакытлы гына икәнлегенә ышанам». Газетадагы бер хәбәр дә аның күңелен күтәреп җибәрә. Яшь төрекләр солтан Габделхәмитне конституция хакында вәгъдә бирергә мәҗбүр иткәннәр! Әһә, без, яңа мәгыйшәт тарафдарлары, җиңәбез бит!

Вакыт инде соң. Таң якынлашып килә. Әнә әтәчләр кычкыра башлады. «И таң, ат инде тиз генә! Мин сине көтәм һәм тиздән булуыңа ышанам!».

Менә әсәрнең соңгы аккорды. Оптимистик аккорд. Ләкин бу гади оптимизм гына түгел, бәлки ныгып җиткән дөньяга карашка нигезләнгән оптимизм.

Укучы игътибар иткәндер, «Авырулар галәмендә» нәсер-очеркы башыннан ахырына чаклы «капма-каршы янәшәлек» дип атарга мөмкин булган алым кулланып язылган. Төньяктан исә торган җил һәм мәрхәмәтсез язмыш, урмандагы агачлар һәм кешеләр арасындагы тигезсезлек, тәгәрмәчле креслога баглы яшь кыз һәм сау-сәламәт аристократка карчык...

Фатих моңарчы да җәмгыятьнең өстеннәргә һәм «түбәннәргә», байга һәм фәкыйрьгә, изүче һәм изелүчегә, эшләүче һәм эшләтүчегә аерылганын белми түгел, белә иде. Шул социаль контрастның үз гаиләсендәге, тирә-күршедәге, мәчет ишек төбендәге, бистә һәм Казан урамнарындагы чагылышларын үз күзе белән мең мәртәбә күреп үткәрде. Әмма: «Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә», дигән халык җырында әйтелгәнчә, болар әле йөрәгенә яра ясарлык ук тәэсир итми иде. Инде килеп, көтмәгәндә башына төшкән фаҗига Фатихны кимсетелгәннәр һәм фәкыйрьләргә якынайтты да куйды! Дөрес, аның бәхетсезлеге социаль сәбәпләргә бәйләнмәгән. Табигать «бүләге». Әмма бәхетсезлек — бәхетсезлек инде. Моннан соң ул үзе кебек авыруларга гына түгел, бәлки ачлыктан тилмерүчеләргә дә, туклыктан ни кыланырга белми торган байларга да икенчерәк күз белән карамый булдыра алмый иде.

Очерк буйлап гизгәндә без әнә шул фикерне раслый торган гаять көчле бер кисәкне сикереп узган идек. Шул урынны тулысынча күчерүдән тыела алмыйм.

«Фатирыма юнәлдем. Очраган йортларның тәрәзәләренә күзләремне сала барам: иртә сәгать 5 тән торып эшкә китәргә мәҗбүр крестьяннар, өйләренә ут та алмастан, йокларга ятканнар. Үзләренең теләсә кай вакыт торырга

---

* Мөшарәкәт — кушылу.

ихтыярлы икәнен белә торган дачниклар, сәгатьнең унике сугуына карамыйчан, гыйш-гашрәтләрендә дәвам итәләр. Өй эчендә гитарада уйнаган тавышлар, кокетка дамаларның чырык-чырык итеп көлүләре ишетелеп торалар.

Нинди контраст!

Бу йортта үлеп яталар, аның күршесендә бик ләззәт белән гомер сөрәләр. Уйлап-уйлап гаҗәпләнә башлыйм: бәгъзе кешеләр шуның икесен бер диләр бит, шуларны аерып йөрткән кешеләрне миллият * хисеннән мәхрүм дип сүгәләр бит; шул ике фирканең ** берсе мазлум *** дисәң, ачуланалар бит; әгәр сез монда без гомер сөрсен өчен үлеп ятсагыз, җәннәттә сез дә безнең шикелле булырсыз, дип юатырга тырышалар бит!»

Рус авылындагы социаль контрастларга карап әйтелгән булса да, бу сүзләр, билгеле инде, авторның идея дошманнары — «милләт хадимнәре»нә адресланган.

Әнә бит ничек: хәтта авыруы да Ф. Әмирханның революцион-демократик карашларын ныгыткан икән. Ә иманың нык булса, ул синә көч-куәт өсти, яшәвеңне мәгънәлерәк итә, киләчәккә ышаныч белән карарга мөмкинлек бирә. Терелеп, аякка басуга күзе җитмәсә дә, Фатихның яшисе, гади тән яшәве белән генә түгел, рухи, мәгънәви яшәү белән яшисе килә. «Яңа мәгыйшәт» хакына, тормышта гаделсезлек һәм кан-яшьнең, фәкыйрьлек һәм тигезсезлекнең бетүе хакына яшисе килә. Күзәтүче булып кына түгел, көрәшче булып.

Илле-илле биш көн аз түгел. Бу вакыт эчендә, билгеле инде, эреле-ваклы күп вакыйга булган, байтак китап укыган, көн аралаш дип әйтерлек хат алган, җавап язган. Казаннан һәм Самарадан күрешергә килеп чыгучылар да булмый калмаган.

Мәзәк катыштырып, төрлечә кылларын чиртеп, Трифонов карт һәм аның семья әгъзаларын да сүзгә тарткан, үзен кызыксындырган мәгълүматларны суырып алган. Санаторийның үзендә һәм фатирда торып дәваланучы авырулар арасыннан танышлар булдырганлыгына шулай ук шикләнмәскә мөмкин. Кичке якта Фатих еш кына яшьләр чолганышында калган, җанлы сөйләшү булган, чырык-чырык көлүләр яңгырап торган дип күз алдына китерсәк, шаять ялгышмабыз.

Безгә аз-маз билгеле вакыйгалардан берсе — июль

---

* Миллият — милләтне сөючелек.

** Фирка — төркем, партия.

*** Мазлум — золым ителгән, изелгән.

урталарында Ризван Алуши белән хатыны Фәрхәнәнең килеп чыгуы. Җитди сүз күпме сөйләнгәндер, әмма мәзәк хәлләр, уен-көлке җитәрлек булган. Фәрхәнәгә язган хатында Фатыйх болай дип куя: «Минем коляскага утырып Серноводск урманына барганыбызны хәтереңә китерәмсең? Пенснэгә кыстырган утын кисәге төшеп калганы юкмы әле?»

Шул ук адресатка җибәргән икенче бер хатыннан мондый сүзләр укыйбыз: «Менә мин монда теге Ш. туташ Камалова (Серноводскидагы) гашикъ булдым дип исем чыгардым. Яшьләрнең һәммәсе шуны мөзакәрә* белән мәшгульләр. Ник гаҗәпләнәсең? Гыйшык Йосыф пигамбәрдән калган сөннәт** ул!».

Шәмсениса туташ, былтыргы кебек, быел да анасы һәм бер яки ике сеңлесе белән килгән булыр. Алушилар ике-өч көн генә торганга һәм Шәмсениса үзенекеләрдән аерылып йөри алмаганга, кунаклар һәм кыз анда аралашмаганнар. Әмма, хаттан күренгәнчә, ничектер туры килеп, Фатих дусларын Шәмсениса белән таныштырган.

Камаловалар санаторийда Фатих кебек озак тормаган тәкъдирдә дә, егет белән кыз еш кына очрашкан, араларында шактый сүз булган дип уйларга кирәк. Аларның үзара мөнәсәбәтен без бүген фараз итеп һәм «Кадерле минутлар» хикәясенә таянып кына беркадәр күз алдына китерә алабыз.

Хикәянең эчтәлеге студент Рәшат авызыннан сөйләнгән өч мәхәббәт тарихыннан гыйбарәт. Соңгысы нәкъ менә Серноводск белән бәйле.

Яңа гына өлгергәнлек аттестатына имтихан биреп бетергән Рәшат аяклары авырта торган әбисенә юлдаш һәм ярдәмче сыйфатында Самара ягындагы күкертле су санаториена китә. Анда ул электән таныш гаилә кешеләрен — Хәерниса карчыкны һәм аның ике кызы Разия белән Мәрьямне очрата. Үсмер чакларында алар Разия белән очраша, уйный, шаярыша торган булганнар. Кыз мәчедән бик курыкканга, Рәшат аны, өстеңә мәче куям дип, еш кына рәнҗетә икән. Разия, «Рәшат абый, былбылым, зинһар тимә», дип ялына торган булган. Моннан дүрт ел элек аларны «намәхрәм» дип, бер-берсеннән аерганнар.

Хәзер инде Разия «үскән, тагы да матурланган, тагы да нурланган, менә хәзер генә, шушы секундта гына ачы-

---

* Мөзакәрә — сөйләшү, фикер алышу.
** Сөннәт — пигамбәр кылган эш.

лып җиткән яшь, яңа, гаҗәеп хуш исле гөл чәчәге шикелле балкыган». Озын кара керфекле коңгырт күзләр, алсу нәфис яңаклар, килешле иреннәр, коңгырт калын чәч толымнары, сыгылмалы нечкә, зифа гәүдә.

Тукта, Шәмсениса түгелме соң бу? Шәкерт чакта Фатих Закир хәзрәтнең улы Ибраһим белән аралаша, кече сеңелләре белән шаярыша, үчекләшә иде. Яисә менә түбәндәге диалогка игътибар итик. Намәхрәм ясап аерулары турындагы сүзгә каршы Разия елмаеп болай ди:

«— Без хәзер «намәхрәм»нәр түгел инде!

— Мин бик шат! Ул турыда Кәрим ярдәм иткәндер сезгә?

— Әйе, абыйның бик күп файдасы тиде. Мин быел дүрт класстан гына имтихан да тотып чыккан булдым...»

Соңрак мулла булган, ләкин тора-бара чалма-чапанын ташлап, үз кул көче белән көн күрә башлаган Ибраһим Камаловның атадан яшь калган кече сеңелләрен тәрбияләүгә күп көч куйганлыгы билгеле. Чистай татарларының яратмый сөйләүләренә, кайберәүләренең хәтта ләгънәтләренә игътибар итмичә, ул аларны хосусый укытучылар яллап укыткан, ә берсеннән гимназия тәмамлаткан.

...Икенче көнне кичкә таба, сүз куешкан булмасалар да, бер-берсен күрү өмете белән бар кешедән дә алда паркка киләләр. Кызның һәр сүзе, һәр хәрәкәте, һәр кыланышы Рәшатны сокландыра, тәкатен ала. Менә алар якындагы урманга китәләр, тар сукмактан кысылышып бара торгач, бер аланга килеп чыгалар. Бу алан егет белән кызга «зөбәрҗәт койма белән әйләндерелеп алынган, батарга бара торган кояшның соңгы нурларыннан читләре алсуланган ак болыт кисәге белән түбәләндерелгән» хыялый чатыр булып күренә.

Бер-берсенә тартыла торган ике яшь йөрәк арасында гына була торган, тыштан караганда мәгънәсез һәм мантыйксыз, әмма үз эченә күп мәгънә яшергән сөйләшү. Тартына, ояла торган яшь кызның языла баруы, «мин сезне бик сагынган идем. Рәшат» дип әйтеп ташлавы. Егетнең, тәкать тота алмыйча, кызны кочып алуы, чәченнән, күзеннән үбүе, иреннәрнең иренгә тоташуы.

Коляскадагы Фатих белән яшьлектән, саулыктан, гимназия тәмамлау куанычыннан адарынган Рәшат арасына тигезлек билгесе куеп булмаган кебек, Разияне дә Шәмсенисаның күчермәсе итеп карарга ярамый. Аларның Серноводскидагы аралашулары, билгеле, нәкъ хикәядәгечә була алмаган.

Тулып, пешеп җиткән Шәмсенисаны кабат күргәч, Фа-

тихның гаҗәпләнү катыш соклануы, таң калуы, кызның тышкы матурлыгына тиң эчке матурлыгын да абайлап алгач, башын җуяр дәрәҗәдә гашыйк булуы исә хак. Рәшатның күп кенә кичерешләре, һичшиксез, Фатихның үзенеке.

...Августның уннары тирәсендә Фатих җыенып, төянеп, Серноводскидан Казанга юл тота. Ул аннан әллә ни чаклы тәэссорат, иҗат планнары, язылып беткән һәм языла башлаган парчалар белән берлектә Шәмсениса туташның якты сурәтен күңеленә салып алып кайта.

## 6

Казан, төгәлрәк әйтсәк, туганнары, дус-ишләре һәм «Әльислах» идарәсе сагындырган икән. Аны сагынучылар да байтак. Хәл белергә килүчеләрнең хисабы юк: өйгә дә, идарәгә дә.

Узган ел ахырында килеп кушылган һәм тора-бара «Әльислах»ның даими язышучы һәм сотрудникгына әверелгән Кәбир Бәкернең тәкъдиме белән редакцияне бүтән төшкә күчерергә карар ителгән була. Чөнки «Болгар» — татарның кайнап торган урыны: киләләр, китәләр. Өстәвенә ашханәсе бар, рестораны. Редакция бүлмәсе кешедән өзелеп тормый.

Екатерининская урамындагы Шәкүр Апаков йортының беренче катыннан зур гына бүлмә алып җиһазлыйлар да 1908 елның март тирәләрендә күченәләр. Истәлекләрнең берсендә «Әльислах» белән берлектә Фатих үзе дә шул өйгә күчеп, Вафа Бәхтияров белән бергә тора башлады дигән мәгълүмат бар. Дөресрәге болай: шул ук өйдән фатир өчен тагын бер бүлмә алганнар. Вафа шунда бөтенләй күченгән, ә Фатих ара-тирә кунып калган.

1908 елның 26 октябрендә Исмәгыйль Аитовка язган бер хатында Фатих болай ди: «Ниһаять дәрәҗәдә акчасызлык, уртача чибәр генә дәресләр белән шөгыльләнү, бераз язу, һәркөнне редакциядә булу, әдәбият мәҗлесләре сылтавы белән атна саен кунакта булу, Ш. К. туташны күрсәм, куану — менә хәлләрнең иҗмале *. Син язасың, «Әльислах»ны ташла да, акча эшләп, дәвалан башла дип. Җаным, минем бөтен удовольствиемдә хәзер шул көн саен редакциягә чыгудан гына гыйбарәт бит: ял итү дә шул, гомер итү дә шул».

Редакциядәге беренче эше илнең төрле почмакларыннан килгән хат, корреспонденция, мәкалә, шигырь һәм хи-

* Иҗмал — кыскартып әйтү.

кәяләрне күздән кичерү, басарга ярарлыгын сайлап алып төзәткәләү, ярамастайларына почта аша яисә газета битендә җавап язу.

Утызынчы-кырыгынчы еллар атмосферасы тәэсир иткәнме, әллә инде адаш абыйсының тел чәнечкеләреннән алган ярасы һаман үзен сиздереп торганмы, Ф. Әмирхан II әдипнең авторлар, бигрәк тә яшь язучылар белән эшләү рәвешен мактамый. Редакциягә язмасын күтәреп килүчеләрне Фатих, янәсе, салкын каршылаган, «әсәрләрен» укып мәшәкатьләнмичә яисә күз генә ташлап һәм мыскыллы сүзләр әйтеп, үзләренә кайтара икән. Истәлекче моны хәтта Ф. Әмирханның артык һавалы булуы, үзеннән бүтәнне әдәбиятка уздырмаска теләве белән аңлатмакчы.

Әйе, «Әльислах» битләрендә үз исемнәрен күрергә теләгән күп кенә яшьләр редакциядә дә, газетаның соңгы битендә дә гомер онытмаслык ачы-ачы сүзләр ишеткәннәр. Менә кайбер мисаллар.

«Миргазиз Укмасыйга — йибәрелгән назымнарың басылмаячак. Чыңгыз бабай гайрәте белән мактануның, хөкеме бу көннән бетерелергә тиеш».

«Ш. Гаунигә — Гаспринскийның һәрбер әйткән сүзенә ул кадәр шәрех ителү артык кеби тоела».

«Әстерханнан Х. Максудига — шигыреңез моннан ун ел әүвәл языларга тиеш иде».

«З. Бәширигә — сезнең шигырь дип язган нәрсәләреңез бик тупас назымнар гына».

Ун-унике еллык газиз дусты Ризван белән дә шул җирлектә үпкәләшү килеп чыга, дөресрәге, мәкаләләрен басмаган өчен Алуши үпкәли: «...минем кулыма каләм тоттырып, язу язарга үгрәткән сез идеңез һәм гаҗитләргә мәкаләләр яза тору куәи тәхририянең *, артуына олуг ярдәм була дәю төшендергән дә син идең. Шуңар бинаән **, бән бәгъзан гәҗитләргә мәкаләләр язгалыйм, ел әйләнәсендә һәрбер гәҗитәгә аз-маз язып чыгам. Фәкать, мең тәэссеф, язган мәкаләләрне «Әльислах»ка, каю ки үз гәҗитәмез саналган «Әльилах»ка ярата алмаем».

Дустын аяпмыдыр, Фатих газета битендә җавап бирми, әмма хат аша үз фикерен яшерми-нитми әйтә. Р. Ибраһимов-Алуши «Бәянелхак» һәм аның өстәмәсе булып киткән «Казан мөхбире»ндә күренә башлагач, мәсәлән, бер хатының ахырында, русчага күчеп, ирония белән болай ди: «Казан мөхбире»ндә хикәягезне укыгач, мин, әлбәттә, бик

---

* **Куәи тәхририя** — язу куәте.
** **Бинаән** — нигезләнеп.

шатландым, минем ун еллык иптәшемдә югары сыйфатлы язучылык таланты бар икән ләбаса... Шунысы да мактауга лаек: Сез Казан газеталарын онытмыйсыз һәм Сәйдәшевләрнең кап-кара газеталарын үз талантыгыз белән яктыртып торасыз».

Шул ук Ф. Әмирхан Тукайны күтәреп ала, язганнарын «Әльислах»ка тоткарсыз үткәрә, һәр китабына югары бәя биреп, рецензия яза, «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» поэмасына багышланган рецензиясендә болай ди: «Тукаевның бу әсәрен һәм «Яшен»дә көлке шигырьләрен укый торгач, аңар татар галәменең иң оста юмористы диясем килә башлады».

Менә Казанга булачак зур әдип Г. Ибраһимов килеп чыга. «Әльислах»ка «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле озын хикәясен тәкъдим итә. Газетаның даими сотрудниклары, шул исәптән Тукай, бу язманы басмаска тырышсалар да, Ф. Әмирхан, яшь егеттә талант сизеп, үз сүзен итә, әсәрне дөньяга чыгара.

Юк, хикмәт Фатихның тар күңеллелегендә һәм үзен зурга куюында түгел. Хикмәт аның гадәттән тыш таләпчәнлегендә. Бу елларда зәвыклы тәнкыйтьче булып танылган Ф. Әмирханның мәкалә һәм рецензияләрендә дә бу сыйфат ачык күренә. Идея дошманнары өстенә ул, билгеле инде, юлбарыс кебек ташлана. Бусы аңлашыла. Ләкин бит ул демократик лагерьга кергән авторларның да зәгыйфь һәм хәтта уртакул әсәрләрен аяп тормый. 1905 елгы революциядән соңгы 4—5 ел эчендә татар әдәбияты гаять зур сыйфат сикереше ясаган икән, моның белән ул, бүтән сәбәпләрдән тыш, шундый ук тәнкыйть тарафдары булган Тукайга, Г. Ибраһимовка һәм безнең Ф. Әмирханга бурычлы.

...Агымдагы эшләр беркадәр тәмам булып, көн кичкә таба авышкач, «көн тәртибенең» икенче өлеше башлана. Вафа Бәхтияров белән Кәбир Бәкер күптән монда. «Яшен»нән бушаган чагы булса, Тукай да шунда. Менә Фәхрелислам Агиев, Ибраһим Кулиев килеп чыга. Солтан Рахманкулый белән Вәли Апанаев күренә. Икесе дә кызмача. Сирәк-мирәк Г. Камал күренеп китә. Элегрәк С. Рәмиев тә була иде. «Бәянелхак»ка эшкә керүеннән бирле «Әльислах» белән арасы суынды. Байбәтчәләрдән дә мондый мәҗлесләрне калдырмаска тырышучылар бар. Бер-ике кыюрак шәкерт тә почмакка кереп сыена. Кайвакыт кызлар да була.

Җиңел темаларга, берсеннән икенчесенә сикерә-сикерә, җанлы сөйләшү, көлешү, тел шомарту, җиңелчә төрттерешү

башлана. Фатих, билгеле инде, игътибар үзәгендә. Үзе күп сөйләми, пенсне пыялаларын ялтырата-ялтырата, кызлар булса, иреннәрен кыса төшеп (артык калын булганга ямьсез дип уйлый), реплика биреп куя, мәзәк сүз кыстыра: сөйләшүне кирәкле юнәлештә алып барырга тырыша. Кайвакыт үз башыннан кичкәнне яисә кешедән ишеткәнне мәзәкләштереп һәм үзеннән кушып сөйләп ала.

Мондый утырышларны Фатих яратмый булмаган. Чөнки тормышның эчпошыргыч якларын онытып тора, ял итә, үзләрен алдынгы яшьләр дип йөргән Казан типларын күзәтә һәм татар дөньясына кагылышлы шактый информация ала.

Югарыда китерелгән хаттагы «әдәбият мәҗлесләре» турындагы сүзләр дә әһәмиятле.

1908 елның август-сентябрьләре тирәсендә ислахчылар «Әдәбият түгәрәге» оештыралар. Максаты — табадан яңа төшкән әсәрләрне укып фикер алышу һәм бүтән телләрдән, башлыча русчадан, тәрҗемә итү эшен тәртипкә салу: ни туры килде, шуңа ташланмаска, сайлап алып, билгеле бер план буенча тәрҗемә итәргә. «Әдәбият кружогы» хәзер тәртипле дәвам итә,— дип яза Ф. Әмирхан,— күп мәҗлесләрдә вакыт җитми кала. Мөзакәрәләр дә бик кызыклы булалар». Әнә шул мәҗлесләрнең берсендә Тукайның да «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасы укылып, зур уңыш казанган.

Түгәрәкнең утырышлары төрле өйләрдә, квартираларда чәй мәҗлесе рәвешендә чиратлашып уздырылган. Арата тирә куәтлерәк эчемлекләр дә үтеп кергән, һәрхәлдә, самовар янынннан урын алырга теләгән. Эчемлек дигәннән, Ф. Әмирхан (бу аңа кайдан килгәндер) гомере буе исерткечкә дошман була. Үзе эчмәү генә түгел, татар яшьләре арасында эчүчелекнең җәелә баруына каршы кулыннан килгәнчә көрәш алып бара.

Татарларда алмашыну вакыты бу, европалашу процессы барган вакыт. Борынгылардан килгән гореф-гадәтләрне яшьләр нәфрәтләнеп кире кагалар, рус-Европа мәдәнияте казанышларыннан файдалана башлыйлар. Тышкы яктан мәдәниләшү, әлбәттә, ансатрак: костюм тектереп киенмә, ак яка, манжет, галстук тактыңмы, чәчеңне үстереп, артка таба яткырдыңмы — син европеец. Рухи яктан мәдәниләшү исә мәшәкатьлерәк, күп вакыт һәм көч сорый. Эчке культурага ирешергә өлгермәгән бер төркем яшьләр, картларга үч итеп, артыграк «европалашып» китәләр: үзләрен кирәгеннән артык хөр тота башлыйлар, эчемлек белән дуслашалар.

«Әльислах»ка тартым яшьләр арасында да шундый бер төркем, бер «круг» оешып алган. Берничә байбәтчәдән тыш бу «круг»ның күренекле әгъзалары: Солтан Рахманкулов, Вәли Апанаев, Ибраһим Кулиев, Фәхрелислам Агиев. Тора-бара бу компания Тукайны да үз эченә ала. Ул гына да түгел, Тукай номеры кәеф-сафа кору урыны итеп файдаланыла башлый.

1908 елның язында бер көнне, редакциядә эшләр бетеп, кешеләр кайтырга җыенгач, Тукай Ф. Әмирханга әйтер сүзе барлыгын белдерә. Тарантаска утырып, алар шәһәр читенә китәләр. Моңарчы дәшми генә барган Тукай, яланга чыккач, кинәт: «Мин үзем эләккән кругымнан разый түгел. Мин Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Минем бүлмәдә көне-төне буш вакытларын кая куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар»,— дип башлап китә дә ярты сәгать буе, тынмый-нитми, җавап та көтми, әлеге «күңелле» тормыштан зарланып бара.

Сәләтле яшьләрнең, эш эшлисе вакытларын бушка уздырып, саулыкларына зарар китерүләре, Тукай кебек зур талантның харап булу куркынычы турында уйлаудан тыш, энесе Ибраһимга бәйле шәхси сәбәп тә Фатихны эчкечелеккә каршы көрәшүгә этәргән.

Ибраһим гадәт-холкы белән дә, сәләт дәрәҗәсе белән дә абыйсыннан күп калыша. Ваемсыз, йомшак характерлы, тормышка карашы утырып җитмәгән. Бердәнбер газиз энесенең бу сыйфатларына ачынып Фатих аны «сыер» дип атый икән. Ибраһим, Тукай сүзләре белән әйтсәк, әлеге «чиле-пешле» кешеләр арасына кереп китә, шешәле мәҗлесләрдә була башлый. Бу, билгеле, ата-ананы да, Фатихны да борчуга салган. Вәгазьләп тә, орышып та карыйлар, бүтән чаралар турында да уйланалар. Тәэсире булмый калмаган, әмма бөтенләй төзәлер чамасы күренми («Ибраһим бу көннәрдә чибәррәк йөреп тора. Ләкин Апанаев, әллә кем, әллә кемнәрнең тәэсире генә бик начар». 17/IV, 1908 ел). Ахыр чиктә еракка, Бәйрүткә укырга җибәрергә карар итәләр. Моны ишеткәч, Ризван да үзенең юмордан мәхрүм түгеллеген күрсәтергә карар иткән: «Әллә хәзер сыерны кеше итәргә Бәйрүткәме җибәрә башладылар?».

Шәхси үрнәк күрсәтүдән тыш Фатих тел белән дә, каләм белән дә, башкача да эчүчелеккә каршы сугыш ача. Соңгы вакытта беркадәр тыела башлаган дусты Исмәгыйльгә язган 17 апрель тарихлы хатында мондый сүзләр бар: «Вәгъдәңдә торып, озатучыларны сыйламаганлыгыңа самими шатландым. Син киткәч, монда гаеп итүчеләр күп табыл-

ды. Бер-икесен редакциядә публично бик нык сүгеп, гром аплодисментовка мөстахикъ* табылдым».

Шул ук хаттан әлеге әшәке күренешкә каршы көрәшү өчен Фатихның җәмгыять сыман нәрсә оештырганы да аңлашыла: «Аеклык җәмгыяте коруның яшьләргә бераз тәэсире хәзердән үк күренә башлады. Редакциягә кереп, эчүе белән мактанып йөри торган кешеләр яшерә башладылар. «Әльислах»та шул турыда минем мәкалә булачак».

«Яшьләр колагына бер сүз» дип исемләнгән ул мәкалә 29 номерда басылып чыккан. Төп идеясе шул: яшьләр — милләтнең, халыкның киләчәге. Шуңа күрә алар һәр җәһәттән, аерым алганда, әхлак ягыннан үрнәк булырга тиешләр.

Эчкечелек мәсьәләсенә Фатих, практик күзлектән генә карамыйча, теоретик яссылыкка күчереп, аны зур социаль проблема итеп күтәргән. Бу фикерне тагын бер кызыклы документ раслый. Ул да булса әдипнең Л. Н. Толстойга язган түбәндәге хаты (тәрҗемәсе безнеке.— *И. Н.*).

«Лев Николаевич!

Мин Сезгә бер әгъзасы үзем булган милләт өчен гаять мөһим бер мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итәм. Мин татар, бу халык, Сезгә мәгълүм булганча, ислам динен тота. Кайчандыр ислам аның тормышында төп фактор булган: бу хәл, үз чиратында, кайбер уңай һәм тискәре нәтиҗәләргә китергән. Исламның уңай нәтиҗәләреннән берсе — татар халкының абсолют аеклыгы. Хәтердә әле, моннан ун ел гына элек татарлар арасында эчкечеләр гомуми масса эчендә аерым чыгармалар гына иде, масса аларга ихтыяр көченнән мәхрүм мескен кешеләр, ә кайчакта исә җинаятьчеләр итеп карый иде. Безнең Европа цивилизациясенә омтыла башлаганыбызга инде менә ун ел була, ун ел буе без һаман бер урында таптанабыз. Мәдәниятне без бик акрын үзләштерәбез, ә инде эчкечелек һәм бозыклык безнең арада аның саен арта, көчәя бара. Шуңа күрә дә әгәр без 10—15 елдан соң шундый аек халык урынында эчүгә сабышкан массаның үлеп бара торган гәүдәсен күрсәк, һич тә гаҗәп булмас. Мин Сезнең бүгенге Европа цивилизациясенә карата тискәре мөнәсәбәттә булганыгызны беләм, ләкин...»

Хат шушы урында өзелеп кала. Сызып ташланган һәм өстәлгән сүзләр, төзәтүләр бу язманың каралама булганлыгын күрсәтә. Тәмам иткәнме Фатих бу хатын, акка күчереп Толстойга җибәргәнме, җавап алганмы — болар безгә мәгълүм түгел.

---

* Мөстахикъ — лаеклы.

Моңарчы язылганнар — Фатих санаторийга киткәнчегә кадәр булган хәлләр. Ислахчыларның ул барында тыела төшкән әлеге егетләре Фатих киткәч, күрәсең, иркенләп киткәннәр. Тукай Серноводскига җибәргән хатында менә нинди сүзләр яза: «Торам, торам да, ярабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан-авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр аркасында да саклап килдегем истигъдәт очкыны шушы исреклекләр, исерек иптәшләр арасында кабынмаслык булып сүнәрмени инде дим?»

Фатих кайткач та хәлләр бик үк үзгәрмәгән булса кирәк. Менә 1909 елның 27 апреленә караган манзара. «Көн тәртибе»нең икенче өлеше. Сөйләшәләр, көлешәләр, ләчтит саталар. Фатих, бүлмәдәгеләргә бик үк игътибар итмәстән, хат язып утыра. «Солтан, үз выражениесенчә, «все время пьян». Хәзер үзе монда, минем янда, сиңа сәлам укый. Тукаев та минем өстәл янында яңагына таянып утыра, сиңа сәлам әйтми. Солтан хәзер үзе яздырган сүзгә үзе үкенә. Шуңа күрә мин дә ул сүзне язмаганга хисаплыйм».

Әмирхан ислахчылар төркеменең, киңрәк алсак, демократик лагерьның әхлакый сафлыгы өчен моннан соң да хәленнән килгәнчә көрәшәчәк. Әмма эчкечелек һәм башка төр әхлаксызлыкның социаль күренеш булганлыгына, иҗтимагый стройның нигезенә барып тоташканлыгына шул вакытта ук хисап бирми кала алмаган.

## 7

Ф. Әмирханның 1908 ел, 2 декабрь хатында мондый сүзләр бар: «Укый торгансың, мин хәзер «Әльислах»та замана хикәяләре яза башладым». «Замана хикәяләре» дигәнне ничек аңларга?

Беренче оригиналь әдәби әсәре «Гарәфә кич төшемдә» моннан бер ел элек дөнья күргән иде. Димәк, ул аны «замана хикәяләре» җөмләсенә кертми һәм дөрес итә. Чөнки бу әсәр, хикәя булудан бигрәк, әдәби чаралар кулланып язылган публицистика.

Күзе ачыла башлаган шәкерт татар милләтенең алга китеп, чәчәк аткан дәверен төшендә күрә. Архитектураның соңгы казанышы булган мәһабәт татар клубында бәйрәм тантанасы, имеш. Меңләгән кеше арасында кем генә юк! Татар гимназияләрендә, университетта, чит илдә укучы егет һәм кызлар дисеңме, милли театрның артист-артисткалары, әсәрләре европа телләренә тәрҗемә ителгән татар язучылары һәм атаклы рәссамнар дисеңме, бөтен

илдә танылган медицина, хокук, физика, математика, политэкономия профессорлары һәм хатын-кыз врачлар, юристлар дисеңме — барысы да бар.

Уку залындагы зур форматлы һәм күп сәхифәле газеталар, әллә ничә исемдә калын журналлар татар промышленносте, татар фәне һәм татар мәдәниятенең бөтен дөньяга таралган даны турында хәбәр бирәләр.

Татар, татар, татар...

Буржуаз милләтчелек юкмы монда? Татар милләтен бүтән милләтләргә каршы кую юкмы? Бу вакыттагы дөньяга карашын яхшы белгәнгә, кистереп җавап бирә алабыз: юк, һич юк!

Беренчедән, болар яңа гына күзе ачылган шәкерт хыяллары. Икенчедән, яшь автор, героеның уй-тойгыларын беркадәр уртаклашса да, милләтне милләткә каршы куймый, мәгърифәтче буларак (әйе, ул мәгърифәтче дә бит әле), татарларны алга киткән милләтләр дәрәҗәсенә күтәрү турында хыяллана. Әнә бит татар егете белән рус кызы ничек бирелеп шахмат уйнап утыралар. Өченчедән, төштә күрелгән ялтыравыклы тормышның нинди җәмгыять күренешләре икәнен, аңа ирешү юлларын күрсәтү бу әсәр вазифасына керми, авторның максаты да ул түгел. Фатихның әйтергә теләгәне шул гына: бусы — ерак хыял, ә менә бусы күңелсез чынбарлык.

«Гает вакыты җитте, тор!» дигән тавышка безнең шәкерт уянып китә.

Мәчет. Гатырша мае һәм күн исе белән кушылган укшыткыч һава. Мулланың тыңкыш тавыш белән тотлыга-тотлыга хөтбә укуы. Халыкның йокымсырап утыруы. Мәчет ишек төбендәге хәерчеләр. Гает белән котлау өчен ясалган эчпошыргыч визитлар. Шундый ук котлаучыларны өйдә кабул итү. Туйдырып бетергән һәм акылга аз гына да азык бирми торган мәгънәсез сөйләшүләр.

«Заман хикәяләре яза башладым» дигәннән иң элек тормышымны нәфис әдәбиятка багышларга карар иттем дигән мәгънәне аңларга кирәк. Чынлап та бит Ф. Әмирхан әдәби иҗатын каләмдәшләренең барыннан да соңрак башлады. Г. Камалның әнә беренче әсәре — пьеса, Тукайныкы — шигырь, Г. Ибраһимовныкы — хикәя. Ш. Камал, шигырьдән башлап, хикәягә күчә. Ф. Әмирханның теле публицистика белән ачылды. Чөнки безнең Фатих җәмгать эшлеклесе булу хыялы белән яшәп, саф әдип «карьерасы» турында бик аз уйлый иде. Менә ул караватка һәм коляскага баглы булып калды. Нишләргә? Ни белән шөгыльләнергә? Кем булырга? Рус әдәбияты дөньясына чумгач, аның ма-

турлыгын һәм көч-куәтен күреп соклангач, көннәрдән бер көнне карар кабул ителәә: нәфис әдәбият өлкәсендә көч сынарга.

Рус классикларыннан тыш, Белинский, Добролюбов һәм Писаревның мәкаләләрен укып уйлану нәтиҗәсендә Фатихнең әдәбиятка карашы да инде калыплашып җитте. Прозаны хәзер — хикәяме ул, романмы — элеккечә язарга ярамый, яңача, заман таләп иткәнчә язарга кирәк. Муса Акъегет-задә яисә Заһир Бигиевне әйтеп тә тормастан, Риза казый һәм Ф. Кәрими, З. Һади һәм Ш. Мөхәммәдевләр дә әхлак дәресе биреп килделәр. Әйбәт эшләнгән тискәре типлар белән генә чикләнмичә, үз хыялларында ясалган идеаль типны аңа каршы куярга ашыгалар иде. Аларның геройлары еш кына фикер әйтү өчен сылтау хезмәтен генә үти иде. Кара инде син Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» исемле хикәясен! «Имтихан» дигән сүзнең мәгънәсен дә белми торган томана надан бакча каравылчысы, каникулга кайткан ике шәкерткә үзенең өйләнү тарихын сөйләгәч, нәсихәткә күчеп, Жорж Санд һәм Эмиль Золяларны укырга киңәш бирә!

Бүген дә әле әдәбиятта күп үзгәреш сизелми. Һаман уйлап чыгаралар, әкият сөйлиләр, үгет-нәсихәт укыйлар. Әнә Ярулла Вәли кабердән казып алынган хатын турында акылга сыймастай нәрсәләр язган иде. Менә тагын «Ачлык кушты» исемле пьесасында надан хатыннан татарларның борынгы шәүкәте турында фәлсәфә саттыра.

Ярулла — Ярулла инде. Шигырьдә һәм прозада тәҗрибә туплаган М. Гафури да искергән алымнардан арынып җитә алмый. «Үги балалар» повестен ул, мәсәлән, «үткән татар ханнарын мактап язган шигырь белән башлап, төрле-төрле белә торган фикерләрен сөйләп бетергәннән соң, бер татар хатынын өч кател * җинаятендә гаепле ясап тәмам итә».

Дөрес, яңа рухтагы әсәрләр дә күренә башлады. Ләкин алары да театр әдәбияты өлкәсендә генә. Менә Г. Камалның «Беренче театр»ы, менә С. Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә»се. Комедиясен Г. Камал, ди Ф. Әмирхан, «хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган булса да, урта буржуазный классның психологиясен бик яхшы төшенгәнлегеннән, комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумият бирә».

Ф. Әмирхан фикеренчә, заман турында заманча язарга кирәк. Материалны тормыштан ал, аны, объективлык сак-

---

* Кател — үтерү.

лап, эшкәрт, әйтергә теләгән фикереӊ беләп сугар, ләкин ул фикереӊ төртеп тормасын, сурәтләргә сеӊгән булсын. «Замана хикәяләре» дигән гыйбарәнеӊ төп мәгънәсе әнә шуӊа кайтып кала.

Бу төргә кергән хикәяләрдән беренчесе «Бәйрәмнәр»-неӊ «баш герое» Вәли абзый — типик кадимче сәүдәгәр, һәр яӊалыкныӊ дошманы. Әмма автор аны каралтырга керешмәстән, битараф булган булып, кешегә хас кайбер уӊай якларын да яшермичә, эчке дөньясын анализлый.

Менә Вәли абзый гарәфә кич ястү намазыннан гадәтенчә моӊсуланып кайта. Чөнки татарныӊ бер төсле тормышын азмы-күпме бизи торган рамазан аеныӊ соӊгы көне бу. Киләсе уразага кадәр әллә торыла, әллә юк... Карчыгы Гайникамал, хәләл җефетенеӊ гадәт-холкын белгәнгә, аӊа тәмам яраклашкан. Йомшак кына сөйләшәләр, яшь чакларын искә төшереп, моӊланып алалар.

Бәйрәмгә әзерләнеп йөрүче хатынына дөнья эшләренә бик бирелеп китмәскә, изге бәйрәм кичен гыйбадәт беләнрәк уздырырга киӊәш биреп, Вәли абзый намаз укырга утыра. Аннары ул ашыкмый гына чишенә дә, аягыныӊ бармак араларын казып, йокларга ята.

Гает көн дә гадәтчә башланып, гадәтчә дәвам итә. Мәчет. Иртәнге намаз. Ел да була торган күренешләр, шул ук тәкәллефләр. Мулланыӊ вәгазен тыӊлаганда ирләр мышмыш йокласа, Вәли абзый гына лышык-лышык елый. Намаздан соӊ, тиешле садакаларын биреп, ул өенә кайта. Хатыны елдагыча кулын үбеп күрешә. Елдагыча өстәл мул әзерләнгән. Улы Габделгалләм дә атасы беән олылап күрешә. Егетнеӊ кыяфәте бәйрәмчә: ап-ак такыр баш, өр-яӊа кара кәләпүш, ялтыр читек, тубыкка кадәр төшкән чалбар. Казаки изүеннән ак якасы күренеп тора. Ата кеше, улыныӊ болай фырт киенүен өнәп бетермәсә дә, «урыска охшап йөрмәвен» истә тотып, сүз әйтми.

Менә Вәли абзый, яхшы атка утырып, улы белән берлектә зиратка китә. Анда да елдагы йолалар үтәлә, тәкәллефләр башкарыла. Вәли абзый садака җыючыларга, дәрәҗәләренә карап, хәер өләшә. Саилчеләргә дә юмартлык күрсәтә: бер тиен урынына икешәр тиен бирә.

Һәр елдагы гадәт буенча ата белән угыл бәйрәм визиты ясый башлыйлар. Бераз икеләнеп торганнан соӊ, Вәли абзый европача яши башлаган яшь купец Габделмәҗиткә дә керергә була. Чөнки аныӊ атасы Вәли абзый белән дуслык мөнәсәбәтендә булган.

Габделмәҗитнеӊ, бөтенләй «урыслашып» җиткәнлеге хакында Печән базарында күп мәртәбәләр ишетсә дә, Вәли

абзый болай ук булыр дип уйламаган. Зур рояль, стеналарда җанлы нәрсә сурәтләре, өстәлдә татар ашлары урынына — куличлар. Болары әле бер хәл. Әнә күрше бүлмәнең ачык ишегеннән озын чәчле егетләр һәм марҗа кебек кызларның көлешү, чыркылдашулары ишетелеп тора. Вәли абзыйның дини-милли тойгысы кузгалып куя, сүгеп, хурлап чыгып китәсе килә. Әмма ул сабыр кеше, бәйрәм хакын, хуҗа хакын хаклап, тыелып кала: гайрәт чәчеп кенә заманны үзгәртә алмассың.

Эчке бүлмәдән яланбашлы егет белән хуҗа килеп чыгалар. Егет репетициягә ашыкканын әйтә: бәйрәмнең икенче көнендә әдәбият кичәсе буласы икән. Вәли абзый түзеп кала алмый, егетне оялтырга, битәрләргә, инсафка китерергә керешә. Оста язылган диалогны егет болай дип очлап куя: «Сез, бабай, кызып китмәгез, беләсез бит, безнең шикелле халыкка кызып китеп, сүгенеп, ачуланып кына бер эш тә эшләтеп булмый. Алар һәммәсе безгә көлке генә тоела».

Габделгалләм беркадәр бүтәнрәк хисләр кичерә. Өйнең эчке күренеше, егет һәм кызларның өс-башлары, татар булсалар да русча кыланулары аңар алай ук ямьсез күренми. Яланбашлы егет белән атасының бәхәсен тыңлаганда, үзе дә хисап бирмәстән, егет сүзләрен хуплый. Иртәгә булачак әдәбият кичәсе турындагы хәбәр дә колагын торгыза.

Гаетнең икенче көне. Галләмнең кәефе юк, башы авырта: кичә үз ишләре белән шәпләп бәйрәм иткән иде. Шулай да әдәбият кичәсе дигәннәренә барасы иде бит. Әмма атасы, улының ниятен сизгәндәй, әйтеп куя:

«— Менә, улым, кичә күргәнсең, ул шәйтан кичәләрен нинди динсезләр ясап йөриләр. Кайда барсаң — бар, әмма анда аяк атлыйсы булма, бездән рөхсәт юк!»

Габделгалләм, икеләнеп торганнан соң, тәвәккәлләргә була. Күреп калмасыннар дип курка-курка Купеческое собрание бинасына бара һәм, билет алып, эчкә керә. Аптырау катыш кызыксынып күзәтә. Бәлки калыр да иде, әмма атасының якыннарыннан берсе күренүгә, китү ягына борыла.

«— Юк ла, Җамали абзый, монда безгә килешерлек нәрсә юк икән лә!

— Әйе, әйе, монда урыс-улак.

Габделгалләм китте. Ул бүген төнлә кайтмаска китте. Юлда барганда: «Юк ла, без, мөселманга, килешми лә», дип уйлыйдыр иде. Ул әдәбият кичәсендә вакыт уздырма-

ды, атасының сүзен тотты». Хикәя үтергеч иронияле әнә шундый сүзләр белән тәмам була.

Күренә ки, Ф. Әмирхан иске тип татар сәүдә буржуазиясенең арурак вәкилен сайлап алган, бик үк карага буямый гына үзенчә яшәргә, үзенчә гамәл кылырга юл куйган, героена карата антипатиясен сиздерми генә акрынлап аның эчке дөньясын ачып биргән.

Ф. Әмирханның «заман хикәяләре»нә укучыларның реакциясе дә кызыклы: андагы геройларда бик күпләр үзләрен таныйлар. Менә без белгәннәре генә.

«Бәйрәмнәр» басылып чыккач бер «типкеч бай малае» үзе турында язылган дип уйлап, «Әльислах»ка вәгъдә иткән акчасын бирмәгән икән *.

«Милләт тәрәккый иттерү» хикәясе басылып чыга. «Икенче көнне,— ди Ф. Әмирхан,— Кули Ибрай, Хатип, тагын әллә кемнәр килеп, үзләре көләләр, үзләре мине сүгәләр». Андагы мишәр сурәтендә үзен күреп, Ризван да дустына бик каты үпкәләгән.

«Хәкарәт саналган мәхәббәт» дигән бер кыйссачык яздым. Газетада чыгып бер-ике көн узгач, Сәгыйть Рәмиев, Фәхрелислам Агиев килеп, мине эт итеп сүгәләр. Ник? Чөнки мин ул кыйссада аларның вакыйгаларын язган икәнмен. Чөнки алар гашыйклар икән дә, мин аларның гыйшкыннан көлгән икәнмен. Мин сорыйм, соң господа, минем язган героем бер генә, кайсыгыз инде ул? Синме, Рәмиев, әллә синме, Агиев? Икесе дә үзләрен күрсәтәләр».

Үпкәләүчеләрнең кайберләре чынлап та «замана хикәяләре»нә прототип булып хезмәт иткән. Ә күпчелеге алдында Фатихның «гөнаһы» юк. Әмирхан геройларында алар үзләрен көзгедә күргәндәй күргәннәр икән, бу хәл әлеге хикәяләрнең тормыштан алынып, гомумиләштереп, типлаштырып язылган чын реалистик әсәрләр булганлыгы турында сөйли.

«Замана хикәяләре»нең беренчесендә без эчкә яшерелгән сатира күрдек. «Милләт тәрәккый иттерү» — ачыктан-ачык сатира. «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә дә без тышы яңа, эче иске булган байбәтчәнең колоритлы сатирик образы белән очрашабыз. Моннан соң ул тагын берничә менә дигән сатирик хикәя бирү белән бергә, «Фәтхулла хәзрәт» исемле сатирик повестен дөньяга чыгарып, дан казаначак.

---

* Комментаторлар аны Исмәгыйль Аитов дип юрыйлар. Моның белән килешү кыен. Европалашкан гаиләнең артыграк европалашып киткән әгъзасы такыр башлы Габделгалләмдә үзен күрмәс.

Ф. Әмирхан иҗатында юмор һәм сатираның шундый зур урын тотуы ни белән аңлатыла? Барыннан да элек, әлбәттә, әдипнең табигате, характеры белән. Тумыштан зирәк, үткен һәм тапкыр. Гыйлем-мәгълүматы тиз арту белән бәрабәр рухи яктан да тиз өлгерде. Болай да үчекләүгә, ирештерергә, мыскыл итүгә һәвәс яшүсмер, тора-бара үзенең өстенлеген тоеп, искелек күренешләренә, аның терәкләренә ачы көлү, ирония белән карарга күнегеп китте.

Икенчедән, тормыш үзе, тарихи барыш аны сатира каләмен эшкә җигәргә кушты. К. Маркста тирән мәгънәле мондый фикер бар: «Дөньякүләм тарихи форманың соңгы фазисы — аның комедиясе». Ягъни җәмгыять — колбиләүчелекме ул, феодализммы, капитализммы — югары ноктасына җиткәннән соң төшүгә, таркалуга, җимерелүгә таба йөз тота һәм үлеменә кадәр берничә баскыч, берничә фазис уза. Соңгысы — аның комедиясе. Чөнки бу строй инде тәмам картайган, бетәшкән, кабер кырыена килеп баскан, әмма, җыерчыклы битенә иннек-кершән ягып, карт тәнен асыл киемгә төреп, бөкресен чыгармаска тырышып, яшь, таза, һәм сау булып күренергә тели, үзен дә, бүтәннәрне дә моңа ышандырырга азаплана. Шуннан туа көлке, шуннан туа эчтәлек белән форма туры килмәвенә нигезләнгән комедиячел хәл.

Реакцион татар руханиларының һәм иске тип сәүдә буржуазиясенең яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, тормыш кагыйдәләре, XX гасыр кергәч, феодализмның соңгы фазисы гына да түгел, бәлки анахронизм хәленә килгәне иде. «Иске — изге» дигән караштa торып, үзләрен генә хаклы, үзләрен генә дөнья тоткасы дип санаган кадимчеләрнең сөннәтчә кырылган сакал-мыек, сөннәтчә тегелгән калыпсыз казаки, кырган башны яклап күсәк күтәрүләре көле генә тудыра иде. Әнә шул анахронизмны тарих чүплегенә илтеп ташлар өчен, иң кулай әдәби корал сатира булды.

## 8

1909 елның язында «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәч терелүе» исемле 24 битле китапчык укучылар кулына керә. Озакламый «Фәтхулла хәзрәтнең гает көне» исеме астында икенче кисәге дә китап киштәләрендә урын ала. Соңгы кисәкләре 1910 елда чыга. 1911—1912 елларда инде тагын бер кисәк өстәлеп, димәк, биш китап булып, әсәрнең икенче басмасы дөнья күрә.

1909 елгы 2 февраль хатында түбәндәге сүзләр бар: «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәч терелүе» дигән кыйсса яза

башладым. Әти, Йосыф хәзрәтне тәхкыйрь итәсең дип, башыма кыямәтләр кубара». Фатих, күрәсең, булачак әсәрнең тәэсир көчен сынарга яисә әтисен ирештерергә теләпме, язган кадәресен өйдәгеләргә укыган. Зариф хәзрәт исә мөхтәрәм Фәтхулла хәзрәт артында кем торганны шунда ук аңлап алган. Әдип үзе дә моны кире какмый. Без дә Йосыф ахун һәм Фатихның үзара мөнәсәбәтләре турында байтак нәрсә белгәнгә, Зариф хәзрәтнең хаклы булганлыгына шикләнмибез.

...1950 елның зөлхиҗҗә аенда Казан университетының медицина профессоры Мөслимов, ярдәмчесе доктор Әхмәт белән берлектә, кабердән чыгарып, өч ай эчендә билгеле бер рәвешкә китерелгән Фәтхулла хәзрәткә җан кертә. Казанда мулла булып торган, «Дин вә мәгыйшәт» журналына берничә мәкалә язган, ишанга кул биргән, прогресска һәм прогресс тарафдарларына бөтен көче белән каршы торган мөхтәрәм хәзрәт кырык ике елдан соң яңа дөньяда, яңа шартларда яши башлый.

Казан һәм аның кешеләре танымаслык булып үзгәргән. Җиде-сигез катлы мәһабәт торак йортлар һәм мәрмәр колонналы сарайлар дисеңме, бихисап автомобиль һәм һава көймәләре дисеңме, канат куеп очып йөрү һәм көзгеле телефон дисеңме — ни генә юк! Диварлар сынлы сәнгать әсәрләре белән бизәлгән, музыка яңгырап тора. Кешеләрнең өс-башы тоташ европача, хатын-кызларның чәчендә генә кечкенә калфак. Эчке дөньялары да бөтенләй бүтән. Бер-берсенә мөгамәләләре ягымлы, итагатьле, үзләрен әхлак кагыйдәләре кысасында тоталар. Әхлак бозучылар өчен «Бозыкларны төзәтү» җәмгыяте бар. Гаебе артык зур булмаса, мулла вәгазьләү белән генә чикләнә, зуррак булса, төрле срокка мөселман монастырена ябалар. Дин тоту вөҗдан эше, беркем сине көчләми. Бөтен шәһәргә бер — әмма гаять зур мәчет. Артык зиннәтләнмәгән гади бинасы шәһәрдән 20 чакрым ераклыктагы урман эченә урнашкан. Теләгән кешеләр гыйбадәт кылып яисә костюмлы, галстуклы мулланың лекция-хөтбәсен тыңлап, рухи яктан сафланып кайталар.

Фәтхулла хәзрәт йөрерлек хәлгә килгәч, улы Әхмәт аны өенә алып кайта. Урамдагы могҗизаларны, Әхмәт өендәге җиһаз-зиннәтләрне күргән, ашап туйгысыз ризыкларын татыган хәзрәтнең акылы хәйран. Кайда ул? Әллә оҗмахтамы?! Булса да булыр: җәдитләрне дөньялыкта сүгеп, хур итеп яшәде. Алай дисәң, ник хур кызлары күренми? Әһә, әнә берсе пәйда булды. Фәтхулла хәзрәт кочагын җәеп килгән генә иде — чалт яңагына. Асрау кызны кочак-

ларга теләгәне өчен хәзрәтне бозыкларны төзәтү җәмгыятенә илтергә дип канатлы ике егет килеп керәләр дә, айваена карамый, кәрзингә утыртып алып китәләр.

Яисә менә көзгеле телефонда бер егет күренә һәм Ләйлә туташны сорый. Кара син бу оятсызны, көпә-көндез кыз катына килгән! Җитмәсә, бабасыннан сорый. Хәзрәт егет белән шактый әрепләшкәннән соң, гайрәткә кереп, урындык күтәрә һәм көзгене чәлпәрәмә китерә.

Театрга бару эпизоды да гыйбрәтле. Хәзрәт өйдәгеләрнең кая җыенуларын белеп алгач, элеккеге гадәте буенча гайрәт чәчә башлый. «Теләсәгез кайда барыгыз, мәсәлән, теләсәгез нинди урында, фаразан, булыгыз, ләкин татар тиятренә, мәсәлән, барырга миннән рөхсәт юк». Аның сүзен колакка да элмичә, тегеләр җыена бирәләр. Көфер белән куркытудан да файда чыкмый. Нишләргә? Китәләр бит инде, бабаларын калдырып китәләр... Картның исә барасы килә, чөнки театрны ул хатын-кыз белән кочаклашып бию урыны дип белә. Ничек итеп ияргә боларга? Һәм менә безнең хәзрәт беркатлы хәйлә уйлап таба: «Тиәтергә баруның җәвазына *, мәсәлән, хәзер берәр гыйбарә таптыгызмыни соң?»

Г. Камалның Хәмзә бае театрның үзен үк туктатмакчы иде. Әмма улы һәм кызын, кияве һәм киленен дә спектакльгә барудан тотып кала алмады. Ә бит кулында — аталык власте дигән көсәк бар. 1950 елда кабат яши башлаган Фәтхулла хәзрәт кулында исә салам гына. Шул салам белән кизәндереп, язучы хәзрәтнең комедиячел асылын соңгы чигенә җиткергән.

Тукайның Кисекбашка карата әйткәне Фәтхулла хәзрәткә дә туры килеп тора:

> Бу мидә бардыр җәһаләт ун вагон,
> «Мин беләмлек» дәгъвасы — бер мең вагон.
>
> «Иске — изге» фикре бардыр ун келәт.
> «Һәр җәдит — кяфер» — егерме склад.

Әсәрне укыганда тагын шуны сизәсең һәм аңлыйсың: Фәтхулла мулланың бу сыйфатлары тумыштан килмәгән, бәлки татар җәмгыятендә сакланып калган урта гасырчылык яшәеш кагыйдәләреннән йоккан. Аның һәр сүзе, һәр кыланышы кадимчеләр лагерена сатира угы булып кадала.

«Фәтхулла хәзрәт»нең икенче басмасы кисәкләп чыга башлагач, кемдер берәү «Йолдыз» газетасында «Тимербай» имзасы белән фельетон бастыра.

---

* Җ ә в а з — дөрес булу, рөхсәт ителгәнлек.

Фәтхулла хәзрәт, янәсе, комсызланып ашагач, өйдәгеләр белән кычкырышкан һәм асрау кызга кул сузганы өчен кисәтү дә алгач, сәйранга чыгып киткән. Кайтышлый шәһәрдәге бердәнбер белгән кешесе Ф. Әмирханга килә һәм күргәннәрен сөйләп бирә. Фельетончыга иң ошамаганы шул: ничек инде яңа гына мәеттән тере кешегә әверелгән карт хәзрәт шул кадәр күп итеп ашый алсын?!

Шул ук «Йолдыз»да басылган җавабында Ф. Әмирхан болай ди: «Фәтхулла хәзрәт» рисаләләрендә миңа — язучысына матлуп булган нәрсә фәкать: мөбәрәк хәзрәтебезнең хәзинәи фикрия вә рухиясeдер *. Калганнары, фәкать, канва эшләүче татар кызына марляның әһәмияте кадәр генә әһәмиятледер... Марля күзләренең бик пөхтә, тигез булуына артык игътибар итмәгән канвачы, занымча **, бик зур җинаять иясе түгелдер». Ягъни авторның төп максаты — дин-мәгыйшәт айгырларының типик образын тудыру, киләчәк җәмгыять күренешләре исә әнә шуңа хезмәт итә торган чара гына. Кара тап ак җәймә өстендә тагын да карарак булып күренгән шикелле, алга киткән җәмгыять фонында Фәтхулла мулланың иске тормышта калыплашкан гадәт-холкы, кыланышлары, иманы тагын да искерәк, тагын да көлкерәк булып күз алдына килеп баса.

Болары шулай, әмма мәсьәләнең тагын бер ягы бар: марля — марля булсын, чыпта ярамый. Әсәрдәге фантастик дөнья Ф. Әмирханның киләчәк турындагы уйлануларына, әлбәттә, якынча туры килә.

Соң нинди җәмгыять бу?

Заманында вульгар социологизм шаукымына бирелгән язучы һәм тәнкыйтьчеләр кистереп әйткәннәр иде: буржуаз җәмгыять, капиталистик строй. Әсәргә кабат күз ташлыйк. Бармы анда бер генә бөртек фабрикант? Ялланып эшләүче кеше? Сәүдәгәр? Ахыр чиктә, бармы бер приказчик? Әхмәтнең шофер һәм асрау кыз тотуын яисә эшсез калганнар файдасына иганә биреп китүен җитди дәлил итеп карап булмый. Хезмәтчеләр доктор Әхмәт өчен табыш чыганагы булмаган кебек, социализм җиңгәч тә бар кешегә дә тигез муллык урнашып җитмәве мәгълүм нәрсә.

Повестьны язган чагында Ф. Әмирханның социализм тарафдары булганлыгын белгәнгә шикләнми әйтә алабыз: әсәрдә тасвир ителгән җәмгыять әдип аңлаган социализмнан бүтән нәрсә түгел. Без белгән социализмга бик үк

---

* Хәзинәи фикрия вә рухия — рух һәм фикер хәзинәсе.
** Занымча — фикеремчә.

ошап җитми икән, нишлисең, демократ язучыдан көрәзә-лек могҗизасы таләп итеп булмый. Бу бер. Икенчедән, киләчәк җәмгыятьне тасвирлаганда ул, үзе әйткәнчә, төгәллеккә дәгъва итми.

Дин мәсьәләсенә килик. Ф. Әмирхан, билгеле, кайдадыр гаршедәге көрсиендә утыра торган сакаллы аллага, оҗмах һәм тәмугка ышанмаган кебек, коръәннең каршылыклы фикерләр һәм әкиятләр җыелмасы булганлыгын яхшы белә. Дөрес, аның табигать һәм җәмгыять белән идарә итүче ниндидер югары көчкә яисә җанның үлемсезлегенә ышанган булуы, һәрхәлдә, ышанырга теләве ихтимал. Әмма бу мәсьәләне белгечләргә калдырып, Ф. Әмирханның дингә мөнәсәбәте мәсьәләсенә генә тукталып китик.

А. М. Горькийның «В. Г. Короленко» исемле истәлегендә мондый бер диалог бар. Короленко бервакыт Горькийдан: «Ничек соң сез — марксист булдыгызмы инде?» — дип сораган. «Мин аңа: шуңа якын дигәч, ул күңелсез генә елмайды:

— Мин төшенеп бетмим аны, идеализмнан башка социализмны мин аңламыйм! Материаль интересларның берлеген аңлау нәтиҗәсендә генә этика тудыру мөмкин дип уйламыйм, ә этикасыз бернәрсә дә эшли алмыйбыз». Әнә бит Әмирханның ихтирамын казанган демократ Короленко да (Фатих аның турында әле мәкалә дә язачак) җитештерү чараларын халык милкенә әверелдерү һәм эксплуатацияне бетерү җирлегендә генә яңа әхлак нормаларының эшләнеп чыгачагын күз алдына китерә алмаган. Безнең Әмирхан да җәмгыятьне үзгәртеп коруда демократик революциядән тыш әхлак тәрбиясенә зур урын бирә иде. Ул да, бүтән мәгърифәт чараларыннан кала, яңа әхлак нормаларын халык аңына сеңдерүдә идеализмның бер төренә — «тән селкетүләр»дән, «шаманлык»тан азат булган саф дингә өмет баглый. Әдипнең фикердәшләре Г. Камал һәм Г. Тукай, М. Гафури һәм Ш. Камал да дин һәм әхлак мәсьәләсен шулай аңлыйлар иде.

## 9

Туктауга якынлашып килә торган «Әльислах»ка җан кертү өчен көч кую, «Фәтхулла хәзрәт»нең яңа кисәкләре өстендә эшләү белән берлектә, Фатих бер-бер артлы яңа әсәрләр яза. 1909 елның февралендә «Картайдым» исемле хикәясен тәмамлый. Шул ук айның ахырында «Татар кызы» нәсерен язып бетереп «Сабах» нәшриятына тапшыра. 23 апрель хатында мондый сүзләр бар: «Май башларында

«Алмашыну көннәрендә» исемле өч пәрдәле бер пьеса язып тәмам итсәм кирәк. Хәзер өченче пәрдәсенең яртысы язылды инде. Яшьләрдән бик күп кешеләргә язылган кадәрен укыдым. Ошаталар». Монда соңрак «Яшьләр» дигән исем астында дөнья күргән пьеса турында сүз бара. Үзенә ошап җитмәгәнгә күрә өр-яңадан төзәтергә керешкәндерме, әсәр июль ахырында гына тәмам булган.

Драматургия өлкәсендәге беренче омтылышы ук Фатихка уңыш китерде. Гаҗәеп тере һәм тормышчан персонажлар, кискен һәм шулай ук тормышчан конфликт. Яшьтән үк театрга якын торуы һәм рус классик драматургиясен тырышып өйрәнүе, күрәсең, бушка китмәгән.

Ф. Әмирхан турында язган барлык әдәбиятчылар да дип әйтерлек «Яшьләр»дә «аталар һәм балалар» проблемасы куелган дип белдерәләр. Бу фикерне инкяр итеп булмый. Пьеса күпмедер дәрәҗәдә, һичшиксез, татар тормышына И. С. Тургенев иҗаты, бигрәк тә аның шул исемдәге романы яктылыгында карау нәтиҗәсендә туган.

Кемнәр соң алар иске тормышны яклаучы аталар? Бу лагерьга иң элек Печән базары сәүдәгәре Рәхимҗанны кертергә кирәк. Ул типик «дин-мәгыйшәт айгыры»: үтеп чыккан надан, кире, бозык. Аныңча, һәр «иске — изге». Икенчесе — Хөсәен. Аваз методы белән укытуны яклый, шәригать мөмкинлек биргән дәрәҗәдә яңалыкны кабул иткән, улларын «адрес язарлык» һәм «гәзитә укырлык» кына русча укытырга да риза булган. Кыскасы, бу — җәдитче татар купецы. Хатыны Мәрьям һәм кызы — Рәхимҗанның хатыны — Фәхернисa, табигый, шушы лагерьга керәләр. «Милләтче» дип тәкъдим ителгән Зыя яше, өс-башы, сөйләшүе һәм аралашу даирәсе ягыннан «яшьләр» лагерена карый кебек. Әмма бу — тышкы охшашлык кына. Түбәндәге ике репликаны чагыштырыйк.

«Р ә х и м җ а н. Әлегечә, шул инде, кеше арасына керәсе килсә, Газизгә кибеттә дә күренгәләп, агай-эне арасындарак йөрергә кирәк шул».

«З ы я. Көненә бер-ике мәртәбә кибетегезгә төшеп менсәгез, ара-тирә мәчеттә күренгәләсәгез, атагызның дус-ишләре белән катнашкаласагыз, милли киемдә йөрсәгез — сезгә нинди зарар килер иде?»

Янсә мондый бер деталь. Фатима исемле курсистка: «Ашагач дога кылу фарызмы, түгелме?» — дигән сорау бирә. Динне яхшы белгән яшьләр ачык әйтәләр: фарыз түгел. Шуннан кыз Зыяга мөрәҗәгать итә, тегесе болай ди: «Фарыз ук булмаса да, дога кылган яхшы». Менә бит нинди ул Зыя. Бәхәстә урта юл эзли, каршылыкларны ки-

лештерергә омтыла. Моннан инде Газиз белән атасын гына түгел, бәлки крестьян белән алпавытны, эшче белән фабрикантны килештерергә омтылуга да ерак калмый. Яшәп килүче строй адресына шактый ачы сүз әйтелгәч, Зыя: «Бу сүзләрдән 1905 нче ел исе килә»,— дип ычкындыра. Усал телле Йосыфның тапкыр җавабы, мәргән җәясеннән очкан ук кебек, төбәлгән ноктасына кадала: «Кстати сказать, милләтче борынына бер дә килешми торган ис». Милләтче Зыя, димәк, картлар лагере вәкиле.

Яшьләр лагерена Хөсәеннең уллары Газиз һәм Йосыф, кызы Зәйнәп, атасы ишаннан ваз кичкән Гали, «демократ» Әхмәт, учитель Зәкәрия, гимназистка Сара һәм башкаларны кертергә мөмкин. Уртак теләкләре — татар тормышын нигезеннән сүтеп кору. Ләкин ничек, нинди юл белән? Җаваплар төрле. Арада ике программа өстенлек итә. Берсен Гали әйтеп бирә: «...безнең бу көнге задачабыз искене вату. Без, бүген үк яңаны эшләп, татарның күз алдына китереп куя алмабыз... Без Рудиннар, Базаровлар була алсак, халыкка бер туктамый искене җимерү идеясен сөйләсәк, киләчәктә чын эш эшләрлек кешеләр дә җитешерләр, яки без үзебез үк күп тәҗрибәләр белән эшләрлек кешеләр булып чыгарбыз». Галинең рус разночинецларын һәм народникларын күздә тотып сөйләгәнен искә алсак, бу «программа»ны якынча революцион-демократик эчтәлекле мәгърифәтчелек дип бәяләп булыр иде.

Икенче «программа» Әхмәт авызыннан әйтелә. Зыяга җавап рәвешендә ул болай ди: «Юк, брат, әгәр сез татарны чынлап алга җибәрәсегез килсә, фәкыйрь халыкка: крестьян, рабочийга сознание кертергә тырышыгыз. Фәлән байның һиммәте, фәлән байгураның шәфкате дип кәгазь буяганчы, шул фәләннәрнең ничек итеп кеше эшләгәнне ашаганлыкларын, шулар эше аркасында баеганлыкларын языгыз». Яшьләрнең бер урында аны «социалист», икенче урында «демократ» дип атауларыннан чыгып, без Әхмәтне социал-демократлар карашын алга сөрүче итеп саный алабыз. Авторның аны «Учительская школа тәмамлап, аттестатка хәзерләнүче» дип тәкъдим итүе дә очраклы түгел.

Газиз белән Йосыф, эш-хәрәкәтләре һәм уй-фикерләре күрсәткәнчә, Галигә якын торалар. Шунысы кызык: Газиз озын-озын монологлары белән Рудинны хәтерләтсә, кыска һәм үткен реплика, ирония һәм сарказмнары белән Йосыф нигилист Базаровка охшый.

«Нәрсә эшләргә?» дигән атаклы сорауга пьеса Гали «программасы» яктылыгында җавап бирергә тиеш кебек.

Әмма әсәрдә учитель Зәкәрия бар бит әле. Галинең искене җимерү идеясен туку өчен халык арасына башта көчләп керергә кирәк дигән сүзләренә каршы ул болай ди: «Менә мин Казан губернасында ике ел учитель булып тордым. Әүвәлге елны балаларын укыттым, үзләре белән эшем булмады — ул елны ничево. Ә икенче елны кичләрдә, карт мужикларны җыеп, газета укып сөйли башладым. Җыеннарына барып, белгәннәремчә, файдалы советлар бирә идем. Теләгәннәренә буш русча укыттым. Нәрсә булды дип уйлыйсыз? Донос ясап, урынымнан кудырттылар. Менә көчләп кереп хезмәт ит!»

Кала бер юл: Әхмәт «программасы».

Пьесада күтәрелгән тагын бер проблема — хатын-кыз хокуксызлыгы мәсьәләсе дә әнә шул рәвешчәрәк хәл ителә. Әсәр политик азатлык һәм социаль тигезлек яулап алу өчен мәгърифәт коралы гына җитмәгән кебек, хатын-кызны коллыктан коткаруда да бу корал үзе генә көчсез, дигән фикергә китерә.

Бер хатында Әмирхан болай дип яза: «Яшьләр» тугрысында берникадәр отзывлар алдым. Яшьләр «Яшьләр»не бик, хәтта артык яраткалыйлар икән. Бу да бер нәүгы партия тәгассыбы бит. «Яшьләр»нең художество җәһәте бик начар бит» (11 апрель, 1910). Әсәрне күккә чөеп мактауда әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше генә түгел, бәлки политик көрәш исәп-хисаплары да күпмедер роль уйнаган икән. «Бик начар» дигән сүзләргә килсәк, болар, билгеле, урынсыз кулланылган. Шулай да авторның үз әсәреннән канәгатьләнеп җитмәгәнен инкяр итеп булмый. Нәрсәсе ошамаган аңа дигән сорауга җавап бирү кыен. Тик шуны гына әйтергә мөмкин: сәхнә таләбеннән чыгып караганда, ике тема арасында бәйләнеш аз булып, вакыйга берлеге җитеп бетми, катнашучылар күп, кайбер персонажлар артык озын итеп сөйлиләр. Бәлки укучы да чамалагандыр, вакыйга һәм анда катнашучылар тормыштан алынган. Хөсәендә, мәсәлән, Зариф хәзрәт чалымнары күзгә ташлана. Пьесадагы хатын-кыз образларын да ул дус-ишләреннән, туган-тумачаларыннан алган. Фәхернисаны әтисенең сеңлесе Мәрьямнән күчергән булуы мөмкин. Бервакыт шулай Мәрьям апасы килеп чыккан, хәл-әхвәл сорашырга керешкән. Чират Фатихка җиткәч, үгет-нәсихәт бирүдән дә тыелып кала алмаган. «Абый,— дип яза истәлекче,— шәех шикелле кулын кушырып, бик җитди кыяфәттә тыңлап утырды-утырды да, бер паузаны туры китереп кинәт болай диде: «Мәрьям апа, син әтәч булып кычкыра беләсеңме? Зинһар, бер ки-и-икрик-ү-ү-ү-к дип җибәрә күрсәнә».

Әхмәт һәм Гали артында да, һичшиксез, шул заманның билгеле яшьләре тора. Зәкәрия исә хәтта исеме дә үзгәртелмәгән хәлдә пьесага килеп кергән. Ф. Әмирханның 1917 елгы мәкаләсеннән күренгәнчә, шушы елның җәендә сугышта үтерелгән подпоручик Зәкәрия Гали улы Бәхтияров (Вафаның бертуган энесе) Учительская школаны тәмамлагач, авылларда учительлек иткән, балалар укыту белән генә чикләнмичә, авыл халкы арасында да агарту эшләре алып барган.

Пьесада Фатих үзе бармы? Бар, әлбәттә. Менә, еш кына нечкә ирония кулланып, салкын кан белән генә сөйләшә һәм акланырга яратмый торган горур Газиз. Бу, әлбәттә, Фатих. Менә тапкыр һәм үткен сарказмнарын уңга да, сулга да чәчә торган кызу табигатьле, хәрәкәтчән Йосыф. Бусы да — Фатих! Һәрхәлдә, Ибраһим түгел. Димәк, автор үзенең бай рухи хәзинәсеннән ике героена да өлеш чыгарган.

Тукай белән танышу уңаеннан Ф. Әмирханның беренче күргән кешесен «тишеп» каравы, төрлечә сораулар биреп, аңларга, тормыштагы типларның берсенә кертергә тырышуы турында сүз булган иде.

Замандашы мондый мәгълүмат бирә. Бер көнне шулай коляскасында нидер укып утырган Ф. Әмирхан шул тирәдә уйнап йөргән малайларны чакырып китергән дә йөртеп кайтуларын үтенгән. «Юлда ул безне көлдереп бетерде,— ди истәлекче.— Ниләр сөйләгәне инде онытылган. Тик бер сүзе хәтердә. Менә каршыга бер кеше килеп чыга. Фатих абый бездән сорый:

— Я, әйтегез, бу нинди кеше?

— Юан кеше,— дибез. Тагын берәү күренә.

— Бусы нинди кеше? Бусы да юанмы?

— Юк, бусы юан түгел,— дибез.

Әйләнеп кайттык. Рәхмәт әйтте дә, «берәр конфет сезгә, тик хәзер үк сорамагыз», диде. Күпмедер вакыт узгач, чакырып алып, безгә бер урынына икешәр конфет бирде:

— Бусы көтеп торган өчен».

Истәлекче, бала чагында Фатих абыйсыннан ишеткән сәер сорауларның мәгънәсен төшенмәгән кебек, күп еллардан соң да бу турыда баш ватып маташмаган. Ә бит ул чакта Фатихның эчке дөньясында җитди рухи процесс барган! Юлда очраган кешене ул күзе белән сөзеп ала да уйлана башлый: бу кем, нинди кәсеп кешесе, гадәт-холкы ни төсле, гаиләсе бармы, булса, кемнәре бар, хәзер кая ашыга, ни турында исәпләп бара һ. б.

Әмма әсәрдә учитель Зәкәрия бар бит әле. Галинең искене җимерү идеясен туку өчен халык арасына башта көчләп керергә кирәк дигән сүзләренә каршы ул болай ди: «Менә мин Казан губернасында ике ел учитель булып тордым. Әүвәлге елны балаларын укыттым, үзләре белән эшем булмады — ул елны ничево. Ә икенче елны кичләрдә, карт мужикларны җыеп, газета укып сөйли башладым. Җыеннарына барып, белгәннәремчә, файдалы советлар бирә идем. Теләгәннәренә буш русча укыттым. Нәрсә булды дип уйлыйсыз? Донос ясап, урынымнан кудырттылар. Менә көчләп кереп хезмәт ит!»

Кала бер юл: Әхмәт «программасы».

Пьесада күтәрелгән тагын бер проблема — хатын-кыз хокуксызлыгы мәсьәләсе дә әнә шул рәвешчәрәк хәл ителә. Әсәр политик азатлык һәм социаль тигезлек яулап алу өчен мәгърифәт коралы гына җитмәгән кебек, хатын-кызны коллыктан коткаруда да бу корал үзе генә көчсез, дигән фикергә китерә.

Бер хатында Әмирхан болай дип яза: «Яшьләр» тугрысында берникадәр отзывлар алдым. Яшьләр «Яшьләр»не бик, хәтта артык яраткалыйлар икән. Бу да бер нәүгы партия тәгассыбы бит. «Яшьләр»нең художество җәһәте бик начар бит» (11 апрель, 1910). Әсәрне күккә чөеп мактауда әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше генә түгел, бәлки политик көрәш исәп-хисаплары да күпмедер роль уйнаган икән. «Бик начар» дигән сүзләргә килсәк, болар, билгеле, урынсыз кулланылган. Шулай да авторның үз әсәреннән канәгатьләнеп җитмәгәнен инкяр итеп булмый. Нәрсәсе ошамаган аңа дигән сорауга җавап бирү кыен. Тик шуны гына әйтергә мөмкин: сәхнә таләбеннән чыгып караганда, ике тема арасында бәйләнеш аз булып, вакыйга берлеге җитеп бетми, катнашучылар күп, кайбер персонажлар артык озын итеп сөйлиләр. Бәлки укучы да чамалагандыр, вакыйга һәм анда катнашучылар тормыштан алынган. Хөсәендә, мәсәлән, Зариф хәзрәт чалымнары күзгә ташлана. Пьесадагы хатын-кыз образларын да ул дус-ишләреннән, туган-тумачаларыннан алган. Фәхернисаны әтисенең сеңлесе Мәрьямнән күчергән булуы мөмкин. Бервакыт шулай Мәрьям апасы килеп чыккан, хәл-әхвәл сорашырга керешкән. Чират Фатихка җиткәч, үгет-нәсихәт бирүдән дә тыелып кала алмаган. «Абый,— дип яза истәлекче,— шаех шикелле кулын кушырып, бик җитди кыяфәттә тыңлап утырды-утырды да, бер паузаны туры китереп кинәт болай диде: «Мәрьям апа, син әтәч булып кычкыра беләсеңме? Зинһар, бер ки-и-икрик-ү-ү-ү-к дип җибәрә күрсәнә».

Әхмәт һәм Гали артында да, һичшиксез, шул заманның билгеле яшьләре тора. Зәкәрия исә хәтта исеме дә үзгәртелмәгән хәлдә пьесага килеп кергән. Ф. Әмирханның 1917 елгы мәкаләсеннән күренгәнчә, шушы елның җәендә сугышта үтерелгән подпоручик Зәкәрия Гали улы Бәхтияров (Вафаның бертуган энесе) Учительская школаны тәмамлагач, авылларда учительлек иткән, балалар укыту белән генә чикләнмичә, авыл халкы арасында да агарту эшләре алып барган.

Пьесада Фатих үзе бармы? Бар, әлбәттә. Менә, еш кына нечкә ирония кулланып, салкын кан белән генә сөйләшә һәм акланырга яратмый торган горур Газиз. Бу, әлбәттә, Фатих. Менә тапкыр һәм үткен сарказмнарын уңга да, сулга да чәчә торган кызу табигатьле, хәрәкәтчән Йосыф. Бусы да — Фатих! Һәрхәлдә, Ибраһим түгел. Димәк, автор үзенең бай рухи хәзинәсеннән ике героена да өлеш чыгарган.

Тукай белән танышу уңаеннан Ф. Әмирханның беренче күргән кешесен «тишеп» караавы, төрлечә сораулар биреп, аңларга, тормыштагы типларның берсенә кертергә тырышуы турында сүз булган иде.

Замандашы мондый мәгълүмат бирә. Бер көнне шулай коляскасында нидер укып утырган Ф. Әмирхан шул тирәдә уйнап йөргән малайларны чакырып китергән дә йөртеп кайтуларын үтенгән. «Юлда ул безне көлдереп бетерде,— ди истәлекче.— Ниләр сөйләгәне инде онытылган. Тик бер сүзе хәтердә. Менә каршыга бер кеше килеп чыга. Фатих абый бездән сорый:

— Я, әйтегез, бу нинди кеше?

— Юан кеше,— дибез. Тагын берәү күренә.

— Бусы нинди кеше? Бусы да юанмы?

— Юк, бусы юан түгел,— дибез.

Әйләнеп кайттык. Рәхмәт әйтте дә, «берәр конфет сезгә, тик хәзер үк сорамагыз», диде. Күпмедер вакыт узгач, чакырып алып, безгә бер урынына икешәр конфет бирде:

— Бусы көтеп торган өчен».

Истәлекче, бала чагында Фатих абыйсыннан ишеткән сәер сорауларның мәгънәсен төшенмәгән кебек, күп еллардан соң да бу турыда баш ватып маташмаган. Ә бит ул чакта Фатихның эчке дөньясында җитди рухи процесс барган! Юлда очраган кешене ул күзе белән сөзеп ала да уйлана башлый: бу кем, нинди кәсеп кешесе, гадәт-холкы ни төсле, гаиләсе бармы, булса, кемнәре бар, хәзер кая ашыга, ни турында исәпләп бара һ. б.

Яисә мондый бер эпизод. 1914 ел башында Әмирханны мәүлет бәйрәме уңае белән үткәрелгән балалар кичәсенә чакыралар. Спектакль дә күрсәтелгән, балалар катнашында концерт та булган, кечкенә кунакларны сыйлагач, төрле уеннар да уйнатканнар. Аннары балаларга яшенә һәм җенесенә карап, төрле бүләкләр өләшәләр.

«7—8 яшьлек бер балага,— дип яза Ф. Әмирхан,— бик матур бер кара савыты эләккән. Мин, баланы туктатып, үз бәхетенә чыккан нәрсәдән разыймы икәнчелеген белергә телим:

— Энекәем, сиңа шәп нәрсә эләкмәгән икән шул! Я мылтык, я күзен йома торган курчак эләккән булса, шәбрәк булыр иде.

— Курчак уйнарга мин кыз кешемени? — дип, бала елмаеп куйган була.

— Алай булса, мылтык яхшы булыр иде.

— Мылтык белән нишлим, бу ичмасам эшкә ярый.

Бу җавапны ишеткәч, мин: менә чын татар баласы! Җиде яшеннән әйбернең эшкә ярап, ярамавы хакында фикер йөртә бит, «җүләр», дип уйлап куям».

Әнә шул килеш кешеләрнең эчен-тышын аңларга, аларны төркемләп, типларга аерырга тырышу Фатихның канына сеңгән.

Ләкин бу әле Ф. Әмирхан, тормыштан күчереп алып, ничек булганча яза дигән сүз түгел. Мәкалә һәм рецензияләрендә без индивидуальләштерү һәм гомумиләштерү турындагы фикерләр белән еш очрашабыз. Бер рецензиясендә, мәсәлән, мондый сүзләр бар: «Тип дип, мәгыйшәттән алып ясалган вә тасвир ителә торган мәгыйшәтнең халыклары арасында махсус бер фиркага тугъры килә торган сурәте әдәбиягә * әйтеләдер».

Типик характерлар иҗат итеп, аларны типик хәлгә куеп күрсәтү, мәгълүм булганча, җитлеккән реализмның төп сыйфаты. 1908 елда «Ачлык кушты» исемле темага язылган рецензиядә түбәндәге юллар укыла: «Мондый олуг темалар (ачлык темасы.—*И. Н.*), хосусан бөтен бер халыкның, хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән килгән күренешләр хакында язылган драмалар социальный характерда язылырга вә асыл сәбәп булган яманлык, төрле тарафларыннан вә сәбәпләре белән тәфтиш ** ителеп, укучы күз алдына тәрсим ителергә *** тиештер».

---

* Сурәте әдәбия — әдәби образ.
** Тәфтиш — тикшерү.
*** Тәрсим — рәсемен ясау.

Хөрмәтле укучым, без астына сызган сүзләргә кайтадан игътибар итсәгезче. Ачлык фаҗигасе ходай яңгыр бирмәгәнгә түгел, бәлки илдәге экономик мөнәсәбәтләрдән килеп чыга икән бит... Бу турыда язганда аның социаль сәбәпләре яктылыгында язу тиеш икән... Дөрес нәтиҗәгә килү өчен төрле яклап тикшерергә, анализларга кирәк... Әнә шул рәвешле табылган хакыйкать җанлы сурәтләр, тормышчан картиналар булып укучы күз алдына бассын.

Рецензия авторы соңыннан тәнкыйди реализм дип йөртелә башлаган иҗат методының асылын аз сүзләр белән ачкан да биргән! Әгәр ахырда «Дамелля» дигән имза тормаса, бу сүзләрнең 21 яшьлек татар егете тарафыннан язылганына ышану кыен булыр иде.

«Замана хикәяләре»н, «Фәтхулла хәзрәт» повестен һәм «Яшьләр» пьесасын биргән Ф. Әмирханны без, икеләнмичә, татар әдәбиятында тәнкыйди реализм юнәлешен нигезләүчеләрнең иң күренеклесе дип бәяли алабыз.

10

68 номеры чыккач, цензура кысу һәм акча кытлыгы сәбәпле, «Әльислах» җәйгә таба яшәүдән туктый. Озакламый шул ук сәбәпләр аркасында «Яшен» журналының да тавышы тына. Дәһшәтле ике вулкан сүнгәч, карагруһчылар гына түгел, либераллар да җиңел сулап куйдылар бугай. Әмирхан һәм Тукай ике кулсыз калгандай булалар.

Хәер, начарның яхшы ягы да бар дигәндәй, газета мәшәкатьләреннән котылу Фатихка әдәби иҗат белән ныклабрак шөгыльләнергә һәм өлгергәнлек аттестаты имтиханына басылыбрак әзерләнергә мөмкинлек бирә.

1909 елның җәе «дача»да узган. «Мин хәзер ботанический бакча янында бер квартирада торам,— дип яза Фатих.— Халыкка дачада торам дип сөйләп шапырынам. Бәгъзе әтрафта зур-зур бакчалар, алты-җиде адым киткәч, Кабан күле, гайре мөтәнаһи * казлар, бөтен әтрафтагы кешеләрнең авыл халкы шикелле простой халык булучылыгы, бөтен әтрафтагы халыкның безне, озын чәчле булганга күрә, ученыйлар дип йөртүе, бил ахир ** дә, өчебезнең (Кәбир, Вафа, мин) коммуна кагыйдәсе белән кызыклы гына итеп торуыбыз дачада торабыз дип сөйләү хакын бирә» (19 май). Моңа өстәп шуны гына әйтергә мөмкин: элеккеге Дальне Архангельская урамындагы Литовченко

---

* Гайре мөтәнаһи — иге-чиге булмаган.
** Биль ахир — ахыр килеп, ниһаять.

дигән кеше өе турында сүз бара. Шул өйдән, күрәсең, берничә бүлмә алганнар да (Фатих «квартир», ди) коммуна булып яши башлаганнар. «Яшен»дәге эше тоткарлаганмы, Тукай әле килеп өлгермәгән.

Вакытлары ничек узган соң? Билгеле инде, «дача»дагы кебек. Фатих, гадәтенчә, мәзәкләштереп болай ди: «Сәгать 12 дә торабыз, икегә хәтле чәй эчәбез, бишкә кадәр обед тугърысында киңәшәбез, 7 гә кадәр шаярып уздырабыз». Су да коенганнар, әлбәттә, балык каптырырга да азапланганнар, кунак каршылау, кунак озату белән дә мәшгуль булганнар (Әмирхан бар төштә кеше өзеләмени?!).

Шул ук вакытта эшләми дә тормагандыр. Фатих «Яшьләр» драмасының соңгы пәрдәсен тәмамлый. «Фәтхулла хәзрәт»нең икенче кисәген язып бетерә.

Ак яка, манжетлардан котылган хәлдә, баштанаяк чишенеп, уйнап-көлеп, файда белән рәхәтне бергә кушып үткәргән хозур көннәр артта кала һәм тагын эш-мәшгулият башлана. Имтихан дип, дәреслекләргә кадалып утыру, рус классикларының программага кергән һәм кермәгән әсәрләрен уку, фикер даирәсен киңәйтү максаты белән төрле өлкәләргә караган китапларны күздән кичерү, рус һәм татар матбугатын күзәтеп бару, «Танышмаганлыктан таныштык» хикәясен язып тәмам итү, «Вак-төяк» исемле хикәяләр җыентыгын әзерләү, язганнарын төзәтү, корректура карау... Төннәр буе бүлмәсендә үт сүнми.

1910 елны инде безнең Фатих атаклы мөхәррир булып каршы ала. 12 январьда чыккан мәкаләсендә мактауга саран Г. Ибраһимов менә нәрсә ди: «Хикәячелек мәйданында соңгы көндә чыккан әрбабе каләм * эчендә, яңлышмасам, башкалардан Фатих Әмирхановны алда күрергә мөмкин дип беләм». Әдипнең дуслары, ислахчылар, шәкертләр һәм бүтән төр күп санлы укучылар исә алай саранлык күрсәтеп маташмыйлар. «Ярый әле син ике елдан артык табигать һөҗүменә каршы көрәшеп, өстен чыктың,— дип яза Ризван Алуши.— Югыйсә, бирелеп куйган булсаң, бөтен өмет вә максутларымыз вөҗүткә чыкмый, бергә бетә иде... Хәзер син мәңгегә бар!» (1910, 29 март). Моны «Милләтне тәрәкъкый иттерү»дә үзен күреп гаять тә хәтере калган. язучылыкка дәгъва итеп тә, дусты Фатихтан җылы сүз ишетмәгән һәм язганнарын «Әльислах»та бастыра алмаган кеше әйтә!

---

* Әрбабе каләм — каләм әһелләре, язучылар.

Наширләр дә яңа әдипне бик тиз күреп алалар, һәр язган нәрсәсен кулыннан йолкып дигәндәй алып китә башлыйлар. Билгеле инде, каләм хакы мәсьәләсендә дә ул алгы планга чыга, иң зур гонорар алучы «өчлек»нең берсе (тагын берсе — Тукай) булып китә. Әнә бит 1911 елда «Мәгариф» нәшрияты, әдәбият теориясе буенча бер китапчык язып бирсә, Әмирханга 240 сумга кадәр түләргә вәгъдә иткән. Фатих баш тартып, бу эшкә бүтән кеше алынырга булгач, нәшрият аңа 90 сумнан артык түләргә риза булмаган икән.

Ф. Әмирханның 1911 елгы бер хатында мондый сүзләр бар: «Имтиханнан соң җәйне шактый кызыклы уздырдым: кунаклар, «мәшһүр кешене күреп китәргә килгән заирлар *, кызлар вә иләх ** миңа скучать итәргә бер дә ирек бирмиләр иде». Үтәр тагын ике-өч ел, Толстой — Россиянең икенче патшасы дигән сүзгә охшатыпмыдыр, шаян телләр Ф. Әмирханга «Казан короле» дигән кушамат тагып куярлар.

Өстенә авып төшкән дан-шөһрәтне Ф. Әмирхан ничек күтәргән? Тыныч, хәтта бик тыныч... Акыл иясе буларак, ул үзенең дәрәҗәсен, мөмкинлекләрен арттырмый һәм киметми, дөрес бәяли белә. Бу бер. Икенче: язганнарыннан ул канәгать түгел. Күңелендә, хыялында яшәгән сурәтләр, манзаралар кәгазьгә ничектер сыегаебрак күчә. Ниһаять, аның әсәрләрен күккә чөючеләрнең күпчелеге фикер ягыннан балигъ булып җитмәгән кешеләр.

Игътибар үзегенә әверелү Фатихка баштарак азмы-күпме канәгатьлек тойгысы, рәхәтлек китерми булмас. Әмма тора-бара бимазалый башлый. Вакытны да алалар. Эзләрен суытыр иде, тик мәшһүр кешегә сокланып, гаҗәпләнеп, хәйран булып карап торган яшь кызларга һәм егетләргә ничек тупаслык күрсәтәсең? Кала бер чара: юмор һәм ирония. Ничектер шулай бер туташ әдиптән «интервью» алырга карар иткән:

— Сандугач сайравын яратасызмы, Фатих әфәнде?

Ни дип җавап бирсен инде моңа Фатих?

— Юк,— дигән,— мин карга кычкырганны яратам.

— Ничек инде, Фатих әфәнде...

Йөзенә җитди кыяфәт чыгарып, Фатих әйтеп куйган, имеш:

— Сандугачның сайравы хатын-кыз чәрелдәвен хәтерләтә. Каргадан ичмасам ирләр тавышы чыга.

---

* Заир — күрергә килүче.

** Иләх — һәм башкалар.

...Хәл-әхвәл шактый җайга салынды, хәзер инде шәхси тормышны да тәртипкә китерергә, ягъни өйләнеп җибәрергә вакыт. Үз аягы белән йөреп китүгә өмет киселгәч, озакка сузуда ни мәгънә? Аяк юк икән, исем-абруе бар, гаилә карарлык кереме бар. Әнә бит киләләр, томырылып карыйлар, саф иреннәрен чак кына ачып тыңлыйлар... Барысы да Фатихның йөгерек телен һәм мәзәкләрен тыңларга гына килмиләрдер шаять. Димәк, тәвәккәлләп, тәкъдим ясарга да була. Кемгә? Билгеле инде, аңа, Шәмсениса туташка.

Югарыда без Фатихның 1908 елгы 26 октябрь хатында «Ш. К. туташны күрсәм, куану» дигән сүзләргә тап булган идек. Серноводскидан соң Шәмсениса Камалова, димәк, Казанда яшәгән. Кайда торган, ни белән шөгыльләнгән — моны без, мәгълүматлар аз булганлыктан, чамалап кына әйтә алабыз. Хосусый укытучы кул астындамы яисә берәр курстамы ул укуын дәвам иттергән булса кирәк. Аз-маз язу-сызу белән дә шөгыльләнгән. Аның вакытлы матбугатта берничә мәкалә бастырганы һәм 1910 елда И. Н. Потапенконың «Букет» исемле бер пәрдәлек комедиясен тәрҗемә итеп дөньяга чыгарганы билгеле.

Фатихның юмордан бөтенләй азат һәм шактый авыр кичерешләр белән сугарылган 1909 елгы 25 февраль хатында мондый сүзләр бар:

«Ну, нәрсә языйм? Әйт, зинһар!..

Үземнең әлегә кадәр йөреми утырганымнымы? Сезнең аны ишетәсегез бер дә килмәгәннән мин бик әмин *.

Атыбызны угырлатып, үземнең бер җиргә дә чыга алмый ятканымнымы? Скучно!

Шәмсенисаның авыруын һәм үләргә әзерләнеп ятканынмы? Минем өчен аны равнодушно язып үтү мөмкин түгел!»

Нәрсәдән, нинди сырхаудан Шәмсениса бу кадәр авыр хәлдә яткан, без моны белмибез. Тик шунысы мәгълүм: бик яшьли ул йөрәк авырулы булган. Камаловаларның Серноводскига барып йөрүләре Шәмсениса өчен дип уйларга кирәк. 27 апрель хатында Фатих: «Туташ» терелде, шуңа күрә мине тәбрик итәргә можешь!» дип куя.

Зәйнәп Нәҗип кызы Әмирханова истәлегендәге мәгълүматлар да кызыклы.

Фатих балалыктан чыгып кына килә торган гимназистка сеңелесе белән кыз-кыркын, гыйшык-мыйшык турында шаярып сөйләшергә ярата икән. Бер көнне ул, сүз иярә сүз чыгып, болай дигән:

---

* Әмин — тыныч, шөбһәсез. Монда: шөбһә итмим.

— Өйләнимме, Зәйнәп? Синең киңәшкә генә терәлгән. Фатиханны бирсәң, абыең бүген-иртәгә башлы-күзле булачак.

Беркатлы кыз чын күңелдән «рөхсәт итә»:

— Өйлән соң, Фатих абый. Яраткан кызың кем?

Фатих бераз уйга калып торгандай итә дә, көрсенеп, «их, иннек-кершәнне дә азрак ягынса», дип, кыздан «җитешсезлек» таба. Сеңелесе, алайса өйләнмә, дигәч ул әлеге «фәрештә»не күккә чөеп мактарга керешә.

«— Карале, сеңелкәем,— ди ул миңа бервакыт,— Шәмсениса туташның күзләре матур бит?

Мин, зәгыйфь кешенең хәтере калмасын өчен, бәхәсләшмим. Шәмсениса апа әнинең кече сеңелләреннән берсе, миңа калса, төскә-биткә әллә ни искитәрлек түгел иде. Әмма күзләренең сөрмәле сихерлелеген инкяр итә алмыйм. Фатих абый минем алда аны шактый еш искә ала иде. «Өйләнсәм, шул Шәмсениса туташка гына өйләнер идем», дигәне дә хәтеремдә калган».

Шәмсениса Фатихны ятратканмы? Борһан Шәрәфнең 1909 елның 23 февралендә Әмирханга язган хатына нигезләнеп, без бу сорауга уңай җавап бирә алабыз. Узган ел ахырында, күрәсең, егет белән кыз арасында җитди аңлашу булган. Эчке дөньясын бик үк ачарга яратмый, бер читен генә ачканда да, мәзәкләштерә торган Фатих бу очракта куанычын эчтә калдыра алмыйча, кәгазьгә түгеп, Б. Шәрәфкә юллаган. Җавап хатында Борһан болай ди: «Үз турыңда язган хәбәрең илә Вирака * Мөхәммәтне тәбрик иткән шикелле тәбрик итәм, кулыңны кысам, авызыңнан үбәм, тигез мәхәббәт телим». Бу вакытта Шәмсениса Казанда булмаса кирәк. Чөнки Борһан болай дип өсти: «Мәгъшукаңа хәбәр ирештерә ала торган булсаң, синең өчен мин аны самимель кальбән ** хөрмәт иттекемә ышандыр».

Хуш, егет белән кызның бер-берсен ятратканнарына ышандык. Соң бу мәхәббәт тарихы ничек төгәлләнгән? Ф. Әмирхан II истәлегендә бу сорауга ачык җавап бар: «Фатихның, өйләнеп, тормышындагы кимчелекне семья һәм балалар турында кайгырту белән тутыру теләге дә барып чыкмады: үзе күптән яратып йөргән кыз (Чистай ишаны Закир Камаловның Шәмсениса исемле кызы) Фатихның тәкъдимен кабул итмәде һәм аңа кияүгә чыгарга риза булмады».

---

* **Вирака** — Мөхәммәт пигамбәрнең сәхабәләреннән берсе.
** **Кальбән** — чын йөрәктән.

Ник риза булмады? Бүтән документ калмаган кебек, табышмакны чишәргә ярдәм итәрдәй кешеләр дә дөньядан китеп беткәннәр... Безгә фараз итәргә генә кала.

Фатихның тәкъдименә кыз шунда ук җавап бирмәгән, уйларга вакыт сораган булыр. Туган-тумачасы белән киңәшкәч һәм аек акыл белән уйлагач, Шәмсениса туташ, күрәсең, анык карарга килгән: ике инвалидның кушылуы җүнлегә булмас. Үзе ярдәмгә, ышанычлы терәккә мохтаҗ Шәмсениса ил күрке Фатихка бәхет бирә алачакмыни? Өстәвенә, әдипнең нәсел калдыру теләге дә бар. Кыз исә моны да вәгъдә итә алмый...

Һәм менә нәтиҗә: гомере буе ялгыз яшәп, өйләнмәгән килеш дөньядан китә. Табылыр иде югыйсә. Фатихка гашыйк булган яисә тирәнтен ихтирам иткән, ахыр чиктә атаклы язучыны милләт, мәдәният, әдәбият хакына бәхетле итәргә теләүче аңлы татар кызлары аз түгел. Ләкин берсе дә а н ы алыштыра алмый, берсенә дә Фатих үз күңелендәге у л билгән урынны бирәсе, а н ы сөйгән хәлдә, берсе белән дә рәсми мөнәсәбәткә керәсе килми.

Фаҗигасен фаҗига, әмма алга таба яшәргә кирәк. Әле бит милләт бар, икеләтә изү астында интегүче халык бар. Фатих — шул милләтнең, шул халыкның бер улы. Гади улы гына түгел, маңгаена талант мөһере басылганы, шөһрәт казанганы, кулында куәтле каләм булганы. Күзләр өмет белән аңа текәлгән.

1910 ел тәмам. Яңа елны Фатих 25 яшьлек егет булып каршы ала. Таланты, ныклы иманы һәм гражданлык тойгысы әле аңа, публицистика һәм әдәби тәнкыйтьтә җигелеп эшләүдән тыш, шактые шедевр булып саналырлык әдәби әсәрләр иҗат итәр өчен илһам бирәчәк.

*5 бүлек*

## «КОЯШ»ЛЫ ҺӘМ БОЛЫТЛЫ КӨННӘР

### 1

1911 елның көзенә таба Ф. Әмирханның әдиплек таҗына тагын бер кыйммәтле таш өстәлә: «Хәят» повесте, цензура күзеннән үтеп, китап киштәләрендә хөрмәтле урын ала. Татар хатын-кызларының аянычлы язмышына багышланган мондый әсәрнең орлыгы Фатихның күңеленә шәкерт чагында ук салынган иде инде.

1909 елда исә бу мәсьәләгә караган программ әсәре «Татар кызы» дөньяга килде. Язылу тарихы да кызыклы.

Көннәрдән бер көнне Фатих янына Ҡ. Бәкер килеп чыккан. «Әльислах»ка кагылышлы көндәлек эшләр турында киңәш-табыш иткәч, татар халкының бүгенге хәле һәм киләчәгенә бәйле гомумирәк мәсьәләләргә күчәләр. Күңелне күтәрерлек, өмет уты кабызырлык күп нәрсә тапмагач, моңаеп калалар. Шул вакыт Рабига абыстай сабак бирә торган күрше бүлмәдә ике кыз бала үзәк өзгеч нечкә моңлы тавыш белән коръән аятен сузып җибәрмәсеннәрме: «Кыямәт көнендә сездән: «кызларыгызны нинди гөнаһлары өчен үтердегез?» дип сорарлар».

Борынгы гарәпләр ир бала тууны артыграк күргәннәр: тереклек өчен кирәкне табучы да ул, сугышчы да. Кыз баладан исә боларны көтеп булмый. Шуның өстенә кабиләләр арасында туктаусыз булып тора торган сугышларда кызларның, дошман кулына төшеп, мәсхәрәләнүләре мөмкин. Берәр гаиләдә кыз балалар күбрәк туа башласа, котылу чарасына керешкәннәр. Буарга яисә чәнчеп үтерергә, күрәсең, куллары бармаган, яңа туган баланы тереләй комга күмеп куялар икән. Мөхәммәт бу йолага каршы көрәшүне кирәк тапкан һәм коръәнгә әлеге аять килеп кергән.

Болай да моңаеп калган Фатих белән Кәбир, кызчыклар укыган аятьне тыңлагач, тәэсиргә бирелеп, шактый вакыт сүзсез утыралар. Бераздан хуҗа телгә килә:

— Син ничек уйлыйсың? Татар кызлары чынлап та мәүвәдәләр * бит. Тереләй күмелгән җанлы җеназалар... Шулай түгелме?

«Шул вакыйгадан дүрт-биш көн дә үтмәде,— дип яза Ҡ. Бәкер,— Фатих әфәнденең үткен каләме, назик хиссияте шуны бик оста һәм шагыйранә бер сурәттә ясап та чыгарды».

Фатихның 1909 елгы 19 май хатында мондый сүзләр бар: «Бу хикәя моңа кадәр язган нәрсәләрем арасында үземнең бер генә ярата торган нәрсәм». Ф. Әмирханның үз язганнарыннан канәгать булмаганын белсәк тә, бу сүзләр безне гаҗәпләндерә. Дөрес, «Хәят»ы, «Кадерле минутлар»ы, «Габделбасыйр гыйшкы» хикәясе әле язылмаган. «Яшьләр»е дә тәмамланып кына килә. «Тигезсезләр» әле — кара савытында. Әмма «Бәйрәмнәр» һәм «Картайдым» хикәяләре инде дөнья күрде. «Фәтхулла хәзрәт»нең ике кисәге укучыларның эчен катырып көлдерә башлады. Шунысы да бар: «Татар кызы», автор үзе «хикәя» дип атаса да, чынлыкта хикәя дә, повесть та түгел. Чөнки анда индивидуальләштерелгән персонажлар булмаган кебек, бер вакыйгага

* Мәүвәдә — тереләй күмелгән (кыз бала).

нигезләнгән сюжет юк. Кемнәр хәрәкәт итә әсәрдә? Татар кызы һәм Кара көч. Тагын — Биктимер... Бусы «татар кешесе» дигән мәгънәне аңлата торган җыелма сурәт.

Талантлы каләм белән көчле язылган публицистик нәсер бу. Анда ике зур проблема — татар хатын-кызларының гасырлардан килә торган аянычлы язмышы һәм реализмның үзәк мәсьәләсе, ягъни шәхеснең уй-тойгысын һәм эш-гамәлен иҗтимагый тирәлек билгеле дигән мәсьәлә күтәрелгән. Формасындагы яңалыктан тыш, әнә шундый күп сыйдырышлыгы әсәрне, күрәсең, авторның күңеленә якын иткән.

«Туды...

Туганда ул кеше иде...»

Әйе, ул туганда ир балалар кебек үк кеше була, бер үк хокук белән файдалана. Алты яшькә кадәр кеше булып кала: бер үк һаваны сулый, бер үк кояш нурында коена, малайлар кебек үк уйный, сикерә, сугыша...

Татар кызы алты яшькә җиткәч, Кара көч ата һәм анадан «Кыз балаларга малайлар белән уйнап йөрергә оят!» дип әйттерә. Татар кызы ышанмый, карышмакчы була. Ана, җиңгә, әби, бабай — һәммәсе бер булып шул сүзләрне кабатлагач, күнә һәм курчак уйнарга керешә.

Ир балалар мәктәпкә киткәндә, Татар кызын абыстайга бирәләр, чөнки «кыз балага ир малайлар белән бергә укырга ярамый!» Кыз тагын тиберченеп карый: ник? Ата, ана, апа, җиңги, әби, бабай тавышына абыстай тавышы да кушыла: «Син гаурәт» *.

Унөч яшендә Татар кызының башына «капчык» кигезәләр. «Ник?» — ди ул, карышып. Кара көч йодрык кына күрсәтә: «Син гаурәт». Унбиш яшендә аны укудан туктаталар да дүрт стена эченә ябып куялар: үзеңне ир дип атала торган зат алып киткәнче көтеп утыр.

Тәрәзәдән күреп, ул кәкре аяклы кибетчегә, бөкре шәкерткә һәм исерек байбәтчәгә гашыйк булган иде, әмма аны тәрәзә яныннан да куып җибәрәләр.

Ниһаять, Татар кызын, ризалыгын да сорамыйча, Биктимергә ярәшәләр. Ата хакы — алла хакы. Аннары Биктимер акчалы кеше, аяк терәп сатулашырга мөмкин.

Шулай итеп, Кара көч теләгенә ирешә: кеше булып туган Татар кызы, иренең күңелен ачуга һәм нәсел арттыруга гына яраклы җанлы курчакка әверелеп, яңа читлек эченә барып керә дә Биктимер алдына тез чүгә. Кара көч куанычыннан кычкырып көлә.

---

* Гаурәт — тәннең күрсәтергә ярамый торган урыны. Хатын-кыз ирләргә бөтенләй күренмәскә тиеш булганга, аңа да «гаурәт» дигәннәр.

Ф. Әмирханның күп кенә хикәя, повесть һәм пьесаларында Татар кызы үзенә генә хас гадәт-фигыле булган шәхес рәвешендә хәрәкәт итә. «Рәхәт көн» (1910) хикәясендә аның дүрт стена эчендә ир көтеп утырган чагы. Кара көч Гайниҗамалның фикер даирәсен шулкадәр тарайткан һәм зәвыгын тупасландырган ки, укымышлы Закирга күңеле төшкән булса да, татлы телле приказчикны ир булырга кулайрак саный. «Кадерле минутлар» хикәясендә (1912) аны яңа гына ир йортына бикләп куйганнар. Элек сөеп йөргән егете белән күрешергә үзендә көч тапкан Хөршид җанлы курчакка әле әверелеп җитә алмаган. Әмма бу — соңгы тыпырчыну гына. «Яшьләр» пьесасында инде фәрештәдәй Фәхернисаның, еллар үткәч, надан, зәһәр һәм килделе-киттеле хатынга әверелгәнлеген күрдек.

«Хәят» повестена кайтыйк. Беренче карашка, Хәят без белгән Татар кызына охшамый. Ул, татарлар аз яши торган шәһәрдә, рус купецлары һәм чиновниклары белән эш йөртә торган сәүдәгәр гаиләсендә туып, чагыштырмача иркен үскән. Европача киенә, русча чиста сөйләшә, алты ай дәвамында русча да укыган. Лиза исемле рус кызы белән дус. Рус егетләре белән аралашудан, дачада күңел ачудан, театрга һәм танцыга йөрүдән дә аны тыймыйлар.

Хәят егетләрнең тәкатен алырлык матур, чын мәгънәсендә гүзәл. Шуның өстенә ул саф, тыйнак, горур. Белеме зурдан булмаса да, йөрәк акылы белән акыллы.

Вакыйга май аеның матур бер көнендә башланып китә. Табигатьнең яңа гына яшәреп җиткән һәм тузанга батарга өлгермәгән нәфис чагы. Дусты Лиза Хәятны дачаларына, яшьләр мәҗлесенә алып китә. «Кояш,— ди язучы,— алар өстенә ак болытлар арасыннан карап, оялчан гына көлеп тора иде». Кояшны да оялтырлык гүзәл Хәятка табигать, гүяки, ак бәхетләр вәгъдә итә.

Кызның идеалы зурдан түгел: әхлаклы, беркадәр зыялы, төскә ярыйсы гына ир, тигез мәхәббәт, Лизаларныкы кебек, дөньяның ямьсез прозасыннан өстенрәк тормыш. Хәттән ашмаган шушы хыялны тормышка ашыру артык кыен булмас кебек. Килмәгән җире юк, ата да кире беткән деспот түгел.

Әмма бәхет сагында әлеге Кара көч тора. Хәятны җанлы курчак итү юнәлешендә ул инде беркадәр уңышка ирешкән. Остазы Мәлихә абыстай җиде ел буе Хәятка «мөселман кеше тормышы өчен борынгыдан эшләнеп килгән» кагыйдәләр өйрәткән, «каршы сөйләү һәм шик итүне күтәрми торган дини вә дөньявый караш» биргән һәм «шушы нәрсәдән дөрес, болардан туры вә болардан кирәк-

ле нәрсәләр дөньяда юк инде дигән фикер» урнаштырган.

Гыймадовларның гаилә тормышы да абыстай сабагын ныгыта килгән. Монда «һәр кеше, үз теләге вә үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгыдан эшләнеп килгән кагыйдәләргә буйсынырга вә шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга тиеш».

Шулай итеп, Хәят ике дөнья, ике тормыш тәэсирендә үсә: берсе — «мөселман» тормышы, икенчесе — «рус» тормышы. Йөрәге белән ул соңгысына тартылса, акылы беренчесенә чылбырлап куйган. Хәзергә әле ул ике тормыш эчендә дә яши ала. Декольте киеп, төнге өчкә кадәр танцы кичәләрендә булу һәм ике-өч сәгать буе төрле догалык салаватлар укып яту ничектер бер-берсе белән яраша. Әмма ике төрле караш, гадәт һәм зәвыклар иртәме-соңмы берберсе белән бәрелешергә, берсе өстенлек алырга тиеш. Һәм шулай була да...

Мясниковлар дачасы. Хәят егетләрнең игътибар үзәгендә. Лизаның Казан университетында укый торган абыйсы Михаил, кинәт үсеп һәм тагын да чибәрләнеп киткән Хәятны кабат күргәч, башын җуяр дәрәҗәдә гашыйк була. Мәхәббәт уты кыз йөрәгенә дә үрмәли.

Менә егет мәхәббәтен белдерә. Хәятка дөнья бер мәлгә тагын да яктырып, ямьләнеп һәм балкып киткәндәй була. Ләкин шул ук вакытта күңелендә ниндидер китеклек сизелә.

Төнге сәгать өчтә Мясниковларның аты Хәятны өенә китереп куя. Аерылышыр алдыннан Михаил пышылдап кына: «Мин җавап көтәм»,— ди.

Хәят үз бүлмәсендә ялгыз. Тын бакчада, кызга бәхетле киләчәк вәгъдә иткәндәй, өздереп сандугач сайрый. Михаил сүзләре исенә төшә: «Ул кош... сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый».

Менә Хәят «почта» уенында килгән хатларны укырга керешә. Барысы да комплимент белән тулы. Михаил хаты аеруча «мәхәббәтле» язылган. Егетнең сурәте, дачадагы эпизодлар, «җавап көтәм» дигән сүзе берәм-берәм кызның хыялыннан кичә башлый. Ирләрчә итеп бер кыз язган хат кына Хәятның ачуын кабарта: мөселман кызы булуыгызны онытмагыз, янәсе. Күңелендәге китеклек кабат әйләнеп кайта, ниндидер шыксыз, эчпошыргыч тойгы булып калка. Әмма көзгедә үзенең гүзәллеген күреп соклану ул тойгыны тагын куып җибәрә.

Хәят, йомшак юрган астына чумып аятелкөрсиләр укыгач, Михаил сурәте тагын пәйда була: «Мин көтәм». Михаил чынлап та бик матур, сөйкемле. Ул Хәятны, тик аны

гына сөя. Ә Хәят — Михаилны? Тукта эле, Михаил — рус егете бит! Дачада күңеленә килгән китеклекнең мәгънәсе кинәт ачылып китә. Михаил кяфер ич! Кяферләрнең урыны — җәһәннәм... Руска гашыйк булып чукынган кызлар турында да ишеткәне бар. Йөзләре кинәт зәңгәрсу төскә керә икән дә, карчыкка әверелеп, дуңгыз ите ашый башлыйлар икән.

Әнә шул килеш бер уй-тойгы икенчесен тудыра, бусы— өченчесен. Яисә баштагы уй-тойгы яңа эчтәлек белән кабат әйләнеп кайта, капма-каршысына әверелеп, тагын юкка чыга. Беренче карашка тәртипсез булып күренгән, еш чалулый, кат-кат чигенешләр ясый торган әнә шул уй-тойгылар өермәсендә кызның рухи халәтенә, уй-карашларына сыйфат үзгәреше алып киләчәк ниндидер эзлеклелек, эчке җегәр бар. Бу инде — күңел диалектикасы дәрәҗәсенә ирешкән психологик анализ. Аны әдәбиятка башлап Л. Н. Толстой керткән булса, татар әдәбиятында беренче булып Ф. Әмирхан кулланды дисәк, шаять ялгышмабыз.

Шушы йокысыз төннән соң Хәят алыштырып куйгандай була. Рус дөньясы белән үзе арасында упкын ятканын, язмышының «мөселман дөньясы» белән аерылгысыз бәйле икәнен төшенә. Кара көчнең чираттагы зур җиңүе була бу.

Күпмедер вакытлар узгач, тагын бер егет Хәятның күңеленә керә язып кала. Бусы инде — «мөселман», Гали Арсланов исемле студент. Кара көч тагын каршы төшә: татар егетләре белән үз белдегенчә танышырга ярамый! Моны байлык һәм культура ягыннан Гыймадовларга караганда күп югары тора торган Рәхимовларның байбикәсе әйтә. Ник ярамый? Бу очракта инде күбрәк бугенге кагыйдә, ягъни буржуаз исәп-хисап эшкә керешә. Ирек куйсаң, кызның хәерче студентка гашыйк булуы, актерга ияреп китүе мөмкин. Ата-ана үзләре сайлап, үзләре мәгъкуль тапкан, һәр җәһәттән үзләренә тиң кешегә бирәчәкләр. Хәят та бу «кагыйдә»не табигый саный, кире кагу башына да килеп карамый.

Бер көнне шулай Газизә абыстай кызына Салих Фатихов исемле яшь байның фоторәсемен күрсәтә. Егет Хәятның кулын сорый икән. Бик тәүфыйклы, бик образованный, ди.

Безнең Хәят «юк, мин күрмәгән, белмәгән кешегә бармыйм» яисә «танышмыйча бер сүз дә әйтә алмыйм» дип, кистереп җавап бирергә тиеш иде кебек. Кыз беренчесен эшләми, чөнки борынгы кагыйдә аңына сеңгән. Эчке көрәш вакытында икенчесе башына килә килүен, ләкин ди язучы, «яучылагач кына, кияүгә бару өчен генә танышу оят төсле,

мәгънәсез шикелле күренә башлады... Белешкәч тә, сөйләшергә сүз дә табылмас та, товар карашкан төсле бер-берсен карашырлар да, әллә нинди авыр тойгы белән бер-берсеннән аерылышып, акрын гына икесе ике якка китәрләр шикелле булды». Әдипнең көчле психолог булуына сокланмый мөмкин түгел: үзен чолгап алган чәчәкләр, гөлләр, агачлар кебек үк табигый һәм хөр үсеп килгән горур Хәятка, кешенең кешелеген кимсетә торган тәкәллефләргә караганда, күзен йомып никах кочагына атылу артыграк.

Кызның утырган күңеле бер мәлгә тагын үрсәләнеп ала. «Аның» Салихы кырган башына тәвәккәл бүрек кигән байбәтчә үк түгелдер түгелен. Тик менә исерек һәм фахиш адәм булып чыкса? Кала бер чара: Салихны хыялда гына булса да матур итеп, яхшы итеп, тәүфикълы итеп күрү. Әнә егетнең фотодагы сурәте, хыял аркылы үткәрелгәч, матурая төште, арткарак кигән кәләпүше дә алгарак шуышкандай булды.

Хыял эшли, хыял яңадан-яңа күренешләр тудыра.

Тын бакча. Ай күтәрелеп килә. Агач күләгәләре кыскара бара, бакча эченнән «плащка төренгән, башына зур читле кара эшләпә кигән Салих килә!» «Ул тәрәзә аркылы керер. Кергәч, билгеле инде, Хәятның матурлыгын мактап, баритон тавыш белән җырлар: аннары үзенә барырга риза булганы өчен Хәятның маңлай, яңак һәм иреннәреннән үбәр».

Шундый сурәтләр күз алдыннан кичкәч, Хәят, үз-үзеннән оялып, мендәргә каплана да:

— Илаһи, мәхәббәт бир! Илаһи, гомерлек мәхәббәт бир инде,— дип кабатлый.

«Бу теләк кызлык вакытының иң ахыргы вә шуның белән бергә иң куәтле теләге иде».

Әсәр әнә шул сүзләр белән тәмам була.

Нәсердәге Татар кызына бик үк охшамаган Хәятны да иҗтимагый тирәлек, ягъни феодаль-патриархаль яшәеш кагыйдәләре һәм буржуаз исәп-хисап, «җанлы курчак» ясарга әзерли. Моның өчен ул аның акылын, фикерен, карашын агулап, бәхет өчен көрәшергә сәләтсез иткән, үз белдегенчә яшәр өчен хыял дөньясын гына калдырган. Татар кызлары бәхетле булсын, кешечә яшәсен өчен, димәк, җәмгыятьне тамырыннан үзгәртеп корырга кирәк. Повесть әнә шундый нәтиҗәгә, тәнкыйди реализм әсәреннән генә чыга ала торган нәтиҗәгә китерә.

## 2

Повестьның ахырында Ф. Әмирхан түбәндәгечә искәрмә биргән:

«Бу хикәянең маузугсы әүвәл «Матур хатын» исеме белән пьеса тарызында * языла башлаган иде. Яза торгач, маузуг пьесалыктан тарсынды да хикәя тарызына әйләндерелергә тиеш булды. Бу тарызда инде озын бер хикәя булып чыккач, икегә бүлеп нәшер итәргә уйланылды. Алдыгыздагы беренче бүлек — Хәятның кызлык дәвере. Озакламый нәшер ителәчәк икенче бүлек Хәятның хатынлык дәвере булачактыр».

Әмирхан, димәк, «Хәят»ның икенче кисәген дә язган! Тәмамлаганмы? «Кояш» газетасының 1913 елгы 30 апрель саныннан түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Бу соңгы ай эчендә инде мин «Хәят»ның икенче кисәген тәмамлармын дип уйлаган идем»... Фатихның «озакламый» дигәне, күренә ки, ике елга сузылган һәм 1913 елның апрелендә генә әдип финишка якынлашкан.

Ай артыннан ай, ел артыннан ел уза, әллә ничаклы мәкалә, фельетон, очерк һәм истәлекләре чыга, шедевр саналырдай әдәби әсәрләре языла. «Хәят»ның икенче кисәге һаман юк. Кибәнне очлыйсы гына калган иде ләбаса! Ялманып кына калган меңләгән укучылар түземсезлек белән көтәләр. Телдән дә, язма рәвештә дә әдипне ашыктыралар. Әнә Әстерхандагы «Идел» газетасы да кыстый:

> Фатихым, күрсәтче тиз безгә «Хәят»нең калганын,
> Ул Хәят бәгъде тәзәүвеҗ ** нинди төсләр алганын.

Тагын еллар уза... Әдипнең замандашларына «Хәят»ның дәвамын уку насыйп булмаган кебек, безнең дә аны уку бәхетенә ирешә алганыбыз юк...

Әдип кибәнне очлап бетермәдеме? Бетермәсә, нәрсә комачаулады? Тәмамлап та, дөньяга чыгармадымы? Чыгармаса, нәрсә мәҗбүр итте?

Бу сорауларга бәлки архив җавап бирер? Исәпсез-хисапсыз серләр саклый торган тын бүлмәгә керәбез. Папка артыннан папка актарабыз. Әмирханның дөньяга чыккан һәм чыкмый калган әллә ничаклы әсәрләренең кульъязмаларын күздән кичерәбез. Арада «Хәят»нең 1 кисәгенең кульъязмасы бар. Икенче кисәкнең кульъязмасы исә бөтенләй юк! Эзләнүне дәвам итәбез һәм әдип вафат булган-

---

* Тарыз — рәвеш.
** Бәгъде тәзәүвеҗ — кияүгә чыккач.

нан соң өендә калган барлык нәрсәсен күздән кичереп язылган «Актнамә»гә тап булабыз. Анда мондый сүзләр укыла: «13. «Хәят». Хәятнең беренче җөзье. Ундүрт дәфтәр. 136 бит.

14. «Хәят»нең икенче җөзье. Үз кулы белән язылган. Барысы 10 дәфтәр».

Әһә, икенче кисәк чынлап та язылган икән, кулъязмасы 1926 елга кадәр исән-имин булган. Әмма ник ул ун гына дәфтәр? «Матур хатын» исемендә уйланылган пьесаның автор тарафыннан сызып куелган планы күрсәткәнчә, андагы вакыйгалар җыелмасы, беренче кисәк белән чагыштырганда, күбрәк булмаса, һич тә азрак түгел. Менә ул план:

«1) Матур кызның йортында ярымсәтерәлелек * белән тәрбия ителүе.

2) Бай кияүгә бирелүе.

3) Зәүҗесеннән ** туеп, каен энесе белән мәгашәкасе ***.

4) Каен энесе белән атасы йортына качулары.

5) Каен энесеннән туеп, ире йортына кайтуы».

«Хәят»ның икенче кисәген язып бетермәскә сәбәп булмаганны белгәнгә, без кулъязманың тулы булмаган карамасы гына торып калган дигән нәтиҗәгә килергә мәҗбүрбез. Соңыннан анысы да хәтәр җилләрдә тузгып, юкка чыккан. Аяныч, гаять тә аяныч!

Шул ук сорау әйләнә дә кайта: «Хәят»ның дәвамын әдип ник дөньяга чыгармаган? Бу тарихи табышмакка документаль җавап булмаганга күрә, безнең көннәргә килеп җиткән риваятькә егылырга гына кала. «Хәят» повестеның икенче кисәген, янәсе, татарның сәүдә корольләре Хөсәеновлар, дөньяга чыгармау шарты белән, сатып алганнар.

Мондый фаразга җирлек юк түгел: Хәятнең прототибы — Гани бай улы Габделхәмит Хөсәеновка кияүгә чыккан Үлмәс ханым.

Үлмәсбану туташ Сембер (хәзер — Ульяновск) шәһәренең мулласы Вәлиулла хәзрәт Гаффаров гаиләсендә туып үскән. Хәятның да 16—17 яшькә кадәр шундыйрак калада яшәгәнен хәтерлик. Замандашлары сүзенә караганда, тышкы матурлыгы өстенә аңа үзенә тартып, эчтән яктырып тора торган ниндидер мөлаемлык, нәзакәтлелек һәм дәртлелек хас икән. Укымышы зурдан булмаса да, ул инде «зыялыланган»: рус-европа модасынча зәвык белән киенә,

* Сәтер — каплау, пәрдә.

** Зәүҗе — (хатынның) ире.

*** Мәгашәка — бер-берсен ярату.

теләсә нинди мәҗлестә югалып калмый, һәр кыланышы, һәр сүзе урынлы һәм килешле чыга. Үзенең матурлыгын белүдән туган горурлык һәм беркадәр һавалылык юк түгел, капризлану очраклары да булгалый. Сокланып карый торган йөзләрчә күзләр чолганышында үскән бу кыз киенүясану һәм бизәнүдән бүтән нәрсәне белми торган тәти курчакка әйләнсә дә гаҗәп булмас иде. Ләкин кул эшләренә дә, аш-суга да оста булган ул, өй хуҗалыгына да кулы ябыша икән.

Үлмәс туташ 1905—1906 еллар тирәсендә Оренбургка килен булып төшкән, ләкин бәхеткә ирешә алмаган. Беренчедән, Габделхәмитнең анасы һәм байлыкларына масайган күп санлы туган-тумачасы «ярлы тәкәббер» Үлмәсне өнәп бетермәгәннәр. Икенчедән, Үлмәстә электән булмаган мәхәббәт никахтан соң гына туа алмаган. Яшь хатынның берничә тапкыр ирен ташлап Сембергә, атасы йортына кайтып киткәнлеге мәгълүм.

Ф. Әмирханның алдан сызган планы буенча, Хәят каен энесенә гашыйк булырга һәм аның белән берлектә атасы йортына качып китәргә тиеш. Үлмәс ханым тормышында шуңа охшаш хәл булмаганмы? Булган! Хөсәеновларның олы яшьтәге вәкилләренең сөйләвенә караганда, Үлмәс ханым Габделхәмитнең энесе Гатаулла белән мавыгып алган. Качып китеп бергә булганнармы, юкмы, анысын белмиләр яисә әйтеп бетермиләр.

В. Бәхтияров истәлегендә мондый мәгълүмат бар: «8 нче елның җәендә мәшһүр фабрикант Акчуриннарның берсенең аерган хатыны Үлмәсбану Казанга килә. Бу хатын безнең җәйге фатирыбызга бик еш килә башлый. Бу хатын бераз әдәбият белән таныш. Азмы-күпме укыган». Тукай белән, аның тормышы белән дә кызыксынган икән ул, тегеләйме, болаймы, аңа файдалы булырга теләгән. «Фатихның «Хәят» хикәясенең героинясы,— дип яза В. Бәхтияров,—әнә шул Үлмәсбану дип белергә кирәк». Истәлекләргә сак килергә кирәклек бу очракта да раслана. Әнә бит Хөсәеновлар Акчуриннарга әверелгән. Бүтән төгәлсезлекләр дә, ихтимал, юк түгелдер. Әмма Үлмәс ханымны, аның күпмедер вакыт Казанда булуын һәм Фатихлар даирәсе белән аралашуын В. Бәхтияровның уйлап чыгару ихтималы юк.

Фатихның мәзәк һәм җитди сүзләр белән әңгәмәдәшенең симпатиясен казану, көтелмәгән, әмма урынлы сораулар белән ачылып китәргә мәҗбүр итү осталыгын без инде беләбез. Үлмәс ханым исә хәйләсез, эчендәге тышында. Җитмәсә, ике юл аермасында калган: нишләргә, ничек

яшәргә? Башыннан кичкәннәрен ул Фатихка түкми-чәчми сөйли дә бирә. Бу гыйбрәтле тарих әдипне кабызып җибәрә, хыялы эшкә керешеп, пьеса булып җанлана башлый. Әсәрнең исеме дә күңеленә килә: «Матур хатын».

Туганнарының әйтүенә караганда, хатынын шашып яраткан Габделхәмит әфәнде, Үлмәс ханым ташлап киткәч, артыннан бара, ялынып, ялварып, җайлап-майлап алып кайта икән. Билгеле инде, бу маҗаралар, халык теленә кереп, гайбәткә мул азык биргән.

«Хәят» китап булып чыккач, Габделхәмит һәм туган-тумачасы әсәрнең кем тормышыннан алып язылганын шундук абайлап алалар. Иң куркытканы — әсәрнең дәвамы турындагы соңгы игълан. Повестьның икенче кисәге дә чыкса, чүп өстенә чүмәлә булып төшәчәк. Габделхәмитнеңме яисә берәр туганыныңмы, тиешле каләм хакын биреп, әдипне әсәрен дөньяга чыгармый торырга күндергән булулары бик ихтимал. Повестьның беренче кисәк белән торып калуын бүтәнчә аңлату кыен.

«Хәят»ның җәмәгатьчелек һәм укучылар тарафыннан яхшы, хәтта бик яхшы кабул ителгәнен күргән идек. Газеталарда уңай рецензияләр күренә башлый. Ләкин... кирегә сукалаучылар да табыла.

М. Укмасыйга ышансак, «Хәят» басылып чыккач, автор белән бәхәстә ул повестьны төп-күтәрәм юкка чыгарган. Юк, язылышып түгел (ул яктан әсәргә тел тидерә алмыйсың), бәлки андагы «төче» типларны, тәти егет, тәти кызларны. Сугыштан соң батыр күбәя дигәндәй, М. Укмасый оппонентын саллы дәлилләр белән стенага терәгән кебегрәк итеп язса да, Әмирханның ирония кулланып, каты гына тешләгәнен һәм «гомер булса, күрербез әле» дигән сүзен әйтми уза алмаган.

Г. Ибраһимов рецензиясе болай зарарсыз. Ф. Әмирхан, ди ул, татар тормышының моңарчы өртүле хәлдә калган ягын күрсәтеп бирә, әдәбиятта яңа хәдисә ача, каһарманнары турында үзе сөйләү белән мавыкмыйча, холык-табигатьләре кушканча яшәргә, гамәл кылырга ирек бирә, тасвиры җиңел һәм ләззәтле. Әнә шулай мактап килә дә мичкәдәге балга бер кашык дегет тондыра:

— Әсәргә «милли хикәя» диелгән. Мин моның яңлышлыгы хакында кул кисеп бәхәсләшә алам.

— Хәят тибының табигый икәнлеге хакында да бик зур шөбһә бар.

Беренче «тәнкыйть» авылдан килгән фәкыйрь шәкертнең яңа төр зыялыларга кызыгып та, ул даирәгә керә алмаудан килеп чыккан антипатиясеннән бүтән нәрсә түгел.

Икенче тәнкыйть җитдирәк булса да, татар җәмгыятенә, аның көзгесе булган әдәбиятка үсеш-үзгәреш перспективасы яктылыгында карый алмаудан килеп чыккан. Яшь Ибраһимовча, тормыштагы киң таралган күренешләр генә — типик. «Татар кызы» нәсерендәге Татар кызы, мәсәлән, типик образ. Декольте киеп, төнге өчләргә кадәр танцы кичәләрендә булырга хокуклы Хәятны исә типик образ итеп карый алмыйсың.

Инде мәсьәләгә тарихи күзлектән килеп карыйк.

XIX гасыр татар мәгърифәтчеләренең чаң тавышыннан уянып киткән татар кызлары, берән-сәрән генә булса да, укырга керештеләр. «Хәят» повесте әдипнең хыялында эшләнә башлаган елларда инде Хәят кебек кызлар гына түгел, бәлки белеме һәм тәрбиясе ягыннан югарырак торганнары да байтак иде. 1911 елгы бер хатында Фатих Казан гимназияләрендә кырыкка якын татар кызының укып ятканын зур канәгатьләнү белән әйтеп уза. Әле бит Уфа бар, Оренбург, Мәскәү, Петербург бар. Дөрес, гимназия бусагасын беренче башлап морза һәм морзалардан булган гаскәри һәм чиновник кызлары атлап керәләр. Тора-бара аларга яңачарак яши, яңачарак уйлый башлаган эре буржуазия катлавы кызлары иярә. Озакламый тагын бер төркем килеп кушыла: ул да булса, Учительская школа тәмамлап, рус теле укыта торган учитель балалары. Ниһаять, уртакул сәүдәгәр кызлары да кузгала. Мисал эзләп ерак барасы юк: Фатихның җизнәсе Шәкүр Апаков кызы Өммегөлсем. Хәтта мулла кызлары арасында да гимназисткалар күренә башлый. Мисалга тагын бер Өммегөлсемне — Шәмсенисаның сеңлесен — һәм Нәҗип хәзрәт кызы Зәйнәпне китерергә мөмкин.

Гимназия аттестаты алган кызларның шактый өлеше, моның белән генә канәгатьләнмичә, югары мәктәпкә омтыла, күбесе теләкләренә ирешә.

XIX гасыр ахырында һәм яңа гасыр башында бүтән юллардан килеп иҗтимагый эшчәнлеккә керешеп киткән хатын-кызларның саны да байтак. Баштарак болай була: берәр авыл яисә шәһәрнең ачыграк карашлы хәзрәтенең сәләтле һәм зирәк кызы әүвәл атасыннан сабак ала, аннары үзлегеннән татарча һәм русча укып гыйлемен арттыра да үзе балалар укыта башлый, язу-сызу эшенә керешеп китә. Соңрак, XX гасыр башында инде бер-бер артлы кызлар өчен махсус мәктәпләр, мөгаллимәләр әзерли торган курслар ачыла башлый. Әнә Фатиха ханым Аитова һәм Ләбибә ханым Хөсәенова мәктәпләре, әнә Буби мәдрәсәсе

каршындагы кызлар бүлеге, әнә Оренбург, Уфа, Троицк шәһәрләрендәге мөгаллимә курслары.

Дөрес, гимназия һәм югары мәктәп тәмамлап, үзлегеннән укып яисә төрле курслар үтеп мөгаллимә, учительница, актриса, шагыйрә, врач, юрист һәм язучы булып киткән кызларның саны, миллионлаган татар хатын-кызлары белән чагыштырганда, диңгездән бер тамчы ук булмаса да, күп түгел иде. Әмма бу тарихи барыш, иҗтимагый үсеш-үзгәреш китереп чыгарган һәм киләчәге гаҗәеп матур булган закончалыклы күренеш иде.

Киләчәге чыннан да матур булды. Йөзләрчә, меңнәрчә татар хатын-кызлары Февраль һәм Октябрь давыллары эченә ташландылар, революциянең җиңүенә, гражданнар сугышы фронтларында яшь Совет властен саклап калуга көчләрен, сәләтләрен, йөрәк ялкыннарын, күпләре исә гомерләрен бирделәр.

Юк инде, киң таралган күренешләр генә түгел, бәлки тормышта аз очрый торган, әмма киләчәктә ишәеп, күңәеп һәм зураеп китәчәге котылгысыз булган күренешләр дә типиклык сыйфатына ия!

Менә ни өчен шул күренешләрне бар итеп, зур итеп, тулы канлы образларда гәүдәләндереп күрсәткән Ф. Әмирханны без реализмнан читкә китүче түгел, киресенчә, реализмны яңа баскычка күтәрүче әдип итеп бәялибез. Ул, тормышның моңарчы язучылар күзеннән читтәрәк калган почмагын ачып күрсәтеп, зур талантка хас булганча, «чирәм күтәрде», татар әдәбиятының «географиясен» киңәйтте һәм мәгънәви эчтәлеген тирәнәйтте.

«Гомер булса, күрербез әле» дигәндә, кем белә, бәлки ул шушыларны күздә тоткандыр...

3

«Кара сакалың — калмый» дигәндәй, өч ел буе әзерләнеп, Фатих быел, ягъни 1911 елның май башында 3 нче ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына имтиханга кергән иде дә тапшыра алмый чыкты. Арифметика, алгебра һәм геометрия буенча язма эшләрне яхшы башкарса да, рус теле белән француз теле аяктан екты: баштагысыннан — «2», икенчесеннән «1» билгесе алганга, моннан соңгы имтиханнарга кертмәделәр.

Комиссия артык таләпчән, татар егетләренә карата аеруча мәрхәмәтсез, әнә бит Давыт Әхмеров һәм Каюм Гобәйдуллиннар да авып төштеләр дип күңелне юатыр иден дә, имтиханга кергән 32 егетнең егерме тугызы руслар бу-

лып, шуларның нибары алтысы аттестат алу бәхетенә иреште.

Биш яшьтән чалма-чапан кию, унбиш-уналты яшькә кадәр Фәтхулла хәзрәт дәрәҗәсенә ирешергә тырышып уку, күзе ачылгач та ата-ана теләгенә каршы барырга көч-куәт тапмау Фатихны рус-европа мәдәниятеннән шактый ерак тотты. Аттестатны максат итеп әзерләнә башлагач та укуы ярым-йорты булды. Авырып аяктан егылгач, ныклап торып ябышты ябышуын, әмма рус балалары 8—10 ел буе зур хезмәт куеп ала торган гыйлемне ике-өч ел эчендә, анда да төп эшеннән бүленә-бүленә үзләштерү ай-һай кыен икән! Шул инде, әлеге «кара сакал».

Ләкин Фатих бирешмәячәк, барыбер ул каһәр төшкән аттестатны кулына алачак («Быел кыш укып чыгып, киләсе язга тагын шул ук имтиханга керергә уйлап торам» — 1911, 3 октябрь). Хәзер исә бераз ял итәргә кирәк, бик йончытты.

Фатихның быелгы җәе дә Кабан күле буенда, «дача»да үтә. Дусларына язган хатларына караганда, ялы шактый кызыклы узган. Күңеленә якын иптәшләре — шундый ук дачниклар белән көн уздыру, ашау-эчү, шаярышу, көлешү. Шуның өстенә, үзе әйтмешли, «мәшһүр кеше»не күрергә килгән «паломниклар» һәм кыз-кыркыннар да ялгыз калдырмыйлар.

Ял итәргә маһирлыгы булса да, Фатих каләм дә тотмый тормаган. Теләсә дә булдыра алмас иде: башында әллә ничаклы план, сюжет, өстәлендә языла башлап та имтихан аркасында өзелеп калган әсәрләр. Шушы җәйдә ул «Хәят» повестен тәмамлап нәшриятка тапшыра. «Көндезге сәхәр яки рузасызлар» исемле хикәясен язып ташлый.

Менә дача сезоны тәмам. Фатих яңадан атасы йортында, үз бүлмәсендә. Озак ач торган кеше комсызланып ашка ташланган кебек, иҗат эшенә чума. «Фәтхулла хәзрәт»нең соңгы кисәгендә, Миңсылу кодачаны да тергезеп, мөбарәк хәзрәтне «ялгызлык»тан коткара. Бусын тәмамлап бетерер-бетермәстән зур күләмле әсәр итеп уйланылган «Урталыкта» романын язарга керешә. Бу әсәрнең 1912 елда бер-бер артлы ике китап булып чыккан өлешен тәмамлагач, яисә, тәмамлап та тормыйча, «Кадерле минутлар»ны яза башлый һәм 1912 елның мартында язып та бетерә.

Ә имтихан? Әзерләнүгә кайчан керешкән, язу эше белән ничек аралаштырган — без боларны рәтләп белмибез. Баштарак, имтиханга әле ерак дип, китапларын тотып та

карамаган булыр. Чөнки илһамы килеп, язу өянәге кузгалган дәвер бу. Аннары, вакытның тиз үтүен, язның котылгысыз рәвештә якынаюын абайлап, әлеге дә баягы үзен аяктан еккан рус һәм француз телләренә керешкән. Анда да, уенга хирыс малайның тизрәк урамга чыгып чабар өчен сабакларын ашык-пошык әзерләгәне кебек, хыял дөньясына чумарга, геройлары арасына кереп китәргә ашыккан дип уйларга кирәк.

Ниһаять, өметләнеп һәм куркып көткән 27 апрель көне килеп җитә. Иртәнге ун тулар алдыннан Фатихны русча сочинение яздырылачак класска күтәреп кертеп утырталар. Барлыгы унҗиде егет язачак. Татарлардан, Фатихтан кала, Давыт Әхмеров һәм Фәхрелислам Агиев.

Ун тулып егерме минут үткәч, теманы игълан итәләр: «Батырларны һәм җырчыларны дөнья онытмас» (Г. Державин). Аңлатмасы да бар: «1812 ел һәм Л. Н. Толстойның «Сугыш һәм солых»ы геройларының киләчәк буыннар хәтерендә сакланырга хаклы булуларын ачыкларга».

Нәрсә язган Фатих, ничек язган — без моны белмибез. Протокол сакланып калганга күрә, кайчан караламасын тәмамлаганын, акка күчереп кайчан тапшырганын исә беләбез. Хәтта Давыт белән Фәхреләмның 2—3 минутка чыгып кергәне, ә Фатихның 5 сәгать буе кымшанмый утырганы да мәгълүм.

28 апрельдә алгебрадан, 30 ында геометриядән, 1 майда француз теленнән язган.

Нәтиҗә? Нәтиҗә... тагын күңелсез. Математика фәннәренең барысыннан да «дүрт» билгесе алган булса да, телдән бирелә торган имтиханнарга кертелмәгән, чөнки сочинение һәм француз теленнән — «ике» билгесе.

Әлеге «кара сакал»ны һәм Фатихның имтиханга ашык-пошык кына әзерләнгәнен белсәк тә, үз-үзебезгә кайбер сораулар куймый кала алмыйбыз.

Директор, инспектор һәм өч укытучыдан торган комиссия объектив булганмы? Фатихның белем дәрәҗәсенә карамаган исәп-хисапларның катышы юкмы? Атаклы язучы һәм публицист булып халыкка гына түгел, бәлки күпмедер охранкага да танылганлыгы роль уйнамаганмы?

Әнә Давыт Әхмеров алгебраны язма рәвештә дә, телдән дә «ике» билгесенә тапшырды. Француз теленнән язмасы шулай ук «ике»легә бәяләнде. Шулай да, телдән тапшырыла торган имтиханнарга кертелеп, өчледән өчлегә бара-бара, ерып чыкты. Комиссия әгъзаларының күңеленә ходай, күрәсең, шәфкать орлыгы салган: ни әйтсәң дә бу егет Казан татар учительская школасының элеккеге баш-

лыгы, статский советник мәрхүм Шаһбазгәрәй Әхмеров баласы.

Ә Фатих Әмирханов кем? Русларга йөзен чытып карый торган фанатик татар мулласының улы. Җитмәсә, күтәртүгә калган. Нәрсәгә аңа университет? Мондый адәмнең югары белем алуыннан дәүләткә ни файда? Өстәвенә, әйтүләренә караганда, чиктән ашкан панисламист икән, сепаратизм фикерләре белән татар яшьләрен аздыра, ди. Директор һәм инспекторга турыдан-туры күрсәтмә бирелгәнлеген яисә әлеге мәгълүматларның бүтән юл белән килеп җиткәнлеген раслый торган документ юк. Ләкин бер нәрсә ачык: комиссия әгъзалары күңелендә Әмирханга карата шәфкать хисе булмаган.

Имтихан вакыйгасы Фатихка куаныч өстәмәгән кебек, бу елгы җәе дә бик үк күңелле үтмәгән булса кирәк. Хатларында Кабан күле буена дачага чыгу турында да сүз юк.

Бу җәйдә булган истәлекле вакыйгаларның берсе шул: Троицк ягында кымыз эчеп яткан Тукай июль урталарында Казанга кайтып төшә. Беренчеләрдән итеп ул, әлбәттә инде, Ф. Әмирханны зиярәт итәргә бара. Сагынышканнар билгеле, аеруча Тукай сагынып кайткан. Сөйләшеп сүзләре бетмәгән дисәк, арттыру булыр. Шулай да Фатих дустыннан сәяхәт тәэссоратын кирәк кадәр сыгып чыгарган һәм үзенең дә борчу-куанычлары белән азмы-күпме уртаклашкан дип уйларга кирәк. Бу очрашуның гадәти вакыйга гына булмаганлыгы тагын шуның белән раслана: алар, фотографиягә барып, икәүләп рәсемгә төшәләр.

Тукайның соңгы сәяхәте турында сүз чыккач, шуны да әйтик: урын алыштыру һәм юл йөрүне бик үк сөйми торган шагыйрьдән аермалы буларак, Фатихның кая булса да чыгып китәргә, яңа җирләр, яңа кешеләр күрергә атлыгып торганын без инде беләбез. Әмма сәер хәл: бәхетсезлеккә дучар булганнан соң, аның Серноводскида булып кайтуыннан соң бүтән сәяхәте турында мәгълүмат табылмады. Шулай да дүрт ел буе Казаннан чыкмый ятуына ышанасы килми. 1909 елда аны, мәсәлән, кемнәрдер Мәкәрҗә ярминкәсенә чакырганнар. Баргандыр, күргәндер, чакырып торганда баш тартса, ул Фатих буламы? Бу дүрт ел аралыгында аның Чистайга бармый торуын яисә Әстерхан яки Самарадан урап кайтмавын шулай ук күз алдына китерү кыен.

Ничек булса да булган, Ф. Әмирхан 1912 елның көзен үзенең бүлмә-кабинетында каршылый. Җиһаз инде бөтенләй үзгәргән. Барысы да затлы агачтан, барысы да сырлап эшләнгән: карават, язу өстәле, креслолар. Шундый

ук гардероб кереп утырган: Фатихның туктаусыз өстәлә торган күлмәк һәм жилетларына, костюм, пальтоларына урын кирәк ич. Стенада зәвык белән эшләнгән берничә картина. Дыңгычлап тутырылган китап шкафы да бүтән. Һәр нәрсәнең матурын, затлысын ярата торган атаклы әдипнең, димәк, килере шактый арткан.

4

Казанның кызыл мал сәүдәгәрләре һәм билгеле китапчылары бертуган Кәримовлар 1912 елда газета чыгару фикеренә киләләр. Бәрәкәтсез дә, хәтәр дә эш, югыйсә. Күрәсең, яңалыкчы булып абруй казанасылары килгән. Фирмага файдасы да булмасмы. Рекламаның сәүдә эшендә тоткан урынын, кем-кем, Шәрифҗан һәм Мөхәммәтҗан абзаларыгыз бик яхшы беләләр. Менә губернатор канцеляриясенә «Бертуган Кәримовлар» сәүдә йортыннан һәм Казан губернасы һәм өязе, Мәмсә волосте, Кодайгол авылы крестьяны Зәкәрия Садретдиновтан 5 октябрь даталы гариза барып керә. Тикшерү, язышу башлана һәм 29 ноябрьдә имза куелган таныкнамә наширләр кулына тапшырыла.

Редактор итеп билгеләнгән З. Садретдинов, Мәрҗани мәдрәсәсен тәмамлап, 1904 елда Әхмәт бай акчасына Истамбулга белемен баетырга киткән икән. Аннан кайткач, 1908 елдан башлап, Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә укытучы булган.

Секретарь итеп Фатих Әмирханны чакыралар: газетаның уңышы, мөштәриләренең артуы өчен аның исеме генә дә җитәчәк. Фатих каршы килми, чөнки ул бит әдип кенә түгел, журналист һәм публицист та. Үз кулында газета булса, тавышыңны ераккарак ишеттерергә мөмкин.

Кәримовлар гаризасы буенча дәүләт учреждениеләре арасында язышу барган арада, кечкенә генә булса да, штат булдырыла, читтән язучылар белән килешүләр ясала һәм «Амур» кунакханәсеннән зур гына бүлмә алып җиһазландырыла. Басу эше җиңел: куәтле матбага Кәримовларның үз кулында.

Газетаны алып бару җиңелрәк булсын өчен (беркадәр өйдән китеп тору ихтыяҗы да булырга мөмкин), Фатих шул ук кунакханәдән номер алып тору фикеренә килә. Бу турыда Тукай белән дә сүз булган, күрәсең, шагыйрь, кабынып китеп һәм Фатих белән бергә булырга теләп, «Амур»га күчәргә карар итә. Фатих гаиләле кешеләргә исәп ителгән ширмалы, зур тәрәзәле 11 номерга керә (аның

бит әле «малае» да бар). Тукай бер кешелек 9 номерга урнаша. Шагыйрьнең «Амур»га күчүенең тагын бер сәбәбе бар. Фатих, материаль ярдәм булсын дип, редакциядә утырып эшләүне шарт итеп куймыйча гына 40 сум вазифа хакына шагыйрьне даими язышучы итеп алуга ирешкән. Хәер, атаклы шагыйрьнең исеме зарарга булмас дип исәпләп алган газета хуҗалары бик үк каршы килмәгәннәрдер.

10 декабрьдә, ниһаять, газетаның беренче саны басу машинасыннан чыга. Фасонлырак эре хәрефләр белән «Кояш» диелгән, язылу бәһасы күрсәтелгән, кергән материалларны төзәтүдә идарә хаклы, кулъязмалар кире кайтарылмый дип тә искәртелгән. Аннары игъланнар китә. Беренче битнең почмагына баш мәкалә кереп сыенган. Икенче һәм өченче битләрдә, гадәттәгечә, «Хариҗи хәбәрләр», «Дахили хәбәрләр», «Казан хәбәрләре». Дүртенче битендә тагын — игълан, игълан, игълан.

Аннары икенче саны, өченче саны чыга, шулай бер-бер артлы тезелеп китә. 1913 елның маенда берадарән Кәримовлар, газетага материаль ярдәм күрсәтүдән тукталмаганнары хәлдә, наширлек шәрәфеннән рәсми баш тарталар һәм Зәкәрия Садретдинов нашире дә, редакторы да булып кала. Үзен көндәлек газета дип белдергән «Кояш», баштарак көн саен чыга алмаса да, тора-бара чынлап та көндәлеккә әйләнә. 1913 елның урталарыннан башлап кайбер саннары хәтта алты битле булып чыга. Яшь газета иңгә дә, буйга да үскән саен, билгеле, аның кухнясы да киңәергә, штаты артырга тиеш. Гыймад Нугайбеков эшли башлый, бераз соңрак Ибраһим Биккулов килеп кушыла, аннары — Заһид Нуркин.

Газетаның мәсләге, тоткан юлы нинди соң?

Билгеле инде, зур байлар акчасына чыгып, шактый тук яши торган газета артык радикальный булмас. Шулай да кистерен нәтиҗә ясарга ашыкмыйк.

Газетаның исеме астында мондый сүзләр укыла: «Могайян * бер партия программасына иярми торган көндәлек тәрәкъкый пәрвәр ** татарча газетадыр». Менә шулай, без сул партияләргә иярмибез, әмма уңнар, шул исәптән либераллар җырын җырларга да исәбебез юк.

Газета чыга, тарала, йөз-кыяфәте ачыклана бара. Дуслар да, дошманнар да тел төбен аңларга, кемлеген танып белергә тырышалар. Аеруча хөкүмәт әһелләре һәм цензура җентекләп күзәтә. Менә матбугат эшләре комитеты-

* Могайян — билгеле бер.
** Тәрәкъкый пәрвәр — прогрессив.

ның доклад язуыннан бер өзек: «Кояш» ...«Йолдыз» кебек үк, милләтче газета, әмма сулрак һәм оппозиционрак булуы белән аерылып тора».

Күп еллардан бирле «Кояш» чорында Ф. Әмирхан уңлашты, милләтчелек һәм динчелек уй-хисләре белән сугарылды дигән фикер яшәп килде. Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Г. Толымбайның әдипне буржуа ялчысы итеп күрсәткән китап һәм мәкаләләренә тукталырга хаҗәт юк. Китаплары да, үзләре дә тыныч кына гүрдә ятсыннар. Илленче елларда да әле ул фикерне теге яки бу басмадан укый идек. Хәзер дә юк-юк та ишетергә туры килә: Ф. Әмирхан уңлашты.

Өстән генә караганда, мондый нәтиҗә өчен нигез юк түгел. «Кояш»ның баш мәкаләләреннән һәм Фатихның имзасы куелган бүтән материаллардан без инде сул партияләргә, шул исәптән социал-демократларга ачыктан-ачык симпатия белдерүне дә, хөкүмәт һәм иҗтимагый төзелешкә тел тидерүне дә, милләтне изүче һәм изелүчеләргә кискен аерып карауны да, социаль мәсьәләләрне уртага салып, «тар милләтчеләр» белән пычакка пычак килеп сугышуны да тапмыйбыз. «Кояш»ның төп игътибары милли мәсьәләгә, дини һәм милли учреждениеләргә юнәлгән. Газета милләт турында, милли культура турында гомумән сөйли, еш кына 20 миллионлы Россия мөселманнары, хәтта 300 миллионлы бөтен дөнья мөселманнары исеменнән сөйли.

Дөрес нәтиҗәгә килү өчен иң элек безгә цензура басымын истә тотарга кирәк. Дөрес, цензура элек тә бар иде. Әмма ул газетаны басылып чыккач кына карап үткәрә иде. Хәзер исә эчке эшләр министрлыгы кайбер урыннарда, шул исәптән Казанда, алдан карап үткәрү (предварительная цензура) тәртибе кертә. Бу яңалык «Йолдыз» газетасын бик үк борчымаган булыр. Һади абзагыз хәвеф-хәтәрдән башаяк дигәндәй, дөньяга чыгачак материалларны элек тә күрсәтеп кайта иде. «Кояш» газетасына авырракка килә. Баягы чиновник әнә нәрсә ди: «Ул («Кояш» — *И. Н.*) Матбугат эшләре комитетының аеруча игътибарын таләп итә». Икенче бер документта мондый сүзләр бар: «Кояш» газетасы алдан караганнан соң гына дөньяга чыгарылганга күрә, эчтәлеге белән кискенрәк күренгәннәре гадәттә алып ташлана».

Бу бәйләнештә Фатихның «Төркестан шивәсендә * матбугат мовакатә» ** исемле мәкаләсе гаять кызыклы. Кул

* Ш и в ә — диалект.
** М о в а к а т ә — вакытлы.

яссуы чаклы бердәнбер атналык газетаның бөтен Урта Азия өчен көлке дәрәҗәсендә аз булуын әйтеп уза да ул газета эшен юлга салу өчен кайбер киңәшләр бирә. Шуларның берсе — цензурадан ничек саклану мәсьәләсе. Аныңча, газета башында тәҗрибәле редактор торганда Россиядә матбугат иреге урнашканга кадәр дә газетаны чиновниклардан яптырмыйча алып барырга мөмкин. Моның өчен газета урта юл тоткан булып күренергә һәм бик күп милли мәсьәләләрдә ачык сүзләр урынына ишарәләр, нокталар гына куеп китәргә тиеш. Фатих боларны, билгеле инде, үз тәҗрибәсеннән чыгып язган.

Әмирханның дөньяга карашы турында сүз алып барганда, димәк, «Кояш»та басылган мәкаләләре белән генә чикләнмәскә, ул материалларны укыганда да юл арасындагысын укырга, әлеге ишарә һәм нокталарны тотып алырга тиешбез.

Икенчедән, яңа революцион күтәрелеш башлану белән бәйле рәвештә илдә һаваның үзгәреп китүе. Пролетариат сынын турайтып һәм җиң сызганып үз хокуклары өчен көрәш башлады. Крестьян да хәрәкәткә килде. Алпавытлар власте — самодержавие, якынлашып килә торган революцияне булдырмау өчен, кискен чаралар күрергә тиеш булды. Ул чараларның берсе — Россиядә яшәүче милләтләр арасына таркаулык кертү, аларны бер-берсе белән дошманлаштыру.

Хөкүмәт рус булмаган милләтләрне, шул исәптән татарларны, экономик, политик һәм культура ягыннан тагын да ныграк кыса башлый, охранка яшерен оешмалар эзли, илнең бердәмлегенә каршы юнәлтелгән сепаратизм фикерләре табарга тырыша, мәктәпләрне тар-мар итә, җәмгыятьләрне тарата, газета-журналларны чыгудан туктата, прогрессив карашлы кешеләрне эзәрлекли, тентүләр ясый, төрмәгә яба, сөргенгә озата.

Карагруһчылардан бик үк калышмыйча, либераль-буржуаз матбугат та милли-азатлык хәрәкәтенә каршы юнәлтелгән чыгышларын куәтләндерә бара. Азчылык милләтләрне, шул исәптән татарларны, Россиягә дошман күз белән карауда гаепли, аерылып чыгу омтылышы бар дип ышандырырга тырыша, культуралары үсүгә, үз телләрендә сөйләшү һәм укытуга ирек бирсәң аерылырга омтылуның чынга ашуы бик мөмкин дип исбат итмәкче була.

Кыскасы, 1912—1913 елларда бөек рус шовинизмы котырына башлады, һәм, шуңа реакция рәвешендә, азчылык милләтләрдә буржуаз милләтчелек куәтләнде. Менә ни өчен партия документларында һәм В. И. Ленин хезмәт-

ләрендә билгеләп үтелгәнчә, 1912 елдан башлап азатлык хәрәкәтендә милли мәсьәлә күренекле урынга чыкты.

Әнә шул шартларда Ф. Әмирханның публицистикасында, димәк, дөньяга карашында азмы-күпме үзгәреш булмый кала ала идеме? Әлбәттә, юк. «Әльислах»та башлыча социаль мәсьәләләргә юнәлгән игътибары «Кояш»та инде милли мәсьәләгә таба борылырга тиеш булды. Бу хәл, үз чиратында, Ф. Әмирханның татар либераль буржуазиясе һәм аның идеологлары — «тар милләтчеләр»гә булган мөнәсәбәтенә дә яңа төсмер, яңа сыйфатлар өстәми кала алмады. Изелгән милләт буржуазиясенең милләтчелегендә гомумдемократик элементлар барлыгы турында В. И. Ленин әйткән сүзләрне дә онытмыйк.

Татар буржуазиясе яңа тип мәдрәсәләр саламы, аларны үз акчасына асрыймы? Салсын, асрасын. Андый мәдрәсәләрдән яңа мәгыйшәт өчен көрәшүче каһарманнар чыкмый калмаячак. Яңа журнал яисә газетаны аякка бастырыр өчен акча бирәме? Бирсен. Аларны җәмәгатьчелекнең һәм киң халык массасының фикерен тиешле якка юнәлтүгә хезмәт иттереп булачак. Тамырыннан череп бара торган самодержавиегә зарармы болар? Зарар. Әгәр шулай икән, татарның сәүдәгәр һәм промышленникларын, барын бер җепкә тезеп, эттән алып эткә салып сүгү акыллылык булырмы?

«Тар милләтчеләр»гә килик. Әйе, алар хөкүмәт золымыннан наразый булган эре буржуазиянең хакын хаклыйлар. Әмма алар хөкүмәтне тәнкыйтьләп нидер сөйлиләр, язалар, яшәп килүче политик тәртипләр зарарына нидер эшлиләр икән, ник моны хупламаска, нигә тагарактагы суны эчендәге бала белән бергә түгеп ташларга?

## 5

Әйе, яңа революцион күтәрелеш елларында милли мәсьәләнең алга чыгуы демократлар белән либераллар арасын якынайтты. Бүтәнчә була да алмый иде. Үзара сугышып ята торган ике малайны зур егет килеп кыйный башласа, алар ни эшли? Билгеле инде, артык куркак булмасалар, арадагы дошманлыкны онытып егеткә бергәләп каршы тора башлыйлар.

Ләкин тормыш тормыш инде, милли хис-тойгылар белән генә тук булып булмый. Теңкәне корыта торган социаль мәсьәләләр калкып куя да, әлеге егет туктап торган арада малайларның яңадан чукыша башлаганнары кебек,




«Эльислах» газетасы редакциясе урнашкан йорт (хәзерге Тукай урамы, 63 йорт.)


№27

الاصلاح

ЕЖЕНЕДѢЛЬНАЯ ГАЗЕТА
„ЭЛЬ-ИСЛАХЪ"

«Эльислах» газетасының беренче бите



«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре (уңнан): Фатих Әмирхан, Исмәгыйль Аитов һәм Ризван Алуши. 1906 ел.

«тар милләтчеләр» белән демократлар тагын бер-берсенә ук җибәреп алалар.

Менә Романовлар династиясенә 300 ел тулуга багышланган зур бәйрәмгә әзерлек башлана. Бу вакыйгадан, билгеле, татар җәмәгатьчелеге һәм газеталар да читтә кала алмый. «Кояш»та да — туган көненнән башлап 1913 елның урталарына чаклы (хәтта соңрак та) — бу мәсьәлә төп темаларның берсе булып китә. Газета 24 декабрьдәге баш мәкаләсендә, читтән торып күзәтүче булганын сиздерә төшеп, әйтә: мөселманнар да бу тантанага катышырга итәләр икән, аны берәр гыйльми җәмгыять ачу белән билгеләп үтәргә кирәк.

Бер төркем прогрессив яшьләр кызлар өчен татар гимназиясе ачарга рөхсәт сорау фикеренә киләләр, шуны кыздыра башлыйлар. Башларында Казанның дүрт-биш мулласы торган иске фикерле «картлар», гимназияне шундук кире кагып, ятим балалар өчен приют ачарга кирәк дип чыгалар. Ике лагерь барлыкка килә. Киңәш мәҗлесләре, җыелышлар, газета битләрендә фикер алышулар башлана. Бер-берсен хурлау, гаепләү китә, кычкырышалар, үпкәләшәләр. Күптәннән килә торган кадим белән җәдит тартышының үзенчәлекле бер гәүдәләнеше була бу. Чөнки либераллар да, демократлар белән берлектә, гимназия идеясен яклыйлар. Әмирхан белән Тукай да, бу көрәштән читтә кала алмыйча, «гимназияче»ләр файдасына үткен-үткен чыгышлар ясыйлар.

Ләкин либераллар лагеренда да гимназиягә каршы кешеләр табыла! Әнә «Йолдыз» газетасы кирегә сукалый башлады. Әнә «Вакыт», «Йолдыз»га көч биргәндәй, тарихчы булырга дәгъва итә торган бер хәлфәнең зур мәкаләсен басып чыгарды. Кызлар гимназиясе — буш хыял,— ди Әхмәтзәки Вәлиди. Чөнки Казанда милли эшләрне җиренә җиткереп башкарырлык кешеләр юк. Казанлылар эшсез көйгә шөһрәт казанырга ярата торган халык.

Фатих, моны үткәреп җибәрә алмыйча, сатираның югары таләпләренә җавап бирерлек усал фельетон белән чыга.

Безнең авылда, ди фельетончы, җилкәләре һәм күкрәге бераз чыгынты, аяклары кәкре, тәбәнәк бер малай бар иде, кушаматы Кәрлә иде. Кулыннан бер эш килмәсә дә, ул бишкә төрләндереп мактанырга яраткан. Үзеннән күп озын малайларның авызына сугарга үрелгән.

Әнә шул Кәрләгә мөрәҗәгать итеп, фельетончы болай ди:

«— Их, Кәрлә, Кәрлә, син тип идең; ләкин сине безнең урамның 20—30 малае гына белә, синең ләззәтле мак-

тануларыңны шулар гына ишетә иде. Зәки абзаң да шул синең типның бер шәхесе, ләкин ул үзен сиңа караганда да югарырак тота. Син, мәрхүм, буең җитмәслек кешеләрнең авызына сугарга үрелә идең... Әмма Зәки абыең синнән уздырды, ул бөтен Казан халкының авызына сукмакчы булды, дөрес, бу эштә ул үзе чалкан егылды, ләкин зарар юк, гайрәтле булырга кирәк».

М. Бигиев, Ш. Мөхәммәдьяров һәм Х. Әбүзәров шул ук «Вакыт» газетасында «тәәссеф» белдереп чыгалар: янәсе, «гүзәл тарихымызны язган» бер затның «гүзәл мәкаләсе»н Ташмөхәммәт әфәнденең «урам малайлары» теле белән хурлавы гаять тә үкенеч.

Фатих бусына да җавап бирә: үз фикеремдә калам ди, андый эчтәлекле мәкаләгә җитди җавап бирү үзе көлке булыр иде ди. «Тәәссеф» авторлары пайтәхеттән булганга күрә, Петербург дусларыма сәлам дип тә өсти.

Билгеле инде, З. Вәлиди дә җавапсыз калмый. Фатих тагын Кәрләне чакырырга мәҗбүр. «Хәтереңдәме, Кәрлә дус,— ди ул,— син бервакыт атаңның арба майлаганда кия торган дегетле бияләен киеп урамга чыккан идең дә, малайлар синнән көлә башлагач, син аларга:

— Ә, үзегезгә эләкмәгәч, көнләшәсезмени? Көнләшәсезмени? Үзегезгә эләкми шул! — дип җавап биргән идең».

Әнә Зәки абзаң да шулай: «дегетле бияләе белән малайларны түгел, хәтта газеталарны да көнләштерергә тырыша». Дегетле бияләй деталеннән «тар милләтчеләр» вәкиле кара фикерле «картлар» җырын җырлый башлады дигән мәгънәне аңлау кыен булмаса кирәк.

«Тел телне уза, кул — кулны» дигәндәй, бу бәхәскә гыйззәте нәфес, ягъни самолюбие, шәхескә тиешү, үпкәләшү дә катышмый калмаган. Ләкин, тулаем алганда, Әмирханның Оренбург һәм Петербург белән шактый ачы сүзләр кулланып әйткәләшүе демократлар белән либераллар арасында тукталыбрак торган атышларның тагын бер кабынып алуыннан бүтән нәрсә түгел.

Бусы 300 еллык юбилейга кагылышлы аерым бер эпизод булды. Ә бәйрәмнең үзенә, шуның сәбәпчесе булган династиягә «Кояш»ның мөнәсәбәте ничек? Шактый сак һәм салкын. Вакыйгаларны битараф төстә генә теркәп бара. Патша хәзрәтләре адресына катлы-катлы эпитетлар юлламаган кебек, бәйрәм шау-шуына да, аллы-гөлле бизәкләренә дә бик үк мөкиббән китми. Власть ияләре дә моңа игътибар иткәннәр. «Киевская мысль» газетасының 27 апрель саныннан без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Казан татарлары февральдәге юбилей көннәрен аеруча тан-

тана белән билгеләп узганнар. Бәйрәмнең уңышы хакына татар матбугаты да бик тырышкан. Ләкин «Кояш» газетасы ни булганны объектив төстә яктыртып бару белән генә чикләнгән. Губернатор «күзендә» бу инде җинаять. Һәм ул редакторны чакырып ала, тантана вакытында газетада патриотик тонның булмавы, халыкның дөрес фикер йөртә торган өлешендә искиткеч күтәренке рух хөкем сөргән бер вакытта салкынлык күрсәтүе өчен кисәтү ясый. Ул гына да түгел, әгәр газета үзенең тенденциоз юнәлешен үзгәртмәсә, сөргенгә озату белән дә куркыткан».

Газета тукталганга кадәр бергә эшләячәкләрен белгәнгә ачык әйтә алабыз: Зәкәрия абзагыз, Фатихны катыштырмыйча, бөтен гаепне үз өстенә алган. Ул заманда күп кенә редакторларның хәле шундый инде: газетаның дилбегәсе бүтән кеше кулында булып, аның вазифасы — хуҗалык эшләре, цензура белән аңлашу, власть ияләренең кисәтүен тыңлау, төрмәгә кереп утырырга әзер тору...

Ф. Әмирханның «Кояш»та чыккан мәкалә һәм фельетоннарын җентекләсәк, сүзләрен генә түгел, сүз аралыгын да укысак, мәгълүм сәбәпләр аркасында милли һәм дини хис-тойгыларының беркадәр көчәюенә карамастан, «Әльислах» чорында калыплашкан фикерләреннән ваз кичмәгәнлегенә тагын бер кат ышанырбыз.

Рус милләтенә мөнәсәбәте мәсьәләсенә күз ташлыйк.

1907—1909 елларда ул хөкүмәт кешеләрен, алпавытлар һәм буржуазияне үз кул көче белән көн күрә торган рус халкына каршы куя иде, «Үги балалар» исемле әсәрен дөньяга чыгарган М. Гафурины «рус милләте белән бюрократиясен бер сарадан* йөрткәнлеге» өчен тәнкыйтьләгән иде.

Менә «Кояш»ның 1913 елгы 23 январь санындагы баш мәкаләсе. Русның күренекле бер җәмәгать эшлеклесе «Русская молва» газетасында биргән интервьюсында саф руслар мөселманнарга яхшы карыйлар, әмма Идел буе мөселманнары арасында Ватанга тугрылыкны бетерергә тырышучылар күренә башлады дигән мәгънәдә сүз әйткән икән. Юк, ди «Кояш», без рус халкына түгел, бәлки Идел буе мөселманнарының хокукларын чикләү өчен үткәрелә торган чараларга дошман. Мәкалә астында «М. Зарифов» дигән имза тора, ягъни Мөхәммәтфатих Зариф улы.

Патша хөкүмәтенең милли-колониаль политикасының асыл максаты, нәтиҗәсе һәм зарары да Ф. Әмирханга сер

---

* **Сарадан** — тигез итеп.

булмаган. 1914 елның июнендә ул менә нәрсә дип яза: «Рус милләтенә үзе белән бергә гасырлар буена дус яшәп килгән карт бер милләтне кысу, рәнҗетү нинди генә мантыйк белән караганда да матлуп * була алмас. Кысу, рәнҗетү һичбер вакытта хәер тудырмаганнар, алар фәкать үзләренә каршы гакселхәрәкәт ** тудырып кына, милләтләр арасында бер якка да файда итми торган дошманлык асрарга яраганнар».

Хөкүмәт һәм уң партияләр тараткан карагруһчыл шовинизмның рус һәм татар халыкларының аңын агулавы Ф. Әмирханны бик тә борчыган булса кирәк. Моңа ышану һәм бер очтан аның кечкенә факттан зур мәгънә чыгару сәләтен күрү өчен «Сабан туенда» исемле очеркыннан бер өзек китереп узыйк.

1913 елның май башларында Фатих Пороховой бистәсенең сабан туена барып чыккан. Ахырынарак кына өлгерсә дә, күп кенә гыйбрәтле хәлләрне күреп үткәргән. Очеркта ул, үзе бала чактагы сабан туе белән чагыштырып, мәдәниләшү ягыннан зур үзгәреш булганлыгын билгеләп үткәч, бер ямьсез һәм тиешсез гадәткә карата үкенеч белдерә. Ул да булса, рус белән татар көрәшкәндә тамашачыларның ике милли төркемгә аерылып тарафдарлык итүләре, сүз көрәштерү һәм әйткәләшүләре.

«Рус екса да, татар екса да барыбер түгелмени?..

Теләсә нинди зур рус галимен, рус мөхәррирен теләсә нинди татар ломовой ямщигы көрәшеп ега ала бит. Һәм, билгакес, татарның теләсә нинди галимен, теләсә нинди язучысын теләсә генә нинди бер йөк ташучы рус көрәшеп ега ала, ләкин моның белән мактанган татар ломовой ямщик яхут йөк ташучы рус көлке генә булып калыр иде.

Рус ега икән, бик яхшы: шул рус шул татардан көчле булган була. Татар ега икән, ул да бик яхшы: шул татар шул рустан көчле булган була. Ләкин моның белән милләтләр үлчәшмиләр.

Мин татар гавамына бу мәсьәләгә һичбер әһәмият бирмәскә вә бу тугрыда рус гавамы белән һичбер төрле моназарага керешмәскә киңәш бирәм. Бу тугрыда моназара ахмаклык һәм аңсызлыктан башка нәрсә түгел».

Юк, Фатих Әмирхан бервакытта да төп мәсьәләләрдә, социаль мәсьәләләрдә, либераль буржуазия позициясенә күчмәде. Уңлашса, күпмедер уңлашты, әмма революцион демократ буларак уңлашты.

---

* Матлуп — теләнгән, тиешле булган.
** Гакселхәрәкәт — реакция.

## 6

Аерылышу көннәре якынлашып килә...

Декабрь башыннан бирле алар бер табактан ашап дигәндәй яшәделәр. Дөрес, бүлмәләре янәшә булганлыкны сәбәп итеп кенә, бер-берсеннән чыкмый ятканнар дип әйтергә туры килми. Көндезләрен һәркайсы үз эшендә. Тукай «Ялт-Йолт» арбасын төпкә җигелеп тарта. Өстәвенә зур күләмле китабын әзерләргә кереште. Фатихның да эше муеннан. «Кояш» яңа газета бит, «яшь» газета. Абруй казансын, яздырып укучылары күбәйсен өчен әйбәт итеп, матур итеп күрсәтергә кирәк. Әнә «Хәят»нең дә икенче кисәге һаман тәмамланып җитмәгән хәлдә.

Очрашулары — күбрәк кичке якта. Коляска тәгәрмәчен кулы белән әйләндерә-әйләндерә, Фатихның Габдулла бүлмәсенә барып керүе күпме кабатлангандыр, әйтү кыен. Тукайның «визит»лары исә еш булган. Менә ул, шакыпнитеп мәшәкатьләнмичә, ишекне чак кына ачып, үткен күзләре белән әүвәл дустының номер эчен сөзеп ала (хатын-кыз таифәсе юкмы?). Аннары, акрын гына кереп, урындыкка барып утыра. Мондый хәл кабатланып торганга, кем кергәнен Фатих яхшы белә һәм утырышын аз гына да үзгәртмичә, укуын яисә язуын дәвам итә. Тукай, шактый вакыт уйланып утыргач, сүз башлый, Фатих, каләмен куеп, аңа таба борыла...

Бер көнне шулай чит шәһәрдән килгән курсистка кызлар Фатихтан Тукай белән таныштыруын үтенгәннәр. Габдулланың исә бер сәер гадәте бар: кызлар һәм яшь хатыннар белән танышу, аралашудан, алар булган мәҗлестә утырудан кача. Юк, оялудан түгел. Вәсвәсә һәм горурлыктан. Хатын-кызлар бит, шигырьләрен укып, аны зур итеп, мәһабәт итеп күз алдына китерәләр. Шагыйрьнең үзен күргәч, кызның йөзенә чыккан алдану галәмәтен күрү, сизү Тукайның горурлыгына барып тия.

Фатих очраштыруның кыен булачагын әйтеп караса да, туташларның күрми китәселәре килми. Кызларны Фатих ширма артынарак, кергән кешегә бик үк күренми торган урынга утырта да хезмәтче «малаен» Тукайны чакырырга җибәрә. Ике-өч минут та үтми, ике кулын чалбар кесәсенә тыккан шагыйрь, борын эченнән нидер көйликөйли бүлмә уртасына килеп җитә дә... кинәт, кырт борылып, гаять җитезлек белән чыгып китә.

— Тукай, йомышым бар сиңа!

Кая ул, туктатырсың, бар. Шуннан Фатих «илчесен» яңадан җибәрә: әйт, йомыш ашыгыч, кичектерергә яра-

мый торган, тиз керсен. «Илче» мондый җавап белән кайта: «Ашыгыч булса үзе килсен, булмаса, кунаклары киткәч барырмын».

Кызларны Тукайның үз номерына алып барып таныштыру планы да тормышка ашмый: җыенып бүлмәдән чыккач карасалар, шагыйрь инде коридорның аргы башына, урамга чыга торган баскычка барып җиткән.

Икенче көнне Тукай җайсыз хәлгә куя язганы өчен дустын битәрләп ала. Кызларның ихлас теләкләрен аяк астына салу ярамый иде дигән сүзләргә каршы болай дип кенә җавап бирә:

— «Төсмәгы бил Могайди хәйрен ән тәраһы» * диясең калган.

Икенче вакыйга тагын да мәзәгрәк.

Көннәрдән бер көнне Рабига абыстай улының хәлен белергә дип «Амур» номерына килеп чыга. Оның кызы сигез яшьлек Разия дә ияргән. Хәл-әхвәл сорашып, тегесенмонысын сөйләшеп алгач, тәмле-тәмле күчтәнәчләрне тапшырып торганда Тукай килеп керә.

— Фатих...

— Әйдүк, Тукай, уз, бер туташ белән таныштырыйм үзеңне.

Бу сүзләр әйтелеп тә бетмәстән ишек шап итеп ябыла: син күр дә, мин күр, Тукайдан җилләр искән.

Фатих үзенең калын, көр тавышы белән рәхәтләнеп көлеп җибәрә:

— Тукайның котын алдың бит, туташ!

...Февраль башларына таба шагыйрьнең саулыгы күзгә күренеп начарлана. Көннәрен дә, төннәрен дә аның горык-горык йөткерүе стена аркылы аермачык ишетелеп тора башлый. Фатих һәм бүтән дус-ишләре авыруына җитди карарга, врачка күренергә киңәш итәләр, үзе бик үк ашыкмагач, врачны номерына китереп караталар. Больницага кереп яту мәсьәләсе килеп баса. Ашыктыралар, кыстыйлар. Кичектермәс эшләрен төгәлләүне сылтау итеп Тукай һаман суза.

Фатихның бу соңгы ике-өч айдагы үй-кичерешләрен күз алдына китерү кыен түгел. Бит ул Тукайның сирәк талантын, татар мәдәнияте һәм шигъриятендә токкан урынын бүтән һәркемгә караганда дөресрәк аңлый, тирәнрәк күрә. Ятимлектә үсеп, халык шагыйре булып җитешкән, олы җаны тончыктыргыч тар мохитка сыймыйча йөрәк

* Гарәп әйтеме: «Могайдине күреп белүгә караганда, ишетеп белү яхшырак».

капын савылдырып яшәгән, ниһаять, газаплы авыру кочагында калып, үлем көтә башлаган Тукайны ул ниндидер әрнүле бер кызгану белән кызгана. Җаны өшегән шагыйрьнең, җылы эзләп, аның саен дусты катына килүе Тукайны Фатих күңеленә тагын да якынайта, аңарда аналык хисенә охшаш тойгылар уята. Баласы үләргә яткан һәм коткарып калу мөмкинлегеннән инде өмет өзгән ананың кичерешен күз алдына китерик. Хәер, Әмирхан үзе сөйләсен.

«Төннәрнең берсе иде. Тукайның озак-озак сузылган йөткерүе минем бүлмәдәге тынлыкны бозып, бөтен төнге дәһшәте вә куркынычлыгы белән колагыма керде. Менә, менә ул йөткерүләр аның үпкәләрен тәмам-тәмамга өзеп ташлар да, Тукай дөньядан сәфәр иткән булыр шикелле тоела башлады. Минем бүлмәмнән бер стена белән генә аерылган җирдә дөньяның иң зур серләреннән, иң дәһшәтле серләреннән булган вакыйга (үлем) менә хәзер, менә хәзер вакыйг булыр шикелле хис иттем, урынымнан торып утырдым, киенеп Тукай янына кермәкче булдым. Ләкин 2—3 минут үткәндә инде Тукай үзе минем янымда иде. Ул йөткерә-йөткерә сүз башлады:

— Үлемнән качып синең янга кердем әле! Юк, үлемнән түгел, ялгызлыкта үлемнән качып...

Төнге лампаның зәгыйфь кенә яктысы астында «ялгызлыкта үлемнән» качып кергән Тукайның зәгыйфь торышы минем күзләремә үлемнең нәкъ үзе, шул серле үлемнең нәкъ үзе булып күренде, йөрәк сикеренде, җан куркынды, бугазга яшьләр килеп тыгылдылар.

— Мә, Тукай, ал минем таза үпкәләремнең берсен, берәр үпкә белән дә дөньяда торырбыз әле,— дип кычкырасы килгән шикелле булды».

Шәхеснең сүзенә түгел, гамәленә карап бәя бирергә кирәк дигәннәр. Фатихның моңа кадәрге һәм моннан соңгы гамәлләрен белгәнгә, без ышанып әйтә алабыз: әдипнең һәр сүзе чынлыкка туры килә, бу шулай булган, шулай гына була алган!

25 февраль көнне кич Тукай тагын Фатих бүлмәсенә килеп керә. Ниндидер күңелле вакыйга көткәндәй, йөзе шактый яктырган. Анысы-монысы турында сөйләшеп алгач, ул, йөзендәге шул яктылыкны саклаган хәлдә, балаларга хас ниндидер бер җиңеллек белән гади генә әйтеп куя:

— Мин иртәгә Клячкинга керәм, мин киткәндә син тормаган булырсың... Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде!

Фатих, докторлардан ишетеп, шагыйрьнең ай, ай ярым гомере калганын яхшы белә. Димәк, бу «хуш» — иң соңгы, иң ахыргы «хуш». Шулай да ул гадәт буенча әйтелә торган сүзләр белән җавап бирә:

— Тиз терелеп чык, тиз күрешик...

Тукай, ишеккә таба китә башлап, кинәт борыла һәм:

— Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә! — ди дә тиз генә чыгып китә...

Тукай больницада үткәргән бер айдан чак кына артык вакыт эчендә Фатихның авыру янына барып чыгуы турында мәгълүмат юк. Әмма хәлен белеп торган, араларында хәбәрләшү, язышу өзелмәгән. Тукайның дустына язган бер хат-запискасында мондый сүзләр бар: «Больница хәдимнәре миңа: «Ник алданрак больницага кермәдегез?» — диләр. Мин аларга: «Без больницаны үлемнең әүвәлге станциясе дип беләбез, аз булса да дөньяда торып калыйм дип әйттем»,— дидем».

2 апрель көнне кичен авыру шагыйрь янында кунарга дип киткән иптәшләреннән берсе үзәк өзгеч хәбәр китерә: Тукай вафат...

Мәрхүм шагыйрьне якын итүчеләр җыелып киләләр. Төнге өчкә кадәр киңәш-табыш итешәләр, күмү комиссиясе сайлана. «Чәһәршәмбе көнне, 3 апрельдә янәдән киңәшләр башланды,— диелә «Кояш» газетасында.— Бу киңәшләрнең мәркәзе «Кояш» идарәсе булып, ул көн буе Габдулла Тукайның мөхипләре * вә дуслары белән тулып торды. Һәйәәт тәхрирриясеннән ** Габдулла Тукайны җуйган «Кояш» идарәсен тәгъзия*** итәргә килүчеләр, аның хакында шигырь вә мәкаләләр китерүчеләр хисапсыз иде».

Катып калу хәленнән чыгып, ис-акылын җыюга, Фатих Тукай турында мәкалә язарга утыра һәм язганы 4 апрельдә, ягъни шагыйрьне соңгы юлга озату көнендә, баш мәкалә булып басылып чыга. Бу мәкаләсендә ул, беренчеләрдән булып, Тукайны халык шагыйре итеп бәяли: «...аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды».

Фатих, мәрхүмнең гәүдәсен озата барып, каберенә туфрак салып кайта алганмы? Белмибез. Чөнки ышанычлы мәгълүмат юк. В. Бәхтияровның кулъязма хәлендә саклана торган истәлегендә генә бер хәбәр чагылып үтә:

---

* Мөхип — сөюче.

** Һәйәәт тәхририя — редколлегия әгъзалары.

*** Тәгъзия — кайгы уртаклашу.

Ф. Әмирхан җеназаны капка төбеннән генә үкси-үкси озатып калган, имеш.

Бу сүзләргә ышансак, болай булган була. Җеназаның маршрутын һәм Печән базары мәчете янында тукталып узачагын яхшы белгән Фатих, вакыт җиткәч, үзен урамга чыгарырга куша. Бер заман җеназа, Проломныйдан борылып, Сенная буйлап Печән базарына таба елыша башлый. Зарыктыргыч авыр минутлар үтә тора һәм, ниһаять, яшьләр җилкәсендәге табут мәйданга керә. Табут артыннан берничә мулла атлап килә. Араларында Фатихның әтисе Зариф хәзрәт тә бар. Урамны тутырып килгән халык агымының ахыры бөтенләй күренми.

Урыны җайлы булса, Фатих, тамагына төер утырган хәлдә, җеназага кагылышлы тәкәллефләрне һәм фотографларның тыз-быз килеп өч аяклы аппаратлары белән табут тирәсенә тупланган кешеләрне рәсемгә төшергәннәрен күзәткән. Аннары табутның Евангелистлар урамына таба акрын гына йөзеп китүен, эчтән үкси-үкси, карап калган...

Бу риваятьне дөрес дип тапкан очракта да Фатихны гаепләп булмый. Атка утырып зыярәт капкасына кадәр бара да алыр иде. Анда эш тагын күтәртүгә кала, халыкны ырып-ерып керәсе була. Бәлки болай да яралы йөрәкне кабат борчыйсы килмәгәндер. Җирләү тәкәллефләренең кайберләрен яратмавы да сәбәп булырга мөмкин. Еш кына болай да була бит: бөек затның яктысында үзләрен күрсәтергә теләгән кайбер әрсез кешеләр, ул шәхеснең чын дусларын читкәрәк этәреп уртага чыгалар, башлап йөрүче булып китәләр...

Шикләнми әйтергә мөмкин: юк кайгысын бар итеп күрсәтергә азапланган кайбер кешеләрдән аермалы буларак, Ф. Әмирхан эчтән кайгырган, эчтән кичергән. «Хәят»нең икенче кисәген көтә торган укучыларына җавап итеп язылган ачык хатыннан да бу бик яхшы күренә. «Казан яшьләре арасында соңгы көннәрдә булып киткән зыяглар *, хосусан Тукайның вафаты, күпмегә булыр инде, мине бөтен яза торган нәрсәләремне ташлап торырга ирексез итте».

Ничек кенә булмасын, Фатих Тукайны үлемсезлеккә илтә торган соңгы юлына җаны-рухы белән озаткан, каберенә күңеленнән туфрак ташлаган, хушлашу сүзләре әйткән...

Тукайның якты сурәте, үз чиратында, Фатих Әмирханны моннан соңгы гомер юлында шулай ук каберенә чаклы

---

* Зыяг — югалту.

озата барачак. Хатларында, мәкаләләрендә һәм әдәби әсәрләрендә мәрхүм шагыйрьне бик еш телгә алуы шул турыда сөйли. Бөек шагыйрьгә махсус багышланган истәлекләре һәм мәкаләләре шул ук фикерне куәтли.

7

«Кояш»ның 21 май санында без мондый хәбәр укыйбыз:

«Кадерле иптәшебез Фатих Әмирханның бу соң көннәрдә каты авырып китkәнен, күңелемез ачыган хәлдә, хәбәр итәргә мәҗбүрмез. Табиплар чиктән тыш арыганлыктан диләр. Җәй көне ял итәргә нәсихәт бирәләр».

1911 елда «Хәят» һәм «Урталыкта» кебек зур әсәрләрен язу өстенә өлгергәнлек аттестатына әзерләнде. Имтиханда уңышсызлыкка очраганнан соң, рәтләп ял итәргә дә өлгермәстән, тагын иҗат эшенә чумды. Аннары тагын имтиханга әзерләнү, тагын уңышсызлык. Инде менә «Кояш» газетасының комсыз тамагын туйдыру, редакторлык вазифасын башкару. «Кояш» белән бер үк вакытларда дөньяга килгән «Аң» журналы да Фатихның шактый вакытын алган булса кирәк. Г. Ибраһимовка адресланып, 12 декабрь датасы куелган хатта мондый сүзләр бар: «Хәсәни «Аң» портфелен култык астына кыстыра да Фатихка йөгерә, Фатих — вершитель судеб». Милләтнең «иске»ләре һәм З. Вәлиди, М. Бигиев, Һ. Максуди кебек «яңа»лары белән көрәш тә нервларын байтак какшатты. Ниһаять, күз алдында булып үткән фаҗигале үлемнәр... 1911 елда дөнья куйган апасы Сәгадәт калдырган яра төзәлеп тә җитмәстән, Тукайны озату. Тагын өч атна да үтмәде, «Кояш»та тәрҗемәче булып эшләүче Исхак Бикчурин муенына элмәк салды. Фатих хәлендәге кеше өчен болар, әлбәттә, аз түгел.

Терелеп «аякка баскач», җәйнең калган вакытын Фатих дачада үткәрә. Газета хәбәрләреннән күренгәнчә, быел ул яңа урында — «Кояш сайфиясе»ндә ял иткән. (Абруйлы газета, күрәсең, үзенең дачасын да булдырган.) Бу «сайфия» дә ял урыннарының үзенә магниттай тарта торган иң күңеллесе булып киткән дисәк, шаять ялгышмабыз. Сәбәбе билгеле: Фатих Әмирхан. Казандагы һәм Казаннан читтәге йөзләгән, меңләгән табынучылары күрү һәм тавышын ишетүне генә дә бәхет саныйлар.

Гади укучылар гынамы! Август башында әнә, хатыны белән берлектә, Галиәсгар Камал килеп чыккан. «Кояш» белән «Йолдыз» бер-берсе белән «сугыш мөнәсәбәтендә»

булсалар да, секретарьлары арасында, күрәсең, бүтәнрәк мөнәсәбәт яшәгән. Хәер, 1905 елгы революциядә алар баррикаданың бер ягына басып сугыштылар. Соңрак та «Әльислах» белән «Яшен» иңгә-иң куеп көрәштеләр. Хәзер «уңлаша» төшсәләр дә, бер чама «уңлашканга» күрә, бер үк лагерьда торып калдылар.

Ял сиздермичә узып китә. Тән-җисем ягын ныгыткан кебек, Фатих рухи яктан да язылa, кулга каләм аласы, пыклап торып язасы килә башлый. Ләкин эчендә әлеге сәяхәт шайтаны утыра бит, котырта да тора: җәй дә узып китте ич, дөнья күреп, һава алыштырып, тузан кагып кайтмау ни дигән сүз?

Сентябрь башында бер көнне Фатих хезмәтче егете һәм тагын бер юлдашы белән поездга утыра да кинәт юлга чыга. Рузаевкада пересадка ясап һәм юлдашыннан аерылып, Пенза ягындагы бер станциягә кадәр бара, аннары, ат яллап, ниндидер рус авылына килә дә фатирга керә.

«Кинәт» дип яздым язуын, әмма бу бәлки алдан планлаштырылган һәм максаты ачык сәфәр булгандыр. «Кыска сәфәрдә» дигән исем астында «Кояш»ның биш санында чыккан юлъязмасы булуга карамастан, бүтән чыганаклар табылмаганга күрә, бу сәяхәт мәсьәләсе хәзергә томанлы кала. Кем киңәше һәм кем чакыруы белән ясалган ул? Ни максат белән? Нинди авыл бу? Ни өчен рус авылы?

Юл очеркларында безнең сәяхәтче үзе күргән вак эпизод, кечкенә маҗаралар, кызыклы очрашу һәм сөйләшүләрне тасвир итә дә, аңа гына хас булганча, зур гомумиләштерүләр ясый. Менә кеше аңламаслык хәрефләр белән газета, китаплар басып тарату урынына рус теленә генә күчсәләр, татарларга яхшырак булмас иде микән, дип фикер йөртүче бер рус карты белән вагондагы бәхәс; менә Рузаевка һәм башка станция биналарының шыксызлыгы, аларда хөкем сөргән тәртипсезлек; менә әлеге рус авылында сөт, май, язу карасы эзләп тә таптыра алмавы, ә самогонның коеныргa җитәрлек булуы; менә «исемең русча ничек була?» дип сораган өй хуҗасына татар кешесе исеменең русчасы, рус кешесе исеменең татарчасы юк икәнен, әллә ничаклы дәлил китереп тә, аңлата алмавы; менә авыл мужиклары һәм күршедәге рус алпавыты тормышы арасындагы контраст. Тик югарыдагы сорауларга гына җавап юк...

Сәфәр чынлап та кыска булган. Фатих аны, теләсә, озайта да алыр иде: сәбәп табу кыен түгел, барыр җирләргә кытлык юк. Ләкин әнә һавалар бозылып китте, аннан да бигрәк, Фатихны Казанда үзе өчен күңелле вакый-

га — «Яшьләр» пьесасының 17 сентябрь көнне «Шәрык клубы»нда булачак премьерасы көтеп тора.

1909 елда ук язылып беткән бу әсәрне, урындагы цензура кире кагу сәбәпле сәхнәдә куйдыра алмагач, Фатих аны Петербургка җибәргән иде. Шактый вакытлар узгач, анда да Заһид Шамил ярдәмендә генә көч-хәл белән рөхсәт ала алды.

Инде менә көткән көн килеп җитте, күптәнге хыял тормышка ашты: Фатих үзенең әсәрен сәхнәдә күрә. Рецензия яисә тәфсиллерәк информация чыкмаганга күрә, без бу спектакльнең ничек узганын белмибез. Соңрак күрсәтелгән икенче спектакль исә, Г. Кәрәмнең озын рецензиясеннән аңлашылганча, җанлы узган, халык күп булган, туктаусыз алкышлаганнар. Премьерасы да якынча шулай узган дип уйларга кирәк.

Ничек булса да була, күңелле кичә узып китә, Ф. Әмирхан драматурглыкка уңышлы имтихан тота. Тагын эшмәшәкать белән тулы көннәр бер-берсен алыштыра башлыйлар. Ара-тирә алты битле булып чыга торган көндәлек газетаның тамагын туйдыру җиңел түгел. Тәрҗемә ярдәм итә итүен, әмма үз казаныңда пешкән туклыклы азыксыз ерак бара алмыйсың. Димәк, үзеңә язарга, читтән кергәнне, кешеләр язганны төзәтергә кирәк.

Публицистика да Әмирханның яраткан жанры. Ятагына һәм коляскасына баглы булуына карамастан, үзен җәмәгать эшлеклесе итеп саный. Карагруһчыл хөкүмәт һәм милләт эчендәге «дегет чүлмәкләре», бердәм фронт тәшкил итеп албастыдай басып яткан заманда Фатихны әрнеткән, кайгыга салган яисә җен ачуларын чыгарган хәлләр көн саен диярлек булып тора. Ничек дәшми каласың да нәфрәт сүзеңне ничек әйтми түзәсең. Кыскасы, Ф. Әмирхан әнә шул шыксыз дөньяда яшәргә, чәнечкеле чытырманлыкны ерып барырга, тәнен ерттыруга, баш-маңгаен күптерергә мәҗбүр. Ал-ял алырга теләп, үзе тудырган дөньяда яшисе килдеме, әйтеп булмый, 1914 елга кергәч Фатихның әдәби иҗаттагы активлыгы артып китә. «Хәкимә әби», «Нәҗип», «Танс кичәсе», «Балалар атавы», «Габделбасыйр гыйшкы» — менә аның бу елда дөнья күргән эреле-ваклы әсәрләренең тулы булмаган исемлеге.

«Габделбасыйр гыйшкы» хикәясен (кечерәк повесть дисәң дә ярый) кайчан кәгазьгә төшерә башлагандыр, әйтеп булмый, соңгы нокта куелган көне исә билгеле: 31 июль. «Аң» журналының 1914 елгы 1 июнендә чыккан 11 санын ачабыз да аптырап калабыз: «Габделбасыйр гыйшкы» басыла башлаган ич! 12, 13, 14 саннарда дәвам иткән һәм

августның беренче яртысына карый торган 15 санында басылып беткән. «31 июль» датасы белән шушы фактны ничек яраштырырга?

Күрәсең, «Гарәфә кич төшемдә» хикәясен язуга охшаш хәл кабатланган («...мин хикәямнең ахырын язып яткан вакытта, башы матбагада тискать ителеп бетә бара иде»). Повестьның сюжеты, төп героеның төс-кыяфәте, гадәтхолкы, авторның әйтергә теләгән фикере башта, хыялда күптән эшләнеп килгән. Март тирәсендә Фатих аны кәгазьгә төшерә башлаган булыр. Язылып беткән кадәресен «Аң» редакциясенә тапшырган да — алга сикереп булса да әйтик — Буа якларына бер айлык ялга чыгып киткән. Журналның чираттагы ике саны өчен булган дәвамын ял вакытында язып, шуннан җибәргән булыр. Ахырын үзе белән алып кайткан яки Казанда язып бетергән дип уйларга кирәк.

Тагын шунысы игътибарга лаеклы: әдип үзе исән чакта әсәр, аерым китап рәвешендә булсын, берәр җыентыгында булсын, кабат басылмыйча, журнал вариантында торып калган. Гаҗәеп хәл: ашык-пошык язылуына, басмага кисәкләп тапшырылуына һәм кабат эшкәртелмәвенә карамастан, «Габделбасыйр гыйшкы» повесте шедевр булып санала ала.

Дөрес, беренче карашка әллә нәрсәсе юк. Габделбасыйр исемле гадәти бер шәкерт мәдрәсә күршесендәге йортны сатып алган Рәүф байның кызы барлыгын ишетә дә гашыйк була. Җаен туры китереп, ул кызны күргәндер (яшьме, чибәрме?) һәм, матурлыгына сокланып, танышу чарасына керешкәндер, хат аша яисә үзен күреп мәхәббәтен белдергәндер дип уйлый күрмәгез. Кызның ул якты йөзен бер генә мәртәбә күрә алмаган кебек, кыз да бу егетнең дөньяда барлыгын белми. Нинди мәхәббәт соң бу? Габделбасыйр мәхәббәте, хыялдагы мәхәббәт.

Габделбасыйр — хәлле генә крестьянның төпчек улы. Атасы аны муллалыкка укытырга уйлаган.

Егетнең төс-кыяфәте, өс-башы гадәти. Дүрт почмаклырак яссы йөзендә төссез соры күзләр, саргылт кашлар, почыграк борын, шактый ерынкы авыз һәм тар маңгай. Каракүл үк булмаса да ярыйсы гына бүреге, яңа дип әйтерлек бишмәте, тупасрак булса да читеге бар. Үз фикеренчә, бай кызының күзе төшмәслек түгел.

Рәүф бай күчеп килгәннән бирле безнең Габделбасыйр, битен-муенын исле сабын белән өчәр кат юып (кыз күрсә, оятка калуың бар), коймадагы ярыктан күрше ишегалдын күзәтә башлый. Аннары мәхәббәтен белдерергә ом-

тылыш ясый: башта ярыкка зәңгәр кәгазь кыстыра, аннары кызыл белән алыштыра (кызлар кызылны ярата). Бервакыт бусы юкка чыга. Әлбәттә инде, кыз алган. Димәк, Габделбасыйрның мәхәббәте мәгълүм булды, кызның йөрәгенә ут кабынды.

Көннәрдән бер көнне Габделбасыйр, ярыктан күзәткәндә, кызның буй-сынын «күрү», исемен белү һәм тавышын «ишетү» бәхетенә ирешә. Чапанга төренгән ике хатын биек болдырдан менеп барганда берсе әйтә: «Итәгемә бастың, Диләфрүз». Әһә, исеме «Диләфрүз» икән! Тавышы да тавышы! (Габделбасыйр логикасы гына «Диләфрүз» дип эндәшкән хатынны Диләфрүзнең үзе итеп юрарга мөмкин.)

Мәхәббәтен белдерү өчен булган чираттагы һәм соңгы омтылышы болай була: кызыл кәгазьгә ике генә юллык мәхәббәт хаты яза да әлеге ярыкка кыстыра. Эшне шуның белән беткәнгә санап, безнең Габделбасыйр көн саен, шәкертләр йокыга талгач, үзенең сөйгәне белән хыялда кавыша башлый.

Менә аның түм-түгәрәк битле, нечкә борынлы, кызыл иренле, симез гәүдәле Диләфрүзе якынаерга базмыйча, тартыныбрак кына басып тора.

— Кил, җаным, кил, кочагыма керәсең киләме, былбылым?

Мондый манзаралар кабатлана торгач, мадди таянычка ихтыяҗ туа: безнең гашыйк, бишмәтен юрган астына алып, коча, үбә башлый, мәхәббәт сүзләре сөйли, «кыз»дан да шундый сүзләр әйттерә.

Вакытлар уза, егетнең гыйшкы һаман куәтләнә бара, Диләфрүз (соңыннан аның Газизәбану исемле булганлыгы беленә) һәр төнне бишмәт кыяфәтендә егетнең куенына керә. Йөгәнсез хыял исә үз эшендә. Яңа детальләр, эпизодлар, маҗаралар өстәлә, бөтен бер мәхәббәт романы барлыкка килә. Габделбасыйр Әхмәтне бу романның сәхифәләре белән таныштыра тору белән бергә, «сиңа гына әйтәм» дип, тагын берничә иптәшенә серен ача. Бер көнне Әхмәткә ул, уйлап җиткермәстән, Диләфрүздән килгән хатны укырга вәгъдә итә. Җайсыз хәлдән чыгу өчен Габделбасыйр үзенә хат яза һәм, хушбуйга манып, икенче көнне иптәшенә тоттыра: менә укы. Мондый хатлар өч көн саен «килә» башлый. Әхмәт күзеннән дә кичерелгәч, алар тагын да кадерлерәк булып китә, Габделбасыйр һәркайсын үбеп, сандыгына салып куя.

Бәлки безнең мәхәббәт «каһарманы» ярты акылдыр? Шулай булмаса, Рәүф бай кызы белән үзе арасында бер-

нинди дә гыйшык-мыйшык була алмаслыгын аңлар, буш хыялга бирелеп, бишмәт кочаклап ятмас иде.

Юк, Габделбасыйр — үз акылындагы сау-сәламәт егет. Әмма татлы хыял аның акылын караңгы почмакка куып керткән. Вакыт-вакыт, хыял зәгыйфьләнеп, акылы калкып чыга да мәхәббәт романының чын түгел икәнен исенә төшерә. Дөнья кинәт караңгылангандай була, егетнең җаны өшеп китә, тормышында бернинди ямь калмый. Һәм ул аек акылны тизрәк үз урынына, караңгы почмакка куып кертергә, татлы, ямьле хыял дөньясына чумарга ашыга.

Моннан соң инде Габделбасыйрның кыз белән чынлап торып танышу чарасына керешмәвен дә аңлау кыен түгел. Әлеге аек акыл әйтә: син кем дә, ул кем? Эт баласы урынына тибеп очырыр. Хыялдагы Газизәбану (әйе, хәзер ул бөтенләй Газизәбануга әверелде) исә бөтенләй бүтән: Габделбасыйрны шашып сөя, кочагына керергә әзер тора.

Чү, ялыга төшкән укучының ризасызлык белдергән тавышын ишеткәндәй булам:

— Сөйлисез дә сөйлисез. Шедевр дип атарлык нәрсәсе бар? Бер пешмәгән калачның тозсыз мәхәббәте...

— Сорауга каршы сорау: өяз чиновниклары бер җилкуарны ревизор дип кабул итәләр дә, хаталары ачылгач, көлкегә калалар. Нәрсәсе бар?

— Чагыштырдыгыз! Ул бит Гоголь!

— Бу — Фатих Әмирхан! Кадерле укучым, боз тавы — айсберг принцибын хәтерлисездер? «Ревизор» комедиясе Городничий, Ляпкин-Тяпкин яисә Хлестаков турысындамыни? Бөтен Россиянең чиновникчыл-бюрократик строена сатира ич!

— Яхшы. «Габделбасыйр гыйшкы» хикәясенең су асты өлеше нидән гыйбарәт?

— Чамаламадыгызмыни? Җәмгыятьне үзгәртү өчен көрәшү түгел, хәтта аңа яраклашырга да сәләтсез булган социаль төркемнәрнең трагикомедиясен ачып бирү.

— «Габделбасыйр гыйшкы» да мәдрәсә турында түгел, димәкче буласызмы?

— Юк, алай димим. Мәдрәсә турында. Чөнки Габделбасыйрларны күбрәк иске тип татар мәдрәсәләре эшләп чыгара иде. Әнә бит Тукай да «Печән базары...» поэмасында баю хыялы белән Кабан күленең кибүен көтеп яткан шәкертләрнең янтавына төртеп узды. Мәдрәсә турында гына да түгел. Хәятне онытмагансыз, укучым? Күрмәгән, белмәгән кешегә кияүгә чыгу мәҗбүрияте алдында калгач, ул нишли? Хыял дөньясыннан юаныч эзли түгелме?

Габделбасыйрларны искелектән котылып җитмәгән буржуаз гаилә дә тудырган икән ич.

— Бу инде хәттин ашу! Фәрештә белән «пешмәгән калач» арасына ничек инде тигезлек билгесе куярга мөмкин?

— Габделбасыйрның әшнәләре татар дөньясыннан читтә дә бар дисәм, тагын ачуланырсыз микән, укучым? Әнә Иван Александрович Хлестаков. Габделбасыйрның нинди генә! Илһамга бирелеп һәм шуңа ышанып, үзен Петербургның министр дәрәҗәсендәге чиновнигы итеп күрсәтә. Яисә менә Илья Ильич Обломов. Көннәр, айлар, еллар буе ятагында аунаган хәлдә, утарын тамырыннан үзгәртеп кору турында грандиоз планнар кора.

— Габделбасыйрны, Обломов, Хлестаковлар белән бер тактага куеп, үзегез дә хыял дилбегәсен кулдан ычкындырдыгыз түгелме, язучы иптәш?

— Мин аларны тигезләргә җыенмыйм. Конкрет шәхес буларак Хлестаков белән Обломов бер-берсенә охшамаган кебек, Габделбасыйр да бөтенләй үзгә. Һәркайсы билгеле бер иҗтимагый мөнәсәбәтләр җимеше. Әмма адәм дигәннең табигатеннән үк чыга торган бер сыйфат аларны үзара якынайта.

— Гадирәк итеп әйтсәгез лә, без бит сезнең кебек үк галим кеше түгел...

— Яхшы. Кулны күкрәккә куеп әйтегез әле, укучым, үзегез өчен уңышсыз беткән бәхәстән соң, өйгә кайтып юрган астына чумгач, әлеге вакыйганы күңел аша кабат кичереп, берсеннән-берсе саллы дәлилләр белән оппонентыгызны стенага терәгәнегез булмадымы? Яисә башыгыздан үткән хәлне үз файдагызга чак кына үзгәртеп сөйләгәнегез юкмы? Һәркайсыбызның эчендә — зурмы, кечкенәме — Габделбасыйр утыра. Посып кына утыра. Җае чыгу белән баш калкыта.

Кыскасы, Габделбасыйр социаль тип кына түгел, бәлки психологик тип та, икесен аерылмас берлектә алсак ул тиңдәшләре Хлестаков белән Обломов һәм бүтән төргә караган Молчалин, Манилов, Гамлет, Тартюф, Иудушка Головлев һ. б. кебек үк, гомумкешелек тибы.

— Белмим, белмим... Бик югары күтәрдегез. Үзегез үк автор исән чакта хикәя кабат басылмаган дидегез. Әдәби тәнкыйтьнең дә бу әсәргә бик үк мөкиббән киткәне юк шикелле.

— Бусы минем өчен дә табышмак. Вакыт бәлки әле үз сүзен әйтер...

Бәхәс сыман нәрсәне шушында туктатыйк та әйләнешкә кергән бер хатаны төзәтеп узыйк.

В. Бәхтияров истәлегендә Габделбасыйрның прототибы — Тукай дип белдерелә. Бу раслауның хаталыгын исбат итәргә дә хаҗәт юк. Өстәвенә, бу мәсьәлә соңгы вакытта ачыклана төште. 1925 елда, Әстерханга барып чыккач, Ф. Әмирхан «Идел» газетасының элеккеге нашире һәм редакторы Габдрахман хәзрәт Гомәридә кунакта була. Шул вакыт тышкы кыяфәте белән муллага тартым бер адәм килеп керә. Ул Фатихның «Мөхәммәдия»дә бергә укыган шәриге булып чыга. Ул кеше күпмедер утырып киткәч, әдип, мәҗлестәгеләргә карап: «Бу минем бер хикәямнең герое бит»,— дип куя. Г. Гомәри кайсы хикәя икәнлеге белән кызыксынгач, ул «Габделбасыйр гыйшкы»н атый.

— Ул кемгә гашыйк булган иде соң? — дип сорый Гомәри. Әмирхан бераз дәшми тора да, көлемсерәп җавап бирә:

— Кызы мотлакка *.

Истәлекче бу кешенең Казан артыннан икәнлеген дә хәтерли, ләкин, кызганычка каршы, исем-фамилиясен оныткан.

... Ф. Әмирхан тормышының 1913—1914 еллар аралыгы балалар өчен күп язуы белән дә аерылып тора.

Менә аның күздән яшь китерерлек кыска гына хикәясе «Ул үксез бала шул». Менә «Корбан» исемле хикәясе, безгә кечкенә, ә балага зур булып күренгән драматизм: малайның назлап үстергән бәрәнен корбанга чалалар. «Нәҗип» хикәясендә автор, маңгайга бәреп әйтмичә генә, тырышлыкны, хезмәт сөючәнлекне һәм һөнәр белүне пропагандалый.

«Балалар атавы» исемле хыялый повестьта дуслык, туганлык, хезмәттәшлеккә корылган җәмгыять тасвир ителә. Авторның социализмны күздә тотуын чамалау артык кыен түгел.

Ф. Әмирхан драматург буларак та балалар өчен берничә әсәр яза башлаган, ләкин никтер тәмамламый калдырган.

Ф. Әмирханның сәфәре мәсьәләсенә кайтсак, 29 май көнне Буа якларына чыгып китеп бер ай торып кайтканыннан бүтән нәрсә белмибез. Димәк, тагын фараз итәргә кала.

---

* Кызы мотлак — кыз-абстракт.

Бу вакыт «Кояш» редакциясендә Ибраһим Биккуловның эшләгәнен укучы хәтерлидер. Фатих белән бергә «Мөхәммәдия»дә укыган, «Ислах»ның актив әгъзаларыннан берсе булган. Әнә шул Ибраһимның ата бер, ана башка абыйсы Касыйм Биккулов Буа өязенең Яңа Тинчәле авылында мулла булып тора. Яңарак карашлы, берничә китап авторы.

Фатихның торып китү ихтималы булган гаиләләрнең берсе шушы. Бәлки әле алар И. Биккулов белән бергә барганнардыр. Буаның үзендә яисә тирә-як авылларның тагын берәрсендә Фатихның бүтән танышлары да булырга мөмкин.

Тәгаен билгеле булганы шул: әдип ял итү белән берлектә басылып эшләгән. «Габделбасыйр гыйшкы»ның күп өлешен шунда язганын инде без беләбез. «Нәҗип» хикәясенең ахырына үзе үк 16 июнь датасы куйган. Шушы ук елда аерым китап булып чыккан. «Балалар атавы»ның да Буа якларында язылган булуына шикләнмәскә мөмкин.

Бер ай эчендә Ф. Әмирхан өязнең үзәк каласы һәм авыллары табигатеннән булсын, төрле катлау кешеләреннән булсын, әллә ничаклы тәэсир-гыйбрәт алган дип уйларга кирәк. Тишеп карый торган күзе, төпченү гадәте һәм болыт кебек суырып ала торган зиһене бар. «Габделбасыйр гыйшкы» повестеның ахыр өлешен укыганда мондый юлларга тап булабыз: «Өлгереп, саргаеп беткән арыш басуы, күз күреме җиргә җәелеп, акрын искән җәнүб * җиле белән акрын вә матур дулкынланып тора, үзенең бертөрлелеге белән күзләрне бераз ялыктырса да, киңлеге, зурлыгы вә бөтенлеге белән күңелдә үзенә каршы бер хөрмәт тудыра иде.

Габделбасыйр кунагын тыгыз сафланып торучы алтын саплы башаклар арасына кысылып калган тар ат юлы буенча алып китте. Каршында җан иясе күренми, башаклар дулкынлануыннан чыккан акрын чыжылдаудан башка бер тавыш та ишетелми иде». Аз сүз белән арыш басуының бу чаклы төгәл һәм җанлы сурәтен тудыру өчен Фатих күзе, Фатих колагы өстенә, аның авыл юлларында атка утырып гизүе кирәк.

Ниһаять, ял тәмам. Әдип җыенып, төянеп юлга чыга. Июньнең 27 сендә без аны Казанда күрәбез. Бу вакыт инде дөньяларның капылт үзгәреп китүенә күп калмаган була...

---

* Җ ә н ү б — көньяк.

*6 бүлек*

# ЯҢА ДАВЫЛЛАР АЛДЫННАН

## 1

Күктә сугыш болыты күптән куера башлаган иде инде. 19 июль көнне, ниһаять, яшен яшьнәп күк күкрәде. Европаның бөек дәүләтләре һәм кайбер бүтән илләре дә сугышка тартылдылар. Озакламый башка континентларның күп кенә илләрендә дә сугыш уты кабынып китте.

Империализм чоры каршылыкларыннан туган талау сугышы иде бу. Шушы дәвергә хас тигезсез, сикерешле үсү нәтиҗәсендә алгарак чыккан илләр бүленеп беткән дөньяны яңадан бүлмәкче булдылар. Майлы калҗаны элегрәк кулга төшереп калганнары исә аны ычкындырмаска, көндәшләрен зәгыйфьләндерергә, җае чыкса, калҗа янына калҗа өстәргә тырыштылар.

Сугышучы илләрнең, бигрәк тә Россиянең, хөкүмәт һәм буржуазияләре юл уңаенда тагын бер мәсьәләне хәл итәргә — гаять тиз үсеп бара торган революцион хәрәкәтне сугыш утында көйдереп ташларга теләделәр.

Барлык илләрнең, шул исәптән Россиянең, буржуазиясе һәм аның партияләре сугышка ике куллап ябышты. II Интернационал партияләре дә, аерым ныклы интернационалистларны исәпкә алмаганда, бу сынауны үтә алмыйча, ватанны саклау байрагы астында сугышны яклау юлына бастылар.

Россиянең большевиклар партиясе бердәнбер дөрес политика үткәрде. Ул дөнья сугышының сыйнфый асылын, политик максатын ачып бирде, империалистик сугышны гражданнар сугышына әверелдерү бурычын куйды, самодержавиене аудару ансатлаша төшсен өчен Россиянең җиңелүе хәерле дип белдерде.

Татар буржуазиясе дә сугышны хуплап каршылады. Пролетариат һөҗүменнән имин калу өчен самодержавие канаты астына сыенган кебек, сугыштан килә торган файдадан үзенә өлеш чыгарырга теләде.

Либераль буржуазия белән милләтнең карагруһчыл төркемнәре арасындагы азмы-күпме каршылыклар да онытылды. Алар «патриотизм» байрагы астына тупландылар. Моның беренче чагылышы 3 августта үткәрелгән манифестациядә күренде. Эреле-ваклы сәүдәгәр һәм купецлар, руханилар белән берлектә, дәүләт флагы һәм патшаның

рәсемнәрен күтәреп, башта губернаторга, аннары гарнизон башлыгына бардылар, үзләренең патшага, ватанга турылыклы булуларын белдерделәр. Динчеләр органы «Дин вә мәгыйшәт» журналы болай дип язды: «Һәркем, кирәк кай милләттән вә кирәк кай диннән булсын, гаклы вә фикере сәламәт булса, ватан файдасын күзәтүне һәр нәрсәдән алда тота». «Вакыт» газетасы шул ук җырны җырлады: «Безләр бу сугышка Россиянең «үз истикъбалеп * кайгыртуы» дип карыймыз, аның хаклы булдыгын, аңсыз калу мөмкин булмадыгын тәсдыйк ** итәмез».

Төркиянең дә Германия империализмы ягыннан торып сугышка катнашып китүеннән соң татар буржуазиясенең комсыз табигате тагын да ачыграк күренде. Идеологларыннан берсе Сәетгәрәй Алкин, мәсәлән, «дин һәм кан кардәшлеге» дигәнне онытып, «Казанский телеграф» газетасы трибунасыннан болай дип белдерде: «Барлык шикләнүчеләр, ышаныгыз, безнең көчләр (ягъни мөселманнар — *И. Н.*) Көнбатышта германлыларга каршы атакага теләп катнашканы кебек, яңа фронтта төрекләргә каршы да теләп сугышырлар».

«Патриотизм» шаукымы вак буржуаз интеллигенцияне дә читләтеп узмады. Эсерлар белән бер аяктан атлап баручы Ф. Сәйфи-Казанлы («Йолдыз», 1914, 9 август) фикеренчә, Россия ягыннан бу гадел сугыш. Немецлар исә — басып алучылар («Мәдәни аталган немец халкы вәхшиләрдән уздырып җибәрделәр»).

Ф. Әмирхан сугышка нинди мөнәсәбәттә булды? Хәрби хәлгә хас булганча, цензурага чикләмәгән хокук бирелгәнгә күрә, бу сорауга җавапны «Кояш» сәхифәләреннән табу җиңел булмаса да, эзләп карыйк.

Турыдан-туры сугышка багышланган баш мәкаләләр стильләре белән үк, «юк, без Әмирханныкы түгел» дип кычкырып торалар. Хәтта аларда да «падишаһ һәм ватан» дип төчеләнү бик үк күренми. Ф. Әмирхан каләме белән язылган һәм тегеләйме, болаймы сугышка кагылышлы имзасыз һәм имзалы мәкаләләрдә исә аның сугышны өнәмәвен һәм ура-патриотизм тойгыларыннан азат булганлыгын чамаларга мөмкин.

Менә Һ. Максуди, Гариф мулла Салихов һәм безгә яхшы таныш С. Иманколый инициативасы белән яралылар файдасына иганә җыю өчен «Мөселман комитеты» оештырыла. «Йолдыз» газетасында шул турыда информация

---

* Истикъбаль — киләчәк.
** Тәсдыйк — раслау.

чыккач, Ф. Әмирхан «Бергәме, аерыммы?» дигән мәкалә бастырып, мондый комитетның кирәксезлеген исбат итә, иганә җыю тиеш икән, бу эшне руслардан аерылмыйча, алар барлыкка китергән җәмгыятьләр аша эшләү дөресрәк булыр, ди.

Ике газета арасында тагын фикер дуэле булып ала. «Йолдыз»га җавап итеп язылган икенче мәкаләсендә Фатих үз фикерендә калганлыгын белдерә. Моңа өстәп тагын шуны да әйтә: бу минем шәхси фикерем, газета редколлегиясенең кайбер әгъзалары аны уртаклашмый. Карап торышка кечкенә бер мәсьәләнең принципиаль төс алуы, Ф. Әмирханның, азчылыкта калып булса да, кайта-кайта үз позициясен яклавы очраклы хәл түгел, билгеле. Хөкүмәт эшләргә тиешле эшне өскә алмаска, сугыш алып баруда самодержавиегә ярдәм итмәскә чакыру юкмы монда?

Бу сорауга җавап бирүне кичектереп, тагын бер дуэльгә тукталып китик.

С. Алкин шул ук «Казанский телеграф» газетасында «Мөселманнарга мөрәҗәгать» бастыра. Ватан өчен хәвефле көннәрдә, ди ул, безгә бер җан, бер тән булып яшәргә, дошманны җиңү хакына бер нәрсәне дә кызганмаска кирәк. Ләкин, дип дәвам итә ул, сезнең гражданлык вазифаларыгызның мәгънәсен бозып аңлатучылар бар. «Алар сезнең наданлыгыгыздан, рус телен белмәвегездән файдаланып, матбугат хәбәрләрен бозып тәрҗемә итәләр һәм сезне ялгыш юлга этәрәләр».

Ташның кем бакчасына ыргытылганын шундук аңлап, Ф. Әмирхан «Кояш» редакциясе исеменнән җавап яза һәм мәкаләсен таләп куеп тәмам итә: Сәетгәрәй әфәнде яки газетаның исемен атап, үзе ташлаган гаепнең дөреслеген исбат итсен, яки, исбат итә алмаса, сүзен кайтарып алсын. С. Алкин туры җаваптан качып алай боргалый, болай боргалый да ахыр чиктә мәсьәләне бер үк нәрсәгә — татар газеталары хезмәткәрләренең русчаны начар белүләренә кайтарып калдыра.

Бу җавап Ф. Әмирханның «Мирза һәм рус теле» исемле гаять үткен һәм көчле фельетонының язылуына сәбәп була.

Үзен «гололобый татарин»нардан өстен күрергә теләгән морза, имештер, Крыловның 21 мәсәлен ятлап алган да горурланып йөри башлаган. Вакытлар уза, бервакыт «гололобый татарчонок» та ул мәсәлләрне ятлап алган, хәтта арттырыбрак ятлаган. Морза, бу хурлыкка түзә алмыйча, улын гимназиягә бирә. Бервакыт күрә: «гололобыйлар»дан да гимназиягә керә башлыйлар. Ул гына да

түгел морза баласы ярты-йорты белеме белән торып калганда, «гололобый татарин» югары мәктәпкә барып керә. Хурлыгыңнан шартлап үләрсең! Шулай да морза абзый бирешергә теләми, Крылов мәсәлләреннән оештырып бер мәкалә яза да:

— Русчаны мирзалар гына беләләр! А вы, гололобые, научитесь по-русски! — дип кычкыра.

Кадетчыл «Камско-Волжская речь» газетасы да бәхәскә катышып китә. «Мусульманка» имзалы бер «господин», морзаларның татар мәдәниятенә керткән өлешен бик югары бәяләгәннән соң, «Мирза һәм рус теле» фельетоны авторын гаепләргә керешә. «Гололобыйлар»ның күзен ачкан өчен рәхмәт әйтү урынына, янәсе, ул морзаларны хурлый һәм җәберли. Аннары үзенчә каты тешлим дип уйлап, Крыловның «Свинья под дубом» мәсәлен укып мәгънәсен аңларга киңәш бирә.

Фатих «Бу да татарлар хакында» исемле фельетон белән җавап бирә. Бусында автор милли мәсьәлә белән генә чикләнмичә, социаль мәсьәләләр югарылыгына күтәрелә.

«Бичара мирзалар, аларны гололобыйлар ничек тәхкыйрь * итәләр, ә алар һаман..., алар һаман... «гололобыйлар»га вәли нигъмәт ** булып торудан баш тартмыйлар: урта һәм гали мәктәпләргә кереп күрсәтәләр, Крылов баснялары белән гамәл кылырга киңәшләр бирәләр, соңрак калып булса да, рус теленең кирәклегенә дәлилләр китереп, «Камско-Волжская речь»кә язалар, татарларны ватанга хыянәт иттерергә тырыша торган татар газеталары өстеннән рус әфкяре гаммәсенә *** шикаять итәләр вә иләх.

Гоголь мәрхүмнең бичара Собакевичы шушылай кызганыч иде: аны крестьяннар һаман җәберләп торалар, ә ул аларга һаман вәли нигъмәт булып торудан баш тартмый иде».

Морзалар белән алдынгы карашлы «гололобый»ларның тырышлыгы, омтылыш һәм идеаллары арасында, ди Ф. Әмирхан, зур аерма бар. Соңгыларының тырышлыгы һәм эшчәнлеге кайчандыр мәшәкать чигә-чигә халыкка хезмәт иткән рус зыялыларының, ягъни народникларның, гамәлен хәтерләтә.

«— Мирза мәшәкатьне коллежский асессор булыр өчен

---

* Тәхкыйрь — хурлау.
** Вәли нигъмәт — яклаучы.
*** Әфкяре гаммә — җәмәгатьчелек фикере.

чикте, әмма рус зыялысы... бу мәшәкатьләрне башкарак идеаллар өчен чигә иде.

— Сабыр ит, мирза! Коллежский асессор булырсың! — дибез без аңар». Цензура чекрәеп карамаса, Ф. Әмирхан нокталар куеп тормыйча ярып салыр иде: народниклар крестьяннарны әнә шул Собакевичлар золымыннан коткару хакына төрмә, сөрген, дар агачларына бардылар.

«Свинья под дубом» мәсәленә килгәндә, мирзалар имән, «гололобый»лар дуңгыз түгел», ди Ф. Әмирхан, киресенчә, милләтнең демократик катлаулары һәм алдынгы мәдәнияте имән булса, С. Алкин һәм «Мусульманка» әфәнделәр кебек морзалар — шул имәннең әкәләсен ашап та, тамырын корытучылар.

Ф. Әмирханның сатириклык талантын С. Алкинга каршы юнәлтүе котылгысыз иде. Кадетлар партиясе әгъзасы булган бу шәхеснең Төркиягә кагылышлы белдерүенә турыдан-туры каршы чыгу, билгеле, мөмкин түгел иде. Карап торышка кечкенә мәсьәләгә карата язылган әлеге ике фельетон, С. Алкинга җавап булу белән бергә, сугышны тырышып-тырышып яклаучы либералларның сыйнфый асылын аңлауга хезмәт итте. Әмирхан сугышны өнәмәгән, аңа каршы булган дигән фаразыбыз дөрескә чыга түгелме?

— Большевик ясагыз тагын! Бәлки әле Әмирхан сугышны гражданнар сугышына әверелдерү тарафдары да булгандыр?

Тынычланыгыз, укучым, тынычланыгыз да әйдәгез минем белән тагын архивка. Жандарм идарәсе фондының 3620 номерлы эш папкасын ачабыз да башына «Бөтенләй яшерен» дигән сүзләр язылган документны укыйбыз. Фатих Әмирханов «... «Кояш» газетасының секретаре генә булса да, аның юнәлешенә зур йогынты ясый. Бүтән татар газеталары, хәтта «Вакыт» кебек прогрессив һәм абруйлылары да, үз битләрендә Россия мөселманнары Төркиягә каршы бара торган бу сугышка карата да, элеккесендәге кебек үк, лояль булырга тиешләр дигән мәгънәсендәге мәкаләләр урнаштырган бер вакытта, «Кояш» газетасы үзенең секретаре Фатих Әмирханов басымы астында гына мондый мәсьәләләрне читләтеп уза. Анда урнаштырылган патриотик тондагы кайбер нәрсәләр — тик редакторның һәм хәрби цензура комиссиясенең ... (бер сүз танылмый.— *И. Н.*) нәтиҗәсе».

Шул ук КГЖУдан шул ук губернаторга җибәрелгән икенче бер документтагы сүзләр сезне, укучым, тагын да гаҗәпләндерә төшәр дип беләм.

«Әмирханов Фатих... 1914 елгы сугыш игълан ителгән-

нән башлап соңгы вакытларга кадәр бу сугышның нәтиҗәсенә кагылгышлы карашын яшерми. Аның фикеренчә Россия тегеләйме, болаймы җиңүче булып калса куәтле реакция башланачак. Бу реакция башлыча инородецларга, аерым алганда мөселманнарга кагылачак. Шунлыктан ул Россиянең җиңелүен тели һәм шуңардан мөселманнар өчен файда күрә».

Ф. Әмирхан Европа һәм Россиядәге партияләрнең, шул исәптән большевикларның дөнья сугышына мөнәсәбәтләрен, әлбәттә, яхшы белгән. Әмма, моннан чыгып һәм жандармерия сүзенә таянып кына ул сугышка мөнәсәбәттә РСДРП(б) позициясенә баскан һәм Россиянең җиңелүе мәсьәләсенә ленинчыл мәгънә салган дигән нәтиҗә ясау дөрес булмас иде.

Без инде Фатихның милләтне һәм милли культураны буган патша хөкүмәтен җаны-тәне белән дошман күргәнен беләбез. Самодержавиене аударып, демократик строй урнаштыру аша гына милли азатлык яулап алырга мөмкин дигән караштa торганына да ышандык. Шулай булгач, самодержавие мәнфәгатенә хезмәт итә торган сугышта Россиянең җиңеп чыгуын тели ала идеме Ф. Әмирхан? Әлбәттә, юк. Бу карашка аны, димәк, үз сукмагы, үз фикер логикасы китергән. Большевиклар йогынтысын да инкарь итеп булмый, билгеле.

Сугыш темасы Ф. Әмирханның әдәби иҗатына үтеп керә алдымы? Бу сорауга алды дип тә, алмады дип тә җавап бирергә мөмкин. Чөнки бу темага ул, 1914 һәм 1915 елгы корбан гаетләре уңае белән, «Зәгыйфь карчыкның корбаны» һәм «Мостафа» исемле ике хикәя бирде. Алар да, жанр ягыннан, рус әдәбиятындагы «святочный рассказ»ны хәтерләтә торган сентименталь хикәяләр иде. Кеше җырын кеше тавышы белән җырлаганын абайлап алгандай, Ф. Әмирхан, шушы ике хикәя белән чикләнеп, үз темасына кайта, үз материалын эшкәртә, электән килә торган иҗат планнарын тормышка ашыра башлый.

## 2

1914 елның күпмедер өлеше Ф. Әмирханның тагын бер шедевры — «Тигезсезләр» драмасын язуга киткән. Ел ахырында, эш тәмам булып, соңгы нокта куелган. Күп тә узмый, пьеса, кульъязма хәлендә үк цензура аша үтеп (Казан аргуслары, күрәсең, бәйләнерлек нәрсә тапмаганнар), «Сәйяр» труппасы кулына барып керә. Алалар, укыйлар, рольләрне бүлешеп репетиция ясыйлар да 1915 ел-

ның 9 февралендә Новый клубта (хәзер ТДАТ бинасы) уйнап күрсәтәләр. Режиссеры Г. Кариев булып, Рокыя ролен Н. Таждарова, Сәлимәне Г. Болгарская башкарган. К. Тинчурин — язучы Сөләйман, Н. Сакаев — Закир ролендә чыкканнар.

И. Биккуловның газетадагы кыска информациясеннән күренгәнчә, зал шыгрым тулы булган. Тамашачылар уенны бүлдереп тә, пәрдә төшкәндә дә озаклап кул чапканнар. Хәбәрдә **шуннан** артыгы юк. Әсәрнең моннан соңгы постановкаларына язылган рецензияләрдән һәм соңрак Рокыя ролен башкарган Фатыйма Ильскаяның сөйләгәннәреннән этелеп китеп хыялны беркадәр эшләтсәк, премьераның финалын шактый дөрес итеп күз алдына китерә алырбыз.

Уен тәмам. Пәрдә ябыла. Тамашачылар урыннарыннан калкып дәррәү кул чаба башлыйлар. Пәрдә яңадан акрын гына ике якка шуып китә, артистлар сәхнәгә чыгып тезеләләр, рәхмәт белдереп баш ияләр. Алкышлау тагын да куәтләнә. «Мөхәррирне — сәхнәгә!» дигән тавышлар ишетелеп китә. Ул да булмый, залның бер ноктасына төбәлеп, артистлар үзләре кул чаба башлыйлар. 4—5 рәтләр турында коляскасында утырып тора торган Фатих Әмирханны котлыйлар икән. Пәрдә тагын ябылып ачыла. Берничә артист һәм артистка сәхнәдән автор янына төшәләр, котлыйлар, кулын кысалар. Аларга әдипнең залда утыручы дуслары, поклонник һәм поклонницалары кушыла. Аякка баскан зал ду килә, котырып кул чаба...

Спектакльнең уңышын ни белән аңлатырга? Пьеса яхшы, режиссеры да ни житте кеше түгел, башкаручылары да профессиональ татар театрының иң яхшы көчләре дип кенә узар идек тә, уйландыра торган нәрсәләр бар.

Пьесада тамашачы күреп күнеккән күкрәүле вакыйга да, кайсы иблисне, кайсы фәрештәне хәтерләтә торган геройлар да, атыш, үтерешләр, чәчне үрә торгызырлык драматик эффектлар да юк. Чәй эчәләр анда, тормыш хәлләре турында гәпләшәләр, вак-төяк мәзәкләр белән юаналар, гашыйк булалар, тойгыларына җавап тапмасалар да, муеннарына элмәк салырга керешмиләр. Драматизм булса да, ул күзгә бәрелеп тормый, кайдадыр эчтә, аста...

«Тигезсезләр» пьесасы А. П. Чехов драматургиясе рухында, Чехов стилендә язылган булып, «Акчарлак» пьесасын бик нык хәтерләтә. Икесендә дә, Чехов әйтмешли, «пот ярым» мәхәббәт. Икесендә дә танылган язучы яшь кызда мәхәббәт кабынуга сәбәпче була, бүтән персонажларның үзара мөнәсәбәтләренә, үзе дә сизмәстән, нindидер үзгә-

реш кертә. Кайбер бүтән охшаш ситуацияләр, охшаш характерлар да бар.

«Акчарлак»ның сәхнә гомере триумф белән башланмаган иде. Петербургның Александринский театрындагы премьерасын тамашачы, йомшатыбрак әйткәндә, салкын кабул итте. Моннан соң да күп кенә театрлар бу «каты чикләвек»не вата алмыйча тешләрен сындырдылар. Бүтәнчә була да алмый. Чехов — рус классик драматургиясендә яңа стадия, яңа баскыч. Аны сәхнәләштерү өчен, әйтик, Островский театры чаралары һәм алымнары инде ярап җитми. Чеховка бүтәнчә якын килергә, сәхнәне бүтәнчә корырга, геройларны бүтәнчә уйнарга кирәк иде. МХАТ кына, тиешле ачкыч табып, пьесаның фикер байлыгын һәм сәнгатьчә матурлыгын ачып бирә алды.

Ф. Әмирхан да «Тигезсезләр»е белән татар драматургиясендә яңа этапны башлап җибәрде дисәк, шаять ялгышмабыз. Әгәр Г. Камал якынча А. Н. Островский принципларын тормышка ашырган булса, Әмирхан драматургияне Чехов стадиясенә күтәрде.

Инде уйлап карыйк: үз-үзебезне ничаклы көчләсәк тә, режиссер, «Тигезсезләр» пьесасының үзенчәлеген тиз аңлап, тиешле ачкыч тапкандыр, артистлар, башкару манераларын тамырыннан үзгәртеп, яңача уйнаганнардыр дип әйтә алмабыз. Шулай да көтелмәгән уңыш...

Халыкның агылып килүе аңлашыла: пьесаның авторы— Фатих Әмирхан. Тамашачыларның составы да премьераның уңышына хезмәт итми калмаган. «Оят, яки күз яше» һәм «Ачлык кушты» кебек пьесалардан тәм табучы публика күпме булгандыр, әмма күпчелекне тәшкил итүчеләр — күзе ачылган приказчик һәм конторщиклар, мөгаллим, мөгаллимә һәм шәкертләр, тәрәкъкый пәрвәр купец һәм сәүдәгәрләрдән кала, журналист һәм язучылар, студент һәм курсисткалар, гимназист һәм гимназисткалар, татарның аз санлы булса да чиновниклары һәм белгечләре — учитель, юрист, врачлар.

Шулай да төп сәбәп — драманың үз вакытында язылып, нәкъ үз вакытында сәхнәдән күрсәтелүе. Сүзнең нәрсә турында барганы соңрак аңлашылыр, хәзер исә әсәрнең үз эченә кереп китик.

«Уртача тормышлы» һәм «искерәк модада европача киенә торган» мануфактура сәүдәгәре Сафый Насыйбуллинның улы Гомәр, атасыннан сума алып, оптика магазины ачкан һәм мөстәкыйль эш башлап җибәргән. Олы кызлары Сәлимә дүрт класстан имтихан бирергә әзерләнә. кечесе Рокыя гимназиядә укый.

Күбрәк экспозиция хезмәтен үтәгән беренче пәрдәдә әле вакыйга дип әйтерлек вакыйга юк. Драматург кайбер геройларының уй-фикер, әмәл-омтылышлары белән генә таныштыра. Менә карт һәм яшь Насыйбуллиннар сәүдә ысуллары турында бәхәсләшәләр. Сафый, яңа дип мөкиббән китмичә, сыналган иске ысулларга таяну ягында. Гомәр исә заман кушканча эш итмичә һәм тәвәккәллеккә бармыйча рус һәм яһүд коммерсантларын куып җитеп булмый дип ышана.

Бу пәрдәдә без тагын апалы-сеңелле ике кызның берберсен бик үк өнәп бетермәгәннәре, җиңешүләре, араларында кечкентәй «тигезсезлек» яшәгәнлеге белән танышабыз. Ана белән Гомәр Рокыяга яратып, сокланып карыйлар, һәр теләген үтәргә әзер торалар, Сәлимәдән исә күбрәк эш таләп итәләр.

Икенче пәрдә белән беренче пәрдә арасында ике ел вакыт үткән. Сафый инде вафат, фирма тулысы белән Гомәр җилкәсенә күчкән.

Насыйбулиннар дачасы. Сезонның әле башы гына. Сәлимә, алданрак килеп, өйне рәткә керткән. Рокыяның бүген соңгы имтиханын биреп гимназия тәмамлавы уңае белән кунаклар буласы икән. Насыйбуллиннарның яхшы танышы, атаклы язучы Сөләйман да киләчәк, ди. Террасасы гына күренеп тора торган күрше дачадан Мәскәү университеты студенты, касимлы Габдулла бүлмә алган. Сәлимә белән инде танышып өлгергәннәр. Бер-берсенә карата җылы хис туган. Кызда бу хис мәхәббәткә әверелеп бара.

Менә, әнисе белән берлектә, Рокыя килеп төшә. Тагын да матурайган, өлгереп, пешеп җиткән. Куанычыннан бер урында тора алмый. Сөләйманның киләчәген дә ишеткәч, бөтенләй балкып китә.

Рокыяны котларга дип берәм-берәм яшьләр килә башлый. Менә начар укуы сәбәпле коммерческое училищедан чыгарылган яшь купец Галиев. Менә яратмаган кешесенә кияүгә чыгып, беренче мәхәббәтен сагынып яшәүче Гөлчирә ханым. Менә бишкә төрләндереп сөйли торган тел бистәсе Закир.

Озакламый Гомәр Сөләйманны алып килә. Үзара танышу, чәй эчү башлана. Рокыя мәһабәт кыяфәтле чибәр әдиптән күзен ала алмаган кебек, Сөләйман да Рокыяга карап соклана, нечкә һәм нәфис комплиментларын җибәрә башлый.

Чәйдән соң бер инцидент булып ала. Рокыяның матурлыгыннан күзләре чагылып, Сәлимәне күрми башлаган

Габдулла, рус һәм татар сүзләрен буташтыра-буташтыра, әдәбият турында сүз башлый да Рокыяга сорау бирә: рус язучыларынмы, татар язучыларынмы күбрәк яратасыз? Гаҗәп сорау, ди кыз, берсен бер төрле, икенчесен икенче төрле яратам. Сүз артыннан сүз чыгып, Габдулла әйтеп ташлый: «Татарның хәзерге эшләре барысы да вакытлы бизәк шикелле эшләр генә: мәктәпләре дә, литературасы да — барысы да бервакыт хлам булып кына калырлар». Рокыя моны үткәреп җибәрә алмый, тупас итеп җавап бирә: «Сез ялганлыйсыз! Ул дөрес түгел! Ул, бәлки, сезнең күрми торган күзләрегезгә генә шулай күренә торгандыр».

Шушы бәрелештән соң Сөләйман белән Рокыя арасында түбәндәге сөйләшү була:

«Сөләйман *(Рокыяга)*. Юкка ул кадәр кәефеңне бозгансың, Рокыя. Фонвизинның Иванушкасы бервакыт рус мәдәнияте, рус милләте тугрысында шундый түбән фикердә булган бит. Аңар карап рус мәдәнияте үсүдән, рус милләте ныгудан туктаганмыни? Без хәзер рус милләте шул вакытларда уздырган хәлне уздырабыз: бездә дә шундый Иванушка-Абдулкалар була икән, аларга кәеф китүдән бигрәк, алардан көләргә, хәтта аларны шундый көлке булганлыклары өчен кызганырга кирәк!

Рокыя *(ачылып китеп, җанланып)*. Шулай бит, Сөләйман абзый, чынлап та шулай бит! Иванушкалар, Иванушка-Абдулкалар! *(Сонгый* көлеш белән көлә.)*

Сөләйман. Коллар... коллык психологиясе!.. Барин шәп... һәммә нәрсә баринныкы гына яхшы!..

Рокыя. Бу Иванушка-Абдулкага минем торып-торып ачуым килә.

Сөләйман. Тынычлан, Рокыя, ник юк нәрсәгә ачу килергә? Иванушка-Абдулкалар теләсәләр ничек уйласыннар, әмма мең еллык тарихы булган, башкаларныкыннан бер дә калышмаслык кабилияте булган, тырышып саклап килгән дине вә гадәтләре булган, үзенең язуы, әдәбияты, җыры, көе булган, гасырлар буенча мәктәп вә мәдрәсәләре булган бер милләтнең бернәрсәсе дә бервакытта да чүпкә чыкмый, чыга алмый! Чөнки аны чыгару Иванушка-Абдулкалар кулыннан килә торган эш түгел.

Рокыя *(Сөләйманның кулына тотыныр дәрәҗәгә җитеп., аңар карап.)* Шулай бит, Сөләйман абзый! Шулай бит!»

---

* Сонгый — ясалма.

Шушы урында чак кына тукталып торыйк та спектакльнең уңышы мәсьәләсенә кайтыйк. Премьера вакытында гөрләп кабынган алкышларның берсе Сөләйманның әнә шул кечкенә монологыннан соң булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. Хәер, матбугатта да моны раслаучы мәгълүмат бар.

1915 елның 30 июлендә В. Мортазин-Иманский һәм аның хатыны М. Иманская җитәкчелегендә Оренбург һәвәскәрләре «Тигезсезләр»не уйнаганнар. «Карт мөхәррир ролендә чыккан Мортазин-Иманскийны,— диелә рецензиядә,— икенче пәрдәдә татарлар арасында милли әдәбият вә милли матбугатка нәфрәт белән карый торган бер кыйсем милли хәяттан мәхрүм яшьләр, «Иванушка-Абдулка»ларның бетәргә тиешлеге вә бетәчәкләре хакындагы нотык уртасында бүлдереп, бик нык алкышладылар».

Милли мәсьәлә тагын да кискенрәк рәвеш алып, милли хис-тойгылар аның саен куера барган бер вакытта, милли җирлектән аерылмаган хәлдә, рус-Европа мәдәниятенә әшнә булган гүзәл Рокыя яисә акыллы һәм нәзакәтле Сөләйманның милли патриотизм идеяләрен гади һәм ачык итеп әйтеп бирүләре тамашачыларның күңеленә, билгеле, хуш килми калмаган.

Икенче һәм соңгы, өченче, пәрдәләр арасында тагын ике ай вакыт үтеп киткән.

Рокыя Сөләйманга чын-чыннан гашыйк. Эчендәге — тышында. Әдип Гөлчиһрә белән аралаша башлагач, көнләшүен туп-туры әйтеп бирә. Сөләйман да кызның тылсым көченнән котыла алмый, эшнең тирәнгә китүеннән куркып, күңелендәге сиздермәскә тырышса да, яратканын әйтеп ташлый.

Габдулланың да яратуы арта бара. Кызның салкынлыгына гаҗиз булып, озын итеп хат яза, җавап көтә, янакөя. Габдулладан суына алмаган Сәлимә исә, студентның аны бар дип тә белмичә Рокыя мәхәббәтен яуларга тырышуын күреп, тамуг газаплары кичерә.

Менә Габдулла, апа белән сеңел үзара аңлашып торганда, йөреп килергә чакыра. Нияте—Рокыяны аерып алып, тагын бер кат йөрәген ачып күрсәтү. Кызлар (Сәлимә икеләнебрәк, Рокыя катгый рәвештә) баш тарталар. Шул вакыт Сөләйманның «Рокыя!» дигән тавышы ишетелә һәм Рокыя баш-ала шул якка ташлана. Габдулла, Сәлимә белән ялгыз калмас өчен, тиз-тиз китеп бара.

«С ә л и м ә. Я алла, ник болай тигезсез иттең бәндәләреңне! *(Гасаби һәм тотнаксыз рәвештә җылап җибәрә.)*»

Пьеса әнә шул сүзләр белән тәмам була.

Ф. Сәйфи-Казанлы «Тигезсезләр» пьесасын «Ялтыравыклы ялган» исемле мәкаләсендә («Тормыш» газетасы, 1916 ел) Рокыя табигый, реаль тип түгел ди, «аңар татарларның тарихи кысрык, күңелсез тормышы тузан кадәр дә тәэсир итмәгән», ул «хәятны әдәбиятта матурлар өчен уйланган, мөхәррирнең ясалмасы» гына, ди.

Шул ук «Тормыш» газетасында Х. Искәндәрев Ф. Сәйфигә каршы чыга. Рокыя, ди ул, реаль тип. Аңа хас гамьсез сафлык, нәфислек, сөя-ярата белү кебек сыйфатлар кызларның табигатендә яшеренеп ята. Боларның калкып чыгуы өчен азатлык кына кирәк. Рокыя нәкъ менә кара көч басымыннан азат булган гаиләдә туып үскән. «Тигезсезләр» мәркәз шәһәрләрнең дә алдынгы сыйныф татарлары даирәсен күздә тотып язылган бер әсәр булганлыктан, аны интикад * иткәндә «Чураман» авылына карап торырга ярамый».

Үз заманында «Тигезсезләр»гә карата әдәби тәнкыйтьтә, шулай итеп, капма-каршы ике фикер барлыкка килде. Революциядән соң, бигрәк тә 20 елларның икенче яртысында һәм 30 елларда беренчесе өстенлек алып һәм тагын да тирәнәя барып, әсәр бөтенләй тискәре бәяләнә башлады. «Тигезсезләр»,— дип язды шул ук Ф. Сәйфи-Казанлы,— бөтенләе белән буржуа сыйныфын идеаллаштыру өчен язылган агитка». Бу әсәр,— диде Г. Толымбай,— «...сәүдәгәрлекне һәм динне мактауга, эротикага өндәүгә корылган». Мондый хөкем, беркадәр йомшара барып, илленче елларның ахырына кадәр дәвам итте.

Ачындыра һәм уйландыра торган нәрсә булмаса, әдәбият белеменең «Тигезсезләр»не бүген башкача бәяләгәнен истә тотып, үткәндәге хаталарны казып маташмас идек.

Драманың сәхнә гомере, матур башланып, матур дәвам иткән иде югыйсә... Казанда сезон саен берничә мәртәбә куелуы өстенә, төрле шәһәрләрдә профессиональ һәм һәвәскәр труппалар тарафыннан күп мәртәбә уйнала килдекилде дә 1920 елның августында Уфада күрсәтелгән постановкасы белән сәхнә гомере өзелеп калды. Шушы көнгә кадәр бер генә режиссерның да әсәрне тергезергә омтылып караганы юк. Театр җитәкчеләрен һәм режиссерларны, бәлки, 20—30 еллардан килә торган өрәк куркытадыр? Әгәр шулай булса — юкка.

«Буржуа сыйныфын идеаллаштыру» мәсьәләсеннән башлыйк.

---

* Интикад — тәнкы

Әсәрдә либераль буржуазия вәкилләре итеп санарлык өч персонаж бар: Сафый, Гомәр һәм атасыннан зур гына мирас алып калган Галиев. Фикер дәрәҗәсе һәм культурасы чамалы булган соңгысын хәзер үк читкә атыйк. Искелектән аерылып җитмәгән Сафый карт та мисал булып хезмәт итә алмас. Кала — Гомәр. Ул инде чынлап та татар либераль буржуазиясенең алдынгы вәкиле, аның «каймагы». Әгәр драматург уңай шәхесләрдә табыла торган матур сыйфатларны тагын да үстерә төшеп Гомәргә туплаган булса, бу персонажны идеаллаштырылган образ итеп караудан бүтән чара калмас иде.

Гомәр интеллигенция вәкилләре белән дә аралаша, сүзләрен, бәхәсләрен ишетә. Әмма ул ничектер һаман читтә, күләгәдә, тыңлаучы ролендә кала килә. Дөрес, бер тапкыр аны да бәхәскә тарталар. Сүз Рокыяның нинди юл сайларга тиешлеге турында бара. Кыз художник булырга тели, Гомәр юристлыкка укырга димли. Фикерен ул менә ничек дәлилли: «...художество мәктәбеннән чыгып, бездә бер кисәк икмәк тә табар хәл юк. Әмма юрист һәрвакыт үз-үзен туендыра ала». «Корсак» фәлсәфәсе, мещанлык фикер йөртеше дип кенә узар идек тә, мондый сорау туа: ни өчен Гомәр сеңлесен, әйтик, доктор булырга кыстамый? Врач кеше дә үзенә икмәк таба ала ич. Монда ул, күрәсең, үзе хисап бирепме, юкмы, коммерциясен кайгырта. Врач — врач инде, акчаңны түлисең дә дәваланасың. Туганың юрист булса — бөтенләй башка. Гомәр боларны ишеттереп әйтә алмый, билгеле, әмма түбәндәге сүзләрне ычкындырып ташлый: «...яхшы юрист һәрбер эшнең башында тора ала, теләсә нинди эштә ул файдалы була ала!»

Милләтне ярату һәм милли эшләргә булышлык итү ягыннан да Гомәр аерылып тормый. Дөрес, магазинына өйрәнчек алганда милләт мәнфәгатен күздә тоткандай итә: татар малае булсын иде, ди. Әмма шуңа ялгап ук ул «хәзергә әле эш белми торган кешегә жалованьены күп бирә алмыйм» дип кисәтеп куя, элекке урында алган эш хакының яртысын гына бирәчәген белдерә.

Мондый эпизод та кызыклы. Сөләйман оптика магазинын юлга салуы өчен Гомәрне мактагандай итә дә болай ди: «Ләкин әле Казаныгызның зыялыларыннан берәү яшь сәүдәгәрләрдән шактый зарланып утырды, һимматсезләр, сәүдәләренә бикләнәләр дә гомуми эшләрнең һәммәсеннән качалар, гомуми эшләргә беркадәр акча сарыф итәргә туры килә башласа, акчаларын берәр тиенләп саныйлар, башка эшләрдә аталары гадәтләреннән читкә чыга алсалар да, бу тугрыларда аталары белән аермалары телләре белән

киемнәрендә генә кала», ди. Үткер почмакларны болай да шомартырга ярата торган Сөләйман, кунак кеше дә булгач, туры бәреп әйтә алмый, әлбәттә. Уйлап-нитеп тормый торган Закир исә Гомәргә төртеп күрсәтә дә кычкырып җибәрә: «Хак, хак, хак, Сөләйман әфәнде! Бу каһәр сукырлары һәммәсе шулай».

Яки менә ялган сөйли белми торган Рокыя абыйсы турында ни ди: «И, таптыгыз да шәп кеше! Безнең абый андый мәҗлес өчен бер дә кул кеше түгел. Иң әүвәл, сәгать унике тула башласа, аның күзләре йомыла башлый: икенче, андый нәрсәләрдән кызык та тапмый төсле ул, сәүдә дип җенләнгән бер кеше инде ул шунда...»

Гомәрне идеаллаштыру бер якта торсын, аңа карата хәтта эчкә яшерелгән тәнкыйть сизелә! Либераль буржуазиянең «каймагы»на шундый мөнәсәбәт икән, бу социаль катлауны идеаллаштыру турында сүз була аламы? Әлбәттә, юк.

Иделлаштыруга бәлки Рокыя мисал була алыр? Әсәрдәге ир-егетләрнең барысы да бу кызга гашыйк булган кебек, автор үзе дә аңа соклана. Матур ул, саф, дәртле, сәләтле һәм туры сүзле. Беркатлылык белән кушылган аек акыл һәм романтик ашкынлык та бар аңарда. Хәтта кимчелекләре — чытлыклана белүе, иренчәклеге һәм җыйнаксызлыгы да ничектер килешеп тора. Кыскасы, Рокыяга тоташ көмештән коелгандай бөтенлек хас.

Дворян һәм буржуа хатын-кызларының дистәләгән соклангыч образларын без Пушкин һәм Толстойдан, Тургенев һәм Гончаровтан яисә Островский һәм Чеховтан да табабыз. Болар сафлыклары белән генә түгел, бәлки характер ныклыгы, кайбер очракта хәтта иҗтимагый активлык ягыннан да ирләрдән өстен торалар. Идеаллаштыру түгел бу, монда тормыш чынлыгы: ирләр, карьера һәм табыш артыннан куарга мәҗбүр булып вакланса лар, ныклык һәм бөтенлекләрен югалтсалар, хатын-кызлар, андый практикадан читтәрәк торганга күрә, кешелек сыйфатларын һәм бөтенлекләрен күбрәк саклый алганнар.

Рокыя турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Бала чагы һәм үсмер еллары «европача» яши торган купец гаиләсендә узган. Гимназиядә тормыш, яшәеш турындагы купшы фикерләрне күңеленә сеңдергән, рус әдәбиятыннан мәгънәви азык алган. Гаилә һәм гимназиядән тыштагы дөнья аңа әле ал да гөл булып күренә. Шуңа күрә Рокыя хәзергә әле саф, намуслы һәм бербөтен булып кала.

Ф. Әмирханны сәүдәгәрлек һәм динне мактауда, эротикага өндәүдә гаепләүләр дә идеаллаштыру хакындагы



Әмирхановлар гаиләсе (уңнан): утыралар Рабига апа, Сәгадәт кызы Разия, Сәгадәт; басканнар Фатих һәм Ибраһим. 1906 ел.



«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасы



Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай



Фатих Әмирхан. 1915 ел.

фикер белән берлектә авып төшәләр. Дөрес, намаз уку кебек йолаларга Сөләйман, үзе әйтмешли, көлеп караса да, дингә гомумән каршы түгел. Әмма Ф. Әмирхан үзе дә — хәтта «Әльислах» чорында — бүтән демократ язучылар кебек үк дингә әхлак төзәтү чарасы итеп карый иде. Тәнкыйтьчеләрнең «Тигезсезләр» драмасында эротика күрүләренә килсәк, әллә болар бу сүзнең мәгънәсен белмәделәр микән дип уйларга гына кала.

Әсәр нәрсә турында соң? Пьеса милли нигилизм чире белән авырый торган Иванушка-Абдулкалардан көлү яисә Сөләйманнан милләт һәм милли мәдәният турында купшы монологлар сөйләтү өчен генә язылмаган, билгеле. Исеменә игътибар итик. Кемнәр алар тигезсезләр, нинди тигезсезлек турында сүз бара? Иң әүвәл, Сафый байның ике кызы арасындагы тигезсезлек: табигать һәм җәмгыять Сәлимәгә карата саранлык күрсәткән. Аның матурлыгы да ниндидер салкын, үзенә бик үк җәлеп итми торган матурлык. Шуннан килеп чыга мәхәббәттә тигезсезлек. Икенчедән, Сөләйман белән Рокыя арасындагы тигезсезлек. Берберсен яраталар, ләкин араларында — яшь аермасы.

«Тигезсезләр» драмасының үзәгендә, димәк, кеше бәхете, кеше язмышы мәсьәләсе. Башлыча ул мораль-психологик планда хәл ителә. Әмма, күзгә бик үк бәрелеп тормаса да, социаль сәбәпләрне дә чамаларга мөмкин. Чөнки әсәрдә сүз гомумән кеше бәхете хакында түгел, бәлки буржуаз җәмгыять шартларындагы кеше бәхете турында бара.

Сәлимә, мәсәлән, ни өчен үзен бәхетсез хис итә? Унтугыз яшенә җитеп, ул гимназиянең дүрт классыннан гына имтихан биреп йөри. «Синең белән безнең заманнар башкачарак иде», ди Гомәр. Икенче пәрдәдә инде Сәлимәне без абыйсының магазинында кассир итеп күрәбез. Габдулланың илтифатсызлыгыннан гаҗиз булып, ул яратмаган кешесенә — бай малае Гайсага кияүгә чыгарга җыена. Киләчәгенең ничек буласын Гөлчиһрә язмышыннан чамаларга мөмкин.

Рокыя карап торышка бәхетле, аның киләчәге матур булыр төсле. Ләкин Рокыяның да хыял дөньясыннан реаль чынбарлыкка атлыйсы бар. Хәзер үк инде ул чынбарлык белән конфликтка керә башлаган. Рокыя үзенә тиң булырдай кеше, бербөтен кеше эзли, тик таба алмый. Аңа таныш егетләрнең барысы да ничектер төссез-чырайсызлар, кечкенә һәм вак җанлылар. Җилбәзәк Зәкир белән Галиев кенә түгел, студент Габдулла да шундый. Абыйсы Гомәр дә болардан күп ерак китмәгән булгач, Сәлимәне ала-

чак Гайса да, таныш булмаган бүтән егетләр дә шундыйдыр...

Рокыяның игътибарын җәлеп итәрлек бердәнбер кеше — Сөләйман. Ләкин, беренчедән, яшь ягыннан ул Рокыяга әти булырлык, икенчедән, күп кенә матур сыйфатларга ия булуына карамастан, идеал ныклыгы җитенкерәмәүдән аңарда күңел бушлыгы сизелә. Бай гаиләләрдә матур поза күрсәтү, тормыштан туйган кеше кыяфәтенә керү, яшь кызлар һәм ханымнар белән җиңелчә флирт — болар, күрәсең, беркадәр шул бушлыкны тутыру өчен.

Акыллы һәм тәҗрибәле Сөләйман Рокыяга өйләнү кебек тәвәккәллеккә бармас. Чөнки ул кызның ярты-йорты белән канәгатьләнми торган таләпчәнлеген, яраткан кешесен бик тиз танып алып, аннан бизү ихтималын яхшы аңлый. Рокыяны беркадәр «суытырга» теләп, Сөләйман болай ди: «Син минем үзеңне сөйгәнемне белмә, мин синең минем чал чәчләремне дә гафу итәргә хәзер икәнеңне белмим. Шуларны белешкән минуттан безнең икебезгә дә җәһәннәм булыр. Мин сине, Рокыя, шул минуттан чәчләренә чал кермәгән бөтен кешеләрдән көнләшә башлармын, мин сине газаплармын, үзем синнән артык газапланырмын!»

Күренә ки, Рокыяның дөньяга ачык күз белән каравы, чылтырап чыга торган саф көлүе, күбәләктәй очынып йөрүләре озакка түгел. Буржуаз чынбарлык аны да гарип итеп ташлаячак. Рокыя да, «аек карашлы» абыйсының киңәшен тотып, күп дигәндә юрист булыр. Апасы әйтмешли, «И нишләп ялганлап торыйм соң» дип, бер эшен оттырыр, икенчесен... «Ялганларга» өйрәнә алмаса, бу эшеннән бизеп, икенчегә ябышыр, анысыннан да күңеле кайтыр. Кияүгә чыгуы да гадәтчә булыр. Икенче бер «Гайса»га тап булып, тук, ләкин кызыксыз яшәү белән яши башлар. Мондый тормыш белән килешергә теләмичә «бунт» күтәрсә, язмышы һәлакәт белән очланыр.

Буржуаз җәмгыятьтә матурның, сафның, бәхет идеалының язмышы әнә шундый. «Тигезсезләр»дә Ф. Әмирхан кешенең табигый хыяллары белән реаль чынбарлык арасындагы каршылыкны күрсәтеп бирде һәм объектив рәвештә капиталистик мөнәсәбәтләр хакимлек иткән җәмгыятьтә чын кешелек бәхетенә урын юк дигән хакыйкатьне раслады.

Пьесаның нинди гаилә тормышыннан алып язылганлыгы, катнашучыларының прототиплары турында мәгълүмат табылмады. Тик шуны гына әйтергә кирәк: Рокыя кебек типларны да уйлап чыгарасы юк, алар тормышның үзендә бар. «Төрек хатыннары» исемле мәкаләсендә Ф. Әмирхан

менә нәрсә дип яза: «Безнең хатын-кызларымыз кирәк укуда (хәзер бездә профессорлыкка хәзерләнер өчен мәкатиб галия * хозурында калдырылган кызларга хәтле бар), кирәк эштә (бик иҗтиһат белән мәктәп алып бара торган мөгаллимәләремез), кирәк милли гайрәттә (Балкан сугышында мөшарәкәт ** иткән студенткаларымыз) ирләремездән калышмаска гына түгел, аларны узарга гайрәт итә башладылар».

Урта һәм югары мәктәптә укый торган яисә тәмамлап эшкә керешкән кызлар һәм ханымнарның күбесе белән Фатих таныш. Аралаша, сөйләшә, күзәтә. Арада Гөлсем Апакова һәм Зәйнәп Әмирханова кебек кан кардәшләре булганлыгы турында да әйтелгән иде.

Гөлсем туташның вакытсыз үлеп китүе уңае белән язылып, Ф. Әмирхан имзасы куелган мәкаләдән күренгәнчә, уртача тормышлы сәүдәгәр гаиләсендә туган бу кыз башта Казанның иң алдынгы кызлар мәктәбендә татарча гыйлем алган, аннары хосусый рәвештә әзерләнеп гимназиягә кергән, гадәттән тыш хезмәт куеп, классташ рус кызларын куып җиткән һәм, ахыр чиктә, гимназияне медальгә бетергән. Бер үк вакытта музыка мәктәбенә йөреп көткәннән артык уңыш казанган.

Зәйнәпнең бала чагы, үсмерлек һәм яшьлек еллары да Фатих күз алдында үтә. Татарча башлангыч белем алгач һәм әтисеннән гарәп теле өйрәнгәч, ул Чистай гимназиясендә укый башлый һәм 1914 елда, Казанга күчеп килеп, Ряхина гимназиясенең 8 нче классында укуын дәвам иттерә.

Гөлсем белән Зәйнәп, күренә ки, милли һәм рус-Европа тәрбиясе берлегенең гәүдәләнеше буларак, Ф. Әмирхан күрергә теләгән татар кызы типлары җөмләсенә керәләр. Рокыя образын иҗат иткәндә Әмирханның шушы сеңелләреннән дә файдаланганлыгына шикләнмәскә мөмкин.

Пьесада катнашучы бүтән персонажлар өчен кучермә булырдай шәхесләр дә Казанда бетәсе түгел.

Кыскасы, Рокыя татар тормышында ишәеп бара торган реаль типларның сәнгатьчә гәүдәләнеше булган кебек, «Тигезсезләр» драмасы чын мәгънәсендә реалистик әсәр.

---

* Мәкатиб галия — югары мәктәпләр.
** Мөшарәкәт — катнашу.

## 3

Сугыш дәвам итә. Аның комсыз киң тамагы шинель кигән эшче-крестьянны меңәрләп йота тора. Ятимнәр һәм толлар саны арта бара. Кыйммәтчелек үзен бик нык сиздерә башлый.

«Кояш», билгеле, шактый сак кыланып һәм битараф булырга тырышып фронт хәлләреннән хисап биреп килә, сугышка кагылышлы бүтән төр материаллар да урнаштыра тора. Әмма мондый язмалар ахырыннан без Фатих имзасын тапмыйбыз. Баш мәкалә булып басылганнарының да стиле аның язу рәвешенә охшамый. Сугыш һәм аның барышы әдипне бер дә борчымаганмы? Борчыган, әлбәттә, бик борчыган һәм уйландырган. Ләкин каты цензура шартларында әйтергә теләгәнне әйтеп булмый, цензорлар бәйләнмәслек итеп язсаң сугышны яклаучы исемен күтәрүең мөмкин. Эзоп бабай теле белән язылып, Фатих стилен хәтерләтә торган «Бер мөләхәзә» (1915 ел, 8 ноябрь) исемле баш мәкалә дә бу раслауны юкка чыгармый. Социал-демократ һәм трудовиклардан кала барлык партияләр, ди автор, сугышны яклыйлар. Уңнар ачыктан-ачык әйтәләр: җиңгәнчегә кадәр сугышырга! Болар белән вактөяктә әрепләшә торган партияләр исә шул ук фикерне томанга өртебрәк әйтәләр. Мәкалә авторы, башын җүләргә салып болай ди: сугышыргамы, сугышмаскамы дип юкны лыгырдыйлар. Патша үзе башкомандующий ич. Ул сугышырга кирәк ди икән, тагын нинди сүз булырга мөмкин.

1915—1916 елларда милләтнең эчке эшләре турында исә Ф. Әмирхан күп язды, яхшы язды. Әмма болары да «эчке эшләр» генә булып калмый, тегеләйме, болаймы Россиянең иҗтимагый-политик хәленә барып тоташа, еш кына самодержавиенең милли-колониаль политикасын гаепләү, хөкүмәтнең реакцион табигатен фаш итү югарылыгына күтәрелә.

1915 елның җәендә үлгән мөфти урынына яңа мөфти сайлау мәсьәләсе көн тәртибенә басты, матбугат ике ай буе шул турыда шаулый.

Үзенең бер мәкаләсендә Фатих диния нәзараты һәм мөфтинең моңарчы милләткә файдасы аз булды, моннан соң да файда китерәчәгенә өмет аз дип чыккан иде инде. Мөфтине, мөселманнарның теләген искә алмыйча, хөкүмәтнең билгеләп куюын ул милли изү һәм кысуның бер чагылышы итеп күргән иде.

Менә «Кояш»ның 26 июнь санында «Мөфтилек мәсьәләсе вә кандидатлар» исемле мәкалә басылып чыга. Бу

мәсьәләдә, ди Ф. Әмирхан, ике фикер күзгә ташлана: пессимистлар һәм оптимистлар фикере. Беренчеләре әйтә: бездән сорап тормаслар, хөкүмәт диния нәзараты казые Капкаевны яисә Петербург ахуны Сафа Баязитовны тотар да куяр. Юк инде, диләр икенчеләре, хәзер замана үзгәрде, мөселманнар сугышта кан түгәләр, тылда да сугыш хакына җәфа чигәләр, хөкүмәт алар фикерен исәпкә алмый калмас. Ф. Әмирхан, соңгыларга кушылып, баюдан бүтән ихласы булмаган Капкаевны яисә исемен пычраткан Баязитовны хәтта хөкүмәт үзе дә мөфти итәргә базмас дигән өмет белдерә.

Мөфти сайлау кампаниясе кыза бара. «Дин вә мәгыйшәт» тарафдарлары тырышлыгы белән чыннан да С. Баязитов кандидатурасы калкып чыга. Алтынбаев, Өметбаев һәм башкаларның исемнәре телгә алына. Кандидатлар үзләре дә тик ятмыйлар, мөфти чапанын кию өчен чара күрә башлыйлар. Камил Мотыйгый, барысыннан да уздырып, «Вакыт» газетасында «Мин мөфти булырга тиеш!» дигән мәкалә белән чыга. Мин, ди, мөфәссирмен (тәфсир язучы), мөхәддисмен (хәдисләр белгече), каримын, хафизмын, имам, хатип һәм мөдәррисмен. Асыл сыйфат һәм башкарган эшләреннән тагын берсе шул: Тукайны ул Тукай итеп үстергән. Шагыйрь унике ел буе, күрәмсең, аның тәрбиясендә булган, аңардан сабак укыган, янә бик күп нәрсәләр «үгрәнгән».

Болар белән генә чикләнмичә Камил абзагыз фоторәсемен юллый һәм мәкаләсенә түбәндәге сүзләрне кертеп җибәрә; «Кыяфәт һәм килбәт, ягъни «поза» җәһәтләрендә дә һичбер мәһабәтле вә шәүкәтле лорд һәм барон вә гайре адәмнәрдән мин асла ким түгелмен».

К. Мотыйгый бәлки мәзәк корадыр, мәкаләсе бәлки мөфти сайлау кампаниясенә пародиядер? Юк шул, юмор тойгысы чамалы һәм җиңел сөякле, җиңел табигатьле Мотыйгый җитди сурәттә үзен мөфтилеккә тәкъдим итә. Мыскыллы һәм ачы сүзләр ишетә башлагач, Ф. Әмирханга зарын хат язып сөйләргә һәм ярдәм сорарга карар итә. «Тормыш» газетасы, күрәмсең, аны «бик изеп» чыккан. Әгәр ул хәер хаһлык күрсәтүче газета булса, К. Мотыйгый җырчы һәм артист чагында да дин һәм милләткә шул кадәр күп файда иткәнне, мөфти булса тагын да зуррак эшләр башкарыр дип язарга тиеш иде. Хат мондый сүзләр белән тәмам була: «...сездән ошбу шәйләрне мөлахәзә * идәрәк, ошбу хакта җитди бер мәкалә язуыңызны үтенәм».

---

* Мөлахәзә — фикер йөртү.

Бу хат Фатих кулына кергәндә, андый мәкалә инде язылган була һәм ике көннән соң «Кояш»та басылып та чыга.

«Мәдәни ганганәсезлек * хурлыгы» исемле бу мәкаләсендә Ф. Әмирхан мәсьәләне киңрәк алып, киңрәк итеп куйган. Бездә, ди ул, культура түбән, мәдәни традиция юк, шуңа күрә нәфесебез мөмкинлегебезгә туры килми. Әнә Истамбулда укып төрекчә белми кайткан, сигез ел буе аттестатка әзерләнеп тә русчаны вата-сындыра сөйли торган байбәтчә шәһәр думасында гласный булмакчы. Әнә Бохара, Төркестан, Һиндстан якларында киләп сарып йөргән бер авантюрист университет ачам, шуның ректоры булам дип шапырына. Әнә бер мишәр егете барлык Европа илләренең экономик хәлен тамырыннан яхшырту өчен доход чыганагы табып бирергә вәгъдә итә.

Инде менә мөфтилеккә дәгъва итүчеләр күбәеп китте. «Вакыт» газетасы, җитди мәсьәләгә мәзәк төс бирергә теләгәндәй, К. Мотыйгыйның мәкаләсен басып чыгара. Җәмәгатьчелек бот чабып көлде көлүен, ләкин, ди Фатих, аңа гына хас нечкә ирониягә күчеп, мин бүтәнрәк фикердә торам: Камил әфәнденең (үзе дә сизмәстән, клоун хәлендә калса да) мөфти булырга хакы Баязитовныкыннан бер дә ким түгел, чынлап карасаң хәтта артыграк...

Бу мәкалә басылып 3—4 көн үтүгә Петербургтан хәбәр килә: хөкүмәт мөфти итеп С. Баязитовны раслаган! Татарлар яши торган төбәкләрдән дәүләт Думасының мөселман фракциясенә адресланган протест телеграммалары һәм хатлар агыла башлый. Казаннан киткән телеграммада С. Алкин һәм Һ. Максуди исемнәре янында берничә таңчы һәм Ф. Әмирхан имзалары куелган кебек, булачак мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев имзасы да ярылып ята. Шул ук адреска җибәрелгән хат ахырында исә Г. Коләхметов исеме дә бар. Теге егетнең йодрыклары төшә башлагач, малайларның тагын бер татулашып алулары була бу.

1916 елда газеталар вакытлы татар матбугатына ун яшь тулу вакыйгасын билгеләп үткәндә дә үзара татулыкка чакыру авазлары ишетелми калмады. Бу яктан «Кояш» та аерылып тормый. Ләкин моны да иман алыштыру итеп карарга ярамый. Самодержавие һөҗүмгә күчеп, шовинизм котырган бер вакытта тактиканы гына үзгәртү бу. Башта золымнан котылып, милли азатлык яулап алыйк, анна-

---

* Ганганә — традиция.

ры... күз күрер. Хәзергә бергә барырга, бергә хәрәкәт итәргә, газета-журналлар бер тавыштан җырларга тиешләр.

Әмма Ф. Әмирхан һәм аның фикердәшләре ничаклы теләсәләр дә, берлек урнашып җитә алмый. Әле анда, әле монда әйткәләшү кабынып китә. Сәбәбе еш кына вак нәрсә була: укучыларның санын арттыру өчен җиңешү, материалларда ычкынган теге яки бу төгәлсезлек, бер-берсен аңлап җиткермәү, шәхси исәп-хисап. Ләкин, тулаем алганда, ара-тирә кычкырыш-талашка барып җиткән бәхәсләр милләтне тәшкил итә торган сыйныфлар һәм социаль катлаулар арасындагы каршылыкларның чагылышыннан бүтән нәрсә түгел.

Мөфти мәсьәләсе кызып киткәч, Фатих Кәрими җавап мәкаләсе белән чыга, Қ. Мотыйгый мәкаләсен басуда бернинди исәп-хисап юк, бу матбугат иреге хакына эшләнде, ди. «Вакыт»ка бәйләнүе Ф. Әмирханның сүз ирегеп, фикер ирегеп ригая итмәве турында гына сөйли, ди. Кече Фатихның җавабы тагын әзер: үз фикеремдә калам, «Вакыт»ның Мотыйгый мәкаләсен басуы кирәкмәгән мәзәкчелек, урынсыз клоунлык. 1907 елдан бирле ике Фатих арасында фикер көрәше дәвам итеп килгәнгә, «Яңгырлар ява... рәсемнәр ява» исемле кечкенә фельетонны да гадәти бер теш агарту дип кенә карый алмыйбыз. «Вакыт» газетасы «Дож» * сараеның рәсемен басканда «Дворец дожей» дигәнне «Яңгыр сарае» дип тәрҗемә иткән. Фельетонда Фатих әнә шуннан көлә. Яки менә газеталарның берсе, матбугат юбилее дип тормыйча, «Йолдыз»ны эштән чыгарып тәнкыйть итә: ныклы иманы юк, принципсыз, шәхси максаттан чыгып эш итә, килешсез чаралар куллана. Газеталар тагын бәхәскә тартылалар. Кайсы «Йолдыз»ны яклый, кайсы аның тәнкыйтьчесен хуплый. Безнең Фатих та читтә калмый, симпатиясенең «Йолдыз»ны тәнкыйть иткән газета ягында икәнен сиздереп, фикерен әйтеп чыга.

Юк, булмый, бердәм фронт оешып җитә алмый. Һәм гаҗәп тә түгел: ике башлы диюгә каршы көрәшнең экономик ягын тәэмин итәргә тиешле тәрәкъкый пәрвәр байлар хәзер милләт файдасына янчыкларын чишәргә бик үк ашыкмыйлар. Чөнки асларына су керә башлаганны сизәләр: сугыш китергән бәла-казадан ачулары кабарган эшче, солдат һәм крестьяннар патшаны төшерә-нитә калсалар, моның белән генә чикләнмичә, боларга да килеп ябышмагайлары. Шундый хәлгә төшмәс өчен хөкүмәт ягыннан

* Дож — урта гасырларда Венеция республикасының дәүләт башлыгы.

тору дөресрәк булмасмы? Бу уй, хис-тойгы буржуа идеологларына да йокмый кала алмый. С. Алкин — үзе зур бай. Ф. Кәрими яисә Һ. Максуди абзыйларның да күңеленә рабочий, солдат һәм авыл мужигына караганда Хөсәенов һәм Рәмиевләр, Галикәев һәм Әҗемовлар, Акчурин һәм Дибердиевләр якынрак.

Милли азатлык хакына самодержавиегә каршы көрәшүдә ахырга кадәр барырга сәләтле кем кала? Үз кул көче белән көн күрүчеләр һәм алар хакын хаклаган сул партияләр, билгеле. Әмма социал-демократларның большевиклар канаты милли бурычларга икенчел мәсьәлә итеп карый. Аларның эш-гамәле милләт эчендәге сыйнфый каршылыкларның кискенләшүенә генә алып бара. Демократлар япа-ялгыз калып баралар түгелме? Җитмәсә, аларның да бер өлеше, булмас ахры дип, иҗтимагый мәсьәләләргә кул селтәде дә богемачылыкка бирелде, декадентлык сазлыгына кереп батты.

4

1915 елда бөтенләй дип әйтерлек әдәби иҗат белән шөгыльләнмәгән Фатих 1916 елда бер-бер артлы дүрт-биш хикәя язып дөньяга чыгара. Милләт кайгырту белән мавыгып китеп, бар көчен публицистикага сарыф итү ялкыттымы, әллә милләт эчендәге хәл-әхвәлнең ул теләгәнчә хәрәкәт итмәвенә гаҗиз булып, хыял дөньясына китеп торасы килдеме, әллә инде көндәлек ыгы-зыгыга багышланган мәкалә һәм фельетоннар фани, чын әдәбият кына озын гомерле дип уйлый башладымы — ни булса бар, Фатих әдәбиятка кайта.

1916 елда дөнья күргән беренче әсәре — «Сүнгәч» исемле озын хикәя. Сюжеты гади: студент-медик Шакир Әсма исемле чибәр кызны сөя. Кыз да ике елга якын Шакирны якын итеп йөргән. Менә егет, авырып китеп, айдан артык больницада ята. Әсма башта җылы сирпеп, үзе генә утырып киткәләгән булса да, соңрак Шакирның курсташы Госман белән онытылганда бер кереп чыга башлый. Кызның суынуы түгелме бу? Больницадан чыккач та Шакир Әсманың Госман белән ачыктан-ачык чытлыклануын күрә. Кызның кадере, бәясе кимегәндәй була, һәм Шакир, үч итеп, Әсмага салкын йөз күрсәтә башлый. Ахыр чиктә, горурлыгы җиңеп, араларындагы җепне өзеп ташлый.

Карап торышка әллә нәрсәсе юк, гадәти мәхәббәт «өчпочмагы». Әмма әсәрдә мондый бер эпизод бар. Әсма сурәтен күңеленнән йолкып ташлагач барлыкка килгән буш-

лыкны ни беләндер тутырырга теләп, Шакир университетка китә һәм анатомичкада бер карчыкның 24—25 яшьлек егет гәүдәсе янында елап утырганын күрә.

«Қатле нәфесме? * — диде Шакир.

— Әйе, цианистый калий белән,— ди карчык». Бу җавап Шакирда мондый уйлар тудыра: «Бер йотым цианистый калий, менә һәммәсе дә бетте: өмет тә бетте, өметсезлек тә бетте; кайгылар да, шатлыклар да, шуларның һәммәсенең төбе булган тереклек үзе дә бетте...» Хәер, тән бар, рух бар. Кан йөрүе тукталу белән чери башлый торган тән әлегә рухны өреткән чүпрәк кенә бит. Цианистый калий тәнне җиңә алса да, рух алдында көчсез.

Хикәянең финалы да гаҗәеп мәгънәле.

Шакир трамвай вагонында Әсма белән бергә туры килә. Ике ел буе шушы трамвайда ул кызны күп мәртәбәләр озата барган иде. Хәзер исә ерак танышы белән сөйләшкәндәй салкын гына, өзек-өзек кенә сөйләшә, үз тукталышына җиткәч, тавышын тигез чыгарып коры гына: «Миңа төшәргә вакыт җитте. Сәламәт булыгыз, туташ»,— дип әйтә дә төшеп кала. «Бу эшнең,— ди автор,— бер дә уйлап вә тукталып тормыйча эшләнә алуы анда үз-үзеннән ризалык тойгысы тудырды. Ләкин бу тойгыда шигърият тә юк, рәхәт тә юк иде».

Безнең алда иҗтимагый идеаллардан ваз кичә башлаган вак буржуаз интеллигенциянең типик бер вәкиле. Таяныч ноктасы булып мәхәббәт кенә калган иде. Хәзер анысы да юкка чыкты. Менә ни өчен Шакирның «җиңүендә» шигърият тә, рәхәт тә юк.

Шул ук 1916 елда язылган «Яз исреклегендә» исемле әсәре Фатихның бу дәвердәге рухи хәл-әхвәленә туры килеп җитми кебек. Төп герое шулай ук студент, ләкин бәхетле студент. Менә ул майның матур бер көнендә, өчләп җигелгән йомшак рессорлы зур повозкага утырып, курсташ дустына кунакка бара. Аның күзенә бар нәрсә дә матур, көләч, барлык кешеләр дә бәхетле, үз-үзләреннән канәгать булып күренә.

Тик бер хикмәте бар: әсәр «яза башлап ташланган бер хикәядән» дигән искәрмә белән басылган. Димәк, бу язма — ниндидер әсәрнең тик башламы, әйтик, экспозициясе. Егетебез ниндидер шатлыклар, күңелле маҗаралар өмет итеп бара баруын. Ә менә кайтуы ничек булыр да вакыйгалар кая таба үсеп китәр?

---

* Қатле нәфес — үз-үзен үтерү.

Ф. Әмирханны без куәтле сатирик итеп тә күргән идек. Сугыш елларында ничек? Публицистикасына килгәндә, ул элекке Ташмөхәммәт дип әйтерлек. Шул ук ирония, сарказм, шундый ук тапкырлык. Қолу объекты гына үзгәрә төште. Аның каләм очына эләгүчеләр, иске сәүдәгәр һәм кире беткән муллалардан бигрәк, үзләрен эре тотып та ышанычны акламаган милләт хәдимнәре, әлеге либераль эшлеклеләр.

Бу елда Әмирханның ике сатирик әсәре — «Салихҗан кари» һәм «Сәмигулла абзый» исемле хикәяләре басылып чыга.

Беренчесендә без бер байдан бәдәл алып хаҗга барган һәм, озак вакытлар йөреп бөтенләй үзгәреп, «җәдитләнеп» кайткан хыялый фанатикның колоритлы образы белән очрашабыз.

Үзен зур галим итеп саный башлаган Салихҗан кари монда да Мәккәи шәриф тәртипләрен кертмәкче, Қоръән һәм салаватларны андагыча укысыннар, азанны андагыча әйтсеннәр. Ул хәтта Казан голәмәсенең ат менеп яисә велосипедка атланып йөрүен гамәлгә кертергә азаплана. Мәзәк хәлдән мәзәк хәлгә юлыга-юлыга, безнең кари тәмам адәм хуры булып кала.

Икенчесен усал сатира үрнәге итеп карап булмый. Ул күбрәк юморга тартым. Сәмигулла абзый — урта кул сәүдәгәр. Борынгылар васыять итеп калдырганча яшәп ята. Аласын ала, сатасын сата. Иң яраткан гадәт-шөгыле — чәй-шикәр белән әвәрә булу. Нинди чәй алу, кайсын башлау, пешергәндә ничә балкашык салу, өйдә ниндие чыгышлы, юлда кайсысы — әнә шуларны кайгырту хәтта сәүдә эшләреннән дә алдарак тора. Иң сөеп эшләгән эше — пичәтле яңа чәйне тантана белән ачу. Чәй савытын селкетеп карау, ачып иснәү дә аңа иксез-чиксез ләззәт бирә. Шикәр белән дә шул ук хәл. Бар бит башлы шикәр, пилүние, тагын әллә ниндиләре. Қайсын кайчан тоту, юлга кайсын алу, күпме алу — үзе бер мәсьәлә.

Чәй-шикәргә үтә хиреслеге Сәмигулла абзыйны еш кына җайсыз хәлгә дә куйгалый. Бервакыт шулай, кызларын кияүгә биреп туйлар узып киткәч, кияүнең ата-анасын кунакка чакыралар. Табын әзерләнеп бетеп, самовар да килеп утыргач, килен-кыз чәй пешерә башлый. Бер балкашык сала, ике балкашык, өченчегә дип кашыгын батыруы була, җентекләп күзәтеп торган Сәмигулла абзый түзми, әйтеп ташлый бит:

— Чү, кызым, җитте. Ике балкашыгы салдың бит инде!

Мин күп эчмим, анаң да әллә ни күп эчми. Хәер, белмим тагын, ни әйтим, кунаклар күп эчә торган булсалар гына...

Икенче тапкырында шулай Сәмигулла абзый, улы Хәкимулла белән берлектә Мәкәрҗәгә барырга чыккач, пароходка соңга кала. Сәбәбе — әлеге дә баягы чәй-шикәр. Саквояж һәм төеннәрен кичтән әзерләп куйган булсалар да, икенче көнне Сәмигулла абзый барысын да чиштереп, чәй һәм шикәрләрен тагын әвеш-түеш китерә башлый.

Менә алар пристаньнан күтәренеп кайтып керәләр. Хәкимулла ачулы, Сәмигулла, гаебен аңлап, юашлана һәм төчеләнә төшкән. Ярар, хәерле булсын, насыйп түгел икән, иртәгә китәрбез.

Ә төнлә Сәмигулла абзый гаҗәеп матур төш күрә. Ул зур бер бакчада йөри имеш, хуҗасы үзе имеш. Алмагачларда алма урынына пичәтле чәйләр, түтәлләрдә кәгазьгә төрүле башлы шикәрләр үсеп утыра имеш...

Сәмигулла абзыйның Хәмзә бай, Шкафчы яисә «Бәйрәмнәр»дәге Вәли бай кебек әшнәләре искә төшә. Аларның әле шәхси мәнфәгатьләреннән тыш иҗтимагый «идеаллар»ы да бар. Берсе театрны булдырмаска йөри, икенчесе җәдитләр белән сугыша, өченчесе яңалык яклы яшьләр белән әрепләшә. Хәтта Фәтхулла хәзрәт тә үзенчә актив: салам белән селтәнеп булса да яңалык белән сугышмакчы.

Сәмигулла абзыйның инде җәдитләр белән дә, театр-концерт яисә гәзит-мәзитләр белән дә бернинди алыш-биреше юк. Яшәвенең бөтен мәгънәсе, бөтен «идеаллары» чәй тартмасына сыеп беткән яки, башлы шикәр кебек очлаеп барып, бөтенләй юкка чыккан.

Бүтәнчә була да алмый. Заманнар үзгәрде, кадим-җәдит тартышының кызган чаклары узып китте, яңа мәсьәләләр, яңа проблемалар килеп басты. Бер почмакка куып кертелгән кадимчеләрдә — байрак күтәреп көрәшү кайда! — җан асрап калу, ни беләндер юанып яшәү кайгысы. Юанган нәрсәләре дә бик вак, бик кечкенә. Боларга каршы инде сатира пушкасының кирәге юк, юмор ук-җәясе дә бик җиткән.

...Ф. Әмирханның әдиби иҗаты өчен бәрәкәтле булган 1916 ел бетеп килә. Бу вакыт ил тормышында давыл алдыннан була торган киеренкелек ап-ачык сизелә башлый. Фронтта — уңышсызлык артыннан уңышсызлык, тылда — азык-төлек кытлыгы, кыйммәтчелек, спекуляция. Гомуми ризасызлык арта бара, завод-фабрикаларда стачкалар көчәя.

1913 елның җәй башында каты авырып киткәннән соң үз өйләренә кайтуын һәм, шунда торып калуын искә алма-

ганда, Фатихның шәхси тормышында зур үзгәреш юк. Түбәндәге игъланнан көннәренең ничек узганын, режимының ни рәвешле булганын чамаларга мөмкин.

«Фатих Әмирханга хезмәт өчен бер егет кирәк. Белешергә Яңа бистәдә мулла Зариф эль Әмирхани йортыннан һәр көнне иртә 10 нан 12 гә кадәр. Шимбә, дүшәмбе, чәһәршәмбе көннәрдә «Кояш» идарәсендә 1 дән 5 кә кадәр («Кояш», 1916, 28 август).

Димәк, шактый еллар Ф. Әмирхан хезмәтендә булган Мәгъсүм инде киткән. Бу — бер. Икенчедән, вазифасын үтәр өчен Фатих «Кояш» редакциясенә атнасына өч тапкыр, анда да төшкә таба бара икән. Күп вакыты үз бүлмәсендә уку һәм язу белән узган. 1916 елда аның чагыштырмача күп язуы, бүтән сәбәпләрдән тыш, әнә шуның белән аңлатылса кирәк. Кичләре күбрәк театрда, концертларда яисә өй мәҗлесләрендә уза.

Театр дигәннән, Фатих үз пьесалары буенча куелган спектакльләрнең берсен дә калдырмаган дип уйларга кирәк. 1915—1916 елларда «Яшьләр» Казанда дүрт тапкыр, ә «Тигезсезләр» җиде тапкыр күрсәтелгән. Димәк, барысында да булу күп вакыт сорамый. Әмма ул заман өчен бу аз түгел. Һәрхәлдә, Ф. Әмирхан, бүтән драматурглар белән чагыштырганда, күбрәк уйналган.

Менә 1917 ел башлана. Фатихның көннәре элеккечә уза, тормышы шул ук эздән ага. Ләкин без югарыда аның иҗтимагый активлыгы, вакытының бер өлешен җәмәгать эшләренә бүлгәнлеге турында бер сүз дә әйтмәгән идек. Теге яки бу җыелыш, киңәшләрнең ул берсеннән дә калмаска, үз фикерен үткәрергә, шартлар мөмкинлек биргән дәрәҗәдә демократлар файдасына карар чыгартырга тырыша.

13 февраль көнне, мәсәлән, «Амур» кунакханәсенең залында Казан шәһәр Думасына сайлауларга әзерләнү мәсьәләсенә багышланган зур җыелыш була. Сайлауда русларның кайсы партиясе белән барырга һәм кемнәрне сайларга дигән ике мәсьәлә карала. Юрист Ш. Иманаев монархик газета «Казанский телеграф» тирәсенә тупланган уңнар белән барырга, сайлау исемлегенә кертә сикерми торган ышанычлы картларны кертергә кирәклекне кызып-кызып яклый. Ике мәсьәлә буенча да Ф. Әмирхан сүз ала һәм, иронияне мул катыштырып, Иманаевның дәлилләрен берәм-берәм аударып ташлый. Юк, ди ул, безгә «Камско-Волжская речь» тирәсенә тупланган тәрәккый пәрвәрләр белән хәрәкәт итү дөресрәк булыр. Шәйхегаттар әфәндең коты очмасын дип тә өсти, алар арасында сәяси кур-

кынычлы кешеләр генә түгел, бәлки уң фикерлеләр дә бар. Кемнәрне сайлауга килгәндә, ди Фатих, моңарчы Дума урындыгын җылытып һәм мөселманнар өчен саклап тотканнары өчен «картларга» рәхмәт әйтергә дә исемлеккә эш эшләрдәй яшьләрне кертергә кирәк. Һәр ике мәсьәлә тавышка куела, һәр икесендә Әмирхан фикере җиңә.

Тавышка куюның рәвеше дә кызыклы.

Рәислек итүче: уңнар белән диючеләр торып бассын! Ике-өч яраны белән берлектә Иманаев калка.

Рәислек итүче: тәрәкъкый пәрвәрләр белән диючеләр торып бассын! Бөтен зал дип әйтерлек аякка калка, утырып калучылар арасында берсе Ш. Иманаев, икенчесе... Ф. Әмирхан.

Безнең Фатих либераллар тон биргән бу мәҗлескә катнашмаса, кереп утырган тәкъдирдә күзәтүче генә булып калса, яхшырак буласы иде югыйсә. Әмма ул болай уйлый: хәзерге шартларда шәһәр Думасына татарларның азрак керүгә караганда күбрәк керүе, гласныйлык урыннарын монархистларга караганда либералларның биләве хәерлерәк, демократларны күбрәк үткәреп булса, тагын да яхшырак. Дуңгыздан бер кыл дигәндәй, бәлки берәр файдалы эш чыгар.

## 5

1 март көнне хәбәр тарала: патшаны төшергәннәр! Берике көннән вакыйгаларның ничек үскәне, нәрсәгә китергәне мәгълүм була. Эшче һәм солдатлар икенче патша турында ишетергә дә теләмәгәнгә күрә буржуазия властьны үз кулына алырга карар итә. Дәүләт думасының Вакытлы комитеты Петроградның эсер һәм меньшевиклар кубызына бии торган эшче һәм солдат депутатлары Советы белән килешү ясый да «Вакытлы хөкүмәт» дип аталачак хөкүмәтне барлыкка китерә.

Патша кадәр патшаның авып төшүе күпләргә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итсә дә, Фатихка алай ук булып тоелмый. Бу режимның череклеген, иртәме-соңмы җимереләчәген ул күрә һәм белә, тик болай ук тиз һәм җиңел эшләнәсен генә күз алдына китерә алмый иде. «Богаулар өзелделәр» исемле мәкаләсеннән күренгәнчә, Фатихның күңеле иксез-чиксез куаныч белән тулы. Ләкин шатлык исреклегендә озак калып булмый, бу зур тарихи үзгәрешнең асыл мәгънәсен төшенеп җитәргә, миллә һәм аның төрле катлаулары күзлегеннән карап, яңа тәртипләргә мөнәсәбәтне ачыкларга кирәк. «Кояш»ның 7 март санында «Фатих» им-

засы белән «Инкыйлап *вә без» дигән озын мәкалә басыла башлап, ундүрт санга, ягъни 11 апрельгәчә сузыла.

Мәкаләнең эчтәлеге, кысып, кыскартып әйткәндә, түбәндәгечә.

Революция рус демократиясе, башлыча эшчеләр һәм солдатлар кулы белән ясалды. Патша хөкүмәтеннән риза булмаган барлык сыйныфлар һәм партияләр дә катнашканлыктан, ул җиңел һәм кансыз булды. Әнә бит социал-демократ Чхеидзе һәм трудовик Керенский Гучков һәм Шульгин кебек кадетлар белән кулга-кул тотынып эшләп яталар.

Безгә, мөселманнарга, революция биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, үз кирәкләребезгә ирешү өчен оешырга, төрле милли учреждениеләр булдырырга кирәк. «Мөселман иттифакы»ның традицияләренә таяну кулай булыр. Дөрес, аның экономика һәм политикага караган положениеләрен үзгәртергә туры киләчәк.

Хәзер кадетлар һәм алардан уңдарак торучы партияләр белән демократия арасында көрәш бара. Беренчеләре өскә чыгып, революция җиңелмәсен һәм монархия кире кайтмасын өчен, безгә Вакытлы хөкүмәтне яклау тиеш.

Революциянең зур казанышы — вәгъдә ителгән Учредительное собрание. Сайлау гомуми, туры һәм яшерен булачак. Собраниегә мөселманнарның санынча мөмкин кадәр күбрәк әгъза үткәрү өчен безгә милләтне бүлендермичә, бербөтен булып барырга, «сыйнфый көрәшне үткенләндерерлек һәрбер хәрәкәт вә һәрбер сүздән» сакланырга кирәк.

Хәзер В. И. Ленинны тыңлыйк.

Февраль революциясе турында ишетү белән үк ул Россиягә түбәндәге эчтәлекле телеграмма җибәрә:

«...Яңа хөкүмәткә тулы ышанычсызлык, бернинди булышлык күрсәтмәскә, бигрәк тә Керенскийдан шикләнәбез, пролетариатны коралландыру — бердәнбер гарантия, хәзер үк Петроград думасына сайлаулар үткәрергә, башка партияләр белән берничек тә якынлашмаска» **.

Ленин — Россиядә. Финляндия вокзалы. Броневикка басып сөйләгән ялкынлы речь. Озакламый атаклы «Апрель тезислары» игълан ителә. Анда мондый сүзләр бар: «Россиядә хәзерге моментның үзенчәлеге, пролетариатның аңлылыгы һәм оешканлыгы җитәрлек булмау аркасында, революциянең властьны буржуазиягә биргән беренче этабын-

* Инкыйлап — революция.

** В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 24 т., 4 бит.

нан аның властьны пролетариат һәм ярлы катлау крестьяннар кулына бирергә тиеш булган икенче этабына күчүдән гыйбарәт» *. Икенче төрле әйткәндә, буржуаз-демократик революцияне социалистик революциягә әверелдерү, пролетариат диктатурасы урнаштырып, социализмның нигезен корырга керешү.

Күренә ки, агымдагы хәлләрне бәяләүдә бер-берсенә капма-каршы булган ике позиция, ике караш. Ләкин нәтиҗә ясарга ашыкмыйк, башта бүтән партия һәм политик төркемнәрнең «Апрель тезислары»на мөнәсәбәтен карап китик.

Буржуаз партияләр, билгеле инде, «Тезислар»га котырынып ташландылар. Эсерлар да большевиклар программасын кабул итә алмадылар, чөнки, аларча, бүтән революция кирәкми, шушысы мәсьәләләрне хәл итәчәк.

Меньшевиклар ничек? Бит алар да социал-демократлар. Алар да үзләрен Маркның турылыклы варислары итеп саныйлар. Ә менә меньшевиклар башлыгы Г. В. Плеханов Ленинның «Апрель тезислар»ын «саташу» дип атый.

Хикмәт шунда, әгәр В. И. Ленин марксизмны иҗади кулланып, империализм чорында социалистик революция аерым бер илдә дә җиңә ала дигән нәтиҗәгә килгән булса, Плеханов, алга адым ясый алмыйча, бер урында торып калды. Аныңча, мондый революция алдынгы капиталистик илләрдә берьюлы башланып кына җиңеп чыга алачак. Күпчелеге вак буржуаз катлаулардан тора торган «чабаталы» Россия әле социалистик революция өчен өлгереп җитмәгән.

«Апрель тезислары»н кабул итмәүдән чыгып кына эсер һәм меньшевикларның барысын да аңлы рәвештә либераль буржуазия позициясенә күчүдә гаепләүнең дөрес булмаганлыгын күңелгә салып куйыйк та Ф. Әмирханга кайтыйк.

Әйе, ул да «Апрель тезислары»н кабул итә алмады. Аны да аңлы рәвештә либераллар ягына чыгуда гаепләргә нигез юк. Ул гына да түгел, әгәр без аның барлык язганнарын һәм сөйләгәннәрен кабат күздән кичерсәк, рус кадетлары һәм шуларга каш сикертүче «милләт хадимнәре» белән үзе арасына чик уздырырга тырышканын күрербез. «Богаулар өзелделәр» мәкаләсендә ул көн тәртибенә баскан зур бурычларның берсе — «җирләр мәсьәләсен катгый сурәттә хәл итеп, халыкның иң зур эксәриятен ** тәшкил итә торган крестьянны адәм хәяты белән тора алыр-

---

* В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 24 т.
** Эксәрият — күпчелек.

лык хәлгә күтәрү» дип язган иде. «Инкыйлап вә без» мәкаләсендә болай ди: иске режим империализм юлыннан бара һәм кечкенә милләтләрне йотарга омтыла торган режим иде. Шуңа күрә без сугышка мөнәсәбәттә ватанпәрвәр, ягъни патриот була алмадык. Хәзер исә мәсьәлә үзгәрде: ватанны саклау — революция казанышларын саклау дигән сүз. Ләкин без «...кадет вә аның уң тарафындагы бер-ике партияләрнең сугышка карашларын бер дә уртаклаша алмаганымызны да әйтеп китәргә мәҗбүрмез. Панславизм фикере белән хәрәкәтләнә торган бу партияләрнең сугышка булган мөнәсәбәтләрен без мәмләкәт вә ватан мәнафигыннан бигрәк, тар милләтчелек нәзариятеннән * чыккан вә бу көндә мәмләкәтемездән файдасыз корбаннар таләп итүе ихтималы булган мөнәсәбәт дип игътикат итәмез». Кадетларның «сугышны җиңгәнчегә кадәр дәвам иттерергә» дигән лозунгларына каршы чыккан кебек, Ф. Әмирхан бөтен дөньяга солых тәкъдим иткән «эшче һәм солдат вәкилләре шурасы»на булган симпатиясен дә яшерми. «Тигез хокуклы, хөр милләтләрнең ватаны булган Россия,— дип яза ул,— бу сугыштан империализм юлына керми чыгарга тиеш булган шикелле, мәгълүп ** булмыйча, икътисади *** изелмичә чыгарга тиештер».

Ф. Әмирхан С. Максуди бакчасына да бер таш атып уза. Кадетлар съездында Садри әфәнде Истамбулны һәм бугазларны тартып алу политикасына каршы чыккан чыгуын, әмма мәсьәләне ялгыш куйган: дин кардәшләребезгә каршы үткәрелә торган мондый сәясәт, дигән ул, без мөселманнарның намусына тия. Ф. Әмирхан фикеренчә мәсьәлә болай куелырга тиеш: сүздә үзләрен вак милләтләрнең бәйсезлеге тарафдары итеп күрсәтсәләр дә, кадетлар Россия буржуазиясенең Истамбул һәм бугазларны яулап алу политикасын хуплыйлар. Бу — «ап-ачык империалистлык карашы». Икейөзләнүләре — «үзләренең империалистлык максатлары өчен».

Учредительное собраниене яклавы һәм сайлауларга бердәм булып баруны хуплавы мәсьәләсенә кайтсак, бу очракта да либералларныкыннан үзгәрәк юл тотканлыгын күрербез. Беренчедән, ул моның асат түгеллеген таный. Икенчедән, бергәлекне ул мәңгеләштерми, «мөгайян бер вакытка кадәр» генә дип белдерә һәм фикерен Г. В. Пле-

---

* Нәзарият — теория.
** Мәгълүп — җиңелү.
*** Икътисади — экономик.

хановның: «Хәзергә бергә, аннары аерылышырга!» дигән сүзләре белән ныгытып куя.

Ф. Әмирханның бу вакыттагы политик яктан карашын якынча түбәндәге рәвешле итеп күз алдына китерергә мөмкин. Әгәр тулаем Россия социалистик революциягә өлгереп җитмәгән икән, гасырлар буе изелеп килгән татар милләте мондый революциягә бигрәк тә әзер түгел. Беренчедән, ул фәкыйрь, икенчедән, халыкның — аеруча эшче һәм крестьяннарның — культура дәрәҗәсе түбән. Демократик республика шартларында башта экономик яктан ныгыйк (үз байларыбыз, үз капиталистларыбыздан башка бу мөмкин түгел), халыкны укытыйк, тәрбиялик, күзен ачыйк, дусны дошманнан аерырга өйрәтик, эшне үз кулына алырлык дәрәҗәгә күтәрик. Шуннан соң инде социальная революция һәм социализм мәсьәләсе көн тәртибенә килеп басар.

Февраль революциясеннән соң да Ф. Әмирханның, кадетчыл либераллар белән алыш-биреш итмичә, революцион-демократик позициядә торып калганына ышандык булса кирәк.

Инде килеп, тагын В. И. Ленинны тыңлыйк: «Хәзер, 1917 елның февраль, март, апрель, май тәҗрибәләреннән соң, Россиядә гомумән «революцион демократия» турында сөйләп йөрүче кеше, ирекле яки ирексез, аңлы яки аңсыз рәвештә, халыкны алдый» *. Чөнки яңа шартларда җир һәм солых мәсьәләсен пролетариат һәм ярлы крестьяннар властьны үз кулларына алып кына хәл кыла алачаклар иде. Менә ни өчен хәзер революцион-демократик мәсьәләләр белән генә чикләнү һәм хәл ителешен Вакытлы хөкүмәттән һәм Учредительное собраниедән көтү буржуазия тегерманенә су коюдан бүтән нәрсә була алмый иде. Бу каршылыклы хәл Ф. Әмирханны да читләтеп узмады. Либераллар белән үзе арасына чик сызыгы уздырырга тырышса да, аның бу чордагы уй-карашы һәм эш-гамәле күп кенә очракта, үзе дә хисап бирмәстән, либераль буржуазия файдасына булды.

Вакыйгалар күз иярмәс тизлек белән үсәләр, Фатихның бу вакыттагы иманына, тоткан юлына бик үк туры килми торган якка үсәләр... Әнә Февральнең беренче көннәреннән үк Г. Сәйфетдинов революцияне яңа баскычка күтәрү юнәлешендә җиң сызганып эшкә керешә. Демократик интеллигенция арасыннан килгән М. Вахитов, К. Якубов, Г. Ибраһимов һәм Ш. Әхмәдиев кебекләр большевиклар белән

---

* В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, 24 т., 564 бит.

эшләшә башладылар. Эшче-большевикларның саны арта бара, большевиклашкан солдатлар күбәя. Апрельдә «Россия мөселманнарының мәркәз бюросы»на һәм Казан «Мөселман комитеты»на каршы көрәшү һәм татар хезмәт ияләрен социалистик революциягә әзерләү өчен М. Вахитов инициативасы белән «Мөселман социалистлар комитеты» оештырыла.

Әнә шул килеш татар большевиклары һәм радикаль карашлы революцион-демократларның бердәм отряды барлыкка килә. 1917 елның июнендә «Мөселман социалистлар комитеты» органы булып чыга башлаган «Кызыл байрак» газетасының М. Вахитов тарафыннан язылган программ мәкаләсендә менә нәрсә диелә: «Без хәзердән түбәндәге нәрсәләрнең булуын телибез: 1) власть эшчеләр, крестьяннар һәм солдатлар Советына күчсен, 2) барлык җир, һич тә кичектерелмичә, крестьяннарга бирелсен; 3) Дәүләт думасы, Дәүләт шурасы таратылсын; 4) иске хөкүмәтнең союзниклар белән ясалган мәгаһәдәләре * халыкка фаш ителсен: аларны үтәүгә Россия халкы мәҗбүр булмасын; 5) сугыш бетсен; 6) завод-фабрикалар һәммәсе эшчеләрнеке, эшләүче халыкныкы итеп игълан ителсен!»

Бер төркемнең аерылып чыгып, гомуми агымга каршы йөзә башлавы Әмирханны куандыра алмаган, әлбәттә. Июнь башында, Ш. Әхмәдиев «Мөселман комитеты»н шактый кискен тәнкыйтьләп чыккач, Фатих «Большевиклыкмы яки демагогияме?» дигән мәкалә белән җавап бирергә тиеш таба.

«Мөселман комитеты»ның политик юлы, ди ул, федератив демократик республика, эшчеләр мәсьәләсендә социал-демократларның меньшевиклары белән, крестьяннар мәсьәләсендә социалист-революционерлар белән бергә бару. Комитетның җитәкчеләре шул ук вакытта дини-милли мәсьәләләрне дә онытмыйлар. Дөрес, комитетның җитәкчеләре крестьян яисә эшче түгел, әмма җитәкченең кыйммәте нинди юл тотуы һәм ничек хезмәт итүе белән билгеләнә. Атаклы революционер Кропоткин әнә — князь. Крепостнойлыкка каршы көрәшкән Тургенев — алпавыт. Лассаль таягының башы саф алтыннан булган.

Моннан соң инде «Март каһарманы» исемле хикәя-пародия язуы һәм «Аң» журналының сентябрь санында бастырып чыгаруы безне бик үк гаҗәпләндермәс.

1917 елның 4 мартыннан соң митингтан митингка чаба торгач, Гыйсмәтулла тәмам социалист булып житә. Ике

* Мәгаһәдә — договор.

сүзнең берендә «рабочий туганнарым», «крестьян җанкисәкләрем» дип төчеләнә, ачуын китергән кешене генә түгел, җансыз әйберне дә «канэчкеч буржуй» дип сүгә башлый. Көннәрдән бер көнне ул, митинг эзләп йөргәндә печән төяп баручы рус мужигына тап булып, «крестьян җаным» дип кочаклый. Аннары, бала күтәргән асрау кызны күреп, «канэчкеч буржуй баласын карыйсың» дип, эт итеп сүгә.

Тора-бара Гыйсмәтулла үзе дә митингларда сүз алып сөйләргә өйрәнеп китә. Нотыкларының кыскача эчтәлеге түбәндәгечә.

— Рабочий туганнарыма бирелсен: 8 сәгатьлек эш көне, таш пулат, тәмле ашлар, сюртук, шиблит, пар ат, карета, театрда ложа...

— Крестьян былбылларыма бирелсен: 25 әр дисәтинә җир, ун ат, ун сыер. Хатыннарына — асыл күлмәк, алтын йөзек, бриллиант брошка...

Вакытлар уза, Гыйсмәтулла чын-чыннан общественный деятель булып китә. 6—7 җәмгыятьтә ул я рәис, ә әгъза. Берсе, мәсәлән, болай дип атала: «Йөктән чәчелеп калган печәнне җыючы мөселман малайлары җәмгыяте». «Мөселман комитеты»на да әгъза булып кергән, Мәскәү съездына да барып кайта. Ләкин губерна эшче һәм солдат депутатлары Советына үтә алмый. Учредительное собраниегә сайланучылар исемлегенә дә кертмиләр. Гыйсмәтулла сүгенеп йөри башлый, үзенең җәмгыятьләрен файдаланып, эш ташлау белән куркыта.

1920 ел. Республика урнашып җиткән. Хөкүмәт башында социалист утыра. Гыйсмәтулла — волостной комитетта секретарь ярдәмчесе. Революция вакытында җыеп калган ун мең сум капиталының 500 сум гына процент китергәне өчен, хөкүмәтне сүгә, рәисен гаепли, барлык социалистларны пыр туздыра, халыкны анархист-индивидуалист булырга өнди.

Ике революция арасындагы куәтле агымга кушылып киткән кешеләр арасында бәлки сирәк-мирәк Гыйсмәтулла кебек салам-торханнар да булгандыр. Ләкин демократик көчләрнең тарихи барыш кушуы буенча эшчеләр сыйныфына йөз белән борылулары, большевиклар партиясе тирәсенә туплана башлаулары вакытында Фатихның сатирик талантын бу памфлетны язуга җигүе, ким дигәндә, урынсыз иде...

Ел тәүлеге җәйгә таба авышкач, Фатих, гадәтенчә, кая булса да барып кайту турында уйлана башлый һәм пароход белән йөреп кайту фикеренә килә.

Фатихның Бишбалта белән тыгыз элемтәдә яшәгәнен

укучы хәтерлидер. Сәгадәт апасы үлгәч тә бу элемтә өзелми. Чөнки, җизнәсе Габдулла мулла белән арада җылы мөнәсәбәт сакланудан тыш, Фатих Бишбалтаның рус-татар мәктәбе укытучысы Габдрахман Рәфыйков гаиләсе белән дә якын мөнәсәбәткә кергән була. Бишбалтага ул еш барган кебек, Габдрахман учитель дә шәһәргә килгән саен, Зариф хәзрәт һәм Фатих янына керми китми икән (1919 елда Г. Рәфыйковның 25 еллык хезмәт юбилеена багышлап Ф. Әмирханның гаять җылы мәкалә язып чыгуы очраклы хәл булмаса кирәк).

Г. Рәфыйковның улы Хәбибрахман капитан ярдәмчесе булып эшли. Ник шушы мөмкинлектән файдаланмаска? Хәбибрахман Фатих абыйсының үтенечен теләп кабул итә. Әдипкә бер төркем яшьләр дә иярә. Арада Габдрахман учительнең кызы Әминә дә бар. Туганнан туган энесе Гомәр Әмирхановны, ярдәмгә дип, Фатих үзе алган булыр.

Менә июнь уртасында сәяхәтчеләр шау-гөр килеп Усиягә төшәләр һәм, пароходка утырып, юлга чыгалар. Маршрут: Казан — Уфа — Казан.

Иртәнге чәйне эчкәч, Фатих палубага чыгып утыра һәм, яшьләр чолганышында калып, мәзәкләштерелгән хикәятләрен сөйләргә керешә. Егет-кызларның гадәт-холыкларын абайлап алгач, аларны да кушып җибәрә, дустанә чеметкәли башлый. Туктаусыз көлеш, өзлексез и-ха-ха да ха-ха-ха. Шат күңелле бу төркем пароходның бүтән пассажирларын да тартып китергәнгә күрә, әдипкә еш кына русчага күчәргә туры килә.

Мондый утырышлардан ялыкса, каютасында укып ята яисә өске катка, капитан рубкасы янындагы кресло-качалкага менгереп утыртырга куша. Агыйделгә барып кергәч, андагы матурлыкка таң калып, кичтән менеп утырган килеш өске каттан кояш чыкмыйча төшми башлый. Агыйдел тар булганга, урыны белән пароход ярга орынып диярлек уза. Эреле-ваклы агачлар, суга иелеп тора торган куаклар, талгын җилдә яфракларын дерелдәтеп, артка шуышалар. Бихисап кошлар чыр-чу килә. Акчарлаклар, ризык ыргытмаслар микән дип, пароход тирәли айкалып очалар. Авыл яныннан үткәндә сыер-сарык, кош-корт тавышлары ишетелеп куя.

Таң вакыты. Барлык кеше тирән йокыда. Ике кеше генә йокламый. Берсе — рубкадагы Хәбибрахман, икенчесе — кресло-качалкасында Фатих. Чөнки алар... вахтада. Бер заман күк кырые алсулана башлый. Күктәге кызыллык киңәя, куера барып, ерак урман артыннан ут көлтәсе бөркелә. Ул да булмый, күзне чагылдырып, кояшның сырты

күренә. Ут шары бөтенләй калкып чыккач, Фатихны каютага төшереп куялар.

— Хезмәтемне үтәдем, инде ял итәм туганкайларым,— ди Фатих.— Унда уятырсың, Хәбип.

Сәяхәт ашап-эчү, уен-көлке, мәзәк, вак-төяк сүзләрдән генә тормаган, билгеле. Әмирханның төпченергә, күпне белергә яратуы безгә яхшы таныш. Пароходның капитаны Борис Григорьевич Иванов белән дә ул күптән инде уртак тел тапты. Үзе белән танышкан пассажирларның кыллары чиртеп карап, сүзгә тартырга тырышканына да шикләнмәскә мөмкин.

Пароход Уфага җитеп туктагач, әдипнең үтенече буенча, Гомәр Әмирханов белән Әхмәт Галиев Фатих Әмирханның килүе турында кемгәдер телефоннан хәбәр бирәләр. Күп тә үтми, өч-дүрт ат белән килеп, Фатихны шәһәргә алып менеп китәләр.

Кемнәр булды болар, Әмирханны кая алып киттеләр, ничек хөрмәт күрсәттеләр — бу турыда, кызганычка каршы, мәгълүмат юк. Әдипне зурлаучылар Уфа язучылары һәм газета хезмәткәрләре булган дип уйларга гына кала.

Икенче көнне, пароход кузгалып китәргә ике сәгать калганда, кырыклап кеше, дөбер-шатыр китереп, Фатихны пристаньга алып төшәләр. Бу тамашаны күреп барлык пассажирлар гаҗәпләнгән кебек, капитан да «вахтадаш»ының гадәти генә кеше, уртача гына язучы булмаганлыгына тагын бер кат ышана. Пароход кузгалганда ул тиешле гудок белән генә чикләнмичә, өч мәртәбә озын-озын итеп хушлашу «салюты» бирә.

Сәяхәттән Фатих күңеле булып, ял итеп, шактый көчкуәт туплап кайта. Әмма монда көтеп торган эш-мәшәкать, борчу-бимазалар аның җыеп кайтканын бик тиз суыра башлыйлар. Казан кайный, вакыйга артыннан вакыйга булып тора. Күбесе Фатихны куандыра алмый. Бигрәк тә үзәктәге хәлләр аның бер рәвеш алган иманын какшата башлый.

Күр инде син бу Вакытлы хөкүмәтне. Апрель вакыйгаларыннан соң составында үзгәреш булып, яртылаш «социалистлардан» тора башлавына карамастан сугышны туктатмау гына түгел, һөҗүмгә күчәргә боерык бирде. Хөкүмәт башлыгы һәм хәрби министр Керенский буйсынмаучы солдатларга карата үлем җәзасы кертте. Җир мәсьәләсен Учредительное собрание хәл итәчәк дип, хөкүмәт крестьяннарны һаман вәгъдә белән сыйлый. Собрание чакыру вакытын исә һаман чигерә тора. Халыкны алдау, күз буяу гына түгелме бу?

3 июльдә энә, патша эшләгән эшне кабатлап, Петербургтагы тыныч демонстрациягә атты, кешеләрне кулга ала, төрмәгә тыга башлады. Хәтта милли мәсьәләдә дә Вакытлы хөкүмәт иске режим эзенә төшеп атлый башлаганга охшый. Хөкүмәт комиссарлары мөселманнар хәрәкәтенә шикләнеп һәм йөз чытып карыйлар, аның саен аяк чалалар. Керенскийның рөхсәт бирмәве сәбәпле, энә «Шура съезды» булмый калды.

Шундый тәшвишле көннәрнең берсендә Казан каласы фаҗигагә юлыгып, халкы өч-дүрт көн буе үлем куркынычы астында яши.

14 август көнне, төш авышкач, Фатих ничектер ялгыз калып редакциядә эшләп утырганда кайдадыр, нәрсәдер гөрселдәп шартлый. Ул да булмый, икенче шартлау яңгырый, өченчесе... Аннары туктаусыз гөрес тә гөрес... Идән, диварлар чайкала, чылтыр-чылтыр пыяла коела, ишекләр шап-шоп ачылып ябылалар. Туп аталар ич! Нәрсә бу? Сугышмы, хәрби өйрәнүләр генәме?

Соңыннан билгеле булганча, Бишбалта ягындагы Пороховой заводта зур янгын чыккан икән дә, снаряд һәм дары төялгән вагоннарга берәм-берәм ут каба башлаган.

Кунакханә хуҗасы Мөбарәкша Рамазанов — мал кадерле булгангамы, әллә бүтән сәбәптәнме — качып та китмәгән, башын да җуймаган. «Кояш» идарәсенә керсә, ярдәмчесез калган Әмирханны күрә һәм, күтәреп чыгып, җиккән атына утырта да алып китә.

Урамда — мәхшәр. Халык ташкынының бер тармагы Яңа бистә ягына ыргыла, икенчесе, Екатеринскаяны тутырып, Кабан күле артына чыгарга омтыла. Күпчелеге — җәяүлеләр. Кечкенә балаларын күтәреп, йөрердәйләрен өстерәп чабалар. Күбесе чыгыр яки ике тәгәрмәчле арба тартып бара. Арбасына яисә тарантасына торып баскан килеш чыбыркысын айкый-айкый атын куып, җәяүлеләрне бәрәгә шәһәрдән чыгарга ашыгучылар да байтак. Елашу, кычкырышу, сүгенү...

Бишбалта ягында һаман шартлаулар яңгырый. Шактый киң булып ялкын сузылган, кара төтен күк йөзен каплаган.

М. Рамазанов әдипне Яңа бистәгә, атасы йортына алып барган дип уйларга кирәк. Анда шул ук хәл. Атлысы, җәяүлесе зиярәт ягына ашыга, бистәдән чыгып өлгереп башын саклап калырга тырыша.

Мәхшәр 17 августка кадәр дәвам итеп, шәһәр бөтенләй диярлек бушап кала. Аннан берсеннән-берсе куркынычрак хәбәрләр, имеш-мимешләр килеп тора.

Менә бервакыт атыласы снарядлар атылып, янасы нәрсәләр янып беткәч, шартлаулар туктый, янгын басыла. Җимерелгән, янып көлгә әйләнгән бина-корылмалар, һәлак булган кешеләр — бихисап. Бәхеткә каршы, ут дары базларына җитә алмый калган. Югыйсә, бөтен Казан шартлап күккә очасы икән.

Шартлаулар туктап өлгерер-өлгермәс халык яңадан шәһәргә агыла башлый. Көн артыннан көн үтә, тормыш акрынлап элекке эзенә төшә.

Менә август та бетте, сентябрь керде. Вакыйгалар ташкыны Пороховой завод фаҗигасенең ямьсез хатирәсен күмеп китте. Фронттан берсеннән-берсе күңелсез хәбәрләр килеп тора. Крестьяннар, Учредилканы көтмәстән, җирләрне тартып ала башлаганнар, алпавыт утарларын яндыралар. Эшчеләрнең стачка көрәше тагын да куәтләнә. Вакытлы хөкүмәтнең һәлакәт чокырына таба тәгәри торган Россияне коткара алмаячагы күзе сукыр булмаган һәрбер намуслы кешегә инде ачык. Бердәнбер юл — дәүләт властен эшче, солдат һәм крестьяннар Советы кулына алу. «Бөтен власть Советларга!» дигән лозунг яңадан көн тәртибенә баса. Ләкин хәзерге шартларда властьны көч кулланып, корал ярдәмендә генә алырга мөмкин иде һәм РСДРП(б)ның Үзәк Комитеты восстание мәсьәләсен куйды, массаларны шуңа әзерли башлады.

Казан губернасы большевиклары да, партия күрсәтмәләре нигезендә, җиң сызганып эшкә керештеләр. Татар большевиклары һәм «Мөселман социалистлар комитеты» да аларга кушылып китте.

Яңа революциянең ишек шакуы Фатих Әмирхан өчен дә сер түгел иде инде. Ни булыр, вакыйгалар кая таба үсеп китәр дә, нәрсәгә китереп чыгарыр? Әдипне куаныч һәм көенеч, өмет һәм өметсезлек, икеләнү һәм чайкалу, иман алыштыруга бәйле газаплы уйланулар белән тулы көннәр, айлар, еллар көтә иде...

*7 бүлек*

## УРТАЛЫКТАН — БУ ЯККА

1

Петроградта кораллы восстание булган, Керенский хөкүмәте кулга алынып, власть эшче һәм солдат депутатлары Советына күчкән. Көне-сәгате белән әнә шул хәбәр Казанга килеп җитә, «Кояш» идарәсенә барып ирешә.

Шунысы да мәгълүм була: эшче, солдат, крестьян депутатларының II Бөтенроссия съезды яңа хөкүмәтне — Халык Комиссарлары Советын барлыкка китергән. Советта большевиклар күпчелекне тәшкил иткәнгә һәм комиссарларның күпчелеге шулай ук большевиклар булганга, ХКС председателе итеп В. И. Ульянов-Ленин билгеләнгән. Яңа хөкүмәтнең беренче декретлары ил һәм дөнья киңлекләренә очып китә: солых һәм җир турында, халыкларның хокуклары турында...

Октябрь борылышы турында ишеткәч, Фатих, Февральдәге сыман, куанычыннан эчми исергән дип әйтү бик үк дөрес булмаган кебек, 20—30 еллардагыча буржуазия властен әйләндереп салган революцияне ул ачу белән каршылады, кайгыга батты, кара янып йөри башлады дип белдерү дә хакыйкатьне тупас рәвештә бозу булыр иде.

Менә Халык Комиссарлары Советының, бөтен Россия мөселманнарына адресланып, Ленин һәм Сталин кул куйган мөрәҗәгате уңае белән язылган баш мәкалә: «Большевиклар — мөселманнарга» («Кояш», 25 ноябрь) «Без,— диелә анда,— мөгътәдил * социалистлар хөкүмәте булган Керенский хөкүмәтенең һаман Россиянең иске нәкыс ганганәсеннән ** котыла алмаганлыгын, дөньядагы иң демократ вә иң изелгән милләтләрдән тәшкил иткән ислам галәменә бер дә әһәмият бирәсе килмәгәнлеген зур тәәссеф *** белән бернйчә мәртәбәләр күрсәтеп киткән вә бу табышмакның ничек хәл ителә икәнен үземез һич ничек итеп аңлый алмаганымызны изһар иткән идек». Аннары автор болай дип дәвам итә: Николай хөкүмәте дә, Керенский хөкүмәте дә милләтләргә, күп дигәндә, «Европа буржуазиясе ганганәсеннән чыгып» караган булсалар, «большевиклар бу кабахәт моданы башлап ертучылар булдылар.

«Мөбарәк булсын бу яңа адым!». Һәм мондый нәтиҗә ясый: «Без, Россия татарлары, большевикларның солых, йир вә милләтләр мохтарияте **** хакында күтәргән шигарьләренә *****, табигый, мөшарәкәт итми кала алмыймыз».

Әнә шул сүзләрне язып чыккан Ф. Әмирхан, Советлар властена һәм большевиклар партиясенә тәмам күңел баглап, М. Вахитов яисә Г. Ибраһимов кебек, яңа тормыш

---

* Мөгътәдил — уртача, умеренный.
** Нәкыс ганганә — начар традиция.
*** Тәәссеф — үкенеч.
**** Мохтарият — бәйсезлек.
***** Шигарь — лозунг.

коручылар ягыннан торып эшли башласа, үзе өчен, татар хезмәт ияләре һәм, ниһаять, бүген безнең өчен бик әйбәт буласы иде дә бит, кызганычка каршы, алай ук килеп чыкмады...

«Кара сакалың — калмый» дигән мәкаль тагын күңелгә килә. «Кара сакал» дигәнебез — бу очракта тәрбиясе, мохиты, шәхси хәле һәм, бигрәк тә, ул вакыттагы дөньяга карашы. Большевикларга симпатия белән сугарылган әлеге баш мәкаләдә ук инде Әмирхан аларның властьны кулларында тотып кала алуларына, тотып калган тәкъдирдә Россия халкы теләкләрен тормышка ашыра алачакларына шик белдерә. Без моңа бер дә гаҗәпләнмибез, чөнки аның Россия әле социалистик революциягә әзер түгел дигән караште торганлыгын беләбез. Әлеге мәкаләдә ул бу карашын ачыктан-ачык әйтеп бирә: «Россиянең һөнәр вә сәнаигътагы * түбән хәле...» сәбәпле «...большевиклар хыял итә торган социализм революциясенә зәмин ** бер дә юк... дөньяның тәрәкъкыйсе аңар йитмәгән».

Ленин һәм ленинчылар бүтәнчә уйлыйлар. Сугышны туктату, җирләрне бөтен халык милкенә әверелдерү һәм милләтләргә тулы хокук бирү кебек буржуаз-демократик революция хәл итәргә тиешле мәсьәләләрне юл уңаенда хәл итеп, Октябрь революциясе үз алдына зур тарихи бурыч куя: һич кичекмәстән социализм строеның нигезләрен сала башларга!

Әйе, җиңел эш түгел бу. Беренчедән, Россия — күпчелек халкы крестьяннар һәм вак буржуаз катлаулардан тора торган артта калган ил. Икенчедән, өч ел ярымга тартылган сугышта экономикасы тәмам чыгырыннан чыкты. Һаман әле ул Германия белән сугыш хәлендә. Өченчедән, буржуазия һәм аның чиновниклары, күпчелеге помещик баласы булган генерал һәм офицерлар, дәрәҗәләрен һәм талап җыйган байлыкларын кулдан ычкындырмас өчен актык чиккә кадәр барачаклар.

Әмма Ленин һәм көрәштәшләре халыкка, аның моңарчы җитәрлек ачылмаган һәм Октябрь борылышыннан соң ургылып тышка чыккан көч-куәтенә ышаналар. Алар фикеренчә, ныклы союз тәшкил итә торган эшчеләр һәм ярлы крестьяннар, власть башында торып, урта хәлле крестьяннарны үз артларыннан ияртә алсалар, контрреволюциянең каршылыгын сындырып, яңа стройның фундаментын салу эшенә керешә алачаклар.

---

* Сәнаигъ — промышленность.

** Зәмин — җирлек.

Юк инде, әфәнделәр, Россия башта Европаның алдынгы илләре дәрәҗәсенә күтәрелсен, аннары социалистик революция турында уйлашырбыз дип без эшче-крестьяннарны кабаттан буржуазиягә коллыкка бирә алмыйбыз. Власть үз кулларында булган тәкъдирдә алар политик төзелеш ягыннан гына түгел, бәлки экономика һәм культурада да Европаны бик тиз куып җитәчәкләр. Тарихи үсеш-үзгәреш тудырган шушы мөмкинлектән файдаланмыйча, властьны бүтән кулларга бирсәк, бу хата гына түгел, бәлки коточкыч җинаять булыр иде. Киләчәк буыннар безне моның өчен гафу итмәс иде.

Октябрь перевороты булу белән үк барлык төр контрреволюцион көчләр, катлау һәм партияләр Советлар хөкүмәтен аудару, революцияне буып ташлау өчен чыннан да котырынып һөҗүмгә ташландылар. Газеталары, агулы төкерекләрен чәчә-чәчә, большевикларны узурпаторлар дип атыйлар, немец шпионнары дип яла ягалар, большевиклар хөкүмәтен дөмектерү өчен бернинди чарадан да баш тартмаска өндиләр. Әле анда, әле монда фетнәләр кабына, төрле учреждение һәм предприятиеләрдә саботаж башлана. Краснов казаклары Петроград өстенә ябырылып киләләр. Донда Каледин баш калкыта. Ул да булмый, Троцкий, Бухарин тарафдарларының Брест сөйләшүләрен өзүләре сәбәпле, немец гаскәре һөҗүм итеп килә башлый. Антантаның яшерен тырышлыгы белән чехословаклар корпусы баш күтәрә. Шулай итеп 1918 елның җәенә таба яшь республика утлы боҗра эчендә кала.

Советлар власте кыл өстендә торган бер вакытта большевиклар ни эшләргә тиешләр иде? Билгеле инде, көчкә каршы көч кулланып, контрреволюцияне рәхимсез рәвештә бастырырга. Барыннан да элек контрреволюция штабы булып әверелгән кадетлар партиясенең газеталарын ябарга кирәк булды. Аннары эсер һәм меньшевик органнарына чират җитте. «Әгәр без социаль революциягә барабыз икән, без Каледин бомбаларына ялганлау бомбаларын өсти алмыйбыз» *,— диде В. И. Ленин. 1917 елның декабрендә бөек юлбашчы инициативасы белән контрреволюционер һәм саботажникларга каршы көрәшү өчен Ф. Э. Дзержинский җитәкчелегендә «чека» дип тарихка кергән орган барлыкка китерелә, һәм ул дошманнарның баш өстендә революция кылычы булып ялтырый башлый.

---

* В. И. Ленин. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә, Татарстан китап нәшрияты, 1961 ел.

Патша цензурасын үз җилкәсендә татыган, Февраль революциясеннән соң иркен сулап алган һәм сүз иреге, матбугат иреге дигәнне буржуаз-демократик рухтарак аңлый торган Ф. Әмирхан «демократик» юнәлешле газеталарның, бигрәк тә татар матбугатының, бер-бер артлы туктатыла башлавы белән килешә алмады. Кулга алу, төрмәгә ябу, кайвакыт исә иң югары җәза куллану да аңа кирәкмәгән шәфкатьсезлек, артык каты куллылык булып күренде. (Большевиклар Николай алымнарын куллана башладылар түгелме?)

«Матбугат хөрриятен буарга теләүчеләр» исемле баш мәкаләдә автор Уфада чыга торган «Тавыш» газетасын япканнары өчен «татар социал-демократларын» гаепли, «март каһарманнары» дип атый («Кояш», 19 декабрь). 21 декабрь баш мәкаләсендә большевиклар милли хәрәкәтне корал көче белән бастыра башладылар диелә.

1918 елгы 4 февраль санындагы баш мәкаләдән исә түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Үләксә янына каргалар җыелган кебек, сабикъ * императорның үләксәсе башына большевиклар менеп утырганнар. Әллә нинди ишекләренә пломбалар салынган вагоннарга утырып Германиядән килгән «каһарманнар», хәзердә Русиягә хуҗа булып, Петроградтан торып, бөтен Русияне җимерәләр». Элек, ди автор, большевиклар арасында татарлар юк иде. «Хәзер инде мөселман эшләрен карый торган комиссариат төзелеп, аның башына татарча язу танымый торган Мулланур Вахитов та менеп утырды». Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Манатов аның ярдәмчеләре булып алдылар. Аларны автор хыянәтчелектә гаепли, куркыта, яный.

Баштагы өч мәкаләнең Әмирхан каләменнән чыкканын яисә чыгу ихтималын таныганым хәлдә, карагруһчылар түбәнлегенә төшкән кадетларча сүгенеп язылган бу мәкаләне кат-кат укыйм да катгый бер фикергә киләм: аны Фатих язмаган һәм яза да алмаган. Беренчедән, көнлек газетаның һәр баш мәкаләсен ул теләсә дә язып өлгертә алмас иде. Икенчедән, мәкаләнең стиле һич тә аныкы түгел. Өченчедән, мәкаләнең эчтәлеге һәм мәсьәләнең куелышы Әмирханның ул чактагы караш киңлеге, фикер дәрәҗәсе белән туры килми. Ленинны һәм иң якын көрәштәшләрен Германия шпионнары итеп караудан ул күп югары тора. Ниһаять, дүртенчедән, тагын бер саллы дәлил — Вахитовны тәмсез сүзләр белән сүгеп чыгу ихтималы юк. Фатих шимбә түгәрәге чорында ук Мулланур белән ара-

* Сабикъ — элеккеге.

лаша башлап, дуслык мөнәсәбәтендә була һәм соңрак та аңа карата ихтирам саклый. 1920 елда ул әле ялкынлы революционерларның шәрык пролетариаты, шәрык ярлылары файдасына ничаклы зур эш башкарганлыгына сокланып, мәкалә язып бастырачак. М. Вахитов Әмирханга карата шулай ук уңай мөнәсәбәттә булган. «Знамя революции» газетасының 1917 елгы 1 декабрь санында басылып, «Корылтай» газетасына һәм редакторы Ф. Туктаровка каршы язылган мәкаләсендә, мәсәлән, мондый сүзләр бар: Ф. Туктаров «...мөселман культурасы өлкәсендә армый-талмый эшләүче танылган язучы Фатих Әмирхановка һөҗүм итә».

Хуш, әлеге баш мәкаләнең Ф. Әмирхан каләме белән язылмаганлыгына ышандык. Шуннан нәрсә? Шуннан — шул: «Кояш» газетасының гомуми политик юнәлеше белән Әмирханның карашлары арасына тигезлек билгесе куярга ярамый! Укучы бәлки онытмагандыр, ярлылар файдасына иганәне ничек җыю хакында бәхәс уңае белән редакция хезмәткәрләренең күпчелеге һәм Әмирхан арасында фикер каршылыгы килеп чыккан иде. Бу очракта да, күрәсең, шуңа охшаш хәл. Яхшы, бусына да ышандык. Әмма үз карашына туры килмәгән материалларны ул ник баса, кире кагарга кодрәте юк икән, ник газетаны ташлап чыкмый?

Ник баса? Матбугат иреге мәсьәләсен, әлеге дә баягы, конкрет шартларны искә алмыйча, буржуаз-демократик рухтарак, ягъни теләсә кем теләсә ни әйтергә, теләсә ни язарга хаклы дип аңлаганлыктан.

Ник ташлап чыкмый? Беренчедән, «Кояш» — аның үз «баласы». Икенчедән, аңлы тормыш юлын җәмәгать эшлеклесе булып башлаган, җәмәгать эшлеклесе булып дәвам иткән һәм җәмәгать эшлеклесе булып калырга теләгән Әмирхан зур тарихи борылыш чорында үз кулындагы матбугат органыннан баш тарта ала идеме? Юк, әлбәттә.

«Кояш» белән Ф. Әмирхан арасыннан — бик үк симез булмаса да — чик сызыгы узганын замандашлары да күрми калмаганнар. «Кызыл байрак», «Чулпан», «Эш» кебек советчыл газета битләрендә «Кояш» адресына тәнкыйть сүзләре ара-тирә очраса да, Ф. Әмирханның үзенә каршы язылган бер генә материал да тапмыйбыз. Җитәкче посттагы татар большевикларының һәм алар белән бер аяктан атлап баручы революцион-демократларның әдипкә булган ихтирамы һәм үз якларына тартырга теләүләре дә роль уйнаган булырга тиеш. «Кояш» газетасының Совет органнары карары белән ябылмаганлыгы, бәлки үзеннән-үзе «сүнгәнлеге» дә очраклы хәл булмаса кирәк. Газетаның

соңгы, яңача 24, искечә 11 июнь санынннан без түбәндәге сүзләрне укыйбыз:

«Идарәдән.

Хәзерге вакытта Русиянең бик күп тарафдарларында эчке сугышлар дәвам итү сәбәпле, почта юллары тукталганлыктан, мөштәриләремезнең күпчелеген тәшкил иткән шул тарафларга газеталарны йибәрергә мөмкин түгел. Шуның өчен гаять кыйммәт бәһагә төшереп газета чыгару акчаны суга салу гына булганлыктан, «Кояш» идарәсе, юллар рәтләнеп, даими рәвештә йибәреп торуга имкян булганчыга кадәр, бу номердан соң нәмәгълүм вакытка кадәр газетаны чыгармый торырга карар бирде».

Шулай итеп, Фатих Әмирхан биш яшь тә алты айга чаклы үстергән «бала»сын үз кулы белән күмеп куя...

Урталыкта өзгәләнеп яшәгән вакытында дөнья Фатихка ал да гөл булып күренмәгән, билгеле. 1918 елның язында әнисе Рабига остабикә вафат булгач исә тормышы беразга бөтенләй шыксызланып кала. Хикмәт Фатихның тәрбиячесез калуында гына түгел. Хикмәт, барыннан да бигрәк, кояш җирне җылыткандай, мәхәббәте һәм мәрхәмәте белән улын җылытып яшәгән иң газиз кешесенең юкка чыгуында. Гаять көчле язылган һәм заманында байтак шаушу тудырган «Тәгъзия» исемле нәсерен анасы үлгәннән соңгы кичерешләренең чагылышы дип уйларга нигез бар. Бу әсәр икенче бер җәһәттән, Әмирханның ул вакыттагы фәлсәфи уйлану һәм эзләнүләрен аңлау җәһәтеннән дә кызыклы.

Яңа гына сабыйлыктан чыккан баласын күмеп кайткаииан соң ата кеше кайгыга чумган карчыгын юатырга тырыша: үлемнән куркырга, үлгәннәр өчен болай ачынырга ярамый, ди. Моны ул түбәндәгечә дәлилли.

1. Үлемнән котылмак юк. «Дөньяга килдеңме — үләргә килдең». Яшәеш ул — «бер күз ачып йому, бер яшен яшьнәп алу».

2. Дөньяны, галәмне һәр яктан җитеш һәм төзек итеп яраткан бөек көчнең тән белән берлектә аның эчендәге рухны, җанны да юкка чыгаруы мөмкин түгел. Дөнья тереклегеннән соң бүтән тереклек булырга тиеш. Җаннар тән кабыгында чакта ук кешегә «югары дәрәҗәдәге тойгылар, бөек дәрәҗәдәге ләззәтләрнең бер кисәкләре килә алганны», әлеге бөек көч, бу җаннар читлекләреннән котылгач, бу җаннар үз өсләрендәге тупас кабыкларын салгач, иң гали ләззәтләргә, иң назик тойгыларга» юл ачмасмыни?

3. Кешеләрнең күңелендә мәрхәмәт тойгысы яши. Әнә шул мәрхәмәтнең чыганагы булган бөек көч киләчәк

тереклектә дә үз мәрхәмәтеннән өлеш чыгармый калмас.

4. Галәмдә хисапсыз күп кояшлар, йолдызлар бар. Аларда билгесез, серле тормыш кайный. Тән эчендә чакта җанга аны күрү һәм аңлау мөмкин түгел. Тән читлегеннән котылган җаннарга исә алар ачылып китәчәкләр.

«Шулай булгач, ник үлемнән куркырга да, ник үлгәннәр өчен сыкранырга, ник хәсрәткә батарга?»

Күренә ки, сүз һәркемне борчыган, борчый һәм борчыячак мәңгелек мәсьәлә — яшәү һәм үлем турында бара. Моңа кадәр дә ара-тирә уйландыра килгән бу мәсьәлә, анасы үлгәч, Фатих каршына бөтен шыксызлыгы белән кабат килеп баскан, күрәсең. Бит һәркем иртәме-соңгы мәңгелек тынлыкка чумачак. Әҗәл белән очланачак яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә? Котылгысыз үлемне ничек тыныч каршыларга?

Баласын җуйган карт әнә үзен дә, карчыгын да җанның үлемсезлегенә ышандырып юаныч тапмакчы була. Фатих ничек? Ихтимал ул да элегрәк, шундый фәлсәфәгә бирелеп, күңел тынычлыгы таба алгандыр. Хәзер дә, саламга ябышкандай, шуннан юаныч эзләгән булыр. Әмма зирәк акылы, киң һәм тирән белеме аңа җанның үлемсезлегенә ышанып җитәргә, белмим, ирек бирде микән? Моны нәсернең үзеннән дә чамаларга мөмкин.

Дәлилләрен сөйләп бетергәч, карт әсәрне тәмамлап куя торган түбәндәге сүзләрне әйтә:

«— Синең үз күзләрең дә яшьләр коялар, синең үз тавышың да кайгылы яңгырый дисеңме, карчык? Әйе, мин дә синең шикелле үк, синең кадәр үк зәгыйфь адәм. Әйе, минем дә күзләрем яшь коялар, тавышым кайгылы яңгырый, йөрәгем парчалана. Ләкин боларның барысы өчен дә мин сәҗдәи шөкер итәм, әйе, сәҗдәи шөкер...»

Карт үзе дә фәлсәфәсенең дөреслегенә ышанып җитми икән ләбаса! Югыйсә югарыда китергән дәлилләрен шик астына алырдай сүзләр ычкындырып ташламас иде.

## 2

Фатихның 1921 елның көзендә яза башлаган көндәлек дәфтәрендә кызыклы мәгълүмат бар. Тормыш турында, агымдагы хәлләр турында үзе аңлаганча, яшерми-нитми сөйләүне гадәт иткән әдипне бервакыт Г. Ибраһимов «Син — контрреволюционер» дип орышкан икән. Шундый ук сүзләр өчен,— дип яза Фатих,— «партиясез зыялылар җыелган кечкенә генә бер эчке мәҗлесендә Газиз Гобәй-

дуллин мине «Син большевиклашасың, большевикларга тәлинкә тота башладың!» дип орышкан иде».

Бу сөйләшүләр кайсы елда булгандыр, билгесез. Әмма алар әдипнең 1919 елның урталарына кадәрге хәл-әхвәлен, фикер-карашларын дөрес чагылдыралар. Симпатиясе һәм антипатиясе аның ике якка да якынча тигез бүленгән. Шуңа күрә бер үк сүзләре өчен бер як аны «контрреволюционер» дип атаса, икенче як «большевик» дип гаепли. Бу яктан да үзләренә тарталар, теге як та бирмәскә тырыша, бу як та үпкә сүзләре әйтә, теге як та шелтәли. Ф. Әмирханның революция башындагы, төгәлрәк әйтсәк, аның беренче ел ярымындагы позициясен «урталыкта» дип атап булыр иде. Кайчандыр урталыкта чайкалган вак буржуаз интеллигенцияне әдәбиятта чагылдыра башлап, шул исемдә роман язарга керешкән әдип үзе урталыкта калды.

Сәбәбе бер генә дә, ике генә дә түгел. Социаль чыгышы, тәрбиясе һәм мохиты да, яшьли фаҗигагә юлыгып күтәртүгә калуы да бар монда. Социализм тәгълиматының әлифбасын үзләштереп тә пролетариат көрәшеннән читтәрәк торуы аркасында дөньяга карашының тиешле рәвеш алып җитмәве дә бар. Акыллы проект буенча дөрес алып барыла торган төзелеш мәйданы читтән торып караган кешегә хаос булып күренгән шикелле, Әмирхан да әнә шул чокыр-чакыр, чүп-чар эченнән мәһабәт бина үсеп чыгачагын күз алдына китерә алмаган, билгеле.

Инде килеп, искене җимерү һәм яңаны кору эшләре дә, нота буенча уйный торган оркестр кебек, партия карарлары, Ленин күрсәтмәләре кушканча гына бармый. Хаталар да җибәрелә, ахмаклыклар да эшләнә, иске дип файдалысын кырып ташлау, яңача идарә итә белмәгәнлектән, шул ук чиновниклык-бюрократлык ысулына кайту очраклары да булгалап тора. Октябрьдән соң партиягә кергән һәм совет-партия аппаратларына урнашып алган кешеләрнең дә һәркайсын чын коммунист итеп карап булмый. Көтү башында йөрергә яратканлыктан яисә «җаваплы паек»ка өмет итеп килгәннәре дә очрый.

Әнә шуларны күрмәсә яки күреп тә дәшми калса, ул Фатих Әмирхан да булмас иде. 1917—1918 елларда, мәсәлән, хуҗалары качкан иң матур һәм нәкышлы йортларга гаскәр китереп тутырганнар. Солдатлар, буржуазный дип, өй җиһазларын, паркет идәннәрне ватып-куптарып ягалар, ванна һәм пар мичләрен җимерәләр, люстраларны, тәрәзә пыялаларын кыралар. Әгәр, ди Әмирхан, бу биналар ватып бетерелмичә сакланган булсалар, бүген шул ук пролетариат һәм ярлы крестьянның баласы өчен җылы, уңайлы, төзек

мәктәпләр, балалар йортлары, шул ук пролетариат һәм ярлы крестьянның үзләре өчен менә дигән төзек шифаханә, клуб, көтепханә, торак булып хезмәт итмәсләр идемени?

1919 елның башында Фатихны Московский урамындагы (хәзер Киров урамы) бер генерал йортын биләгән коммунистлар клубына тар җыелышка чакырганнар. Казармага әверелдермәгәнгә күрә бу бинаның эче — ишек-тәрәзә, диварлары һәм җиһазы элеккечә сакланган. Барысы да ялт итеп тора. Безнең Фатих күзәтүче генә булып каламы соң! Җаен туры китереп һәм йомшарта төшеп, ул югарыда китерелгән фикерләрен сөйли. Көтү башында йөрүне сөючеләрнең берсе, Әмирхан тәгъбиренчә вак карьерист һәм ура-коммунист болай дип җавап биргән: «Массаның үзенең психологиясе, үзенең дәрте, теләге бар. Революцияне удачно алып барыр өчен аның шул инстинктларына да юл куярга кирәк. Ул җимерергә телиме, әйдә бераз җимерсен, күңеле кайткач үзе дә туктар, җимерү урынына төзәтергә керешер. Хәзер әле революциянең ул дәвере җитмәгән».

Күп милләтле Россия шартларында иң четерекле мәсьәләләрнең берсе, мәгълүм булганча, милли мәсьәлә. Яңа революцион күтәрелеш елларында В. И. Ленин, зур-зур хезмәтләр язып, бу мәсьәләне теоретик яктан тирән итеп нигезләгән һәм практик рәвештә тормышка ашыруның юлларын сызган иде. Соңыннан да бу мәсьәләгә еш кайта торды. Октябрьдән соң үзәктә кайнар башлар килеп чыгып, власть пролетариат кулына күчкәч милли мәсьәлә икенче рәвеш алды, Россиядән аерылып чыгу ирегенә кадәр илтә торган үзбилгеләнү хокукын яклау илне таркалуга алып бара, милләтчелекне көчәйтә дип сөйли һәм яза башладылар. РКП(б)ның Казан губкомы һәм Советның губерна башкарма комитеты әгъзалары арасында да шул караштагы торучылар бар иде. Татар коммунистларыннан да аларга иярүчеләр табылды.

Милли мәсьәләне йөрәгенә аеруча якын ала торган Ф. Әмирхан бу карашның ленинчыл милли политиканы бозу икәнен баштарак абайлап җиткермәде. Аны билгеле бер вакытка кадәр урталыкта торткан сәбәпләрнең тагын берсе шушы.

Хәер, тарихта тиңе булмаган гадәттән тыш зур тарихи борылыш дәверендә урталыкта калучы бер Фатих Әмирхан гына идемени! Эсер һәм меньшевиклар арасындагы намуслы шәхесләр турында әйтеп тә тормыйк. Хәтта большевиклар эченнән дә, паникага бирелеп, Россиядә социалистик революция ясау иртәрәк түгелме, властьны кулда то-

тып калырга көч җитәрме, аны бүтән кулларга бирү хәерлерәк булмасмы дип уйлаучылар килеп чыкты.

Яисә менә Алексей Максимович Горькийны алыйк. Совет властеның буржуаз һәм вак буржуаз матбугатка, буржуаз интеллигенциягә карата каты чара куллана башлаганын күреп аптыраштa калган әдипнең еш кына Ленин янында булганлыгы, икеләнүләре белән уртаклашканлыгы һәм большевиклар җитәкчесенең «күзен ачарга» омтылганлыгы билгеле. Сүзен берничек тә үткәрә алмагач, Горький «Новая жизнь» исемле ярым меньшевистик газетага мәкаләләр язып бастыра башлый һәм, шуларны бергә туплап, брошюра итеп чыгара.

Ленин, Горькийны кеше итеп тә, даһи әдип итеп тә яратканга, гаять саклык күрсәтә, хаталарыннан арындырып, дөрес юлга төшерү өчен күп көч куя. Бу бәйләнештә 1919 елның 31 июлендә язылган хаты аеруча зур әһәмияткә ия.

В. И. Ленин Горькийның ул вакыттагы уй-фикер һәм хис тойгыларын илнең иң «авыру» ноктасы булган Петроградта аеруча көчәеп киткән «авыру» караш, «авыру» тойгылар итеп бәяли. Ник Питер «авыру» нокта? Чөнки пролетариатның каймагы фронтка һәм авылга китеп бетеп, шәһәр «эшсез» калган югары дәрәҗәле буржуаз интеллигенция белән мыжгып тора. Горький әнә шул интеллигенция чолганышында яши. Петроградтан торып, ди Ленин, язучы кешегә Россиядә нинди процесс барганны күрү һәм аңлау мөмкин түгел. «Күзәтергә икән, түбәндә, тормышны яңача төзү эшен күрерлек урында, провинциядәге эшчеләр поселогында яки авылда күзәтергә кирәк... Сез бирдә, художник буларак, армиядәге яңалыкны да, авылдагы яңалыкны да, фабрикадагы яңалыкны да күзәтә һәм өйрәнә алмыйсыз». Хатын Ленин түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «...шартларыгызны, мохитыгызны да, тору урыныгызны да, эшегезне дә нигездән үзгәртегез, шунсыз тормыштан бөтенләй туярга мөмкин» *.

Казан да бит бу вакытларда «эшсез» калган иттифакчылар, «Милли шура» һәм «Хәрби шура» башлыклары, эсер һәм меньшевикларга тартым вак буржуаз интеллигенция, милләтчелек белән миләре түнгән журналист, язучы, юрист, врач һәм укытучылар белән мыжгып тора. Әмирханны үзләренеке итеп яисә итәргә тырышып тирәсендә тыз-быз йөрүләре эзсез калган дисеңме?

---

* К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, 279—281 битләр.

А. М. Горькийның чайкалып алуын искә төшерү икенче яктан да әһәмиятле. Каршылыклар эчендә калып дөрес юлны эзләгән Фатих, бүтән чыганаклардан кала, үзәк матбугатны да җентекләп күзәткән. Горький мәкаләләрен укып баруы да ихтимал. Әгәр шулай булса, үзе хөрмәт иткән бөек әдипнең «авыру» рухи хәле аңа да йокмый калмаган.

Урталык дип сөйлибез сөйләвен дә, кем кемне мәсьәләсе хәл ителгән бер вакытта бу асылда мөмкин түгел. Гражданлык тойгысы белән сугарылган актив шәхес булсаң — бигрәк тә. Ф. Әмирханның «Кояш» газетасы битләрендә ачыктан-ачык Советларга һәм большевиклар партиясенә каршы язылган материалларга юл бирүе генә түгел, бәлки үз мәкаләләре дә объектив рәвештә каршы як лагере тегермененә су кою булып чыктылар дип әйтми мөмкин түгел.

Монысы шулай. Әмма Ф. Әмирханның «урталыкта» торып калуына түгел, бәлки аның хәлендәге кешенең чагыштырмача тиз — 1919 елның икенче яртысында ук — баррикаданың без теләгән ягыннан урын алуына гаҗәпләнергә кирәк. Бу турыда әле сүз булыр. Хәзер исә аның көнкүрешенә һәм язучылык эшчәнлегенә күз ташлап китик.

## 3

Фатих шунда ук, Яңа бистәдә, төп йортларында яшәп ята. Әтисе белән аралары зарланырлык түгел. Элек тә политик активлык ягыннан бик үк аерылып тормаган Зариф хәзрәт бу болганчык һәм хәвефле заманда, алга сикереп чыкмыйча, күләгәдәрәк калырга тырыша. Фатих та аңа хәзер әллә ни борчу тудырмый. Вахит мәзин улы Мәхмүт кебек, большевиклар ягына чыгып, кеше рәнҗетеп йөрсә, ни эшләр идең? Дөрес, Ибраһим большевиклыкка язылды язылуын, әмма киртә сикерми. Фатих та аның бу эшенә тыныч карый, араларында низаг чыкканы юк. Заманына карап шулай кирәктер, күрәсең.

Хатын-кызлардан гаиләдә, асраудан кала, ике кеше: Рабига абыстай һәм Ибраһимның хатыны Нәфисә. Соңгы вакытта бирешә төшсә дә, абыстай хуҗалыкны үз кулында тота. Ник дигәндә, килен килен инде. Җитмәсә, Нәфисә, җиңелрәк табигатьле булып, уен-көлке ярата төшә, ашсуга осталыгы да чамалы. Рабига остазбикәнең бит әле, картыннан кала, ярдәмгә мохтаҗ Фатихы бар. Хуҗалыкны кулдан ычкындырдыңмы, аның кирәкләрен җиткереп

тору, күңелен күрү, татлырак кисәкне каптыру шактый кыенлаша...

Фатихка кайтыйк. Көннәре ничек үткән соң? Элеккечә. Аяк тавышлары тынгач ул яза. Икенче көнне соң гына торып, чәй эчә дә аның өчен махсус кайтартылган газеталарны күздән кичерә. Аннары, атын җиктереп, редакциягә китә.

Кичләре төрлечә уза. Ул вакытта сирәк була башлаган әдәби кичә, концерт һәм спектакльләрнең берсен дә калдырмый. Аерым гаиләләрдәге мәҗлесләрдән дә калмый. Кемгә бару, кемгә бармауны политик исәп-хисап белән билгеләми. Татар коммунистлары һәм алар белән эшләшә башлаган кешеләр мәҗлесендә булган кебек, каршы як тарафдарларының чакыруын да кире какмый (ике якның да ни эшләгәнен, нәрсәне хуплап, нәрсәне хупламаганын белү зарар итмәс). Фатихның үз бүлмәсендә дә кеше өзелми дип әйтерлек. Килүчеләр шулай ук чуар: «бу якныкылар» да, «теге якныкылар» да була.

Берәр төшкә бармаган һәм кунаклар булмаган кичләрен укып уздыра. Укыйсы нәрсәләр исә күп, чөнки илдәге текә борылышның мәгънәсенә төшенәсе бар.

«Урталыкта» калып, эчке һәм тышкы каршылыклар эчендә өзгәләнеп яши башлагач, бу рухи хәле тышка бәреп чыгарга һәм Фатихны кырыс табигатьле, караңгы чырайлы кеше итәргә тиеш иде кебек. Яше арту белән бәрабәр басынкылана төште төшүен. Әмма, эчендәген яшерә белгәнлектән, ул элеккеге Фатих булып калды дип әйтерлек. Акыл сатмас, юк-бар сөйләр, мәзәкләштерер, көләр, көлдерер.

Күзгә ташланырдай бер үзгәреш бар барын. Ул да булса — преферанс уенына кергәннән артык вакыт бирә башлады.

Танышларыннан берәү шулай шимбә көн кич Әмирханнарга килгән. К. Тинчурин, И. Биккулов, И. Кули һәм хуҗа үзе преферанс уйнап утыралар. Янәшәдәге өстәлдә — самовар, чынаяк-тәлинкәләр, төрле ашамлык.

Уен күңелле бара. Фатих авызыннан бормалы җор сүзләр коелып торган кебек, Тинчурин да сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел. Сәгать артыннан сәгать уза, ярты төн якынлаша. Соңыннан килгән кунак китәргә җыенып, Фатихның партнерларын да үзе белән чакыра. Тегеләр көлеп кенә куялар. Икенче көнне кичкә таба әлеге иптәше — нинди дер йомышы булгандырмы — тагын килеп чыга. Ни күзе белән күрсен, шул ук кешеләр, шул ук өстәл тирәсендә шул ук рәвештә уйнауларын дәвам итә-

ләр. Балта эләрлек төтен. Янәшәдәге өстәл чәй карасы утырган чынаяклар, ипи катылары, сыр кисәкләре, балык сөякләре белән тулган. Тәмәке төпчекләре көл савытына сыймыйча, өстәлгә коелып төшкән. Уйнаучыларның күзләре кызарып, йөзләре агарып калган.

Истәлекченең язуына караганда, ул бу эшкә хәйран калып һәм Ф. Әмирханны гаять кызганып, үгет-нәсихәттән үзен тыеп кала алмаган: саулык өчен бу бик зарарлы, һич ярый торган эш түгел, туктата күрегез. Фатих, пенсне пыялаларын ялтыратып, вәгазьчегә елмаеп караган да Тукай сүзләрен беркадәр үзгәртеп җавап биргән:

Бозмасын мәҗлес хозурын уйнамас, белмәс кеше,
Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше!

Яз җитеп, җәй ягына авыша. Кая булса да чыгып керәсе иде бит. Ләкин быелгы кебек болганчык заманда кая бара аласың? Әстерханга яисә Уфага китү мөмкин түгел. Кырым-фәлән турында уйларга да юк. Кала бер җир, ул да булса Чистай. Анда ат белән дә барып җитәргә мөмкин.

«Кояш» газетасы туктар-туктамас ук Фатих җыена да шул Чистай ягына юл тота. Күпме булган ул анда, ни эшләгән — болары мәгълүм түгел. Атыннан мәхрүм кала язганын гына беләбез.

Чехлар корпусы, баш күтәреп, Советлар республикасына каршы һөҗүм башлаган чак була бу. Пенза ягыннан килүчеләре әнә Самараны алганнар. Себердән ябырылучылары, Чиләбене алып, Уфага куркыныч тудырганнар. Һәр җирдәге кебек, Чистайда да чехларны һәм аларга кушылган ак гаскәрне тар-мар итү өчен кызу әзерлек бара. Шул исәптән атларга мобилизация башлана. Әмирханга да повестка тоттыралар: атыңны регистрациягә китер. Комиссияне үтсә, ай-ваена карамый, атын алачаклар. Фатих Мөселман эшләре комиссариатының Чистайдагы башкарма комитетына мөрәҗәгать итә. Комитет, үз чиратында, Ф. Әмирханның кемлеген әйтеп, атын караудан азат итүнең кирәклеге турында Совнархозга үтенеч кәгазе җибәрә. Үтенечен, күрәсең, канәгатьләндергәннәр, әдип, чехлар Чистайны килеп басмагайлары дип, Казанга ашыга.

Фатихка килмешәкләрнең һәм акгвардиячеләрнең «нурлы йөзен» күрергә насыйп булган икән: 7 августта чехлар Казанны алалар һәм яңа тәртип урнаштыра башлыйлар. Яңа тәртип дигәннәре партия-совет органнарын туздыру, кулга эләккән җаваплы работникларны төрмәгә тыгу, ату, урыннарына үзәге Самарада булган Учредилка «хөкүмәте» кешеләрен утыртудан гыйбарәт. Әллә кайдан, ярыклардан,

идән астыннан татарның Советка дошман кешеләре,— шурачылар, бай балалары, офицерлар килеп чыгып, тегеләрдән бер дә калышмыйча, ара-тирә уздырып та җибәреп, җимерә, вата, кан коя башлыйлар.

Казанның яңа хуҗалары, «бер сәгатьлек хәлиф»ләргә Әмирханның мөнәсәбәте нинди иде? Әйдәгез, бу турыда үзен тыңлыйк.

«18 нче елның август ахырларында, әле Казан Учредительный собраниечеләр һәм чехлар кулына кереп, алар властенда торган вакытта көннәрнең берсендә мин атым белән Тукай площадена килдем. Җеназа укыла торган чардуган эчендә нindидер бер митинг бара. Мин дә, чардуган янына килеп туктап, нәүбәттәге хатыйпның * сүзен тыңларга керештем. Учредилкачыларның шул көннәрдә Казанда власть башында тора торган берсе сөйли иде. Ул чикылдаган татар арасына төшеп, гаять ахмакана бер сурәттә татарларны «Менә без Германияне җиңгәнгә чаклы сугышны дәвам иттерергә уйлыймыз, менә без мөттәфикъләремезгә ** һаман садакатта *** калуны беренче дәрәҗәдә мөһим саныймыз, без галәм сугышыннан җиңеп чыкканга кадәр барачакмыз» дип, ак армиягә күңелле булып язылырга өнди һәм шул эшләргә бер генә татарның бер генә кул чабу белән дә үзенең хөсне мөнәсәбәтен **** күрсәтмәвенә карамастан, һаман дәртләнеп, сугышны дәвам иттерү белән татардан сөенче алуында дәвам итә бирә иде. Бу — яисә үзенең аңар карап сөйли торган җыелышыңның психологиясен ишәкчә бер тупаслык белән аңламау, яисә шул ук хайван кирелеге белән, мин үземнекен әйтеп калам, дигән сүз иде». Халык тарала башлаган. Фатих янында басып торган берничә кеше дә, «әле болар һаман бер балык башын чәйниләр икән» дип, китеп барганнар.

Бу фетнә Әмирхановлар гаиләсенә дә бәхетсезлек китерә язган. Учредилкачылар урта һәм кече офицерларга мобилизация игълан итәләр. Ибраһим — унтер-офицер. Нишләргә, регистрациягә барыргамы? Юк, ди Фатих, качарга! Озакламый Әмирханга тагын бер нәрсә мәгълүм була: милләттәш саналган берничә кеше мобилизациядән качып йөрүче күренекле татарларның исемлеген төзеп биргән һәм яңа власть аларга карата каты чара күрергә җыена икән. Ибраһимны Кызыл Армиянең Казанга һөҗү-

---

* Хатыйп — оратор.
** Мөттәфикъ — союзник.
*** Садакат — турылык.
**** Хөсне мөнәсәбәт — матур, уңай мөнәсәбәт.

ме һәм аклар белән чехларның шәһәрне калдырып чыгулары гына коткарып калган.

...Язучы язмый тора алмый. Ф. Әмирхан да әдиплек каләмен сандыкка салып куймаган, билгеле. Башында күп сюжетлар йөри, әллә ничаклы типлар җанланып килә иде. Ничек инде шуларны эчтә калдырасың?

Менә «Сибгатулла абзый» исемле хикәя һәм аның «герое». Томана надан буларак динне ата-бабаларыннан гына ишетеп белә, әмма кагыйдәләрен фанатикларча төгәл үтәргә тырыша. Ишектән ул уң аягына гына атлап керер, эшкә бисмилласыз тотынмас. Намаз укыганда ике аяк арасы кул яссуы кадәр микән дип, үлчәп карый, рөкугка иелгәч, аркасына сулы савыт куярга куша, янәсе, тигез торамы. Киез эшләпәсенең бер читен кисеп, ерык итеп куя: кяферләр эшләпәсенә охшамасын. Төшендә хайван күрсә, торгач, ул хайванның йонын яндырып исни.

Тормышында һәм иҗатында актив булып, заманнан калышмаска тырыша торган Ф. Әмирхан иске заман, иске типлар белән генә чикләнә алмый иде. Ул бүгенгегә, яңа чынбарлыкка да әдип сыйфатында үз мөнәсәбәтен белдерми калмады. Аның, мәсәлән, үзәгендә морза кызы Зөләйха торган ниндидер күләмле әсәр язарга керешкәнлеге билгеле. Бер кисәге 1918 елда «Канвалардан берсе» исеме астында басылып та чыга. Өч егет, өч кыз гостиница номерында тәртипле генә, нәзакәтле генә күңел ачып утырганда, шакып та тормыйча, бер кеше килеп керә. Чакырганны да көтмәстән өстәл янына килеп утыра, шешәдән үзе салып эчә һәм авызын чапылдатып ашарга керешә. Мишәрчәләтеп туктаусыз сөйли, шапырына, үзен комиссар дип белдерә. Төгәлрәк әйтсәк, мәгариф органнарында җаваплы хезмәткәр, Февральдә өскә калыккан «март социалисты», «октябрь каһарманы». Зөләйха бу кешедән җирәнеп утыра, номер хуҗасы Нугманның куып чыгару урынына, аңардан курыккандай, нәзакәтлелек сакларга тырышып сөйләшүенә аптырый. Арадан бер егет «комиссарны» куып чыгаргач, Зөләйха үзе ошатып йөргән Нугманга карата тәмам суына.

Әсәрнең кульъязма хәлендә саклана торган кисәгендә без Зөләйханы театрда күрәбез. Ул ялгызлыктан интегә, каршылыклы хис-тойгы, уй-фикерләр эчендә яши.

Театр залында Зөләйха яңа публиканы, ягъни революция чорында калыплаша башлаган типларны күзәтеп утыра. Әнә гаскәри мәктәптә укучы егет. Подумаешь, юнкер! Әнә күн киемле кеше. Учительская школаны бетергән, хәзер — комиссар. Зөләйханы өеннән куып чыгарып, клуб

ясады. Тупас, тәрбиясез. Шушы кеше губернада агарту эшләре башлыгы! Әнә тагын бер егет. Анысы элек приказчик иде, хәзер — бай спекулянт. Ул Зөләйха белән, ярарга тырышып, үзе исәнләшә, ләкин кыз аңа борын җыерып карый. Хатыны Шәмсеруй — гимназия тәмамлаган кыз — байлыкка кызыгып кияүгә чыккан. Зөләйха тыелган брошюрадан кайчандыр ниндидер бер социалистның «Буржуазный гаиләдәге хатын белән буржуазный обществодагы фахишә арасында аерма шунда гына: боларның соңгысы үз тәнен ваклап сата, әүвәлгесе оптом сата» дигән сүзләрен укыган. Неужели, неужели алар хаклы?

Күренә ки, Зөләйха буржуадан җирәнә, большевикларны күралмый. Ләкин соңгыларына карата аңарда хөрмәт тойгысы туып килә.

Әмирханның архивында әнә шундый башланып та төгәлләнми калган хикәя, пьеса һәм повесть «кыйпылчыклары» байтак. Күбесе шул заман турында, революциядән соңгы чынбарлык турында. Әмма алар тирәндәге агымны күреп җиткермичә, күбрәк шул агым кагуыннан калкып чыккан чүп-чарны күзәтеп язылганнар. Шуңа күрә аларны яңа тормыш турында яңача язылган һәм Ф. Әмирхан талантына тәңгәл әсәрләр итеп карап булмый. Хәер, Фатих хәлендәге кешедән шуннан артыгын таләп итү урынсыз булыр иде. Әнә Октябрь таңында ук большевиклар белән бер аяктан атлап киткән Г. Ибраһимов та яңа хакында яңача язылган беренче әсәрләрен 1920 елда гына бирә алды. Совет платформасына күчүдә Г. Ибраһимовтан күп калышмаган Ш. Камалга исә моның өчен артыграк вакыт кирәк булды. Аның революциядән соңгы хикәяләре 1924 елда гына күренә башлады...

## 4

Ф. Әмирханның дөньяга карашындагы борылыш РКП(б)ның VIII съезды һәм Фатихның шушы съезд раслаган яңа программаны тәрҗемә итүе белән бәйле булса да, ул электән әзерләнеп килгән иде.

Күптән түгел гаскәри хезмәттән кайтып эшкә чумган һәм шинелен дә алыштырырга өлгермәгән Мәхмүт Бөдәйли 1918 елның җәй башларында, Ф. Әмирхан белән танышырга теләп Яңа бистәгә, Зариф хәзрәт өенә килеп чыга. Фатих аны якты йөз белән каршы ала; яңа кеше булсын да, ул кеше белән берлектә, яңа хәбәр, яңа мәгълүматлар килеп керсен аңа.

Чәй янында күп сүз була. Революция, илне торгызу, яңа җәмгыять кору турында. Бөдәйлине гаять гаҗәпләндергәне шул: Әмирхан Маркс һәм Ленин тәгълиматын өйрәнүнең кирәклеген әйтү белән бергә, алардан мул итеп цитаталар китереп сөйләгән. Нәрсә бу, танылган «милләт хадиме»нең яшь «комиссар» алдында аклануы һәм үзен Совет яклы кеше итеп күрсәтүеме?

Икенче көнне Фатих яңа танышын сабан туе карарга чакырган. Бөдәйли килеп җиткәндә Ф. Әмирхан инде җигүле тарантасына менеп җирләшкән, ә кучер малай ашык-пошык чәй эчеп утыра икән. Дилбегәне Фатих үзе тоткан килеш, сабан туе буласы мәйданга барып җитәләр. Халык байтак җыелган, уеннар башланганны көтәләр. Ф. Әмирханны шундук танышлары һәм дус-ишләре сырып ала, күрешү, хәл-әхвәл сорашу башлана. Бөдәйлине тагын бер кат гаҗәпләндергәне шул була: танышларының иң күбесе партия-совет аппаратларында югары пост биләүче работниклар: М. Дулат-Али, Ш. Әхмәдиев, Ә. Мөхетдинова һ. б. «Менә шунда инде мин,— дип яза истәлекче,— Ф. Әмирханның «комиссарлар» арасында үз кеше булуына, аны якын итүләренә, аның белән санашуларына ышандым. Димәк, кичәге сүзләр яхшатлану, «кызыл булып» күренергә тырышу өчен генә сөйләнмәгән икән».

Бөдәйлинең әйткәннәрен шик астына алып булмый. Буяуларны куерта төшеп, бераз арттырса да, күп арттырмаган. Югарыда исемнәре саналган кешеләрнең берсенә — Мәхмүт Дулат-Алигә генә тукталып китик.

Фатих кебек үк Яңа бистәдә туып үскән, Фатих кебек үк «Мөхәммәдия»дә укыган, «Ислах комитеты»нда бирелеп эшләгән. Х. Ямашевның кардәше буларак, беренче татар большевигының йогынтысын яшьтән үк татып үскәнгә, политик аңы бик тиз формалашкан. 1907 елда ул РСДРП әгъзасы. Революцион эшчәнлеге өчен кулга алыну куркынычы тугач, Урта Азиягә китә. Анңары — сугыш, солдатлар арасында политик-агарту эше алып бару. Февраль революциясеннән соң Дулат-Али — 5 нче армиянең мөселман хәрби комитетында әгъза. 1918 елда ул эчке Россия мөселманнары комиссариатының бүлек мөдире. 1919 елда — РКП(б)ның Казан губкомы каршындагы мөселман секциясе бюросының председателе.

Революциядән соң да Ф. Әмирхан Дулат-Али белән тыгыз элемтәдә була. 1919 елның 6 мартында Дулат-Алиның, мәсәлән, Фатихка егермеләп исемдә политик эчтәлекле китап җибәрткәнлеге билгеле. Арада В. И. Ленин әсәрләре, А. Бебель, В. Либкнехт, И. Степанов-Скворцов хез-

мәтләре булган. Партиянең яңа программасын Ф. Әмирханнан тәрҗемә иттерүдә Дулат-Алиның катышы булганлыкка шикләнмәскә мөмкин.

Партия-совет җитәкчеләре алдында Ф. Әмирхан, билгеле, ләббәйкә дип кенә тормаган. Кайбер мәсьәләләрдә килешмәгән, бәхәскә кергән, кайберләрен каты гына тешләп тә алгалаган. Шулай да кылган гамәлләрен күреп тору, фикер-карашларын ишетү эзсез калмаган.

Чехлар фетнәсе дә Фатихка үзенчәлекле сабак бирә. Энесе Ибраһимга куркыныч янаганлыгы турында сүз булган иде. Якын кешеләреннән Габдрахман Рәфыйков та әнә төрмәдә утырып чыкты. Фатихны аеруча тетрәткәне С. Н. Гассар һәм М. Вахитовның аклар тарафыннан атылуы була. Әнә шуларны күреп уздырган Ф. Әмирханның чехлар койрыгына тагылып килгән рус һәм татар учредилкачыларының чын йөзен танып алу гына түгел, бәлки кайчандыр үзе идеал иткән Учредительное собраниегә бөтәнчә карый башлавы табигый иде.

Фатихның бу вакыт аралыгындагы яшәеше кайгы-борчулардан гына тормаган, шатлык-куанычлар да арага кергәләгән. 1918 елның 29 январенда, мәсәлән, «Новый клуб» сәхнәсендә аның «Тигезсезләр»е уйнала. Рокыя ролен Ә. Синаева, Сәлимәне Г. Болгарская башкарган. 1919 елның 18 апрелендә «Яшьләр» пьесасы күрсәтелә. Болар Әмирханның аңында әзерләнеп килә торган борылышка өстәмә бер этәргеч булып төшәләр: большевиклар сәнгатьне җимермиләр икән ләбаса, киресенчә, аны халыкка якынайтырга тырышалар.

1919 елның 18 мартында РКП(б)ның VIII съезды ачыла һәм Ф. Әмирхан аның эшен җентекләп күзәтеп бара башлый. Аеруча кызыксындырганы, билгеле инде, милли мәсьәлә. Съездда бу мәсьәлә буенча Ленин һәм ленинчылар белән башлыклары Бухарин булган «сул» коммунистлар арасында принципиаль бәхәс кабынып ала.

Бухаринчылар фикеренчә, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын таләп итү элек, ягъни самодержавие заманында урынлы һәм дөрес иде. Хәзер исә, власть пролетариат кулына күчкәч, ул төбе-тамыры белән дөрес түгел. Чөнки милләт эчендә буржуазия дә бар. Без, коммунистлар, ничек инде кан дошманыбыз булган буржуазиягә үзбилгеләнү хокукы бирә алабыз?! Шуңа күрә автономияле милли республикалар ясау кирәксез, ул гына да түгел, зарарлы нәрсә.

Юк, ди Ленин, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын инкяр итү элек изелеп килгән милләт эчендәге сыйнфый

каршылыкларның кискенләшүен тоткарлау, хезмәт ияләрен милли буржуазия кочагына этәрү, ахыр чиктә шул ук монархия һәм рус буржуазиясе политикасын үткәрү булыр иде. Бу исә бөекдержавачыл шовинизмнан бүтән нәрсә түгел.

Бухаринчылар съездда хур булып җиңелделәр, кабул ителгән программада Ленин формулировкасы урын алды. Ләкин бу әле бухаринчылар хаталарын танып, шундук корал ташладылар дигән сүз түгел. Милли төбәкләрдә, шул исәптән Казан губернасында, милли мәсьәләне «сул» коммунистларча аңлый торган партия-совет работниклары байтак иде. Шундыйларның берсе К. Грасисны 1918 елның маенда Татар-Башкорт республикасының оештыру съездын әзерләү буенча Халык Комиссарлары Советы тарафыннан чакырылган киңәшмәдә М. Вахитов та кискен төстә тәнкыйтьләп чыккан иде.

Бөекдержавачыл шовинизм исе килә торган әнә шул хаталардан арыну өчен әле шактый вакыт кирәк булды. Бу бәйләнештә И. И. Ходоровскийның истәлеге гаять зур әһәмияткә ия. 1919 елда ул үзәктән җибәрелгән һәм Казан губерна башкарма комитеты председателе итеп сайланган.

Эшкә керешүе белән үк Ходоровский совет-партия органнарындагы рус иптәшләр белән татар коммунистлары арасында киеренке мөнәсәбәт яшәгәнлегенә игътибар иткән. Губком президиумының җиде әгъзасыннан берсенең генә татар булуын һәм 25 әгъзалы губисполкомда татарларның 2—3 тән артмаганын да ул нормаль хәл түгел дип тапкан. Үз-үзенә тәнкыйть күзе белән карап язылган әлеге истәлеген И. И. Ходоровский болай дип дәвам итә. «Татар республикасы ишек шакый, ниндидер кискен һәм хәлиткеч борылыш ясарга кирәк иде. Без исә, күп дигәндә, ярым чаралар һәм вак-төяк белән чикләндек, ә күбрәк очракта татар иптәшләрнең чудаклыкларыннан теш ыржайтып көлә идек.

— Кая инде аларга республика белән идарә итү, моңа алар бөтенләй әзер түгел! Буш хыял бу».

Моның белән генә дә чикләнмичә, И. И. Ходоровский, ике хезмәттәше белән берлектә IX партия съезды көннәрендә В. И. Ленин янына кергән һәм Татар республикасы ясауның кирәксез, хәтта зарарлы эш булганлыгын исбат итәргә азапланган. Бөек юлбашчы яныннан алар кикрикләре шиңгән хәлдә чыгалар. «Без, Казанга кайтып, иптәшләргә Владимир Ильич белән булган әңгәмәне сөйләгәч,— дип дәвам итә И. И. Ходоровский,— безнең иптәш-

ләрнең (нигә яшереп торырга?) кәефе кырылды һәм мәсьәләнең шулай хәл ителүен (республика файдасына — *И. Н.*) «хата» итеп санадылар».

Съезд тәмам, Фатих, теоретик һәм политик яктан шактый әзерлекле килеш, яңа программаны тәрҗемә итәргә керешә. Эш процессында аңа тагын күп хакыйкатьләр, шул исәптән моңарчы белми йөргән, әмма белергә тиешле нәрсәләр ачылып киткән. Әмирхан тагын иҗтимагый фикер тарихына чума, тагын Маркс һәм Ленин хезмәтләрен тирәнтен өйрәнергә керешә. Бер төркем җитәкче работникларның үзбилгеләнү һәм автономия мәсьәләсендә Бухарин фикерен алга сөрүләрен коммунист иптәшләреннән бик яхшы белеп торган Ф. Әмирхан бу очракта да, билгеле, битараф кала алмый иде.

Татар-Башкорт комиссариатының хәрби бүлеге органы булып Мәскәүдә чыга башлаган «Кызыл Армия» газетасы 1919 елның март башында Казанга күчә. Күпмедер вакыттан соң Фатихны бу газетага даими язышучы һәм редакция хезмәткәре итеп чакыралар. Аның икәнлеге тәгаен билгеле булган беренче материал — укытучы Габдрахман Рәфыйковның 25 еллык юбилеена багышланган мәкалә — 21 сентябрь санында дөнья күрә.

«Марксист» дигән имза белән чыккан икенче материал — «Ләфызпәрәстлек * кенәме, лакейлыкмы?» исемле мәкалә. Ни өчен безнең Фатих яңа, җитмәсә җаваплы псевдоним алды әле? Үзе бу турыда әйтеп калдырмаганга күрә, тагын фараз итәргә туры килә. Ул, күрәсең, Ленин һәм большевиклар позициясеннән торып язылган бу мәкалә белән моннан ел-ел ярым элек дөньяга чыккан мәкаләләре арасында мәгънә ягыннан туры килеп җитмәүне исәпкә алган. Дус бар, дошман бар дигәндәй, әйдә Фатихның «кызылланып» китүен хәзергә белми торсыннар. Фатихка хас шуклык, киная һәм чеметеп алу да булса кирәк: сез үзегезне марксист дип йөрсәгез дә, мин, партиясез кеше, марксизмның милли мәсьәләгә карашын сездән ким белмим, товарищлар.

Фатих Әмирхан турыдан-туры һәм ачыктан-ачык түбәндәге сүзләрне яза. «Октябрь революциясен нәзари һәм гамәли ** яктан идарә итүче әһле тәфәккер революциянең әүвәлге көненнән үк милләтләр мәсьәләсе белән күзгә-күз очрашты вә шул көннән үк бу мәсьәләне хәл итүдә иң

---

* Ләфызпәрәстлек — хәрефкә ябышып яту, буквоедство.
** Нәзари һәм гамәли — теоретик һәм практик.

радикальный юлны ихтыяр итеп, олуг революциянең кызыл әләменә язды:

«Һәр милләтнең тәкъдире шул милләтнең үз пролетариаты кулына тапшырыла, һәр милләт мөстәкыйль сәяси яшәү хакына маликтыр». «Әһле тәфәккер», ягъни фикер ияләре дигәндә, авторның Ленинны һәм аның фикердәшләрен күздә тотканлыгы тылмачсыз да аңлашылса кирәк.

Ә «сул» коммунистлар, бухаринчылар, Әмирхан фикеренчә, милли мәсьәләдә — ләфызпәрәстләр, ягъни хәреф күшәүчеләр. Алар «коммунизм» нәзариятенең гарептә *, берәр генә милләт тора торган олуг мәмләкәтләрдә вөҗүткә килгән рәвешен хәрефкә-хәреф Россиядә тәтабык ** итәргә» омтылалар һәм шуның белән, телиләрме, юкмы, «великодержавный милләтчелек»не алга сөрәләр.

Татар коммунистлары арасында да, ди Әмирхан, бер төркем, бәхеткә каршы, бик кечкенә төркем килеп чыкты да, бухаринчыларга ияреп, татар пролетариаты исеменнән милли Советлар республикасы оештыруга каршы хәрәкәт башлады. «Бу бит — абсурд, товарищлар! Бу татар пролетариатының үз-үзен милләтләр фиһристеннән *** алып ташлавы; үз-үзен сәяси хәятка мөстәхикъ **** түгел дип хурлавы; үз-үзен мөстәкыйль яшәргә кодрәтсез, иҗат эшенә истигъдатсыз, бәйнәлмиләл ***** бер инвалид дип тануы булыр иде».

Татар «сул» коммунистлары очраганда, дип дәвам итә Ф. Әмирхан, мәсьәләне болай куярга туры килә: хәрефкә ябышып яту гынамы монда, әллә яңа төр шовинизм политикасын үткәрүчеләргә лакейлык итү дә бармы?

Шул ук «Кызыл Армия» газетасында Әмирханның «Мирзалар авыруы» исемле фельетон белән чыгуы да табигый иде.

Гайнетдин Гайнетдинович Сәкыймов, Көнчыгыш халыклары Коммунистик оешмалары съездыннан кайткач, губком каршында отчет бирергә тиешлеген уйлап бик каты борчыла. Чөнки съездда милли Совет республикасы төзү фикере җиңеп чыккан икән.

Иван Иваныч ни әйтер инде, бу хәбәрне ишеткәч? Лев Абрамыч? Мария Исааковна? Ярый ла: «Сез соң нинди көч белән җөмһүрият алып бармакчы буласыз?» — дип,

---

* Гареп — көнбатыш.
** Тәтабык — туры килү, ярашу.
*** Фиһрист — исемлек.
**** Мөстәхикъ — хаклы, лаеклы.
***** Бәйнәлмиләл — интернациональ.

көлеп кенә калсалар. «Сез националистлар, сез шовинистлар!» дип сүгүләре мөмкин.

Гайнетдин Гайнетдинович, бик озак борсаланып яткач, төн уртасында гына йоклап китә. Ләкин йокысы йокы түгел, саташа, бастырыла башлый. Әллә ничаклы кеше аның өстенә ябырылып килә, ачулана, тиргиләр имеш:

— Без сине Мәскәүгә җөмһүрият алып кайтырга җибәрдекмени? Ах, контрреволюционер, ах, шовинист!

Сәкыймов, акланырга тырышып, җавап бирә имеш:

— Товарищ барин, а товарищ барин, ей богу, мин гаепле түгел. Мин әйттем, мин барысына да әйттем: татар эшче-крестьяннары үз җөмһүриятләрен кирәксенмиләр, дидем. Татар ярлы халкы учреждениеләрдә татарча сөйләшүне бер дә теләми, без русча белмәсәк тә, безнең белән русча гына сөйләшсәләр иде дип требовать итәләр, дидем... Татар эшче-крестьяны кулыннан бер эш тә килми, ул бариннан башка хәрап булачак, дидем.

Гайнетдин Гайнетдинович, уянгач та, саташуыннан айный алмый. Врач чакыралар. Доктор, карт коммунист, аның чирен тиз танып алып диагноз куя: лакейлар тифы. Дәвасын да бик тиз билгели:

— Авыруны татар һәм башкорт ярлылары һавасында озак йөртергә кирәк.

И. И. Ходоровский истәлеге яктылыгында карасак, бу фельетонны аңлау һәм аклау гына түгел, бәлки аның дөньяга чыгуы кирәк иде, вакытлы иде дигән фикергә килербез.

## 5

Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасының тууы белән атаклы булып халкыбыз тарихына кереп калган һәм Фатих Әмирхан тормышында аерым урын тоткан 1920 ел башлана.

26 январь. РКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро утырышында Татарстан АССРны гамәлгә ашыру мәсьәләсе карала һәм уңай хәл ителә.

26 февраль. Үзәк Комитетның «Көнчыгыш халыклары арасында эшләүгә карата» дигән исемдә циркуляр хаты игълан ителеп, мөселман халыкларының, шул исәптән татарларның, милли үзбилгеләнү омтылышына уңай карарга кушыла.

22 март. В. И. Ленин РКП(б) Үзәк комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы членнарын кабул итә, Татарстан республикасын төзүгә кагылышлы кыйммәтле киңәшләр бирә.

4 май. Халык Комиссарлары Советы Татарстан республикасын оештыру турындагы декретның проектын эшләү өчен комиссия барлыкка китерә.

25 май. СНК утырышында проект карала һәм яхшы дип табыла.

27 май. Проект ВЦИК утырышында раслангач, декретка әверелеп, В. И. Ленин һәм М. И. Калинин имзалары белән игълан ителә.

8 июнь. РКП(б) Үзәк комитеты Политбюросының В. И. Ленин председательлегендә узган утырышында булачак республикада партия һәм совет төзелешенә кагылышлы мәсьәләләр карала. Шунда ук Вакытлы революцион комитет турында фикер алышу була.

10 июнь. ВЦИК ВРК составын раслый.

25 июнь. Казан губерна башкарма комитеты үзенең вәкаләтләрен ВРК кулына тапшыра. Шушы көн Татарстан АССРның туу көне булып тарихка кереп кала.

26 сентябрь. Эшче, крестьян һәм кызылармеец депутатлары Советының 1 нче оештыру съезды ачыла. Съездда Үзәк Башкарма комитеты сайлана һәм беренче председателе Сәхипгәрәй Сәетгалиев булган Халык комиссарлары советы барлыкка китерелә.

1920 ел... Революциядән соң Ф. Әмирханга зур куаныч, иң олы бәхет китергән ел бу. Публицистик эшчәнлеге иң югары ноктасына күтәрелгән ел. «Кызыл Армия» газетасында һәм бүтән матбугат органнарында көн кадагына сугып язылган тирән эчтәлекле мәкаләләре бер-бер артлы басыла башлый. Әнә шул мәкаләләрне язылу вакытлары буенча тезеп чыгыйк та урталарыннан кызыл җеп булып сузылып бара торган төп фикерне тотып алырга тырышыйк.

**«Шәрык уяна».** Февраль.

Кайчандыр бөек мәдәният тудырган Шәрык, гасырлар үтеп, җиде башлы империализм елансның ихтыярсыз колына әверелгән иде. Кинәт, «кискен яшеннең (Октябрь күздә тотыла — *И. Н.*) кызыл, кан шикелле кызыл уты аждаһаның бер башын (ягъни Россия империализмын — *И. Н.*) кисеп төшерде, калган башларын үзенең дәһшәтле шәүләсе белән сукырайтты, хәлдән тайдырды». Инде Шәрык уяна, күтәрелә, аякка баса башлады.

«— Уян, Шәрык, уян! Адәм балалары хезмәт мәйданына сине көтәләр!»

**«Революция балалары (Яшь кызыл командирларга багышлана)».** Март.

Татар бригадасы каршындагы хәрби мәктәпнең беренче чыгарылышы... Бу ни дигән сүз? Бу, әгәр буржуазия, армияне үз файдасына хезмәт иттерер өчен гаскәр башлыкларын үз балаларыннан әзерләсә, Совет власте революция казанышларын саклап калу өчен командирларны хезмәт иясе балаларыннан әзерли, дигән сүз.

«Алга, сугыш сафларына, кызыл яшьләр!

Сезнең кулларыгызда винтовкалар да бар, чүкечләр дә бар. Революция өчен сезнең нинди коралыгызны тотып, кайсы сафка китүегез кирәк булса, алга, шул сафка, революция балалары!»

**«Яңа сугыш хәзерлеге һәм нефть».** Апрель.

Дөньяның иң зур һәм иң демократик саналган илләрендә дә сәясәтне парламентлар ясамый.

«— Нефть!

Менә бүгенге буржуазный мәмләкәтләрнең бөтен тышкы сәясәтләренең гамиле *, нефть корольләренең табышлары — менә хәзергә буржуазный сәясәтнең чын идарәчесе».

Империалистик илләр сугышсыз тора алмый. Хәзер алар җир шарындагы нефть коеларын кулларына төшерү өчен үзара көрәш алып баралар. Аеруча зур уңышка ирешкәне — Америка Кушма Штатлары.

Нефть — сугыш кораблары, су асты көймәләре, очкычлар дигән сүз. «Бөтен дөньяда чыга торган нефть дөньяның үз хаҗәтләре өчен тәмам җитеп торырлыктыр. Ләкин буржуазия инде үзенең киләсе сугышлары өчен бик күп җыеп куеп, шул җыелып җиткәч, яңадан бер бөтен дөньяны кан диңгезенә батырып алырга уйлыйдыр». Тик менә «нефть корольләренә бу «рәхәтне» күрергә туры килмәс: социальный революция хәзер үзенең кызыл кылычын артык итеп кайрап өлгертте инде». (Мәкалә, әйтерсең лә, бүгенге халыкара хәлне күзәтеп язылган!)

**«Ленин иптәш — төзү, гомран ** итү символы».** Апрель. (Бөек юлбашчыга илле яшь тулу уңае белән язылган.)

В. И. Ленин — Маркс һәм Энгельс эшен даһиларча дәвам итүче. Буржуаз стройны җимерү дәверендә ул кыю фикерле, каты куллы, икеләнүне белмәс юлбашчы иде. Гражданнар сугышы бетәр-бетмәс Ленин тирән ышану белән:

— Иҗат, төзү, яңартып кора башлау! — лозунгларын ыргытты.

---

* Гамил — эшләүче, хәрәкәткә китерүче көч.
** Гомран — төзү, культуралаштыру.

Ленин корган план «Россия шикелле мәдәни артта калган бер дәүләт өчен хыяллар сыйдырмаслык зур, олуглыгы алдында каушап калырлык дәрәҗәдә киң һәм тирәндер».

**«Татар пролетариат җөмһүрияте һәм татар демократия гаммәсе».** Июнь. (Мәкалә Татарстан Совет республикасы турындагы декрет басылган санда чыккан. Менә бу өлгерлек!)

Хакимлек итүче бөек державаларда буржуаз-демократик строй урнашу да милли изүне бетерә алмады. Милләтләрне басу, кысу хәтта тагын да көчәя төште.

«Октябрь революциясе Россиядә буржуазный төзелешне җимергәч, ул төзелешнең тума балалары вә шулар җөмләсеннән көчле милләтнең көчсезләр өстеннән сәяси власть тотуы да җимерелде».

«Социальный революция — менә безнең бүгенге җөмһүриятебезнең анасы».

Татарның эшче-крестьяннары үз республикаларын шатланып каршы алалар. Партиясез, «ярым буржуаз» интеллигенция аңа нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш? Халыкка якын торган намуслы өлешенә бер генә юл бар: «җөмһүрияттә социализм төзелеше әсасларын тәдриҗән * ныгытып, тәрәкъкый иттереп бару юлы гынадыр».

«— Әйе, безнең демократия гаммәбез алдында шушы бер генә юл, җөмһүрият эчендә пролетариат идеалларына хезмәт итү юлы гына торадыр».

**«Төрек милләтчелеге һәм Россия Советлар власте».** Төркияне Европа империализмы коллыгыннан коткарган революция, милли азатлык өчен көрәш рәвешендә барып, буржуаз-демократик эчтәлекле генә булды. Шуңа да карамастан Советлар Россиясе аңа дуслык кулын суза. Чөнки «коммунизм хәрәкәте» бөтен бәни адәмне икътисади ** коллыктан коткару өчен, аны сәяси коллыктан коткарырга» тиеш таба.

Төркия, рәхәтләнеп, Советлар власте кулын кыса. Сон төрек милләтчелеге үзләренә дә коммунизм хәрәкәте килеп керүдән ничек курыкмый? Чөнки ул «бу көндә вак буржуа гонсырына ***, җир эшләүчеләр, крестьяннар сыйныфына таяна».

«Төркиягә большевизм йога икән, Төркия революциясе социальный революциягә әйләнә икән, Төркиягә комму-

---

* Әсас — нигез; тәдриҗән — әзлекле рәвештә.
** Бәни адәм — адәм баласы; икътисади — экономик.
*** Гонсыр — элемент.

низм урынлаша икән, аның өчен әйдә Европа банкирлары, Европа капиталистлары агласыннар».

**«Яңа имкыннар алдында».** Июнь. Татарстанда властьның Вакытлы революцион комитетка күчүе уңае белән язылган бу мәкаләгә махсус тукталырга хаҗәт юк. Әмирханга хас тирәнлектән кала, мәкаләдә — тоташ бер куаныч, шатлык, киләчәккә өмет баглау.

Завод-фабрикаларны идарә итү өчен эшче-крестьян балаларыннан белгечләр әзерләүнең кирәклеге турындагы **«Мөтәхәссисләр җитештерү»** (29 июль), М. Вахитовның революция тарихында тоткан урынын гаҗәеп дөрес билгеләгән **«Мулланур иптәш»** (19 август), сугыш бетүгә бар көчне тыныч төзелешкә бирергә чакырган **«Хәзерлек күрү»** (16 декабрь) исемле мәкаләләрен санап китү белән генә чикләнеп, берсенә махсус тукталып узыйк.

**«Өч ел эчендә».** Октябрьгә өч ел тулу уңае белән язылып, «Кызыл Армия» газетасының 7 ноябрь санында басылган.

Россиядә булган гаять зур үзгәрешләрне күрмичә, ди Әмирхан, вак буржуаз катлаулар тормыш җиңеләйми, киресенчә, авырая гына бара дип зарланалар. Бу зарларның сәяси аңсызлык икәнен ачып бирер өчен, ул революциянең эчке һәм тышкы дошманнарын җиңүгә, социализм нигезенең беренче ташларын салуга кагылышлы мөһим чараларны санап чыга да мондый нәтиҗә ясый:

«Шулай итеп, Октябрь революциясенең бу өч ел эчендә эшләп өлгергән эшләренә гаять өстән генә бер күз төшерү дә безгә бик ачык күрсәтәдер ки, гаять кыска бер гомер эчендә революция үзенең төп шигарьләрен гамәлгә кую юлында инде гаҗәеп күп эш эшләп өлгергәндер».

Сез ничектер, кадерле укучым, әмма мин Фатих Әмирханның киң карашына, тирән фикеренә һәм язу осталыгына сокланмый булдыра алмыйм. Төрле темаларга язылган бу мәкаләләрне берләштерә торган төп фикер, төп пафос шул: тормыштагы социаль гаделсезлекне пролетариат революциясе һәм Советлар власте гына бетерә ала! 1920 елда инде Ф. Әмирхан ил эчендәге катлаулы вакыйгаларны һәм халыкара хәлне тулысынча совет платформасында торып бәяли, партия һәм Совет власте үткәргән һәрбер чараның илдә социализм төзүгә юнәлтелгән икәнен аңлап фикер йөртә.

Менә шуннан соң күп еллар буе Ф. Әмирханга карата яшәп килгән гаделсезлеккә, ачыну белән бергә, гаҗәпләнергә генә кала.

— Әмирхан Октябрь революциясен кабул итмәде.

— Әмирхан Совет властена дошман иде.
— Әмирхан большевикларны куралмады.
— Әмирхан эчке эмигрант иде.

Кем-кем, хәтта Һади Такташ та шундый карашларга бирелә язды. Мин аның «Ул безнең өчен үле иде инде» дип аталган истәлеген күздә тотам. Тәнкыйтьче Гомәр Галинең аңлатмасыннан күренгәнчә, Такташ аны әдип вафат булу белән үк язган, кайбер иптәшләренә укып та күрсәткән, ләкин матбугатка бирмәгән. Шагыйрь үлгәч, Гомәр Гали истәлекне «Яңалиф» журналында дөньяга чыгара.

Бер вакыт Такташ Әмирханны Ленин бакчасында очраткан. Үзе әйтмешли, озак кына утырганнар. Сүз арасында Такташ әдипкә сорау биргән: «Фатих әфәнде, Сез хәзер матбугатта бөтенләй катышмый башладыгыз. Ара-тирә генә булса да язгаларга иде». «Мин элек революциянең гакесен көткән идем,— дигән Әмирхан.— Хәзер инде яза башладым».

Әнә шул сүзләргә соңыннан Такташның, дөресрәге, Г. Галинең җиңел кулыннан Ф. Әмирхан Совет властеның бетүен, җимерелүен теләп яшәгән дигән мәгънә салынды.

Әмирханның Такташка ул сүзләрне әйткәнен, әлбәттә, шик астына алырга нигез юк. Ләкин ул нинди мәгънә салып әйткән? «Җиңелүен, бетүен теләдем» мәгънәсендә дип уйлыйк. Ул чагында берничә сорау туа. Дошман кеше ачыктан-ачык шулай дип белдерерме? Ф. Әмирхан дошман икән, Такташ ни өчен аның янында озаклап утыра, ник язарга кыстый? Әдипнең контрреволюцияне теләгәнлегенә ышанган икән, ник ул истәлеген бастырырга ашыкмый?

Ф. Әмирхан әлеге «куркыныч» сүзләргә, билгеле инде, ул мәгънәне салмаган. Аның әйтергә теләгәне: мин большевикларнын властьны тотып калачакларына ышанмадым. Бары шул! Бу карашын ул «Кояш» мәкаләләрендә ачыктан-ачык әйтеп чыккан иде.

Соң булса да, уң булсын дигәндәй, әйдәгез, Фатих Әмирханга ягылган бу тапны да юып төшерик.

*8 бүлек*

## «ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРЕГЕЗ МИҢА

### 1

1920 ел дәвамында Фатих Әмирхан, метафора кулланып әйтсәк, язылып, тураеп, тарихи барышның олы юлына чыгып, көр күңел һәм киләчәккә ышаныч белән атлый

башлаган иде. Менә 1921 ел кереп, көн артыннан көн, ай артыннан ай узды. Фатихның аяклары ничектер хәлсезләнеп, йөреше акрынайды, ара-тирә чалулап ала башлады...

Нәрсә булды? Ни сәбәп? Атасының вафатымы? Әйе, моны инкяр итеп булмый.

Сау-сәламәт, тап-таза йөргән иде югыйсә. Рабига остазбикә дөнья куйганнан соң тиешле вакыт узгач, өйләнү фикеренә килеп, бу ниятен хәтта тормышка да ашырган иде. Якыннары Зариф хәзрәтнең бу эшен, билгеле, өнәп бетермиләр. Картның үз сүзендә нык торганын күргәч, Фатих вакыйганы шау-шусыз гына үткәрү чарасына керешә. Зарифның хатын булдачы Шәһәр Шәрәф мәхәлләсендә яшәгәнлектән, никахны ул яисә иптәш мулласы Әхмәтҗан укырга тиеш була. Карт соңгысын теләсә дә, Фатих, заманында прогрессив карашы һәм галимлеге белән абруй казанган Ш. Шәрәфне артыграк күреп, атасын аңардан никах укытырга күндерә. Шулай итеп, 1921 елның 4 февралендә Зариф хәзрәт өендә тар гына никах мәҗлесе булып уза. Ләкин Зариф хәзрәтнең «башлы-күзле» булып яшәве озакка бармый, җәй уртасында ул тәүлек ярым гына сузылган ваба чиреннән вафат була.

Бу югалтуны да Фатих авыр кичергән. Бер хатында мондый сүзләр бар: «Соңгы елларда инде әти миңа бер ата гына түгел, бәлки һәм бер иптәш, һәм бер дус та иде: берничә көннәр өйдә булмый торсам, мин аны сагынып, кечкенә балалар шикелле сагынып кайта идем».

Шулай да Әмирханны тагын «урталык»та чайкалып алуга китергән сәбәп бүтән нәрсәгә, дөресрәге, ике нәрсәгә кайтып кала: берсе — ачлык, икенчесе — яңа экономик политика, кыскартып әйткәндә — НЭП.

Фатих моңарчы, үзе татып карамаса да, ике ачлыкны күреп уздырган иде. Балигъ булып, әдәбият дөньясына аяк баскач, ул кабатланып тора торган ачлыкларның сәбәбе турында да уйланды. Укучы хәтерлидер: «Ачлык кушты» дигән пьесага язган рецензиясендә (1908) ачлыкны илнең социаль-экономик төзелешенә бәйләп карау югарылыгына күтәрелгән иде.

Инде менә үзәге Урта Идел булган ачлык тагын Россиянең күп кенә төбәкләрен каплап алды. Бистә һәм шәһәр ярлыларының шешенүләрен, ач үлемнән качып килгән крестьяннарның, хатын-кыз һәм балалары белән берлектә, Казан урамнарында җан биргәннәрен күреп тетрәнгән Әмирхан бу ачлыкны ничек аңлатырга, аңа нинди мәгънә бирергә тиеш иде? Бит бусы — Советлар власте шартла-

рында, Октябрь революциясе булып, дурт ел уткәч килгән афәт!

Юк, Ф. Әмирхан, ярыкларга кереп сыенган дошманнар һәм базар-толчок тирәсендә киләп сарган мещаннар кебек, «Большевиклар халыкны ачтан үтерәләр!» дип, теш ыржайтып көлүдән ерак торды. Бу ачлыкның империалистик һәм гражданнар сугышы нәтиҗәсе һәм ахыр чиктә иске стройдан калган мирас булуын ул яхшы аңлый иде. Шулай да элек изелеп килгән милләт вәкиле буларак, Ф. Әмирхан җирле власть әһелләренә һәм коммунистларга үпкә белдерми кала алмады.

Ул болай фикер йөртә. Иске режим вакытындагы корылык елларында иң күп ачыккан, иң күп үлгән халык Идел һәм Кама буйларында яшәгән татарлар булды. Инде бу ачлыкта да шул ук хәл кабатлана. Шуңа күрә, ди Әмирхан, «революциянең һәм аның белән власть башына килгән партиянең вазифасы — икътисади иң зәгыйфь гонсырларын артыграк күрергә тырышу, аларны бәйнәлмиләлнең тигез әгъзасы хәленә күтәрергә зур әһәмият бирү». Власть башында торган безнең күп кенә партияле иптәшләр исә шушы хакыйкатьне аңламыйлар яки аңларга теләмиләр. Әнә бит хәрби коммунизм вакытында андыйлар, үзәккә яхшы күренергә тырышып, татар авылларына развёрстканы өстән билгеләгәнгә караганда да күбрәк салып, крестьян хуҗалыкларын аяктан екканнар иде. Инде менә нәтиҗәсе...

Икмәк өчен аяусыз көрәш барган чорда, ихтимал, ленинчыл милли политиканы исәпкә алып җиткермәү очраклары да булгандыр. Әмма бу урында бер мәкаль искә төшә: «Ашаган белми, тураган белә». Фатих үзе, әйтик, азык-төлек комиссариатында эшләп, ачларга ярдәм итү мәҗбүриятен үз җилкәсендә татыса, мондый ук кискен хөкем чыгарыр иде микән? Совет хөкүмәте һәм партия Үзәк Комитетының Идел буе ачларына ярдәм итү юнәлешендә үткәргән чараларының күбесеннән хәбәрдар булмаганы кебек, күрәсең, ул Татарстан Халык комиссарлары советы председателе С. Сәетгалиевнең республикада азык-төлек мәсьәләсен җиңеләйтү максаты белән В. И. Ленин янына кергәнлеген дә белмәгән.

НЭП башлангач тагын иләс-миләс килеп алуы исә Ф. Әмирханның совет платформасында торганлыгын, Октябрь революциясе идеалларын уртаклашканлыгын гына раслый. Парадокс? Тик ашыкмыйк, уйлап карыйк.

Әгәр Ф. Әмирхан, 20—30 елларда кайберәүләр уйлаганча, буржуазия «адвокаты», капитализм апологеты бул-

са, НЭП башлангач куанырга тиеш иде: әһә, социальная революция дигәннәре барып чыкмады, шул ук искегә, шул ук сәүдәгәрлеккә, шул ук капитализмга кайталар!

Әйе, НЭП чигенү иде, Советлар хөкүмәте контроле астындагы капитализмга, дәүләт капитализмына таба чигенү иде. Гаскәр дә бит гел генә алга бармый. Уңышлы һөҗүм нәтиҗәсендә дошманны куып китеп, төп көчләрдән аерылса һәм чолгану куркынычы алдында калса, ул ни эшли? Билгеле инде, тәртипле рәвештә чигенә, фронтны тигезләү, сафларны барлау, үзгәртеп кору һәм дошманны тәмам тар-мар итеп ташлау өчен чигенә. Тулаем стратегиядән хәбәре булмаган, әмма уңыштан-уңышка ирешеп, үзен баһадир дип хис иткән аерым кайнар башлар риза түгел:

— Дошманны дөмектерергә бер адым калгач, нишк чигенәбез? Хыянәт бу! Саттылар безне!

Фатих Әмирханга кайтыйк.

15 октябрь көнне аның янына, преферанс уйнарга дип, Ибраһим Кули белән Әхмәтгәрәй Хәсәни килеп чыкканнар. Икесенең дә йөзендә «байлар» кыяфәте, чөнки монда килер алдыннан Казанда яңа ачыла башлаган кондитерский һәм кафеларда йөреп, шәпләп сыйланганнар. Ни генә юк ди! Ак булкамы кирәк, пирожныймы, яхшы кофемы — һәммәсе бар. Нәкъ әүвәлге, революциягә кадәрге заман! Тик акча, акча кирәк икән. Кесәңдә 25—30 мең сум булмаса, кафе ягына борылып та карама. Үзләренчә шаяртып та алалар: «Синең хәл, Фатих, бер яктан уңайлырак: кафеларга йөреп барлы-юклы акчаңны бетерәсең юк».

Әнә шул вакыйга, әнә шул сүзләр уйлану, шактый күңелсез фикерләргә килү өчен җитә кала. Төн уртасы авышып, уенчылар китеп баргач, Фатих көндәлек дәфтәрен ача да түбәндәге сүзләрне язып куя: «Димәк, акрынлап Октябрь революциясенә кадәр булган хәлнең бөтен сәлби* яклары тагы ялтырап кайтып урнаштылар: бер яктан шәһәр тротуарларында хуҗалыкларын җимереп эштән чыгарылган крестьяннар балалары, хатыннары белән ачтан үләләр, э икенче яктан ...совет буржуйлары, совет бюрократиясе, рәхәтләнеп, пирожныйлар белән шикәрле, сөтле кофены рәсми сурәттә, мөзәйян ** кафеда шул фәкараның *** күз алдында эчеп утыра... Соң алай булгач, бөтен бу Октябрь революциясе, бөтен бу дүрт еллык гражданнар

---

* Сәлби — тискәре.
** Мөзәйян — зиннәтле.
*** Фәкара — фәкыйрьләр.

сугышы, бөтен бу үтерешләр, йөзмеңнәрчә корбаннар, бөтен бу вату, җимерү нәрсә өчен генә кирәк булган булып чыкты да нәрсә нәтиҗә бирде?»

Бер уй икенчесен китереп чыгара.

Моннан берничә көн элек энесе Гомәр, мәҗбүри хезмәт лагереннан бер көнгә кайтып, бүтән хәбәрләр арасында Шакир Бәхтиев дигән берәү турында кайбер нәрсәләр сөйләгән. Революциягә кадәр, бигрәк тә сугыш елларында, бу кеше бик нык баеп киткән була. Әмма татар байлары арасында ул иң сараннарыннан, милләт файдасына иганә бирүдә иң кире беткәннәреннән берсе икән. Фатих аның белән шәхсән таныш булмаса да, елкылдап торган каретасына кырын яткан килеш, үзен бик зурга куеп үтеп киткәнен күргәләгән.

Әнә шул Бәхтиев хәзер тоткын сыйфатында хезмәт лагеренда ята икән. Элек төшенкелеккә бирелгән булса да, хәзер башын күтәрә башлаган. Ике сүзнең берендә «дөньяда акча мөһим. Акча булса, бар нәрсә дә була» ди икән.

Әйе, ди Ф. Әмирхан, мин большевикларның тактикасын еш кына ачы сурәттә тәнкыйть итәм, бу тактикадан пролетариатка, шул җөмләдән татар фәкарасына файдалы нәтиҗә чыгар дип ышанып җитә алмыйм... «Ләкин шуның белән бергә мин ул кодсиятсез * мәгърур Шакир Бәхтиевләр, шул кеше хезмәте белән симереп, муены дуңгыз муеныдай булган буржуазия, капиталисттан да дөнья өчен, хәят өчен, гомум халык өчен вә шул җөмләдән төрек-татар гаммәсе өчен бер дә хәер көтмим бит. Социальная революция булгач, шул кодсиятсез буржуазияне таландырмый калган икән, мин аңар бер дә куанмыйм гына түгел, бәлки мин аның өчен коммунистлар партиясен гаепле күрәм, аның хатты хәрәкәсенең ** начарлыгыннан дөньяда шактый бер кирәкле эш эшләнми калган, дөньядан бер нәҗес *** әрчелми калган дип уйлыйм бит».

Моннан да ачыграк итеп әйтергә мөмкинме?! Ф. Әмирхан коммунистлар партиясенә буржуазияне сыйныф буларак бетерүне максат итеп көрәшкәне өчен түгел, бәлки, киресенчә, аны җитәрлек дәрәҗәдә «таландырмый» калдырганы, бу «нәҗес»не бөтенләй күмеп куймаганы, димәк, кирәкле һәм законлы дип ышанган «социальная революция»не ахырына кадәр җиткермәгәне өчен үпкә белдерә!

Әдипнең НЭПны өнәмәве, аның кайбер күренешләрен

---

* Кодсият — изгелек.
** Хатты хәрәкә — тактика.
*** Нәҗес — әшәке, пычрак.

тәнкыйтьләве бу политиканың стратегия чылбырындагы бер буын гына икәнен аңлап җиткермәү, мәсьәләгә тарихи перспективада карый алмау нәтиҗәсе иде, әлбәттә. Әмма мондыйлар ул вакытта бер Әмирхан гына идемени? НЭП кертелү үзбаш фикер йөртергә сәләтле бик күпләрне аптырашта калдырган кебек, хәтта коммунистлар арасында бу сәясәт белән килешергә теләмәүчеләр табылды.

Шунысын да әйтик: яңа экономик политиканы тормышка ашыру эше шулай ук нотага карап уйный торган оркестрдагыча гына бармаган. Бу бәйләнештә В. И. Ленинның Юстиция халык комиссары Д. И. Курскийга адреслап язылган хаты гаять зур әһәмияткә ия. Бөек юлбашчы комиссариатның эшен җанланып бара торган капитализмны дәүләт контроленнән ычкындырмау юнәлешендә тамырыннан үзгәртеп коруны таләп итә. Совет законнарын бозган буржуазиягә һәм нэпманнарга гына түгел, бәлки НЭПтан үзе өчен файдалана башлаган җаваплы работникларга карата да рәхимсез булырга чакыра. «Патша вакытында,— дип яза ул,— прокурорларны отып чыккан эшләренең процентына карап я куалар, я күтәрәләр иде. Патша Россиясенең без иң начарын — безне чын-чыннан буа, тончыктыра торган бюрократизм һәм обломовчылыкны — кабул иттек, ә акыллы нәрсәне кабул итә алмадык. ЮХҚ коллегиясенең һәр әгъзасын, бу өлкәнең һәр эшлеклесен хезмәт күрсәткеченә карап, түбәндәге белешмәне алып бәялисе иде: ничә коммунистны син бер төрле гаеп өчен, партиясезләр белән чагыштырганда өч мәртәбә артыграк биреп, төрмәгә тыктың? Ничә бюрократны син бюрократизм һәм волокита өчен төрмәгә утырттың? Ничә сәүдәгәрне син нэподан явыз файдаланганы өчен атып үтерүгә яисә... уен-муен булмаган бүтән төр җәза бирүгә ирештең?» *

1922 елның 20 февралендә язылган бу хатны Ф. Әмирхан белмәгән һәм белә дә алмаган. Чөнки ул күп еллардан соң гына игълан ителде. Әмма үткен күзле, сизгер колаклы һәм зирәк акыллы Әмирхан совет аппаратларына үтеп кергән бюрократизмны да, сүз белән эшнең аерылу очракларын да, кайбер җитәкче работникларның дәүләт малына кул сузуларын, ришвәтчелеккә бирелүләрен дә, чекада эшләүче аерым кешеләрнең артык узынып китүләрен дә күреп торган. Күреп кенә калмаган, бәлки, көндәлегенә теркәү белән генә чикләнмичә, теләсә кайда, теләсә кем алдында нәфрәтләнеп сөйли торган булган.

---

* В. И. Ленин. Әсәрләрнең тулы, 5 нче басмасы, 44 том, 398 бит.

## 2

Атасы да үлеп киткәч, Фатих бөтенләй ялгыз кала. Дөрес, энесе Ибраһим һәм килене Нәфисә бар. Моңарчы алар бергә оешып яшәгәннәр иде.

Ибраһим 1918 елда армиядән большевиклашып кайтып (1918 елның февраленнән РКП(б) әгъзасы), юстиция һәм Совет органнарында эшләп алгач, 1920 елда үзе теләп фронтка китә, Казан укчылар дивизиясенең политотделы начальнигы ярдәмчесе сыйфатында Кырымны алуда катнаша. Анда аны Симферополь ревкомы әгъзасы ясыйлар, халык мәгарифе бүлегенә җитәкчелек итү эшен тапшыралар. Бер үк вакытта ул Кырым өлкә комитеты каршындагы мөселман бюросы әгъзасы була. Кырымда озакка каласы булгач, Ибраһим хәләл җефете Нәфисәне дә алып киткән.

Фатихның хезмәтче егет һәм асрау тотканлыгы күренми. Әнә бит кресло-коляскасын этеп барырга малай таба алмаганлыктан, ачлар өчен «Ризык» исемле ашханә ачылуга багышланган тантанага чакырылса да, бара алмады.

Фатих билгеле бервакыт аралыгында туган-тумачасы тәрбиясендә яшәгән. Сәгадәт апасының җиткән кызы Разия, үсмер уллары Мәхмүт белән Зәкәрия һәм туганнан-туган энесе Гомәр барлыгын беләбез. Разия, көнаралаш дип әйтерлек килеп, өй эшләрен карап, аш-су әзерләп китә торган булган. Гомәр исә әдип абыйсы янында торып ук калган. Ләкин аны мәҗбүри хезмәт лагерена алганнар.

Материаль көнкүрешенә килгәндә, Фатих ач тормаган торуын, әмма көч-хәл белән генә очны очка ялгап барган. «Кызыл Армия» газетасы тукталды, даими эш хакы киселде, пенсия-фәлән алмый, аз яза, язганы да дөньяга чыкмый, димәк, гонорар килсә дә тамчылап кына килә. Ачлык шартларында китап чыгару турында исә уйларга да ярамый.

Бәлки Зариф хәзрәттән әйберләтә һәм акчалата мирас калгандыр? Көннәрдән бер көнне Фатих этисенең язу-кәгазьләрен актарырга керешә. Зариф хәзрәт, имамлык вазифасын башкару белән бергә алыш-биреш иткәнгә күрә, мәрхүм бу эшен ничек алып барган икән дип кызыксынган, күрәсең.

Уһу, мондагы тәртипсезлек, мондагы хаос! Вак-вак кәгазьләргә, төпләре каерылып беткән кечкенә дәфтәрләргә, чакыру кәгазьләре артларына яисә конверт кырыйларына, төрле саннар утыртып, фәлән абзыйга фәлән сум акча биргәнен язып куйган. Зариф мулла үзбаш сәүдә итмә-

гән, бәлки төрле ширкәтләргә яисә аерым сәүдәгәрләргә файданы уртаклашу хакына акча бирә торган булган.

Зариф хәзрәт кызу характерлы, мавыгучан шәхес булarak, берәр нәрсәне ният иттеме, ахырын уйлап тормыйча һәм киңәш, кисәтүләрне колагына да элмичә, тормышка ашырырга керешә. Мондый «купец»ның уңышка ирешә алмаячагы ап-ачык нәрсә. Картны бик еш алдаганнар, акчасын басып, йомып калганнар. Үзе үлгәндә чит кулларда алтын белән нибарысы йөз сум акчасы калган була. Анысы да «компаньон»нары кулында эреп юкка чыга. Тагын бер нәрсә ачылып китә: аларның гаиләсе ярыйсы гына муллыкта яшәп килгән икән, моның белән ул күбрәк Рабига остазбикәгә, аның килеренә һәм хуҗалыкчыллыгына бурычлы.

Әдипкә калган мирас, шулай итеп, әнисенең бизәнү әйберләре дә кием-салым һәм өй җиһазлары. Ул әнә шуларны сатып киченә башлый. 7 октябрь көнне, мәсәлән, бер хатын-кыз бишмәтен чыгарып саттырган, 200 мең сум акча биргәннәр. Икенче көнне бер пар читек һәм ике пар кәвешне 100 меңгә саттырган. «Моннан ун-унбиш көн әүвәл,— дип яза ул көндәлегенә,— өч пот ярым арыш оны алып куйган, ләкин акчасын түләми торган идем. Кичәге ике, бүгенге бер йөз мең сум белән шул бурычның бер бүлеген түләдем, яңадан дүрт йөз мең сум бурычым калды». Менә заман, дияр укучы, акча белән уйнаганнар соң? Торманың бер данәсе 700 сум торган вакыт шул бу.

Атасы үлгәч, Фатих нервлары какшауданмы, әллә бүтән сәбәптәнме, озак авырып яткан. Хәтта васыять язу уе да күңеленә килгән. Октябрь кергәч кенә ул үзендә тернәкләнү сизә, рухи төшенкелек һәм битарафлыктан арына башлый. «Бүген инде... кәеф шактый төзәлде, беркадәр хәяти теләкләр дә кузгалып торалар: тышка чыгып йөрисе дә килә, операга барып, яхшы бер музыка тыңлау һәвәсе дә кузгала, кызыклырак берәр мәҗлестә булынасы, әллә кемнәрне күрәсе дә килә шикелле» (15 октябрь).

Дөрес, Фатих янында болай да кеше өзелми. Әнә хөкүмәт учреждениеләренең берсендә эшләүче Г. Баембитов һәм милиция начальнигы Х. Габидуллин булып киткәннәр. Шәрык һәм гарәбият буенча зур белгеч саналган Таһир Ильяс хәл белергә килгән. «Татарстан хәбәрләре» газетасында эшли торган ниндидер ике егет килеп чыккан. Төркиянең яңа прогрессив хөкүмәте тарафыннан Россиягә йомыш белән җибәрелгән Исмәгыйль Сөбхи Суиссали дигән кешене алып килгәннәр. Фатихның преферанста даими

партнерларыннан булган И. Кули һәм Ә. Хәсәни кебекләр турында инде әйтәсе дә юк.

Иң кызыгы — Фатихны «син — контрреволюционер!» дип орышкан Галимҗан Ибраһимовның 16 октябрь көнне иртән үк килеп, кичке сәгать дүрткә кадәр утырып китүе. Күп нәрсә турында фикер алышканнар, Галимҗан хәтта шәхси тормышына кагылышлы эч серләрен сөйләгән. Ахырда Әмирханның «Ситдикъ мәхдүм» исеме астында язылып ята торган повестеннан бер кисәген «Ачларга ярдәм мәҗмугасы» өчен, хуҗаның ай-ваена карамый, шытырдатып ертып алган да китеп барган.

Болар өч атна аралыгында килеп чыккан һәм көндәлек дәфтәрендә телгә алынган кешеләр генә. Визит ясаучылар байтак булса да, Фатих моңа гына канәгать түгел.

Нәкъ шушы вакытта аны журналист һәм публицист сыйфатында иҗтимагый эшчәнлеккә кайтырга юл ачачак һәм мәҗбүр итәчәк тәкъдим була, дөресрәге, мәсьәләне үзеннән башка хәл кылалар. Көндәлегенә Фатих бу турыда болай дип язып куйган: «Кули Ибраһим миңа «Татарстан» газетасы идарәсеннән 200 мең сум аванс алып килгән. Кулилар, Фәтхи Бурнашлар (газетаның редакторы — *И. Н.*), минем мәтди хәлнең уңайсызлыгын белеп, мине октябрь башыннан мәзкүр * газета идарәсенең штатына хисаплап куйганнар икән». (Моңа өстәп шуны әйтик: Ф. Әмирханга материаль ярдәм күрсәтү эшкә алуның бердәнбер сәбәбе булмаганлыгына шикләнмәскә мөмкин.)

Әле бит Фатихның төп эше — язучылык эше бар. Анысы ни хәлдә? Бу сорауга да көндәлек дәфтәреннән җавап табабыз. «Язасы килә, башта төрле-төрле маузуглар йөри. Хәзер минем шәхси тормышымда язасы килүдән башка куанычым да юк. Язасы, язасы, очсыз-кырыйсыз язасы иде, бөтен шушы ашарга җүнәтү, өйгә утын җүнәтү, кайгысы белән тулы ... көндәлек тормышымны онытып, баштан чыгарып, язасы иде, шул язуда, творчествода бер ял итү, бер хәл җыю табасы иде. Ә ниндидер шәрәрәт ** җитешми, рәхәтләнеп язарга тотынып китә алмыйм». Әнә «Ситдикъ мәхдүм» повесте яртылаш язылган хәлдә өстәлендә ята. Әнә шартлы рәвештә «Карт кыз» дип исемләнгән булачак зур әсәре. Аның да күпмедер өлеше язылып, бер кечкенә кисәге басылып та чыккан иде.

Әнә шул ике әсәрен генә булса да кышта тәмамларга дип, Фатих көнелендә планлаштырып куя. Ләкин көн ар-

---

* Мәзкүр — телгә алынган.
** Шәрәрәт — очкын, чаткы.

тыннан көн, атна артыннан атна уза, берсенә дә ул керешә алмый. Көндәлегенең 29 октябрь язмасында мондый сүзләр укыйбыз: «Вакыт-вакыт шул бер әһәмиятсез шәкертнең (Ситдикъ мәхдүмнең.— *И. Н.*) беренче гыйшкының шул тәфсыйләле психологиясе бирәүгә дә кирәкмидер, аны язып тору бик габәстер * төсле тоелып куя». Шул ук вакытта әдип мәсьәләгә икенче яктан да килеп карый.

Дөньяда бит геройлар гына яшәми. Ситдикъ мәхдүм кебек карап торышка әһәмиятсез кешеләр дә санап бетергесез. Аларның да әдәбиятта урын алырга хаклары бар. «Дөнья, тереклек үзе шул әһәмиятсез кешеләрнең шул әһәмиятсез психологиясендәге бетмәс-төкәнмәс үзгәрешләрдән тора бит. Әгәр адәмнәр бер-берсенең психологиясенә чын-чынлап кирә алсалар иде, алар бер-берсенә бик күп нәрсәләрне гафу итәрләр, бер-берсен артык күп кызганышырлар иде бит».

Әдәбият һәм сәнгатьнең вазифасы турында бүген дә актуальлеген югалтмаган мәңгелек мәсьәлә! Ф. Әмирхан заманасында дошман сыйныфларга каршы юнәлтелгән үч, нәфрәт ялкынының вакыт-вакыт гаепсез кешеләрне дә көйдереп алганы кебек, бүген дә без бөек төзелешләр гөрелтесендә кешенең йөрәк тибешен ишетеп җиткерми башладык түгелме? Фәнни-техник прогресс казанышларыннан өлгерештән файдаланырга тырышып, арадагы иптәшлек, дуслык, туганлык җепләрен өзеп куйгаламыйбызмы? Әшәкелеккә баш калкытырга ирек биреп, изгелек һәм мәрхәмәтлелекне дефицитка әйләндермәдекме? Тагын шунысы да бар, намуслы «кечкенә» кешенең сугышчан обывательләргә хас ялган, мәкер һәм демагогия дип атала торган калкан һәм сөңгесе булмаганлыктан, ул яклауга мохтаж.

Ф. Әмирханның моннан 65 ел элек әйткән сүзләре, бүген дә урынлы яңгырап, әнә ничаклы фикер уятты. Тулы кулъязмалары табылмаганга күрә «Карт кыз» һәм «Ситдикъ мәхдүм» әсәрләренең ахыр язмышын без белмибез. «Планлаштырылмаган» өченче бер әсәрнең арага кергәнлеге һәм әдипнең аны җиңел кулдан язып ташлаганлыгы исә билгеле.

Җитди рольләрдән өлеш чыкмаганга, комик рольләр башкарып танылган Касим Шамил бенефис өчен моңарчы уйналмаган комедия эзләргә керешә. Бар кебегеннән үзенә кирәклене таба алмагач, Галиәсгар Камал янына бара. Атаклы драматург Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләр-

* Габәс — буш, мәгънәсез.

не сәхнәләштерү идеясен әйткән һәм, үзенең вакыты юклыгын сәбәп итеп, Фатих Әмирханга мөрәҗәгать итәргә киңәш биргән.

Ҡ. Шамил Яңа бистәгә юл тота, әдипкә хәлне сөйләп бирә. Фатихның вакыты да бар, тәкъдим дә кызыклы. Әмма Хуҗа Насретдин турында комедия язу өчен күп хезмәт, күп вакыт кирәк. Борыны салынган Ҡасим иптәшләренә кайтып сөйләгәч, тегеләр әйтәләр: «Соң син, җүләр, ник «Фәтхулла хәзрәт»не сәхнәләштерүен үтенмәдең? Моны ул тиз эшләр һәм спектакльгә тамашачы да күп килер иде». Икенче көнне Ҡ. Шамил тагын Ф. Әмирхан янына бара. Артистлар фикерен ишеткәч, Фатих кычкырып көлеп җибәрә:

— Чынлап та, мулла Ҡасим, син Фәтхулла хәзрәтнең нәкъ үзе! — Аннары, җитдиләнеп өстәп куя:— Белмим, белмим, ул озын хикәядән нинди генә комедия чыгар икән. Шулай да мин уйлап карармын, бер-ике көннән килеп чыгарсың.

Әйтелгән вакытта Ҡ. Шамил тагын барган. Әмирхан инде булачак пьесаның планын уйлап бетергән. Артистны шул план белән таныштыргач, бер ун көндә язып бетерергә вәгъдә итә. Чынлап та ул 12 көн эчендә әсәрне тәмамлап, Ҡ. Шамил кулына тоттыра.

Премьера 1922 елның 22 августында була. Тамашачы күп килгән, ләкин артык зур канәгатьләнү алмаган. Рецензент тә спектакльне мактамый. «Пәрдәләргә бүлгәләүләр һәм башка техника яклары яхшы эшләнгән»,— ди ул.— Ләкин роман яисә хикәядән үзгәртеп эшләнгән пьесалар уңыш казансын өчен, «артистларның күп тырышлыгы һәм яхшы уйнаулары» таләп ителә. «Ширкәт» труппасы исә бу кыенлыкны җиңеп чыга алмаган.

Спектакль авторда нинди тәэсир калдырган? Бу сорауга без Ҡ. Шамил язмасына таянып кына җавап бирә алабыз. Спектакльдән соң әдип болай дип әйткән имеш: «Ничек тә бу бик ашыгыч булды. Башта мин комедия әсәре чыгар дип уйламаган идем, ләкин өстендә ныклабрак утырганда һәйбәт кенә сәхнә әсәре чыгуына ышандым инде». Спектакльнең «гаепле» кешесе әдипнең сүзләрен кыскартып һәм үз файдасына беркадәр үзгәртеп китергән тәкъдирдә дә Фатихның уйнаучыларга каты бәрелмичә, гаепне күбрәк үз өстенә алганлыгы аңлашыла. Пьесаның кулъязмасы өстенә «Халыкның атаклы артисты Ҡасим Шамилгә багышлыйм. Фатих. 1922—21/VIII» дигән сүзләр язып, бенефициантка бүләк итүе дә шул турыда сөйли.

Публицистик эшчәнлегенә килгәндә, «Татарстан хәбәрләре» газетасының штатында торуына карамастан, Фатих бу өлкәдәге уңышлары белән мактана алмый. Ачлык, аның сәбәпләре һәм көрәшү чаралары турында мәкалә язып биргән иде — басмадылар. Г. Барудины күмү уңае белән ачык хат язган иде — аңысын да дөньяга чыгара алмады.

«Фатих Әмирхан» дигән имзалы беренче материал — «Яз бәйрәме — Сабан туе» исемле озын очерк. Бу әсәрне укыганда Әмирханның күзәтчәнлегенә, өс-баш, кыйланыш һәм сүзләренә карап кешеләрне типларга аера белүенә, тапкыр детальләр, аз сүз белән һәр типның гаҗәеп җанлы сурәтен күз алдына бастыру осталыгына тагын бер кат сокланасың.

Менә түләүле автомобильдә килгән вак спекулянт. Аның «әле бөтенләй елкылдап җитмәгән, ләкин инде симерә башлаган йөзендә зур бер ләззәтләнү сизелә. Ул беразелмаебрак, мине күрәләр микән дигән төсле бер кыяфәт беләнрәк як-ягына каранып ала». 

Менә йөзе елкылдый ук башлаган спекулянт лихачка утырып килә. Аякларын чалмаштырып, пролеткага кырын яткан. Як-ягына инде ул алай ук каранмый. Гади халыкка өстән генә бер мәсхәрәле караш ташлый да «Мәхүпҗамалын, кулыннан тотып, лихачтан төшерә».

Менә тагын да шәбрәк лихач бер егет белән бер кызны китерә. «Кавалер бер ведомствоның төрле шәһәрләр арасында йөри торган курьеры гына булса да, киемне хәрби комсоставныкына охшатыбрак в обтяжку кигән». Кызы — бай кызы, гимназистка булса кирәк.

Әнә иске буржуаның карт вәкилләре. Ул инде элекке кебек һавалы түгел. Сабан туена да озын арбалы ямщикка ун кеше янына унберенче булып утырып килгән. Киемсалымы да гадәти генә. Дөрес, ул «таланган» булса да, яшереп калган малы «кызыл купецлар»ныкыннан бер дә ким түгел. Ләкин моны белдермәскә, мескен булып, фәкыйрь булып күренергә тырыша. Ачлар файдасына иганә җыючыларга ул: «Без эш итә торган кеше түгел! Яшь байлардан яхшы кубарыгыз сез, хәзер алар баедылар инде. Безне үзегез талап бетердегез бит»,— дип кенә җибәрә.

Ниһаять, пошкырынып, сигналын кычкыртып, автомобиль мәйданның уртасына ук ерып керә. Аннан властьның түбән баскычында торып та, үзләрен зур итеп күрсәтүче җаваплы работниклар төшә. Итенешләре, ди Әмирхан, өяз

шәһәрендәге коллежский ассессорның исправник күрмәгән чактагы кыланышын хәтерләтә.

Әнә шул типларны күздән кичергәннән соң, Ф. Әмирхан болай дип куя: «Гасырлар белән ясалып килгән типларның кызыл туфан белән себерелеп бетүе өчен дә еллар кирәк була ахрысы, һәм партиягә, һәм Совет властена бу турыда шактый көч сарыф итәргә лазем булачак әле!».

Ф. Әмирханның игътибары аеруча милли мәсьәләгә юнәлгәнне без яхшы беләбез. Бу мәсьәләне, уңга да, сулга да авышмыйча, партия программасында әйтелгәнчә аңлый башлаганына да ышандык. Татар теле дәүләт теле булып игълан ителгәннән соң, бу актны практик рәвештә тормышка ашыру эшләрен Фатих, билгеле инде, игътибар белән күзәтә, күзәтеп кенә калмыйча, кулыннан килгән кадәр булыша, уңышларга куана, кимчелекләргә ачына. Карап торышка кечкенә бер вакыйга уңае белән ул татар телен гамәлгә ашыру комиссиясе исеменә «Татарстан» газетасында ачык хат та бастыра.

Эш болай булган. Ышаныч кәгазен татарча язып (дәүләт теле бит), Фатих бер кешесен үзенә тиешле паекны алырга җибәрә. «Бездә татарча укый белүче юк» дип, бирми кайтаралар. Иртәгә паекны алуның соңгы көне булганга, Фатих, теләсә теләмәсә дә ышаныч кәгазен русча язып бирә. Тегендә бәйләнергә тагын сылтау тапканнар: имзаңны русча куй. Бер рус хатыныннан кул куйдырып, теге кеше көч-хәл белән паекны алып кайткан.

«Татарстанның автономияле җөмһүрият булып игълан ителгәнлегенә инде ике ел тулган бер көндә,— дип яза Әмирхан,— бу урындагы хадимнәрнең татарча неграмотный булучылыклары татарча язылган сәнәдләрне * гамәлгә ашырмаска законлы юл була алмаганы шикелле, Татарстанда «татарча кул куюны игътибарга алмыйбыз» дип игълан итү, иң йомшак тәгъбир белән әйткәндә дә әдәпсезлек, саботаж».

Татар телен гамәлгә ашыру хәрәкәтенең бер тармагы — терминнар эшләп чыгару. Фатих — шуның комиссиясендә әгъза. Теләп эшли. «Мәдәниләшү юлында зур бер адым» исемле мәкалә яза.

Терминнар карарлашмаган хәлдә, ди Ф. Әмирхан, мәктәп тә, чын мәгънәсендә укыту да була алмый. Ә дәүләт учреждениеләре? Фәннең төрле тармакларына караган әдәбият? Аерым алганда, кодекс, карарлар һәм конституцияне тәрҗемә итү мәҗбүрияте? Терминнарны эшләп чы-

* Сәнәд — документ.

гарып, гамәлгә кертү — «татар ярлысының мәдәниләшүе өчен зарур булган нигез ташларының бик әһәмиятлесе». Культуралы телләрдә терминнар гасырлар буе эшләнеп килгән, диярсез. Ләкин, ди Әмирхан, безгә «андый эволюциянең имкяны юк, безгә революция генә мөмкин».

## 3

1922 елда Фатихның тормышында әһәмиятле ике үзгәреш була. Берсе — торыр өчен шәһәргә күчеп китү, икенчесе — яңа туып килә торган татар театр техникумында татар әдәбияты укытучысы итеп чакырылу.

Ибраһим Кырымнан кайтып Казанда эшли башлагач, күрәсең, башларына уй килгән: ата-баба нигезе газиз булса да, моннан ары Яңа бистәдә яшәү мөмкин түгел. Бигрәк тә Фатих өчен. Ат һәм хезмәтче тотып булмый. Яз-көз айларында утраудагы Робинзон хәлендә кала. Ревтрибуналның бер бүлегендә прокурор ярдәмчесе булып эшли башлаган Ибраһимга да Бистәдә торып эшкә йөрү шактый кыен.

Иске нигездә ничек кирәк алай кыш чыгалар да, өйләрен сатып, хәзерге Нариман урамындагы бер йортка барып урнашалар. Ни өчендер анда озак тормыйча, Миславский урамына күчәләр. Анда да озак калмыйлар. 1923 елда инде без аларны Большая Красная һәм Жуковский урамнары кисешкән чаттагы өйдә яшәп ятканнары хәлдә күрәбез.

Зур булмаган ике катлы йорт. Аскы каты тулысынча Әмирхановларныкы. Биш-алты бүлмә. Ике тәрәзәсе Большая Краснаяга, икесе Жуковский урамына караган зур якты бүлмә — Фатихның кабинеты. Янәшәдә — йокы бүлмәсе. Караваты янында телефон. Хәлнең болайга әйләнеп китүендә Әмирханның татар культурасы тарихында тоткан урыны гына түгел, бәлки Ибраһим Әмирхановның эш урыны да билгеле бер роль уйнаган булса кирәк. Бу вакытта инде ул өлкә суды председателе урынбасары. Квартира зурын зур, әмма анда яшәүчеләр дә байтак. Нәфисә белән Ибраһимнан кала Нәфисәнең энисе Газизә дә шунда яши башлый. Педагогия институтына укырга кергән Разия дә бу гаиләгә күчеп килә. Бер замандашымның әйтүенә караганда, тагын бер яшүсмер булган. Икенче бер чыганактан бу яшүсмернең Разия энесе Мәхмүт икәнен беләбез. Фатихка ярдәм йөзеннән даими яшәгәнме ул, торып-торып кына киткәнме — бусы мәгълүм түгел.

Кыскасы, Әмирхан хәлендәге кеше өчен барлык шартлар дип әйтерлек тудырыла. Шәһәр уртасы, барасы урыннар якын, бата-чума йөрисе түгел, эшләсә — кабинеты, авырса — тыныч ятак бүлмәсе, тышкы дөнья белән бәйли торган телефоны бар, һәр теләгән үтәргә әзер торучы якын кешеләре янында гына. Бу үзгәреш, билгеле инде, әдипнең күңеле күтәрелүгә, эш дәртенең артуына сәбәп булмый калмаган.

Техникум мәсьәләсенә килик.

Театр бүген белән генә яши алмый. Ул вакыттагы артистларның барысы да диярлек, махсус мәктәп үтмичә, егыла-тора барып, талант һәм фидакарьлекләре аркасында гына осталыкка ирешкәннәр иде. Моннан соң алай булмасын өчен сәләтле яшьләргә, гомуми белем һәм сәхнә тәрбиясе биреп, җитлегүләрен тизләтергә кирәк. Кыскасы, махсус уку йорты — театр техникумы ачу мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баса. 1922 елның октябрь аенда Мәгариф халык комиссариаты техникум ачу турында карар чыгара һәм әзерләү, оештыру эшләрен Зәйни Солтанов һәм режиссер З. М. Славянова иптәшләргә тапшыра.

Ф. Әмирханның әдәбият укытучысы итеп чакырылуы табигый: зур әдип, драматург, оста тәнкыйтьче, тирән белемле һәм киң карашлы әдәбият белгече. Әдип моны теләп кабул итә. Чөнки файдалы эш, кирәкле эш: татар театрының киләчәге шушы яшь егет һәм яшь кызлар кулында.

Январьга кадәр әзерлек эшләре бара. Хәзерге М. Җәлил урамыннан бина алына, укытучылар алына, тиешле имтихан үткәрелеп, беренче һәм икенче курсларга укучылар кабул ителә. Арада исемнәре соңыннан киң таралган Р. Ишморатов, Х. Сәлимҗанов, өч Галия — Кайбицкая, Булатова, Нигъмәтуллина да бар. Алай-болай гына түгел, техникумга Габдулла Кариев исемен дә кушып куялар.

1923 елның январенда техникум эшкә башлый. Ф. Әмирханның дәресләре кафедра артына басып, конспектына кадалган килеш бер тон белән укый торган «профессор» лекциясе кебек булмаган. Беренче укучыларының раславына караганда, ул җанлы итеп, отышлы мисаллар китерә-китерә дөнья классикларыннан башлап үзе аралашкан әдипләргә кадәр, иҗатларына һәм шәхси тормышларына мөрәҗәгать иткәләп, еш кына юмор һәм ирония катыштырып сөйли икән. Аның «лекцияләре» җанлы әңгәмә рәвешен ала, еш кына бәхәс-диспутка әверелеп китә.

Пушкиннарны заман пароходыннан төртеп төшерергә чакырган, үткәндәге культура мирасын тәпкүтәрәм инкяр

иткән пролеткультчылык В. И. Ленин язган резолюциядә хөкем ителгән булса да, шаукымы әле яши. Яши генә түгел, икенчерәк рәвеш алып, куәтләнә, көчәя бара.

Үзләрен революционер санаган яшь язучылар бер нәрсәдә хаклы: бүгенге турында да, үткән турында да элеккечә язарга ярамый. Ничектер бүтәнчә, яңача язарга кирәк. Сынап карау, эксперимент ясау, форма өлкәсендә эзләнүләр башлана. «Реализм искерде, ул буржуа стиле!» дип аваз салучы кайнар башлар да килеп чыга.

Эзләнүнең табылганнардан чыгып, традициягә нигезләнеп эш иткәндә генә уңай нәтиҗәгә китерүе мәгълүм нәрсә. Элеккеге һәммә нәрсәне, бигрәк тә реализмны чүпкә чыгарып эзләнденме, шул ук үткәндәгегә, әмма аның начарына, яраксызына тап буласың (яңалык — нык онытылган искелек, диләр бит). Безнең «новаторлар» да үзләренә кирәклене Көнбатыш Европада XIX гасыр ахырында ук баш калкыткан, реакция чорында Россиядә дә киң җәелеп киткән декадентлык әдәбиятыннан эзләп таптылар. Лидерлары Гадел Кутуй булган бер төркем яшьләр үзләрен футурист санап, түбәндәгегә охшаш шигырьләр яза башладылар:

Ай
Маена —
Май аена.
Майдан —
Майга — май!
Таң аеннан
Бәйнәлмиләл май,
Майга — майлар
Кычкыра урра!
Майга урра!
— Урра Майга!
Майга —
          тай!

Кави Нәҗми үзен имажинист дип игълан итте һәм шушы агымны татар әдәбиятына кертергә азапланды. Менә аның шул чакта язганыннан бер өзек:

Завод этәче
Корымга манчылган җиз кикериген
Җилгә бәрде.
Таш урамнарның тимер көянтәсен
Зәһәр очкыннар белән чагып,
Югалды ак яшен.

Берәр нәрсә аңладыгызмы, укучым? Сизеп торам, аңламадыгыз. Баксаң, әйтергә теләгәне бик гади нәрсә икән: «Гудок тавышы яңгырады. Урам өстенә сузылган тимер чыбыктан очкыннар чыгарып трамвай узып китте».

Бу төркем үзен соңрак сулфчылар, ягъни «сул фронт» тарафдарлары дип атый башласа да, иҗат принциплары-ның асылы күп үзгәрмәде. Форма белән мавыгу, шул ук формализм. Театрда да шуңа охшаш иҗади-эстетик көрәш барды. Үзләрен яңа театр, революцион театр тудыручылар дип ышанган сәнгать әһелләре «иске» театрның реалистик традицияләренә, реализм тарафдарларына һөҗүм итә башладылар. Бу шаукым театр техникумына да үтеп керә һәм көч ала бара. Я. П. Гамза, Б. Н. Симолин, К. К. Чеботарев кебек укытучылар шикле эксперимент һәм трюклар ясарга, формализмга кайтып кала торган иҗат принциплары урнаштырырга керешәләр. З. М. Славянова, А. М. Кречетов һәм К. Тинчурин кебек реализм тарафдарларына укытучылык эшеннән китүдән бүтән чара калмый. Күпчелеге авылдан килгән тәҗрибәсез, беркатлы һәм әзерлеге чамалы булган яшьләр нишләсеннәр, яңа театр шундый булырга тиеш дип ышанып, укытучылары биргән сабакны тырышып үзләштерәләр. Җитмәсә, арада үзләрен футуризм тарафдары яисә сулфчылар дип йөргән егетләр дә байтак.

Ф. Әмирхан дәресләренең вакыт-вакыт бәхәс рәвешен алуы, димәк, очраклы хәл түгел. Әдип реализмны алга сөрә, әлеге егетләр исә «сул» агымнарны яклыйлар. Тик менә Әмирхан белән алышыр өчен буыннары сыеграк. Әдиптә факт, дәлил, логика — аллага шөкер. Шуңа ирония һәм сарказмны да кушып җибәрсә, судан чыгарылган балык хәлендә калачагыңны көт дә тор. Бервакыт болай дип сөйләгән. «Элек Казанда килделе-киттеле бер кеше бар иде. Муенына калай банка һәм бүтән төр шалтыравыклы нәрсәләр тагып, мәгънәсез такмаклар сөйли-сөйли кешеләрне көлдереп йөрер иде. Баскыч-баскыч итеп язылган, нормальный кешеләр аңламый торган шигырьләре белән Кутуй иптәш һәм Нәҗми товарищлар әнә шул адәмне хәтерләтәләр».

Арада, бәхәстә җиңелеп, бүтән чара тапмыйча әдәпсезлек күрсәтүчеләр, укытучыларын гаепләп «кызыл» сүз кычкыручылар булгаласа да, техникум укучылары Әмирхан дәресләренә теләп йөргәннәр, сөйләгәннәрен йотылып тыңлаганнар. Риза Ишморатов, мәсәлән, Кутуйның якын дусты булуына һәм үзен сулфчы санавына карамастан, Ф. Әмирханның дәресләрен көтеп ала икән. Бүтәннәрдән алдарак өлгереп, аны тарантастан күтәреп алырга һәм класстагы урынына кертеп утыртырга тырыша торган булган. Әдип тә аңа аерыбрак карый башлаган. «Бер көнне,—

дип яза Р. Ишморат,— аны күтәреп барган арада миңа сорау бирә:

— Риза туган, сез бу котырганнар арасына ничек килеп эләктегез?»

Бер заман шулай Әмирхановлар өенә йолкыш кына бер хуҗасыз эт ияләшкән. Чөнки калдык аш-су һәм сөяк-санак җитәрлек. Фатих аңа «футурист» дигән кушамат тагып куйган. Газзә абыстай исә, бу сүзнең «этимологиясен» үзенчә аңлап, «Котурис» дип йөртә башлаган. Ашарга чыгардымы, «Котурис! Котурис!» дип дәшеп ала икән. Фатих моны ишеткәч, кәефе килеп озак итеп бер көлгән. Соңрак үзенең дә бу сүзне куллануы һәм, чыганагы турында сөйләп, тыңлаучыларны көлдергән булуы бик ихтимал.

Ф. Әмирханның реализм хакына футуризм һәм имажинизмны тәнкыйть итүе техникум эчендә генә калмаган. Аерым мәҗлесләрдә дә, төрле утырыш-җыелышларда да уңае чыккан саен фикерен боргаламый-нитми әйтә торган булган, хәтта бу агымнарның вәкилләре кәламеннән чыккан шигырьләргә пародияләр дә язган.

Архивыннан алып бер генә өзек китереп узыйм.

Чүп иләгән сыйракларым —
Урам былчырагын
Таптый, таптый җеп эрләде:
«Мин дә землямер,
Без биш-алтау
Эче куыш башның бер очы —
Аякка сыланган күмергә ут түгә,
Икенчесе —
Марс йолдызының колагын борып,
Чуен баганалар үбә».
Имажинимчә бер сәлам,
Таш муеннар, агач авызлар
Инә аркылы тау йоттылар.
Салам сыйраклардан салам сыйракларга,
Таш борыннардан агач кешеләргә
Кикрикүкле ач сәлам.

Техникумга кайтыйк. Укулар башланып бер ай да үтмәстән ни өчендер З. Солтанов урынына З. Баязитский мөдир булып алган. Бу шәхеснең җитәкчегә хас уңай яклары булуга карамастан, ике ел мөтдәтендә эшләр күп алга китмәгән. Мөдире итеп К. Төхфәтуллин билгеләнүе исә балта биреп шөшле алу кебегрәк килеп чыккан.

Һәрнәрсәне йөрәгенә якын ала торган Әмирханны сәхнә белеме бирүнең куелышы, метод һәм алымнары, билгеле, ачындырган. Педсовет утырышында да дәлилләп сөйли,

театрга кагылышлы җитәкчеләргә дә хәлне аңлатырга тырыша. Уңай нәтиҗә күренмәгәч, Мәгариф халык комиссариатына хат белән мөрәҗәгать итә. Бу хат сакланмаган. Эчтәлегенең бер замандашы хәтерендә калган кадәресе түбәндәгечә.

Большевик агайлар! Сез мине гафу итегез! Бу хатны мин йөрәгем әрнегәнгә күрә язам. Татар театрына һәм ул театрны киләчәктә үстерергә тиешле яшь артистларны ничек тәрбияләп үстерүгә мин читтән торып күзәтүче булып кына кала алмыйм, моңа минем вөҗданым кушмый. Татарның әдәбияты белән бергә сәнгате, театры да бер сафта үсәргә тиеш. Ләкин яшь талантларны хәзерге театр техникумындагыча тәрбияләү татар театрын үстерүгә хезмәт итәчәк артистлар җитештерер дип уйлау хата фикер булыр иде. Татар театры реалистик юл белән үсәргә тиеш һәм аның киләчәктәге артистлары да реалистик юл белән тәрбияләнергә тиешләр. Техникумда уку-укыту эшләрен «футуризм» дигән котсыз бер агым буенча алып бару — яшь талантларны һәлакәткә илтү, агулау һәм харап итү. Бу зарарлы агым тиз арада туктатылыр дип ышанам. Большевик агайлар! Татар театр техникумына килеп кергән шушы «футуризм» авыруын тизлек белән кисеп ташлап, яшь талантларның гомерен агулаудан коткара күрегез. Татар театрының алга баруына бу ярдәм булыр. Бу әйткәннәргә колак салыгыз. Яшь буын өчен, аларның киләчәге өчен без җавап бирәбез, без алар алдында бурычлы.

Бу хаттан соң техникумда хәлләр үзгәрмәү генә түгел, мөдир һәм кайбер укытучылар Ф. Әмирханга кырын күз белән карый башлаганнар, аны искегә ябышып ятуда, буржуа театрын яклауда гаепләгәннәр, буржуа идеологы дигән мөһер басуга кадәр барып җиткәннәр.

Эшләр шулайга таба борылгач, 1924—1925 уку елы башлангач, Әмирхан «мин реализм юлы белән иҗат итүче кадрлар әзерләүне бурыч итеп куйган идем, әмма цирк клоуннары түгел» ди дә, гариза язып, техникумнан китә.

Хәер, без шактый алга сикердек. 1923 елга кайтыйк.

## 4

Плеврит белән авырып, газеталарны тәртипле рәвештә карап бара алмаганлыктан, Фатих Мәҗит Гафуриның 20 еллык иҗат бәйрәмен билгеләп үтүне бераз соңгарып ишетә һәм, соң булса да уң булсын дигәндәй, 6 июнь көнне шагыйрьгә котлау хаты язарга утыра. Сәлам күндереп, хезмәт бәйрәме белән тәбрик иткәннән соң, мәдрәсә шәкер-

те чагында ук Гафури шигырьләрен яратып укый башлаганын һәм хәзер егерме еллык әдәби хезмәтен ихлас күңелдән «тәкъдир итүчеләрнең берсе» булганлыгын белдерә дә түбәндәге сүзләрне язып куя: «Сез соңгы елларда шактый күп нәрсә язып өлгердегез. Бу шагыйрь өчен зур бәхет. Менә мин һаман әле гомеремнең шул дәверенә килеп чыга алмыйм. Бары соңгы елларда гына үземнең «амплуамны» таба алдым, соңгы елларның соңгы көннәрендә генә яза башлау дәверемне башлап китәм бугай».

Барыннан да элек яхшы мәгънәсендә көнләшү сизелә бу сүзләрдә. Кемнән көнләшә бит! Февраль революциясе булу белән үк эшчеләр сыйныфын танып алып, «Кызыл байрак» исемле атаклы шигырен язган, Октябрь революциясен икеләнүсез кабул иткән, революциянең җиңүе, гражданнар сугышында Советлар властен саклап калу хакына армый-талмый каләм хезмәте күрсәткән, илдә тынычлык урнашкач та ал-ял итеп тормастан шигырьдә булсын, прозада булсын чын мәгънәсендә «советчыл» әсәрләрен бер-бер артлы дөньяга чыгарып торган кешедән көнләшә.

«Амплуа» дигәнен ничек аңларга? Сүз жанр алыштыру турында бармый, әлбәттә. «Ситдикъ мәхдүм» кебекләр белән бик үк мавыкмыйча, әйтик, М. Гафури һәм Г. Ибраһимов шикелле яңа кешеләр турында яңача язарга телим дигән мәгънә аңлыйм мин аның амплуа турындагы сүзләреннән.

Хатында тагын Фатих кымызга барырга ниятләп торганын, июнь урталарында Уфага таба юл тотачагын һәм анда, М. Гафурины күреп, озаклап сөйләшеп утыруын өмет иткәнлеге турында яза.

Чынлап та, әйтелгән вакытта Фатих юлга чыккан, Уфага барып, анда күпмедер көннәр үткәргән. М. Гафури белән дә, язучы-журналистлар һәм бүтән мәдәният әһелләре белән дә очрашкан, утырдаш булган. Материаллар табылмаганга күрә, тәфсыйле безгә мәгълүм түгел. 2 июль көнне, Күчем дигән авылда кымыз эчәргә дип, Чишмә станциясенә кадәр поездга утырып киткәне генә билгеле. Моңарчы, күрәсең, Әмирханның кресло-коляскасын поезд вагонына кертми азапланганнар. Шуңа күрә дуслары БашЦИКтан Уфа станциясе начальнигына адресланган һәм тоткарлык ясамаска кушылган үтенеч кәгазе алып озаталар.

Безгә таныш елгачы Хәбибрахман Рәфыйков Ф. Әмирханның 1923 елгы җәе турында бүтәнрәк белешмә бирә. Навигация башлангач, ул әтисе аркылы Фатих абыйсына

сүз салган: пароходта йөреп кайтырга теләмиме, теләсә — кайчан? Әмирхан 25 июнь көнен билгеләгән. Пароход, Әстерханнан менеп Казан пристанена туктагач, Хәбибрахманны, Фатихтан кала, профессор Әбүбәкер Терегулов һәм Зыя Ваһапов көтеп торалар икән. Ә. Терегулов, күрәсең, әдип белән берлектә сәяхәт итәргә карар кылган. Әмирхановларның күршесе һәм якын кешесе Зыя исә, дөнья күреп кайтудан тыш, Фатихка ярдәм йөзеннән юлга чыккан булыр.

Бу сәяхәт турында озын-озак сөйләп торырга хаҗәт юк. Нижний Новгород. Аның күренекле урыннарын карап кайту. Аннары — яңадан Казан. Пристаньда көтеп тора торган туган-тумачалар белән күрешеп китү. Эреле-ваклы шәһәрләрне карап узу. Ниһаять, Әстерхан. Хәбибрахман катнашында шәһәргә чыгу, «Фонарик» бакчасына бару, рестораныңда сыйланып кайту. Ниһаять, пароход Идел буйлап югары якка юл тота һәм безнең сәяхәтчеләр Казанда төшеп калалар.

Әмирханның Нижний Новгород һәм Әстерхан арасында йөреп кайтканына шикләнергә туры килми. Ләкин бу сәяхәт яки Фатих кымыздан кайткач август аенда, яки — бусы ихтималга якынрак — 1924 елда булган.

Техникумда укыту белән бергә 1923 елда Фатих сирәгрәк булса да матбугатта да катнаша, үзенчәлекле хәле һәм саулыгы мөмкинлек биргән дәрәҗәдә утырыш, җыелыш, киңәшмәләрне дә, театр-концертларны да калдырмаска тырыша. Март башында ул, мәсәлән, партия, совет, матбугат эшчеләре тарафыннан ясалган әдәбият кичәсеннән зур канәгатьләнү алып кайта һәм мәкалә язып бастыра. Әдип анда тамашачылар составының күзгә күренеп үзгәргәнлегенә игътибар иткән. «Иске буржуа юк дип әйтерлек, яңа буржуа — нэпман һәм башка һәрбер кичәдәгеләргә караганда азчылык, бу инде өр-яңа бер даирә — совет зыялылары даирәсе. Монда иске зыялы сыйныфның революция белән кулга-кул тотынып эшләп киткән гонсыры белән бергә, әүвәлдә «түбән катлау» дип атала торган чын халык гаммәсенең үз эченнән чыгып та, революция елларында укыган яхут эш өстендә тәҗрибә күреп шомарган, мәдәниләшкән, аңлаш һәм караш даирәсен киңәйткән һәм әле дә киңәйтүдә дәвам итә торган саглам * бер гонсыр партиялесе, партиясезе бер даирә тәшкил иткәннәр».

* Саглам — таза, ныклы.

1923 елда танылган тел галиме Мөхетдин Корбангалиевнең фәнни-педагогик эшчәнлегенә 30 ел тулуга багышланган утырыш була. Чыгып сөйләр өчен Фатих текст яза. Ләкин авыру сәбәпле бара алмый кала.

Ул заман гадәтенчә, Тукайның үлүенә ун ел тулу көнен билгеләп үтәләр. Әмирхан да битараф калмый. «Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим» исемле мәкалә язып бастыра.

Шулай да Ф. Әмирхан күп язган, күп басылган дип булмый. 1924 ел исә бөтенләй аптырашта калдыра: вакытлы матбугатта әдип бөтенләй дип әйтерлек күренми.

Дөрес, эштә юаныч таба торган Фатих тик тормаган. Ул бит әле укытучы кеше. Һәр дәресенә яхшылап әзерләнә, күп укый, күп нәрсәне күздән кичерә.

Тагын бер эше — элек язганнарын барлап, төзәтәсен төзәтеп, кабат бастыруга әзерләү. Бер җыентыгы 1925 елда Казанда басылып та чыга, икенчесе Мәскәү нәшрияты портфеленә барып керә.

Тагын нәрсә? Укыган, гаять күп укыган. Китапханәсенең архивта сакланган китаплар исемлеге күплеге һәм төрлелеге белән гаҗәпкә калдыра. 20 елларга караган куен дәфтәре дә кызыклы. Табып укырга дип язып куелган китап исемнәре нинди генә өлкәгә карамый! Тарих һәм медицина, үсемлекләр дөньясы һәм дарвинизм, философия һәм эсперанто теле, Тимирязев һәм китапханәне тәртипкә салу системасы...

Ф. Әмирханны бөтереп алган тагын бер эш бар... Ул да булса — милли опера, татар операсы тудыру. Юк, опера язарга керешмәде ул, әмма без аны беренче татар операсының кендек әбиләреннән берсе булды дип әйтә алабыз.

Татар театрының бер үзенчәлеге шунда: ул музыка белән тыгыз бәйләнештә үсеп китте. Бер-бер артлы музыкаль драма һәм музыкаль комедияләр барлыкка килде, шаулап бара башлады. Музыкаль драматургиянең тууы, үсүе һәм камилләшә баруы белән берлектә, Солтан Габәши һәм Салих Сәйдәшев кебек композиторлар, Газиз Әлмөхәммәтов, Сара Садыйкова, Галия Кайбицкая кебек җырчылар җитеште.

Кыскасы, татар операсы тудыру мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баса. Һәм моның өчен мөмкинлекләр нигездә өлгереп җитә. Бу эшкә С. Габәши белән Г. Әлмөхәммәтов алыналар. Җәмәгатьчелек опера мәсьәләсен зур куану белән каршылаган шикелле, Татарстан хөкүмәте дә хуплый. Ярдәмгә татар-башкорт көйләре белән таныш булган кү-

ренекле музыка белгече композитор В. И. Виноградовны чакыралар. Хөкүмәт органнары бу «өчлек»кә тиешле эш шартларын тудыра һәм 1923 елда «Сания» дигән исем астында тарихка керәчәк операны тудыру юнәлешендә эш башлана. Рәсми рәвештә үк булмаса да, Ф. Әмирхан да шушы «өчлек»кә кушылып китә. Замандашларының истәлекләреннән күренгәнчә, эш күп вакыт Әмирхан бүлмәсендә барган. Шушы уңай белән ме яки элегрәкме, Жуковский урамына күчкәч Фатих рояль сатып алган. Истәлекчеләр Г. Әлмөхәммәтов, С. Садыйкова һәм башка кайбер җырчыларның Әмирхановлар өендә операдан арияләр башкарганлыклары турында хикәя итәләр.

Ике елдан соң, ягъни 1925 елның язында «Сания» операсы язылып бетә һәм Татарстан автономияле республикасының тууына биш ел тулган көнне сәхнәдән күрсәтергә карар ителә. «Безнең юл» журналының май санында «Беренче татар операсы язылып бетү мөнәсәбәте белән» дигән исем астында басылган мәкаләсендә Ф. Әмирхан, бу хезмәтнең башланышы, барышы һәм әһәмияте турында зур куаныч белән язганнан соң, сүзен болай дип тәмам итә: «Беренче татар операсының барлыкка чыгуында Татарстан хөкүмәтенең үзенең һәртөрле ярдәмнәре белән бик якыннан катнашканлыгын хәтергә алсак, аның беренче куелышының җөмһүрият бәйрәме көнендә булуы коры бер рәсмият кенә түгел, коры бер туры килеш кенә түгел, бәлки шулай булырга тиеш, шулай булучылыгы гына табигый бер эш икәнлеген ачык төшенербез».

Егерменче елларның уртасына таба хуҗалык һәм экономика өлкәсендәме ул, иҗтимагый-политик төзелеш һәм культура өлкәсендәме, Ф. Әмирханны куандырырлык уңышлар аз булмады. Әнә мәктәп юлга салынып бара. Фәндә дә җанланыш сизелә. Тарихчылар яңача, яңа күзлектән карап, татар халкы тарихын өйрәнергә керештеләр. Күпләгән мәкалә һәм аерым китаплар рәвешендә нәтиҗәсе дә күренә башлады. Әдәбият белгечләре дә тик ятмыйлар. Әнә Җ. Вәлидинең «Очерк литературы и образованности татар» дигән китабы, бик тиз сатылып бетү белән бергә, соңыннан билгеле булганча, хәтта В. И. Ленинның шәхси китапханәсенә барып керә. Әнә Г. Газиз белән Г. Рәхим татар әдәбияты тарихын, Адәм галәйһиссәламнан башлап дигәндәй, өйрәнергә керешәләр һәм хезмәтләрен кисәкләп чыгара башлыйлар.

НЭП башлангач, хозрасчет кертелеп, һәр газета яисә журнал үз килере хисабына гына яшәргә мәҗбүр булганга, татар вакытлы матбугаты бер-ике газета белән генә чик-

ләнеп калган иде. Партия-совет органнарының кайгыртуы, эшлекле чаралар күрүе нәтиҗәсендә Казанда һәм бүтән төбәкләрдә чыга башлаган газеталарның саны 1925 елда 12 гә, журналларның саны 9 га җитте (район газеталары бу исәпкә керми).

Әдәбиятның үз уңышларын да күзе сукыр кеше генә күрмәскә мөмкин. Әйдәп баручы әдип Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми?» повесте яисә казакъ халкының талантлы улы язган дип уйларлык «Казакъ кызы» романы үзләре генә ни тора! Яшьләрдән дә шактый күп өметле прозаик, шагыйрь һәм драматурглар үсеп килә. Әнә Ш. Усманов һәм М. Максуд, әнә Һ. Такташ һәм М. Җәлил.

Театрның уңышлары турында сүз булган иде инде, «Сания» операсы уңае белән музыка сәнгатенең нинди югарылыкка күтәрелгәнен күрдек.

20 елларның уртасында һәм икенче яртысында, яңа сыйфат сикереше булып, эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культураның нигез ташлары салынды дисәк, ялгышмабыз.

Әмма гаҗәеп хәл: бер яктан, татар совет культурасының тиз үсешен күреп торган Ф. Әмирханның куанычы арта бара, ә икенче яктан, аңа карата мөнәсәбәт начарлануга таба китә. Бу хәл 1922 елда ук сизелә башлаган иде.

«Татарстан хәбәрләре» газетасының 29 январь санында, мәсәлән, Г. Толымбайның «Сәхнә тирәсендә» исемле кечкенә фельетоны басыла. Ике нэпман, янәсе, театр турында сөйләшеп баралар. Сәүдә эшендә арыгач, театрга барып ял итәләр икән алар. Кызыксыз уеннар (ягъни революцион эчтәлекле спектакльләр) булса да, күңелгә хуш килә торганнары да җитәрлек икән.

— Әй, син ишеттең мәле,— ди берсе,— озакламый Әмирхановның «Тигезсезләр»ен куялар ди, ул да шәп бит, куйсалар, бармый калырга ярамас.

— Әбәзәтельни барабыз,— ди икенчесе,— первуй рәт безнеке инде ул, төкермисең дә, керәсең дә утырасың.

1922—1923 елгы сезон өчен Гыйльми үзәк тарафыннан расланган репертуар исемлегеннән, билгеле инде, «Тигезсезләр»не тапмыйбыз.

«Ярдәм мәҗмугасы»ның ике чыгарылышына язылган рецензияләр дә игътибарга лаеклы. Бер автор «Беренче ашкыну»да порнография күрсә, икенче автор «Тәгъзия»не «буржуазный агым»га кертә.

Вакытлар уза, Әмирханның киңәшенә, ярдәменә мөрәҗәгать итү кимүгә, бетүгә таба бара. Үзәгендә үк булмаса да, Әмирхан катышырга тиешле утырыш, җыелышларга да аны чакырмый башлыйлар. Исеме вакытлы матбугатта күренгәләсә дә, тискәре яктан телгә алына, иҗатына «буржуа язучысы» дигән мөһергә карап бәя бирелә. Мондый бәйләнү һәм чәнчеп алуларны Фатих башта көлеп кенә уздырса да, күбәеп киткәч, системага әйләнеп, кампания төсен алгач, авыр кичерә башлый.

«Безнең юл» журналының 1925 елгы 9—10 санында Хәйретдин Вәлинең «Татар буржуазия әдәбиятында бер тармак» исемле мәкаләсе басылып чыга. Әмирхан — буржуа язучысы дигәнне исбат итәргә көчәнгән бу язмага тукталырга хаҗәт юк. «Ахмак кына, белемсез генә, башында тугыз гына винтлы Хәйретдин Вәлинең,— ди Фатих,— минем турыда нәрсә язуы минем өчен барыбер». Аны бу «мәкалә»нең билгеле бер даирә кешеләренә ярарга тырышып язылуы, үзенә һәм иҗатына каршы башланган кампаниянең бер чагылышы булып дөньяга килүе борчый.

«Кампания»нең икенче чагылышы профессиональ татар театрының тууына 20 ел тулуны билгеләп үтү белән бәйле. Моны без Ф. Әмирханның бастыру өчендерме, әллә үзе өчен генәме язылып, архивында ятып калган «Иҗтимагый оятсызлык» исемле язмасыннан беләбез.

Гыйльми үзәк юбилей комиссиясе барлыкка китерә, председателе итеп театр сәнгатеннән шактый ерак торган һәм, Әмирхан сүзләрен йомшартыбрак әйтсәк, ихласы күбрәк кызларда булган М. Парсин билгеләнә. Әмирхан исә комиссия составына да кертелми.

«Мин,— дип яза әдип,— моннан 20 ел әүвәл татарча спектакльнең башлап йөрүчесе һәм баш батыр ролен уйнаучысы, кирәк хикәяләремдә вә кирәк публицистикада татар театрының башлануы, бара алуы, мөмкин кадәр мәгънәле баруы, мөмкин кадәр санаигы нәфисә * булудан чыкмавы өчен 12—15 ел эчендә иң кызу каләм көрәше алып барган мин, начармы, яхмышы ике пьеса хуҗасы, начармы, яхшымы 20 еллык журналист — юбилейның мәҗлесенә дә ** чакырылмадым!»

Ф. Әмирханга карата мондый мөнәсәбәт урнашуның төп сәбәбен әдәби тәнкыйтьтә әлеге сыйнфый принципның

---

* Санаигы нәфисә — нәфис сәнгать.

** Тантаналы җыелыш ни өчендер 1926 елның гыйнваренда уздырылган.

тупас һәм турысызыклы итеп үткәрелүеннән эзләргә кирәк. Эшче баласы яки аның вәкиле түгелсең икән, яисә завод морҗасына мәдхия җырламыйсың икән, син буржуа язучысы буласың.

Ф. Әмирхан очрагында моңа шәхси исәп-хисап та өстәлгән. Әдипнең туры сүзле һәм ачы телле булганлыгын беләбез. 1923—1925 елларда тел чыбыркысының футурист, имажинист һәм бүтән төр «шәйтанист»лар сыртына төшкәнен дә күреп уздык. Болар бит инде үзләрен революцион каләм ияләре, яңа сәнгать, пролетариат сәнгате тудыручылар дип исәплиләр. Аларга һөҗүм итүче Фатих Әмирхан кем була? Билгеле инде, буржуа хадиме, капитал ялчысы, контрреволюционер була. Ф. Әмирхан культура хәрәкәтенең башында торган Г. Ибраһимовка, хәтта Татарстан хөкүмәтенең зур җитәкчеләренә дә тәнкыйтьтән өлеш чыгарган.

1921 ел көзендә яза башлаган көндәлегеннән күренгәнчә, Фатих ниндидер дустының киңәше белән шәһәр тәэминат бүлегенә пенсия сорап гариза бирә. Шуннан соң дүрт-биш ай вакыт узган, әмма бер егетнең анкета тутыртып һәм бер врачның карап, тикшереп китүен искә алмаганда, күп эш чыкмаган. Мәсьәлә бәлки соңрак хәл ителгәндер? Юк, хәл ителмәгән: пенсия алучыларның 1922—1924 елларга караган исемлекләрен җентекләп карап чыксам да, Фатих фамилиясен таба алмадым. 1925 елның көзендә генә мәсьәлә уңай хәл ителгән: аңа, ниһаять, персональ пенсия билгелиләр.

Мәсьәләнең хәл ителеше елларга тартыла башлагач, сәбәбен волокита белән генә аңлатып булмый инде. Монда, һичшиксез, «сулга каеручыларның», шулай ук үчле һәм көнче кешеләрнең кулы уйнаган: «Совет акчасын буржуа ялчысына, революция дошманына бирергә! Ул ни дигән сүз?»

1923 елда уй-фикере утырып һәм күңеле карарлашып, «амплуа»сын тапкандай булса да, Әмирханның 1924 елда матбугатта бөтенләй күренмәвенә, 1925 елда да күп басылмавына гаҗәпләнергә туры килми. Маңгаена «дошман» дигән мөһер сугып, сакланыгыз, бу безнең кеше түгел дип бармак белән төртеп күрсәтсәләр һәм уклар җибәреп торсалар, белмим, илһам дип атала торган нәзберек нәрсә янына бик ашыгыр иде микән. Моңа тагын соңгы елларда Фатихның еш авыруын һәм күбрәк урын өстендә ятуын өстик.

## 5

1925 елның җәендә Фатих, гомере тәмамланып килгәнне сизгәндәй, бер-бер артлы ике тапкыр сәяхәт ясый.

Июнь башында ул, пароход расписаниесенә баглы булмас өчен Хәбибрахман Рәфыйков игелегеннән файдаланмыйча, үзе белән энесе Зәкәрияне алып, Әстерханга юл тота. Барып җиткәч тә, беркемнән дә бәйле булмас өчен, гостиницага урнаша.

Ф. Әмирханның килүе шәһәрнең мәдәниятле татарлары өчен зур вакыйга булган, күрәсең, аны өлгерештән кунакка чакыра башлыйлар. 9 июнь көнне без аны Габдрахман Гомәри өендә күрәбез. Казан кунагына багышланган махсус мәҗлес булмаса да бу, шәһәрнең бик күп кешеләре, берсеннән берсе ишетеп, Әмирхан белән күрешергә килгәннәр, кайберләре — хуҗаның иң якын әшнәләре — утырып та калганнар.

Көнозынга тартылган бу утырышта күп сүз булган. Кызганычка каршы истәлекче, ягъни Хәмит Гомәров, кереп-чыгып йөреп, ара-тирә генә утырып калганга күрә, барысын да хәтерләми... Исендә калганнарыннан шул аңлашыла: сүз күбрәк төрки халыкларның мәдәнияте, фольклоры, татар зыялыларының шулар файдасына башкарган эшләре, әдәбият һәм сәнгать дөньясында кайчандыр исем казанган аерым кешеләрнең хәзерге хәлләре, яшәү рәвешләре турында барган. Укучы хәтерлидер, Габделбасыйрның прототибы турындагы сүз дә шушы мәҗлестә булган иде.

Үзлегеннән укып, ярыйсы гына белем иясе булган, әдәбият һәм сәнгатькә мөкиббән китеп, мәдәният файдасына хәленнән килгәнчә иганә кертә торган сәүдәгәр Гали Шакиров әдип хөрмәтенә махсус табын әзерләп чакыра. Ашау-эчү арасында җанлы әңгәмә белән шактый вакыт узгач, мәҗлес җыр-бию кичәсенә әверелеп китә. Кунакларның үтенүе һәм әтисенең рөхсәте белән унсигез яшьлек Фатыйма, үзе пианинода уйнап, «Уел» һәм «Эскадрон» көйләрен җырлаган. Кызның тавышы да, моңы һәм башкару рәвеше дә Фатихка ошаган булса кирәк, ул бу һөнәрне ташламаска, укырга, осталыгын арттырырга киңәш биргән. Аннары «Эскадрон» көенең сүзләрен язып бирүен үтенгән. Бүтән кунаклар да кайсы мандолинада, кайсы җырда һөнәрләрен күрсәтә башлаганнар. Биюләр дә булган. Хуҗа белән хуҗабикәне дә тартып чыгарып биеткәннәр.

Бер-ике көннән шушы мәҗлестә катнашкан юрист Борһан Бадамшин тырышлыгы белән, компания булып ое-

шып, Ф. Әмирханны «Аркадия» бакчасына алып барганнар. Әдипне үз өендә кунак итәргә теләгән әстерханлыларның байтак булганлыгына, күбесенә җитешә алмаса да, кайберләренә барганына шикләнмәскә мөмкин.

Санаулы вакыт тиз уза. Көннәрдән бер көнне әдипне пристаньга алып төшеп китәләр дә, пароходның беренчеме, икенчеме класс каютасына урнаштырып, Әстерханнан озатып җибәрәләр.

Бу җәйдә дачага-фәләнгә чыгуы турында мәгълүмат юк. Хәер, Фатихның саулыгы дачаларда кәеф-сафа корып гомер үткәрүдән узган була инде. Интеллигенцияне берәр артлы алып китә торган «социаль» авыру — туберкулезы көчәя. Врачларга күренеп, киңәш-табыш итешкәч, Фатих Кырымга юл тотарга карар итә.

Уналты яшьтә чагында абыйсына ярдәм-хезмәт күрсәтеп юлдашлык иткән Зәкәрия Әмирхановның әйтүенә караганда, алар көньякка путевкасыз-нисез чыгып киткәннәр. Шулай булыр да: әдипкә карата урнашкан мөнәсәбәтне инде беләбез. Йөз суын түгеп, кая булса да путевка сорап мөрәҗәгать итү ихтималы бик аз.

Зәкәрия ага абыйсының материаль хәле кысынкы булганлыгы, шуңа күрә акчага әйләндерергә туры килмәгәе дип берничә алтын әйбер алганлыгы турында да әйтеп уза.

Августның беренче яртысында алар, плацкартный вагонга утырып, Казаннан чыгып китәләр. Юлда күңелле барганнар, мәзәк, уен-көлке җитәрлек булган (Ф. Әмирхан бар төштә күңелсез буламы?). Ике таныш кызының шушы вагонда баруы да әдипкә җорлык өстәми калмаган, күрәсең.

Мәскәүдә алар Фәхрелислам Агиевның Большая Татарская урамындагы квартирасында бер кич куналар. Әсәрләр җыентыгының Үзәк татар нәшрияты портфелендә ятканлыгы әйтелгән иде инде. Шушы нәшриятта эшләүче Фәхрелисламнан ул, күрәсең, җыентыгының язмышы турында белешергә, киңәш-табыш итешергә, кирәк булса, каләм тыгарга дип уйлаган.

Икенче көнне сәяхәтчеләр юлларын дәвам иттерәләр. Симферопольгә җиткәч, извозчик яллап, адрес буенча бер йортны эзләп табалар. Зәкәрия Фатихның визит карточкасын квартира хуҗасына кертеп бирә. Өйдә ыгы-зыгы куба. Ф. Әмирханны өйгә күтәреп алып керәләр. Ә кичен әдип хөрмәтенә 15—20 кешелек мәҗлес ясала. (Кем өе булды бу, кемнәр каршылады, мәҗлестә кемнәр катнашты, кызганычка каршы, яшүсмер егет белә дә, хәтерендә калдыра да алмаган).

Икенче көнне, Фатихның үтенүе буенча булса кирәк, аларны гостиницага урнаштыралар. Кунак йортында узган ике-өч көндә кайдадыр, кемнәрдер әдипне дәвалау мәсьәләсен хәл иткәннәр, ә Фатих килүче-китүчеләрне кабул итү, сөйләшеп утыру, озатып җибәрү белән мәшгуль булган.

Менә аларны хөкүмәт җитәкчеләрен йөртә торган өсте ачык чит ил автомобиленә утырталар да Ялтага алып китәләр. Тауга күтәрелә-төшә бормалы юллардан бара торгач, каршыда диңгез ачылып китә. Безнең сәяхәтчеләрнең күңелләре тулып ташкан. Яр кырыеннан барганда Фатих машинаны беразга туктатырга куша. Каспийны күргән булса да, зәңгәр, күгелҗем һәм яшькелт төсләр белән җемелдәп, җәйрәп яткан Кара диңгезне ул беренче тапкыр күрә. Зәкәрияне инде әйтәсе дә юк, малай кеше бит, машина туктар-туктамас сикереп төшә дә диңгез буена чабып бара һәм су учлап алып теленә тидереп карый.

Бер заман Ялтага барып керәләр, яр буйлап сузылган шәһәрне бер очыннан икенче очына кадәр үтеп чыгалар да тауга күтәреләләр.

Автомобиль, кәүсәсенә ике кеше колачы җитмәслек платан агачлары, сөңге булып күккә төбәлгән кипарислар, көньяк нараты, персик, инҗир һәм лавр агачлары чолганышында калган ике катлы, матур архитектуралы бинаның подъездына килеп туктый. «Гастрия» дип йөртелә торган шушы санаторийның икенче катындагы зур, якты палатага урнаштыралар. Номеры да мәгълүм: алтынчы.

Казанда кагылып-сугылып яшәгән Фатих Әмирханны Кырымда күтәреп алулары, бөек шәхеснең генә өлешенә чыга торган кадер-хөрмәт күрсәтүләре турында уйлыйм да борынгы әйтемне кабатларга мәҗбүр булам: «Үз ватанында пәйгамбәр пәйгамбәр саналмый».

Фатихның вакыты ничек узган соң? Беренче эше, билгеле инде, дәвалану, сәламәтлек җыю. Дөрес, медицина әле хәзерге югарылыкка ирешмәгәнгә күрә, дәва дигәне күбрәк татлы азык, фрукт, диңгез һәм тау һавасына кайтып калган. Моңа өстәп, Фатихка нindидер порошок һәм таблеткалар да биргәннәр.

Күп вакыты беренче катның зур һәм якты верандасында узган. Газета-журнал һәм китаплар укыган, ашауэчүе дә шунда була икән. Бихисап кошлар чыркылдавын тыңлап, еракта җемелдәгән диңгезгә төбәлеп, уйга чумып утырган чаклары да еш булган. Коляскасында аллеялар буйлап тирә-якны күп мәртәбә сәер итеп йөргән һәм паркка тоташып киткән урманга да барып чыккан.

Симферополь һәм Ялтаның үзеннән хәл белергә килүчеләр күп булган. Зәкәрия аларның кемлеген белмәсә дә, тәҗрибәсе аз булуга карамастан, андый-мондый гына кешеләр түгел, бәлки җаваплы хезмәткәрләр икәнлекләрен чамалап калган. Ялтадан килеп йөргән кешеләрнең өчесен без тәгаен беләбез: профессор М. Корбангалиев, фольклор белгече Хуҗа Бадигый һәм Ибраһим Аитов. Чөнки алар анда ял иткәннәр һәм бер килүләрендә пляжда төшкән фоторәсемнәрен Фатихка бүләк иткәннәр. Карточканың артында түбәндәге сүзләр укыла: «Кадерле әдибебез Фатих Зариф улы Әмирханга. Ялта. Мөхетдин Корбангалиев, Хуҗа Бадигъ, Ибраһим Аитов. 22/IX—25».

Фатих санаторийда язганмы? Энесе белешмәсенә караганда, укуга бирелеп китеп, ул язу-сызу белән бик үк мәшгуль булмаган. Һәрхәлдә, вакытлы матбугаттан да, архивтан да Ялтада язылган дип кистереп әйтерлек материал тапмыйбыз. Язса да, күбрәк хат язган. Сакланып калган ачык хатларының берсе игътибарны җәлеп итә. «Хәдичә, Сезгә Кара диңгезнең елы ярларыннан, сәрви агачлары күләгәләреннән, пешеп тора торган персиклар яныннан кызу сәламнәр!

Фатих Әмирхан.<br>Ялта, «Гастрия» санаторийсы.<br>11/X—25».

Бу открытканың үзенә күрә тарихы бар.

Авыл хуҗалыгы институтының I — курс студенткасы Хәдичә Хуҗаханова бер мәҗлестә апасы аркылы Ф. Әмирхан белән танышкан була. Элекке гадәт буенча бәйрәм визитлары ясап йөргәндә Фатих Хуҗахановларга да сугыла. Хәдичә имтихан бирергә киткән икән. Ләкин, бердән имтиханга, икенчедән бәйрәмгә әзерләнү (аш-су, өй җыештыру эшләре аңа йөкләнгән) сәбәпле йокысы туймый барганга, тапшыра алмаган. Кайгыга батып өйгә кайтса, Фатих Әмирханның бәйрәм белән котлап киткәнен әйтәләр.

Тагын кәефе кырыла. Күңел тынычлыгы эзләп, институтка бара да бер курсташ егетенә хәлне сөйләп бирә. Тегесе җавап визиты ясарга киңәш итә. Бергәләп китәләр. Сүз арасында Хәдичә әдипкә имтихандагы уңышсызлыгы турында сөйләп ала.

— Изге гает көнне барган өчен ходай хәза биргән сиңа,— ди Фатих көлеп.

Икенче тапкырында ул Әмирхан янына апасының алты яшьлек кызын ияртеп барган. Аннары, кыюланып китеп,

һәм Разия белән дуслашып алып, үзе генә дә визитлар ясый башлаган. Курсташлары, Хәдичәгә күзе төшеп йөргән Фатих Солтанов дигән студентның үзенә ишеттереп, «Безнең Фатих синең Фатихны дуэльгә чакырырга җыена» диләр икән.

Кырыкка җитеп килә торган әдип белән 19 яшьлек кыз арасында шулай итеп үзенчәлекле дуслык урнашкан.

Кемнең кемлеген тиз аңлый, кешенең эчке дөньясына керә белүе, уен-көлкегә осталыгы сәбәпле, физик кимчелегенә карамастан оптимист булып күренә торган Ф. Әмирхан авырулар саны 50—60 тан артмаган бөтен санаторийның игътибарын җәлеп иткән кебек, медицина персоналының да мәхәббәтен яулап алган. 1926 елның 28 январенда Кырымнан килеп төшкән түбәндәге ачык хат моны раслый торган документ булып хезмәт итә ала.

«Хөрмәтле Фатих Эмир-Хан!

Миңа күрсәткән игътибарыгыз өчен Сезгә рәхмәтемне белдерәм. Сезнең татар санаториенда булып китүегез минем хәтеремдә сакланачак. Энегезгә сәлам. Сезне ихтирам итүче шәфкать туташы А. Урениус».

Шунысы да мәгълүм булсын: «Гастрия» санаториеннан шәһәргә турылап төштеңме, А. П. Чеховның йорт-музеена барып төртеләсең. Ф. Әмирханның күп кенә ягы белән Чеховка охшаганлыгы, аңардан байтак сабак алганлыгы турында әйтелгән иде. Инде килеп, Антон Павловичның гомере төгәлләнгән йорттан ерак та түгел безнең Фатих та гомеренең соңгы айларын үткәрә. Язмыш шуклыгы дими ни дисең моны? Кем белә, бәлки йортының эченә дә үтеп кергәндер... Үзләренең 6 нчы палатада торуларын Чеховның «6 номерлы палата» хикәясенә бәйләп, еш кына шаяртып алуы да ихтимал.

Октябрь ахырында, көннәр суытып, салкын җилләр исә башлагач, Фатих белән Зәкәрия Ялта белән саубуллашып, кайтыр юлга чыгалар.

Казанда күрешергә, хәл белергә дип килүчеләрдән Фатихның ишеге ябылып тормый. Әдипнең кайтканын ишетүгә Хәдичә дә аның янына йөгергән. Шактый вакыт сөйләшеп утырганнар. Әдипнең Ялта турында матурлап, бизәкләп сөйләве тәэсирендәдерме, киләсе елга тагын чакырдылар диюенә каршы беркатлы кыз кинәт әйтеп ташлаган:

— Миңа да сезнең белән Кырымга барырга мөмкинме?

«Гастрия» санаториендагы дәва һәм ял файдасыз калмаган әлбәттә. Үпкә туберкулезы, бөтенләй бетмәсә дә, шактый кимегән. Ләкин озакламый туберкулезның умыртка сөягенә күчкәнлеге билгеле була. Фатихка утырып тору

да газапка әйләнә. 1925 елның соңгы айлары шулай итеп күбрәк үз бүлмәсендә, газета-журнал яисә китап тоткан килеш ятагында уза башлый. Өйдә ятып ялыкса, дару ярдәмендә арка авыртуын баса төшеп, берәр төшкә барып кайта. Үзен кызыксындырган утырышларга, концерт-спектакльләргә элеккеге кебек йөри алмаса да, кайберләрендә булырга тырыша.

1926 елның 16 январенда Фатих, төрле порошоклар йотып, үзен 4—5 сәгать утырып торырлык хәлгә китергән дә «Сания» операсын тыңларга киткән. Нияте, билгеле, музыка тыңлап ләззәт алу гына түгел. Кешеләр күрәсе, аралашасы килә. Хәер, әйдәгез, үзен тыңлыйк.

«Иксез-чиксез халык йөри: киенешкәннәр, бизәнешкәннәр; яшьләре, күренеп тора, нәрсәдәндер бик кәефләнгәннәр дә шикелле, татарча чухырдашалар, ишетелеп-ишетелеп киткән сүз кисәкләренә караганда, әдәбият турысында да күп сөйләшәләр. Югары мәктәп шәкертләре үзләрен аерым сәрбәст * тоталар. Мин болар өстенә хосусый бер дикъкать белән карыйм. Алар да миңа карыйлар, йөздән сиксәне сәламле бер караш белән карый. Һич таныш икәнлекләреннән хәбәрем булмаган бик күпләр күз вә баш белән сәламләп уза. Шулардан берничә таифә ** кешеләр аркылы минем белән танышу тәшәббесенә *** керәләр.

— Ярый танышыйк,— дим, килеп күрешүләре белән.— Сез нишләп җүләрләнеп йөрисез? Әллә кайчан инде модадан чыккан, идеологиясе белән кяфер булган бер мөхәррир белән, кәсафәтеннән курыкмыйча, танышып ятасыз. Башыгызга бәласез үтмәс.

Студентлар, уйларын дөрес калыпка куеп әйтер өчен булырга кирәк, берәр минут җавапсыз калалар да аннан соң:

— Без ни күрсәк тә, Сезнең белән күрергә телибез,— диләр.

Кызу сөйләшү башлана. Шул кыйсем яшьләр белән сөйләшү, үз-үземнән яшерергә хаҗәт юк, миңа һәрвакыт зур бер оптимизм бирә».

Февраль уртасында Фатих нык кына суык тидерә, температурасы күтәрелә. Туганнары врач чакырырга теләсәләр дә, мондый хәл кабатланып торганлыктан, «Инфлюэнца кебек чибәркәйләрне генә мин күп күргән» дип, кул астындагы порошок-пилюлялар ярдәмендә генә үткәреп җибәрмәкче була.

---

* Сәрбәст — бәйсез, ихтыярлы.
** Таифә — төркем.
*** Тәшәббес — башлау, инициатива.

25 февральдә Фатихның авыруы көчәеп, температурасы 39 градуска күтәрелгәч, врач чакыралар. Гриппның күптән инде үпкә шешүенә әверелгәнлеге билгеле була. 26 сында, беренче ярдәмнең күп файда китермәгәнлеген һәм авыруның хәле начарая барганны күреп, якын дуслары Татарстан сәламәтлек саклау халык комиссары Фатих Мөхәммәдъяров янына йөгерәләр. Әдипнең гомере өчен көрәш башлана. Шул ук көнне консилиум ясала. 27 сендә Лурье, Зимницкий, Ә. Терегулов кебек профессорлар, Якимов, Шварцман, Ворошилов кебек атаклы врачлар катнашында тагын бер консилиум чакырыла. Ф. Әмирханның хәле авыр, ләкин өметсез үк түгел дигән нәтиҗәгә киләләр, медицинаның соңгы казанышларына нигезләнеп һәм яхшы дарулар кулланып дәвалый башлыйлар. Яшь врачлар, шәфкать туташлары һәм авыруның дуслары көне-төне чиратлашып дежур торалар.

Көн артыннан көн уза, Фатихның хәле яхшыруга таба китеп, үпкә шешенең бетә башлавы билгеле була. Авыруның тереләчәгенә тәмам ышанып җиткәч, дуслары Сәламәтлек саклау халык комиссариаты һәм социаль тәэминат бүлегендә Әмирханны кабат Кырымга җибәрү турында сүз алып бара башлыйлар.

Ләкин 4 мартка каршы төндә авыруның хәле кинәт начарлана. Үпкәләре уңайланып килсә дә, тагын бер куркыныч чир — эчәк һәм карын шешү башланган икән. Тагын чабышу китә, ярдәм сорау, консилиум, тагын дежур тору. Шунысы игътибарга лаек: дежур торучылар арасында Гадел Кутуй да булган.

Фатих Әмирханны алып калу өчен барган дүрт көнлек көрәш көткән нәтиҗәне бирми. Нишлисең, әдипнең тәмам таушалган организмына ябышкан тагын бер чир алдында Казанның атаклы белгечләре дә, медицина үзе дә көчсез булып кала. 9 март көнне иртән, ун тулып ун минутта әдипнең гомере өзелә...

...Күренекле кешеләрне соңгы юлга озату тәкәллефләре якынча бер рәвешле булганга күрә, Ф. Әмирханны җирләү вакыйгасын җентекләп язу хаҗәт булмас. Шулай да берничә сүз әйтми уза алмыйм.

12 март көнне төшке сәгать бердә, әдипнең гәүдәсен чыгарып, Театр мәйданына китерәләр. Ике меңләп кеше җыелган була. Җирләү комиссиясенең рәисе Фәтхи Бурнаш, мәрхүмнең татар мәдәниятендә тоткан урынын гаҗәеп дөрес билгеләгән кереш сүзеннән соң, матәм митингысын ачык дип игълан итә. Сүз алып сөйләүчеләр арасында без Мөхетдин Корбангалиев һәм Кәрим Тинчуринны, ха-

лык комиссарлары Фатих Мөхәммәдъяров һәм Нәсих Мөхетдиновны күрәбез. Ф. Бурнаш «Хуш, безнең бөек язучыбыз Фатих Әмирхан!» дигән сүзләр белән митингны япкач, процессия Юнусов мәйданына таба юл тота.

Казанның барлык газеталары да бу көн Фатих Әмирханга багышланган материаллар белән тулып чыгалар. «Кызыл Татарстан» газетасы, «Олы, атаклы язучыбыз Фатих Әмирхан үлде» дигән баш астында ике полоса биреп, зур-зур берничә мәкаләдән кала, рәсми оешмаларның һәм аерым кешеләрнең (арада М. Гафури, Н. Исәнбәт һәм М. Мәрҗәни дә бар) Мәскәү, Ташкент, Уфа, Омск, Әстерхан шәһәрләреннән килгән кайгы белдерүләрен баскан.

Безнең Казан, күренә ки, Фатих Әмирхан вафат булгач, сискәнеп китеп, нинди зур кешене, нинди олы шәхесне югалтканын абайлап алды. Митингта булсын, мәкалә һәм кайгы телеграммаларында булсын, тагын 30—40 елдан соң гына ишетелә башлаячак сүзләр әйтелде: «олуг мөхәррир», «бөек язучы», «классик әдип».

Шул инде, Тукай әйткәнчә: «Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!»

## ЭПИЛОГ ДИСӘҢ ДӘ ЯРЫЙ

Фатих Әмирханның 1920 елда язылган «Чәчәкләр китерегез миңа!» исемле әсәре үз урынында ничектер сыймаган, хикәяләүгә кушылып китә алмаган иде. Җанры ягыннан чәчмә шигырьгә, ягъни нәсергә карый торган бу язманың мәгънәсе белгечләр кулы тимәү сәбәпле һаман ачылмаган килеш тора. Нинди уңай белән язылган, нәрсә турында ул, автор ни әйтергә тели? «Гражданнар сугышын галәбәле * тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә багышлана» дигән эпиграф та ачыклык кертми: шигырьнең эчтәлеге белән Кызыл Армия һәм демобилизацияләнүче солдатлар арасында бернинди бәйләнеш юк. Автор шәхси фаҗигасенә кадәрге «яшьлек таңын», беренче мәхәббәттән исереп йөргән чакларын сагына. Гомеренең шул алтын дәверен ул табигатьтәге иң матур чәчәкләрнең нәфис төсләре һәм хуш исләре гармониясенә тиңләп, кабатланмас яшьлеген хыялда гына булса да кайтару өчен күп итеп һәм төрле чәчәкләр китерүләрен үтенә. «Миңа энҗе чәчәкләр китерегез! Аларның газаплы исертүчән салкынчарак исләре минем тирә-ягымны аңкытсын, бәлки, шул газаплы ләтыйф ** истә мин бәхет мөмкин булып та, бәхетсез уздырган яшьлегемнең назыйрәсен *** табармын.

Әдипнең үзе турында, үз «мин»е турында сагышлы-элегик рухта язылган булса да, әсәрнең ахырына яңа төсмер, яңа рух, яңа мәгънә килеп керә: «Китерегез миңа гөл-чәчәкләр? Мин аларны күз алдымда җәелгән киң кырларга сибәрмен, шул кырларда мин аларны назлап, иркәләп үстерермен... Минем гөл-чәчәк кырымнан таралган хуш ис бөтен арыган, талганнарга шагыйрәнә ял бирер!

— А, ишетсәгез лә, китерегез, китерегез миңа чәчәкләр!»

Бу юллардан автор киләчәкне чәчәкле, кешеләрне бәхетле итеп күрергә теләгән дигән мәгънә эзләсәк, шаять бик үк ялгышмабыз ****.

---

* Галәбәле — җиңеп, җиңү белән.

** Ләтыйф — йомшак, нәфис.

*** Назыйрәсен — охшашын (Ф. Әмирхан искәрмәсе).

**** Шигырьгә бирелгән эпиграф әсәрнең башлап «Кызыл дәфтәр» исемле бер генә сан чыгып калган Кызыл Армия журналында дөнья күрүе белән аңлатыла.

Хәер, бу очракта безне нәсернең басылу тарихы һәм идея эчтәлегеннән бигрәк, бүтән нәрсә кызыксындыра һәм билгеле бер уй-тойгылар кузгата. Төрле вариантларда рефрен булып кабатланып килә торган «Чәчәкләр китерегез миңа!» дигән сүз тезмәсен эченә алган нәсер алтмыш биш ел дәвамында, бик еш булмаса да, кабат басыла торды. Әйтерсең лә әдип киләчәк буыннардан үзен хәер белән искә алуларын, иҗатына гадел үлчәү кулланып бәһа куюларын үтенә.

Уйлап карасаң, үтенергә генә түгел, бәлки таләп итәргә, сөрән салырга хаклы ул. Үз аягы белән бер бүлмәдән икенчесенә дә чыга алмаган шушы кеше 18—19 ел эчендә, барысын бергә җыйсаң, зур-зур биш-алты томга җитәрлек, шактый өлеше бүген дә шедевр итеп саналырлык әсәрләр язып калдырды. Самодержавие гыйфрите басып яткан иң кара көннәрдә дә көрәшче булып кала алган бу шәхес арыган-талганнарга көч-куәт бирде, төшенкелеккә таба авышучыларның күңелендә өмет уты кабызды, икеләнүчеләргә иман яңартырга булышты. Ничек бу гомерне батырлык үрнәге итеп карамаска мөмкин?!

Әнә шул шәхесне без, үзе дөньядан киткәннән соң, утыз ел буе күрмәмешкә, белмәмешкә салыштык, исемен телгә алганда да күбрәк тискәре яктан телгә алдык. Әйе, утыз ел буе...

Бу утыз елдан соң тагын бер утыз ел узып китте. Соң ни күрәбез? Нәрсәгә ирештек? Уңышлар юк түгел билгеле. Әдипкә сугылган кара мөһерне юып төшереп, исемен мактап телгә ала башладык, түгәрәк датасын тегеләйме, болаймы билгеләп үтәргә күнектек, берничә томнан тора торган җыелмасын чыгардык, иҗатын урта һәм югары мәктәп программасына керттек, бер-ике диссертация язып якладык.

Азмы бу, күпме? Утыз ел өчен, билгеле, аз, хәтта бик аз.

Һаман әле Фатих Әмирханны белүебез җитәрлек түгел. Бу зур фигураның, иңен-буен үлчәп, әдәбиятта тоткан урынын билгеләп бетергәнебез юк. Сәбәбе — ваемсызлык һәм тарихыбызга битараф мөнәсәбәт булса кирәк. Бүгенге бурычларны хәл итү өчен үткәндәге казанышлардан файдалана белү дә җитенкерәми.

Хәер, мәрхүмнең үзендә дә «гаеп» юк түгел: вакытында туа, вакытында үлә белмәде... «6» цифры белән бетә торган ел якынлаштымы, җәмәгатьчелекнең игътибары әдәбиятыбызның шундый ук ике зур фигурасына юнәлә дә,

Әмирханга көч тә, вакыт та җитми һәм ул һаман күләгәдә кала килә.

Һәр елны без 26 апрельдә шигырь бәйрәме үткәреп, Тукай каберен чәчәккә күмәбез. Ник шунда берочтан Фатих Әмирхан каберен дә бизәп китмәскә? Бу ике бөек шәхес аерылгысыз ич: Тукай диденңме Әмирхан күңелгә килә, Әмирхан диденңме, Тукай искә төшә.

...Чәчәкләр китерегез аңа, кешеләр! Үзенә һәм иҗатына булган мәхәббәтнең билгесе булсын ул чәчәкләр. Халкыбызның күңеле киң, йөрәге олы!

...Китерегез, китерегез аңа чәчәкләр! Фатих Әмирхан шунда лаеклы урынын алсын!

*1980—1985*
*Казан — Пицунда — Васильево — Казан.*

ЭЧТӘЛЕГЕ

*1 бүлек*
«НӘНИ МУЛЛА»
3

*2 бүлек*
МАЯКЛАР АЛЫШЫНГАНДА
20

*3 бүлек*
ҖӘМӘГАТЬ ХАДИМЕ БУЛЫРГА ТЕЛӘП
51

*4 бүлек*
ЯНАР ТАУ ИТӘГЕНДӘ
82

*5 бүлек*
«КОЯШ»ЛЫ ҺӘМ БОЛЫТЛЫ КӨННӘР
140

*6 бүлек*
ЯҢА ДАВЫЛЛАР АЛДЫННАН
179

*7 бүлек*
УРТАЛЫКТАН — БУ ЯККА
215

*8 бүлек*
«ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРЕГЕЗ МИҢА»
242

ЭПИЛОГ ДИСӘҢ ДӘ ЯРЫЙ
276

*Олы һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына*


*Нуруллин Ибрагим Зиннятович*

**ФАТИХ АМИРХАН**

(на татарском языке)

Рецензенты *Р. Әмирханов*
Редакторы *Л. Хәмидуллин*
Художнигы *И. Воробьев*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Л. Тилк*
Корректорлары *Р. Хәмидуллина, М. Мирсалихова*

ИБ № 4865

Җыярга тапшырылды 21.10.87. Басарга кул куелды 27.01.88. ПФ 09023. Форматы 84×108¹/₃₂. Китап-журнал кәгазе. Литературная гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 14,7+рәс. 0,2. Шартлы буяу-оттиск 15,2. Нәшер-хисап табагы 16,1+рәс. 0,2. Тиражы 6500 экз. Заказ Р-553. Бәясе 80 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.